# Казан утлары

3
МАРТ
1969

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК СИГЕЗЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА

**3**

МАРТ
1969


## Бу санда:

ЛЕНИН — БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ


Р. САФИН. Тереләрдән тереррәк. Шигырь . . . . 3
Ә. БАЯНОВ. Ил гизүче карт турында баллада . . 5
Ленин хакыйкате. Рус халык иҗаты . . . . . . . 9
Мич чыгаручы. Рус халык иҗаты . . . . . . . . 11
Тоймә. Рус халык иҗаты . . . . . . . . . . . 12


ПОЭМА


С. ХӘКИМ. Дуга . . . . . . . . . . . . . . 13


СОВЕТ БАШКОРТСТАНЫНЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА


Х. ГЫЙЛАҖЕВ. Әдәбиятыбыз турында берничә сүз . . . . . . . . . . . . . . 23
С. КУДАШ. Яңа өй. Шигырь . . . . . . . . . 28
М. КӘРИМ. Ярлар кала. Шигырь . . . . . . . 29
Н. НӘҖМИ. Үземнеке... Шигырь . . . . . . . 30
Г. ӘМИРИ. Карт имән. Шигырь . . . . . . . 30
З. БИИШЕВА. Кешечә. Шигырь . . . . . . . 31
Х. КӘРИМ. Ташта эзләр калган... Шигырь . . . 32
Г. РАМАЗАНОВ. Революция дәвам итә. Шигырь . 32
Ш. БИККОЛ. Безнең як. Шигырь . . . . . . 33
М. ГАЛИ. Мин тауларга китсәм. Шигырь . . . . 34
Й. ГӘРӘЙ. Ленин янында. Шигырь . . . . . . 34
К. КИНҖӘБУЛАТОВА. Чәй. Шигырь . . . . . . 35
Р. ГАРИПОВ. Өйгә кайтканда. Шигырь . . . . 35
Я. КОЛМЫЙ. Кирәк миңа тынычлык. Шигырь . . 36
А. ИГЕБАЕВ. Авылдашым. Шигырь . . . . . . 37
Р. БИКБАЕВ. Заман! Бирче пульсыңны. Шигырь . 38
Ә. ӘХМӘТХУҖИН. Һыбай чыксам. Шигырь . . . 38
Р. НАЗАРОВ. Мин батыр да түгел. Шигырь . . 39
С. АГИШ. Айлы кич. Хикәя . . . . . . . . . 44
В. ИСХАКОВ. Әтием утырткан өянке. Хикәя . . . 44
Н. МУСИН. Нөгеш буйкайлары бөдрә чаука. Хикәя 47
Ф. ИСӘНГУЛОВ. Гафләт. Хикәя . . . . . . . 58
З. ХИСМӘТУЛЛИН. Киңәш. Хикәя . . . . . . . 59


ШИГЫРЬЛӘР


Р. ГАТАУЛЛИН. Өстәлемдә торна тора. Тел ачкычлары. Иртән язылган кечкенә шигырь. Җил, исмә. Якын килмә. Шигырьләр . . . . . . . 60
Р. ВӘЛИЕВ. Вәгъдә. Шигырь . . . . . . . . . 63
Э. МӨЭМИНОВА. Россия тудырды. Я җыр итеп аны ишетәм. Иң олы мәхәббәт. Шигырьләр . . 64
Г. ЗӘЙНАШЕВА. Яшәгән бу җирдә бер ана. Миңнәхмәт батыр. Шигырьләр . . . . . . . . 66



КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ПЬЕСА

Ю. ӘМИНОВ. Әти балак. Комедия. . . . . . 67

ӘМИРХАН ЕНИКИГӘ 60 ЯШЬ

Г. ХАЛИТ. Таләпчән һәм эзләнүчән талант. Иҗат портреты. . . . . . . . . . . . . . 112

Ә. ДАВЫДОВНЫҢ ТУУЫНА 50 ЕЛ

Р. МИНГАЛИМОВ. Бик бәхетле шагыйрь. . . . . 129

ДУСЛАР ҖЫРЫ

Ф. ЯННАКОПУЛУ. Мин — Эллада кызы. Минем куллар. Мәңгелек сәнгать. Әнкәемә хат язасым килә. Шигырьләр. . . . . . . . . . . . 133
Р. ХАЛИД. Яратам сине, Нева. Өмет. Кояш нуры... Шигырьләр. . . . . . . . . . . . . 136

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

К. ТИМБИКОВА. Алтын сәгать. Очерк. . . . . . 138

ХАЛЫК ИҖАТЫ

ФАТИХ УРМАНЧЕЕВ. Тарихи җырлар . . . . . 144

БЕЗНЕҢ ИНТЕРВЬЮ

Күпне бирсәң, күпне аласың . . . . . . . . 158

ТӨРЛЕСЕННӘН

Г. БӘШИРОВ. «Гөлҗамал» кайсы як кызы!. . . . 162
Ш. ВЯДРО. Уңган кыз. . . . . . . . . . . . 168
И. ВӘЛИТОВА. Тукай шигырьләренең теле хакында берничә сүз. . . . . . . . . . . . . 169

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

С. ЛАТЫЙПОВА. Татар студентлары һәм революцион хәрәкәт. . . . . . . . . . . . . . 174

КИТАП КҮЗӘТҮ

К. МОСТАФИН. Сандугач җыры дәвамлы булсын. 178

СЕЗНЕҢ КИТАП КИШТӘГЕЗГӘ

Б. СӨЛӘЙМАНОВ. Кешеләр һәм чәчәкләр. . . . 183

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

М. ФӘЙЗУЛЛИНА. Мин кунаклар яратам. Юк нәниләр әтәче. Мин Артектан кайттым. Керпе кабак. Шигырьләр. . . . . . . . . . . . . 185
Укучылар сүзе. . . . . . . . . . . . . . . 187
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. . . . . . . 190

**Редакциягә килгән кульъязмалар кире кайтарылмый**

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Баш редактор: **Зәки Нури.**
Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рафикъ Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Производствога бирелде 15/I-1969 ел. Басарга кул куелды 27/II-1969 ел. ПФ 09003. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 84446 экз. Заказ В-21. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1969 ел.




# *ЛЕНИН — БӨЕК ЯКТАШЫБЫЗ*

*Төрле иллэрдэн, төрле теллэрдэн*

**Рафаэль Сафин**

Башкорт шагыйре

## Терелэрдэн тererэк...

*Ленин дисәк —*
*без аңлыйбыз Партияне,*
*ә Партия дисәк —*
*Ленинны.*

В. МАЯКОВСКИЙ.

Киң мәйданнар буйлап,
бәйрәмнәрдә,
безнең сафлар үткән чагында,
мин уйлыймын безне киң мәйданга
алып чыккан Кеше хакында.

Һәм еш кына
шатлык, җыр аралаш
ишетәм:
«Тормыш нинди үзгәрде!
Әгәр безнең белән шул бәйрәмдә
Ленин булса...» дигән сүзләрне.

Тотынырдан алда бик зур эшкә,
үзебезнең генә белемгә
ышанмасак әгәр,
киңәш белән
киләбез соң кемгә? —
Ленинга.

Бәхәсле күп мәсьәләләр була,
күп сораулар безне йөдәтә.
Зур көрәштә кайчак хаталансак,
хатабызны күрми җәфалансак,
безне кем соң? —
Ленин төзәтә.

һәрбер эштә,
авыр эштә
безгә
кул сузучы кем? —
Ул лабаса!

Юк, әйтмик без: «Ленин булсачы...» дип,
нишләр идек, Ленин булмаса?

Дөнья нинди кысык булыр иде!
Караңгылык безне буар иде,
богауланыр иде кул-уйлар.
Ил күзеннән канлы яшьләр генә
агызыр иде явыз колыйлар[1].

Ямь таратып илгә, ничек бүген
уйнар идең, халкым, кураең?
Телле булып туган чичәннәрең
телсез калыр иде, мөгаен.

Кул-уйлардан коллык богауларын
өзеп аткан кем, ул лабаса!
Юк, әйтмик без: «Ленин булсачы...» дип,
нишләр идек, Ленин булмаса?

«Заманалар авыр, михнәтләр күп...»
дип кайчандыр халкым җырлаган...
Артта калды инде ул михнәтләр,
җырлар да бит хәзер өр-яңа.

Заман әле, заман һай катлаулы...
Безгә янап торган туплар бар.
Караны — ак, акны — кара ул дип,
Ленинизм белән сату итеп,
дөнья бутап яткан «дуслар» бар.

Дусның күзен ачкан,
ә дошманны
калтыраткан кем? —
Ул лабаса!
Юк, әйтмик без: «Ленин булсачы...» дип,
нишләр идек, Ленин булмаса?

Без бит һәр чак Ленин, Ленин рухын
раслап килдек бөек иҗатта.
Димәк, Ленин һәр чак безнең белән,
безнең белән килә бер сафта.

Димәк, Ленин —
мәңге тынгы белмәс,
үлмәс һәм җиңелмәс бер йөрәк,
еллар үткән саен кадерлерәк,
еллар үткән саен тирәнрәк!

---

[1] Башкорт түрәләре.

## Әхсән Баянов

# Ил гизүче карт турында баллада

1

Гасыр зиһенен йөртә ул башында,
Гасыр йөген — аркасында.
Тау күтәргән гүя,
Акрын атлый
Һәм бөкрәйгән,
Ахры, шуңа.

Сәфәрче карт — авыл юлларында.
Чак-чак атлап күп җир китә.
Өйдән-өйгә кереп,
Ул йон тетә,
Ул йон тетә,
Заман үтә.

Кыр тузаны кара төскә кертә,
Киезләтә сарык йонын.
Шул киездән ап-ак
Болыт яса,
Болыт яса:
— Тыр — рым, тыр — рым...

Керле йонга сибә пакь он — җирнең
Җан аклыгын, горурлыгын.
Сибә шаянлыгын,
Чаялыгын,
Шаян җырын:
— Тыр — рым, тыр — рым...

— Рәхиләкәй дигән ай киленгә
Йон тетәм шул, мин йон тетәм.
Ашатмаса әтәч боты,
Йонын уч-уч
Калҗалы итәм,
Калҗалы итәм.

2

...Кичләрен ул, җыеп бала-чага,
Сөйли әкият, кучә чынга:
Ил хакында сөйли,
Кыр хакында —
Күчә шунда
Юлбашчыга...

Юк, каян да кушмаганнар аңа,
Тик ул шундый агитатор:
Син, оратор иптәш,
Еракта тор —
Аны чакыр
Һәм тыңлап тор.

Китапларың, газет-журналларың —
Гомере аның алыштыра барын.
Тыңлый җир-суларны,
Укый кырны —
Сөйли шуннан
Укыганын:
«Барабызмы, юкмы дөрес юлдан,
Белим дисәң, сора кырдан.
Тынычта да билчән
Корса буран,
Юлың кыек,
Хилаф, туган.

Кырга калалардан ипи ташып
Җан сакласак, булыр ай яман эш!
Мәйдандагы рәсем,
Кулын изәп,
Әйтер безгә:
— Ялгыш, ялгыш...

Барсак әгәр дөрес юлдан,— кырлар
Иген шавы белән тулган.
Җир елмаеп шулай
Әйтсә рәхмәт,
Барабыз, димәк,
Дөрес юлдан.

Бу сүзләрне җиргә кем калдырган?
Офыккача кемнәр сузган
Иң төз бураэнаны?
Беренче кат
Ленин үе
Ярып узган.

Ленин исән, дибез, Ленин яши...
Ничек яши соң ул, туган? —
Сөйли хәзер безгә
Ленин сүзен
Җир һәм Вөҗдан,
Җир һәм Вөҗдан».

3

Ап-ак сакал белән бәйле-бәйле,
Әллә болыт, төшеп күктән,
Әйләнәме йонга?
Әллә йонмы?
Болыт булып
Күккә күчкән?

Шул болыттан оеша бияләйләр —
Шакшы нәрсә тотып кара!
Ап-ак пима, оек —
Кыек юлдан
Атла кыеп,
Атлап кара!

Кара таплар калыр ап-ак карда...
Юл-кыр әйтер: йөзең кара!
Кая барсаң, шунда
Чал сакаллы
Сәфәрче карт
Озата бара:

«Ленин сүзен сөйли бу басулар,
Ленин сүзен сөйли Вөҗдан...
Ленин — безнең Вөҗдан.
Барсаң, әйтә:
Барасыз, ди,
Дөрес юлдан».

Тургай җырын күчереп язмышларга,
Кемнәр яшел диңгез ясап куйган?
Вөҗдан, Җир аларга
Әйтеп торган:
— Сез барасыз
Дөрес юлдан.

Юлга чыгып, кемнәр буш кырларда
Яшь калалар корган?
Хәерчелек дигән
Ач өрәкне
Мәңгелеккә
Илдән куган?

«Сугыш» дигән гарасатлы җенне
Үз җебенә кемнәр асып куйган? —
Бу ирләрне Вөҗдан
Озата барган:
— Туганнар, сез —
Дөрес юлдан!

4

Сәфәрче карт уза юллар, еллар,
Акрын атлап, күп җир китә.
Өйдән-өйгә кереп
Йон тетми тик,
Комбинатка
Тәяп илтә...

Ап-ак сакал белән бәйле-бәйле,
Уйный кышын җем-җем карлар.
Сәфәрче карт китерә
Яңа еллар —
Йолдыз яуган
Кичләр, таңнар...

«Барабызмы, юкмы дөрес юлдан,—
Җавап бирә чыр-чу бала:—
Ул елмайса, көлсә,
Безнең белән
Сөенә бергә
Дала, кала».

5

Космодромда тынлык. Кунаклар юк,
Фанфара юк, тантана бар.
Тыңлый сәфәрче карт:
— Союз, старт! —
Күккә дә ак
Юл салалар!

Сәфәрче карт йөри ил буйлата:
Очсын тузан, кирәк, купсын буран.
Капчыгына ил-көн
Сүзен җыйган,
Хак сүз җыйган:
— Дөрес юлдан!

Таныш рәсем карый мәйданнардан:
Карый аннан безнең Вөҗдан.
Ул елларга шуннан
Кулын сузган:
— Дөрес юлдан!
— Дөрес юлдан!..

1968

# ЛЕНИН ХАКЫЙКАТЕ

*Русчадан*



Бер авылда ага белән эне яшәгән. Җир сөргәннәр, тир түккәннәр, бил бөккәннәр. Ләкин һич тә байый алмаганнар. Эшләп тапкан бөтен икмәкләрен, тәрбияләп үстергән барлык терлекләрен пан үзенә ала барган, ә теге агай-эненең аркасында камчы эзләре генә калган.

Бик күп еллар шулай интегеп яшәгән алар. Бер алар гына түгел, башка мужиклар да шундый авыр хәлдә булган.

Ниһаять, туйган болар бушка эшләүдән, гарык булганнар. Уйлашканнар-киңәшкәннәр дә ил буйлап хакыйкать эзләргә чыгып киткәннәр. Ай барганнар, ел барганнар. Бара торгач, бер зур авылны күргәннәр. Авыл уртасында пан йорты, ә аның янында таш чиркәү тора, ди.

— Әйдә,— дигән ага белән эне,— шунда барып сорыйк әле, кайдан табып була икән ул гаделлекне?

Авылга килеп кергәч, бик шәп тарантаска утырып килүче пан очрый боларга.

— Кайсы авыл мужиклары сез, кая барасыз, нәрсә эзлисез? — дип сорый пан.

— Фәкыйрьлектә яшәп тәмам интегеп беттек, инде алай яшәр чамабыз калмады да хакыйкать эзләргә чыктык менә. Әйт әле, пан, кайдан табып була ул нәрсәне? — диләр тегеләр.

— Бик әйбәт! — ди пан.— Әгәр теләсәгез, мин сезгә хакыйкатьне үзем күрсәтермен, әмма аның өчен башта сез миндә бер ел эшләрсез.

Риза булып, теге агай-эне эшкә тотыналар: җир сөрәләр, бил бөгәләр, тир түгәләр. Ул арада бер ел үтеп тә китә. Бер елдан соң пан каршына килә болар.

— Я, өйрәт инде, пан, хакыйкатьне без ничек табыйк? — дип сорыйлар.

— Әй, йоннан төргән нәрсәләр! — ди боларга пан.— Сез һәрвакыт безгә, паннарга, хезмәт итәргә тиешсез — хакыйкать менә шул инде ул!

Агай-эне «тфү!» дип бер төкерәләр дә ары китәләр.

Ай баралар, ел баралар. Бара торгач бер авылга килеп керәләр. Бу юлы поп очрый боларга.

— Өйрәт әле безне, атакай,— дип сорый болар поптан,— хакыйкатьне кайдан табыйк икән?

— Бик әйбәт! — ди поп.— Хакыйкатьне мин алладан сорап алып бирермен, ә сез шуның өчен миңа бер ел хезмәт итәрсез.

Агай-эне, риза булып, эшкә тотына: бил бөгәләр, җир сөрәләр, тир түгәләр. Бер елдан соң поп каршына баралар.

— Яхшы эшләгез, аллага тел тидермәгез — хакыйкать менә шул булыр,— ди боларга поп.

Поптан эш чыкмагач, бик бай, юан корсаклы купец янына баралар.

— Ярый,— ди купец.— Мин сезгә хакыйкатьне кайдан табарга икәнен өйрәтермен, тик сез миңа бер ел хезмәт итегез башта.

Риза булып, купецка хезмәт итә башлый болар: бил бөгәләр, тир түгәләр. Купец боларга ничек итеп гадел һәм фәкыйрь кешеләрне алдау юлларын өйрәтергә тотына. Ярты ел да үтми, тегеләрнең энесе әйтә абыйсына:

— Хакыйкатьне бүтән эзләмим инде мин! Дөньяда беркайда да мужикка хакыйкать юк икән ул! — ди.

Шулай ди дә, үз авылларына кайтып китә. Ә абыйсы үз дигәнен итәргә яратучы кеше була, хакыйкатьне тапмыйча кайтырга теләми. Тота да, тәвәккәлләп, бер үзе фабрикант каршына бара бу.

Паннан да, поптан да, купецтан да баерак икән фабрикант. Теге шуның фабрикасына эшкә урнаша. Ә фабрика зур, анда эшләүчеләрнең исәбе-хисабы юк, ди. Башкалар белән бергә, хакыйкать эзләүче теге мужик та бик күп еллар бил бөккән, тир түккән фабрикада. Әмма хакыйкатьне ул да, бүтәннәр дә тәки таба алмаган.

Бер дә бер көнне менә шушы сүзләрне ишетә хакыйкать эзләүче:

— Хакыйкатьне бары тик бер кеше генә белә. Ул кеше Ленин исемле, ә үзе Питерда яши.

Менә шул сүзләрне отып ала да Ленинны эзләп китә бу. Көн үтә, ай үтә, Питерга барып җитә. Бер эшчене күрә дә шыпырт кына:

— Ленинны ничек табып булыр икән монда? — дип сорый.

Ә эшче колагына гына әйтә моның:

— Әйдә, минем белән, үзем алып барам мин сине.

Китаплар белән тулган гади генә бер бүлмәгә барып керә болар. Килеп керүләре була, каршыларына бик үк шәптән булмаса да, чиста гына киенгән кеше килеп чыга. Килеп чыга да, ягымлы гына елмаеп:

— Исәнмесез, иптәшләр, нинди яхшы сүз әйтмәкче буласыз? — дип сорый.

Теге үзенең ничек итеп гаделлек эзләп йөрүен сөйләп бирә Ленинга. Ленин бик озак сөйләшә аның белән. Фабрикадагы тәртипләр турында да сүз кузгата, авыл ярлылары хакында да сораштыра. Аннары әйтә:

— Хакыйкать эзләргә фабрикага килеп бик яхшы иткәнсең син: анда тизрәк табарсың син аны. Хакыйкать сезнең үз кулыгызда ул! — ди. Паннарга, сәүдәгәрләргә, фабрикантларга хезмәт итүдән котылу өчен, ничек итеп көрәшергә кирәклеген аңлата: аларның барысын да, патшалары-ниләре белән бергә, туздырып ташлаганда гына чын хакыйкатькә ирешеп булачагын әйтә.

Шуннан соң теге кеше янә фабрикага бара да иптәшләренә Ленин хакыйкатен сөйләп бирә. Аннары ул иптәшләр шуны үз иптәшләренә сөйлиләр. Берсе сөйләгәндә унау тыңлый, унау сөйләсә — йөз кеше тыңлый. Шулай итеп, Ленин хакыйкате бөтен дөньяга тарала.

Күп еллар йөри ул хакыйкать: фабрикаларда, авылларда була. Үзе барып җиткән бөтен җирдә эшче-крестьяннарны көрәшкә күтәрә. Шулай йөри торгач, унҗиденче елның октябрендә, бөтен дөньяны шаулатып, күтәрелеп чыга бу хакыйкать. Эшчеләр белән крестьяннар бергәләп алпавытларга, фабрика хуҗаларына каршы сугыш ачалар. Шулай итеп, Ленин хакыйкате өскә чыга.

Менә шуннан соң эшчеләр һәм крестьяннар, фабрикантларга һәм паннарга бил бөгеп, хезмәт итмиләр, җир сөрмиләр, тир түкмиләр, фабрикаларга да, җиргә дә үзләре хуҗа булып, рәхәтләнеп яшиләр [1].

[1] Бу әкият «Антирелигиозные сказки народов СССР» («СССР халыкларының дингә каршы әкиятләре») исемле китаптан алынды. Мәскәү, 1939 ел, 112 бит.

# МИЧ ЧЫГАРУЧЫ

*Русчадан*



Бендерин фамилияле бер кеше бар иде бездә. Алтын куллы иде ул: мичен дә чыгара, шүрлеген дә, чанасын да ясый торган иде.

Бервакыт шулай урманга барган да өрәңге кисә башлаган бу. Бик кызып кына эшләп торганда, кинәт:

— Хәерле көн! — дигән тавыш ишеткән. Әйләнеп караса — каршында ниндидер бер ир кеше басып тора, ди.

— Гаеп миндә, ваше высокоблагородие,— дигән Бендерин.

— Ә мин ваше высокоблагородие түгел,— дигән теге кеше.— Мин — иптәш Ленин.

— Гафу итегез, иптәш Ленин,— дигән Бендерин.

— Ярый, кис әйдә, кис! — дигән дә читкәрәк китеп карап тора башлаган Ленин. Шушы кадәр зур агачны нишләтер икән, ничек итеп авылына атсыз-нисез алып кайтыр икән дип, кызыксынып күзәтә икән тегене.

Бендерин агачны аударган, үзенә кирәк кадәресен үлчәп кисеп алган да таудан тәгәрәтеп алып төшеп киткән. Аннары яңадан әйләнеп килгән, тагын үзенә кирәген кисеп алган.

— Бәлки, сиңа булышырга кирәктер? — дигән аңа Ленин.

— Юк-юк, борчылмагыз! — дигән Бендерин,— мин үзем дә булдыра алам.

Икенче бер вакыт, печән өстендә, Бендерин тагын үзенә кирәкле материал алып кайтырга урманга килә. Өрәңгеме, каенмы кисә дә кайтырга чыга. Инешне кичкәч, хәл җыярга туктый. Кичкә таба була бу хәл.

Кинәт күрә Бендерин: өч кеше чабылган печәнне таптап килә.

Шактый коры кеше була Бендерин. Кычкыра бу тегеләргә:

— Нигә буталып йөрисез монда? Беләсезме, быел печән күпме тора? — ди.

Тәки покостан куып чыгара тегеләрне.

— Әй, оста сүгенәсең дә инде, карт,— ди тегеләрнең берсе, Бендерин янына килгәч.

Бендерин аны шундук танып ала да:

— Гафу итегез, иптәш Ленин! — ди...

Кыш җитә. Ул чорда мич чыгаручыларга бик кытлык була.

Ильич бер көнне әйтә:

— Берәр мич чыгаручы табып булмас микән, югыйсә өй бик суык безнең,— ди.

— Бар бер мичче,— диләр аңа һәм Бендерин янына китәләр.

Кызык... Бик шәп юртаклар җигелгән тарантаска утырып, ике хәрби кеше Бендеринның капкасы төбенә килеп туктыйлар да, өенә кереп:

— Син мич чыгаручымы? — дип сорыйлар.

— Әйе,— ди Бендерин.

— Җыен, совхозга барабыз! — ди тегеләр.

Әйе... Бендерин тәмам коелып төшә. Аннары хатынына болай ди:

— Хуш, Катюха! Без бүтән күрешмәбез инде. Ленин минем теге чактагы тупаслыгымны исенә төшергән булса кирәк.

Хәрбиләр белән бергә совхозга китә Бендерин. Барып җитә болар. Каршына Ильич чыга да әйтә моңа:

— Ә мин сине беләм бит, карт! Урманда әрәңге кискән кеше бит син, аннары икенче тапкыр печән өстендә мине куркыткан идең.

Куркуыннан тәмам авыруга сабыша Бендерин.

— Гаеп миндә! — ди.

— Аптырама юкка! — ди аңа Ленин.— Печән вакытында син мине дөрес ачуландың. Чапкан печән өстеннән барып, мин үзем ялгыш иттем ул чакта. Ә хәзер, әйдә, сине ник чакыртуым турында сөйләшик... Минем сиңа бик зур үтенечем бар. Күрәсең, минем эшләр шәптән түгел монда: әйнең бөтен стеналары түтеннән саргаеп беткән. Син мичне төзәтә алырсыңмы икән?

— Төзәтәм! — ди Бендерин. Балчык һәм кирпечләр сорап ала да эшкә тотына.


Эшен бетергәч, Ильич аңа рәхмәт әйтә, тиешле эш хакын түли дә үзе белән бергә чәй эчәргә утырта.

Аннары Бендеринны теге юртаклар белән еенә кайтарып куялар.

— Катюха! — ди Бендерин, ишектән килеп керүгә хатынына дәшеп.— Катюха, мин иптәш Ленинның мичен төзәттем һәм аның белән бергә утырып чәй эчтем! [1]

# ТӨЙМӘ

*Русчадан*



Бервакыт безнең заводка Ленин килде.

— Наторова,— диделәр миңа,— пальтосын элеп куярсың! Клубта бик эссе. Ленин сөйли башлады. Пальтосын салып урындыкка куйды. Мин аны киемнәр элә торган җиргә алып киттем. Карасам — сул як изүендә бер төймәсе юк моның. Үземнең жакеткамның бер төймәсен өзеп алдым да Ленин пальтосына тегеп куйдым. Тиз генә өзелмәсен дип, юан җеп белән тектем.

Ленин кайтып китте, берни дә сизмәде. Ә минем төймә аның пальтосындагы төймәләрдән бераз аерылып тора иде. Эчтән куандым, әмма бу серне беркемгә дә ачмадым.

Шуннан соң байтак гомер узды. Бер дә бер көнне Литейный буйлап бара идем, «Феникс» фотографиясенең тәрәзәсендә Ленинның зурайтылган портретына күзем төште. Шул ук пальтосын киеп төшкән. Якынрак килеп карасам, төймәсе шул — мин таккан төймә...

Ул шул кышта вафат булды. Мин Литейныйдагы фотографиядән теге кадерле портретны әемә алып кайттым. Көзге янындагы рамда тора ул хәзер.

Көн саен килеп карыйм да елыйм.

Ни әйтсәң дә, төймәсе минеке бит [2]...

---

[1] Бу истәлек 1937 елда А. М. Шурыгиннан язып алынган. Истәлек «Творчество народов СССР» («СССР халыклары иҗаты») исемле китапта (65 бит) басылган.

[2] Бу истәлек 1927 елда Архангельскидагы йорт хозяйкасы Натороваддан язып алынган. Истәлек «Творчество народов СССР» («СССР халыклары иҗаты») исемле китапта басылган (56 бит).

## Сибгат Хәким

# ДУГА[1]

## Дугада өченче көн

Истәлекләр, төрле яктан җыелып,
Чиркәү тирәсендә урнаша.
Кырык өчтә, апрель башларында
Алгы частька шушы үр аша
Узган идем мин өч солдат белән.
Плащлардан корып чатырны,
Истәлекләр дөньясына бүген
Үткәннәрем кабат чакырды.
Атаклы үр, соры чиркәүле үр,
Тарихи үр, йөргән урем ул,
Үзем теләп биеклекне сайлыйм,
Биеклектән курка үлем ул.
Моннан миңа Прохоровка күренә,
Гостищево күренә, Белгород...
Тора чиркәү читтә кешеләрне
Бер күрергә гүя тилмереп...
Күренә Ерик, гөнаһсыз саф Ерик
Күкрәгемә агып керде күк,
Челтерәве белән шушы җирнең
Бөтен моңын алып керде күк.
Минем җырга Ерик — шул тар гына
Бер үзәне җитә Дуганың.
Сез белсәгез иде шушы үрдә
Хисләремнең ничек дулавын.
Килде тавыш: тизрәк казы, әйдә,
Кем тәмәке тарта, әй, тагы...
Таныш аваз, таныш тавышлары
Бар дөньямны минем айкады.
Бу — алтынчы армиянең батыр
Солдатлары кора дзотлар.
Кычкыралар кебек ул дзотлар:
Якын килмә безгә, без — утлар...
Карыйсың да: Сталинградтан, дисең,—
Уйлаганың синең чын була,
Танып була икән солдатларның
Чыраеннан хәтта чорны да.
Сталинградтан бушап монда килгән
Солдатларга озак төбәлдек,

---

[1] Ахыры. Башы 2 санда.

Күзләренең карашыннан чорның
Эшләренә күчте тәгәллек.
Казыдылар Жадов, Шумиловның
Солдатлары. Көрәк, ломнары
Ташка бәрелеп чыңлый, ә чор һаман:
Юк, булмады әле, булмады.
Казыдылар өч ай буе төнлә,
Ломнарыңны ташлап, ал баян,
Гвардия солдатлары белән
Биер иде үзе Обоянь.
Низами дус, Низаметдин, Низам...
Тәмәкесен капкан чорнап ул.
Йөзе житди, карый кебек миңа
Траншеядан түгел, чордан ул.
Мин утырам үрдә, көтеп утырам
Эшләренең гүя беткәнен.
Көрәк тавышы, котелоклар тавышы,
Тәмле исе хәтта ботканың
Килгән кебек чирек гасырдан соң.
Кычкырды күк: кемнең кашыгы
Бушады дип Низам... Әй, тулды соң,
Әй, ташыды күңелем, ташыды...
Траншеядан чыгып үтеп китте,
Күреп калдым туры сынын мин.
Ашыгып атлый Низам, калдым күреп
Халкыбызның бөек чорын мин.
Сагышлардан оеп барам төсле
Тиеп киткән саен жил тәнгә.
Солдатларым хәзер эзләп мине
Керерләр күк бәреп чиркәүгә.
Ичмасам бер яңгыратсын иде
Үрне чиркәү. Тып-тын — ул да мин.
Апрель. Әнгер. Ерик авылына
Ял итәргә төшәм үрдән мин.

## Дугада дүртенче көн

Мин утырган үрдән, якты үрдән
Күренә миңа таныш имәннәр,
Яннарында Ерик колхозының
Эскертләре тора, кибәннәр...
Менә алган кадәр биеклектән
Мин дәһшәтле көннәр, мин ерак
Көннәремә карыйм, ул имәннәр
Мин караган саен шомлырак.
Имәннәре Дуга кырларының...
Алар бүген башын игән ник?
Уйларымны, хисләремне күптән
Тартып алды күптән имәнлек.
Әй, сугышчан сакчылыгы жирнең...
Алгы сызыктан да алдарак...
Хисләр минем күптән инде шунда,
Хисләрне син кара алдалап...
Әй, сугышчан сакчылыгы жирнең...
Әмер кыска: жирне саклагыз.

Күп булдык шул кыргый иманлектә
Низам белән бергә сакта без.
Күп таптадык Ерик ындыр артын,
Шуннан ары ләкин узмадык,
Ул сакчылык — безнең гаскәрләрне
Күтәрергә куйган звонок...
Мин Бурмакны шунда күргәләдем.
— Эшләр ничек?
— Урлап эш итәм...
Безнең яннан төнлә разведкага
Үтә иде Бурмак Степан.
Үтә Бурмак... Каты үлән кырда.
Онытылып бара эш күптән...
Степанның үз кырлары, монда
Урган, суккан, койган эскертләр...
Үз болыны, үз җирләре аның,
Тыныч кына атлар җир түгел;
Туып-үскән нигезе, йорты монда,
Тик утлары янмый йортының.
Йокы да юк, ял да разведкага,
Кайт борылып «тел» дә алмыйча.
Без көтәбез шомлы иманлектә,
Без көтәбез тын да алмыйча.
Кыр яңгырый, кырда кинәт шартлау:
Менде берсе мина өстенә.
Аяк тавышы... якынлаша тавыш:
Бире китер, бире өстерә...
Ракеталар яктысында алар
Төнлә кырда кулдан ычкынган
Арсланнар сыман күренделәр,
Ут чорнаган кылган эченнән
Атылып чыккан арсланнар сыман...
Бу эш миннән булмас эш икән.
Шуннан бирле баһадирлар төсле
Тора алда Бурмак Степан...

Шунда, кырда уйлар киерелгәндә,
Низам белән сәер, ят телнең
Җәйге төндә ачык яңгыраган
Чит сүзләрен тыңлап яттым мин.
Колакка ят, иманнәргә ул ят,
Нигә ул ят? Серен тап, өйрәт.
Бәрелеп-сугылып йөри кырда сүзләр,
Кабул итми кебек табигать.
Бу сугышта туган вакытлы хис,
Әй, юләр син күңел, әй, юләр,
Әйт, кайчаннан бирле сиңа ул чит,
Сиңа ул ят Генрих Гейнеләр?

Каршылыклы уйга бирелеп шулай
Каршылаган чакта таңны мин,
Аш китергән ике солдат белән
Атлый берәү, үтер, танымыйм,
Юк, булуы мөмкин түгел, безнең
Бу язмышка кем ул кызыккан?
Эзләп, үтеп мина кырларыннан,
Үтеп хәтта алгы сызыктан,

Шагыйрь Гали килсен... Монда фәкать
Разведчиклар гына булгалый...
Унөченче гасыр башларында
Иҗат иткән шагыйрь Кол Гали
Монда әле нишләп йөри икән?
Төз, мәһабәт, горур сынлы ул.
Гел сөйләнә үзе: көтмәгәндә
Очраштыра, гомер шундый ул.
Шигырьләрем карады ул тыңлап,
— Безнең тарих — сезнең кулда,— ди.
Уллары батырлыгын таңда
Тикшерергә чыккан Кол Гали.
Йөри карап безнең имәнлекне,
Тимә, йөрсен, кума, ул моннан
Үзе китәр, ярдәм итәр өчен
Тарих кайчак куба урыныннан.
Йөри карап таңда имәнлекне,
Солдатлары сабыр, гадиләр,
Ярты халык Галиләрдән тора,
Ватанына тугры Галиләр.
Фатихасын бирде, аш китергән
Солдатларга тагын ияреп
Китеп барды Гали... Сугышта да
Күп нәрсәгә була өйрәнеп.
Фатихасын бирде, мин халкымның
Шул рухыннан башка нишләрмен?
Артта калган кышлар, тимер мичләр,
Зәңгәр уты тимер мичләрнең
Яна минем күкрәгемдә, яна,
Мин янганга күрә сүз алам,
Әрнеттереп барсы турында да
Уйландырды мине бу заман.
Торган саен ныграк горурландым.
Үз халкыңны утта танышсың,
Шушы үрдән, шушы биеклектән
Күренә миңа бөтен тарихым.
Имәнлектә хыялымда шунда
Легендага кулым болгадым,
Терелде зур тарих, Аксак Тимер
Көлгә әйләндергән Болгарның
Яна уты күкрәгемдә, яна,
Тарихымны, озын төнемне
Нурландырып ташлар арасыннан,
Хәрабәдән озын толымлы
Яшь кыз чыкты, Болгар туфрагында
Бердәнбер җан... кызы Болгарның —
Тарихым ул... Болгар, Казан өчен,
Орел өчен алга мин бардым.
Сугышларда, утта туган халкым
Ник ялгышып чыксын истән бер,
Шәфәкъ моңсулыгын хәтерләткән
Ерак, ләкин изге хисләрнең
Яна уты күкрәгемдә, яна,
Яна, яна гына өйрәндек,
Туган телнең кадерен белергә дә
Өйрәтте шул серле имәнлек.

Күп уйландым Дуга төннәрендә.
Онытылырга мөмкин җан-дуслар,
Туган телең ләкин искә төшә
Хәл ителгән чакта язмышлар,
Ул язмышлар уртасына керә,
Таң вакыты булсын, булсын кич,
Сызып, телеп, күңел түрләреннән
Күтәрелә башлый моңсу хис.
Чишмәләре кушыла төрле яктан,
Чишмәләрдә кайный бөтен дәрт,
Артта таллар — татар хатыннары
Сөйләшәләр төсле лепердәп.
Сөйләшәләр төсле: бу арада
Балаларның никтер аз хаты...
Туган телем минем әнкәйнең ул
Ризалыгы, соңгы васыяте
Булып кайчак яңгырады миндә.
Моңландырган чагы күп аның,
Бикләмәде, чикләмәде ләкин,
Кырларына тикле Дуганың
Килде алып, тик Тукайда үскән,
Лирикада үскән мин булып
Мин сугыштым хәтта... иҗатымның
Үзәгендә хәзер Белгород...
Иманым бар, идеалым бар җирдә,
Бар тотынган минем бер ноктам.
Дугада мин, Дуга сугышлары
Алдындагы хәтәр тынлыктан
Файдаланып хыялларга бирелэм,
Кыңгыраулы дуга, ат белән
Бөтен төшне гизәм, чынлый Дуга,
Мин бишенче таңны аттырам...
Без эрнедек... Без тормышка кердек,
Чәчтә инде күптән көмешләр.
Нәкъ яртысы безнең гомерләрнең
Сугышлардан торган керешләр.

## Дугада бишенче көн

Тыңлар өчен безнең истәлекне
Чиркәү үзе өскә нелде,
Имәнлектә каршыладык сакта
Без бишенче утлы июльне.
Ни өчендер күксел итеп күрдем
Кырны, хәтта арыш башларын,
Дөнья күксел... Күрдем солдатларның
Имән саен барып басканын.
Арыш башы урын тапмый үзенә
Чыңлап оча, чынлый җиде күк,
Мәскәү яны, Сталинград, Ржев
Ярсуларын Дуга җыйды күк,
Бер үзәндә тыгызланды бар да,
Ихтыяр һәм өмет, көчләрнең,
Төрле фронтлардан сыгып алган
Төрле буяу, төрле төсләрнең
Тупланган бер урыны — утлы Дуга,

Кызган утук төсле, танклар
Утукләде җирне, уз чорыңның,
Уз җиреңнең йөзен таныл кал.
— Рус, бирел,— дип кычкырдылар, бирел,
Имәнлегең — илең таптармын...
— Юк, мин кыргыз, мин Каекбай булам!
— Ялгышасың, ә мин: татармын.
Июль ае... яна дөнья утта,
Имәнме ул, кайсы ялбырдый?
— Юк, мин кыргыз... Колагымда һаман
Каекбайның тавышы яңгырый.
Имәнме ул, Каекбаймы, кайсы?
Атакага ничә кат килгән,
Ничә тапкыр кире чиккән дошман,
Чәрдәкләнеп беткән карт имән...

Чирек гасыр узды, утырам урдә,
Зәңгәр пәрдә каплый күз алдын,
Ләкин ишетәм, мин елавын ишетәм
Шушы урдән һаман Низамның.
Каекбайның һәлак булуын күреп
Елады ул ярсып... Ул аңсыз,
Ул юләр, дип тиргәдем мин, миңа
Дошманнардан оят, уңайсыз.
Сугыш аның елап бетергәнен
Торды көтеп, юат-юатма
Файдасы юк барыбер... шул зур елау
Гомерлеккә калды йөрәктә...

Яна имән артта, Каекбай ул...
Һаман бер сүз: бирел, рус, имеш.
Мин Низамга: син ничек? дим, Низам
Дәшми миңа, үзе дус, имеш.
Калининнан алып бергә узган
Солдат бит син, әйт, дим, кызганма
Бер сүзеңне?! Әсирлектән куркам,
Син ничек? дим тагын Низамга.
Ник бер дәшсен... Бәхәсләшә идең,
Җырлый, көлә идең — бар идең...
Гел шул имән күренә, имәнлек тын,
Кирәмәте кебек мариның.
Без чигендек... Ерик читендәге
Танк базы — тирән базны да
Бергә уздык, төшеп, күләгәдә
Ял итәсе иде аз гына.
Без чигендек, калды Ерик, калды
Шушы чиркәү... Барысы истә бит.
Нәрсә уйлап, ничек сулавыңны
Тыңлап бара кебек пистолет.
Җаен табып, юри кыен чакта
Сорый тормыш бездән: Син ничек?
Сугыш авыр, фәлсәфәсе авыр,
Яшәү, яшәү, кайда синең чик?
Чикләреңне белми яши кеше,
Үлчи күбрәк атлап узганны...
Җиреңнең тәмам асты-өскә килеп
Буталганда җуйдым Низамны.

Бик газаплы, авыр елады ул,
Ил кайгысы — олы елауда.
Андый ирләр аерылмыйлар илдән,
Очраштырыр безне юл алда...

Җирдән фәкать керер җир эзлисең,
Янда Низам, беләм, ул кырда...
Старшина хат китереп китте,
Вакыт тими шуны укырга.
Бер дә юкка әрәм булырмыни
Фронтларны кичеп очканы?
Кесәмдә ул минем, өч почмаклы,
Күкрәгемә төртә почмагы.
Ачар идем, укыр идем йотылып,
Бер минутка туктап калса ут,
Кесәмдә ул минем, өч почмаклы,
Йөри-йөри бетте таушалып.
Күңеленнән авырлыгын хәтта
Карагансың инде үлчәп син,
Үкенече талый, ни үкенеч
Укымыйча әгәр үлсәң син.
Кесәмдә ул минем, өч почмаклы,
Омтылгалап куйдым берничә...
Тормышның иң кирәк соңгы сүзен
Дөньядан кит шулай белмичә.
Балаң кулы, серләрен ач тизрәк
Конверттагы төрле билгенең,
Бугазыңда тавышың: риза, күнәм,
Тик укырга вакыт бир, үлем...

## Дугада алтынчы көн

Июль, Дуга. Дулый сугыш көн-төн.
Сугыш әле кемне аяган?
Прохоровка кабатланса бик еш,
Еш очраса миндә Обоянь,
Гаҗәпләнмә, тормышымның алар
Җиңүгә юл ачкан чатлары...
Утырам үрдә. Кабат-кабат кайтам
Көннәремә мин шул чактагы.
Прохоровка: йорт-җирләре гади,
Кешеләре кебек, таллары
Тыныч, уйчан... Гадәти бер авыл,
Бәрәңгесе, ындыр табагы...
Бер тимер юл үтә... Тарих анда
Таш пулатлар, әйе, салмаган,
Ул элек тә шундый ук бер гади
Бородино кырын сайлаган...
Җир селкетеп, өере-өере белән,
Нык ышанып әзәрләвенә,
Ат көтүен куып кертән кебек,
Прохоровка үзәннәренә
Куды дошман үзенең танкларын,
Актарылган җир, кыр кап-кара,
Прохоровка авылы капкасына,
Халык үзе корган капкага

Бәрелеп тынды авыр танклары!
Ялкыннары кайда, күр, утның:
Чатнадылар ерак Германиядә
Корыч заводлары Круппның...

Июль, Дуга. Дулый көн-төн сугыш,
Кем кулында аның нуктасы?
Дуга минем яшьлегемнең дә ул
Иң югары кайнар ноктасы.
Тик гомеремнең ул ноктасы түгел,
Ул нокталар күренә, югала...
Ышандыра алмас иде үлем
Җиңелерсең дисә Дугада.
Шартлауларның уртасында кырда
Тордым басып... Ничек саклandың?
Барысын онытып, илнең куәтенә
Мин беренче тапкыр шатландым.
Шатлык фронт өсләреннән үтә,
Тамырларга хәтле ул керә,
Моторларда Идел буе, Урал,
Бөтен Себер гүя үкерә.
Түзәм июль эссесенә, түзәм,
Өч көн буе мине эчермә,
Гүләсеннәр фәкать шул моторлар,
Артта калган еллар өчен дә
Шатландым мин үз күгемә карап.
Күккә карый солдат сагынса!..
Санын белмим, әкияттәге төсле,
Самолетлар солдат санынча...

Утырам үрдә, үзенең полкын җуйган
Солдат кебек ялгыз кал шунда...
Гаскәрләре Дала фронтының
Кырык өчтә, август башында
Якынлашкан чакта Белгородка,
Арасыннан куе тузанның,
Икенче бер частьтан, колоннадан
Ишеттем мин тавышын Низамның.
Низамны мик озак көттем, көттем
Күңелемнән инде күмгәч тә...
Колоннадан йолкып алыр өчен
Ябыштым мин аңа күргәч тә.
Безнең юллар озын, безнең юлда
Ачы җилләр карны себергән,
Дивизия безнең данлы Себер
Җирләрендә туган, Себердән.

Безнең юллар озын, бергә сугыш,
Бергә кичер, бергә чиләп дә
Югалт, имеш... Авылларга кергәч,
Ишек алдындагы чирәмгә
Аяк баскач, күңел әллә нишли,
Бауга элгән ап-ак кер исе,
Бакча исе, бәрәңгенең яшел
Алмалары исе, көн исе,
Син яшәргә тиеш көннең исе
Күңелеңне синең били дә

Исерәсең, балаң-чагаң белән
Утырасың килә бер өйдә...

Низам хәзер Белгородка житте,
Белгородка килеп терәлгән
Ак тауларның итәгенә басты,
Беренче йорт әнә, кер алдан.
Атылды ул, йортның капкасына
Чөйде кебек үзе тау аны,
Атылды ул туктатырга теләп
Җирдә барган бөек гауганы.
Үкенүдән үкси кебек иде,
Үләсен дә бәлки белгәндер...
Шулай үлә күпләр, искәрмәстән
Мин ауганын күрдем меңнәрнең.
Кайсы ауды, үлән ашап янда
Аты йөрде, аты иярле...
Кайсы ауды имән төбенә, шунда
Йолкып алыр төсле имәнне.
Биттә газет, черем генә итә,
Бар да уят, эштә ял кыска,
Кайсы ауды, печән чабып арган
Печәнче күк, ятып покоска...

Ауды Низам... Әрем исе килде,
Көйгән исе килде сарутның.
Колагында иң беренче тапкыр
Яңгыраган тавышы салютның,
Вокзалларын сагынып эзли чыккан
Поездларның тавышы, җил-давыл,
Буран тавышы... Санбат... Ишетте күк
Этләренең кырда елавын.
Үкенүдән үкси кебек иде
Аерылганда юлда ташкыннан.
Агылдылар Дала солдатлары
Харьков юлы — олы таш юлдан.
Заман үзенең солдатлары белән
Тигезләнде, атла, шаулап бар.
Сталинград, Дуга, Днепр дип,
Кыска итеп сөйли солдатлар.
Кызганмады, солдатларын утта
Тезде башка, алга, шул вакыт
Шигырьне дә, бер чиратка куеп,
Сынады күк заман чыңлатып.

## Дугада җиденче көн

Утте, кичте тирән эзләр ясап
Давыллы һәм утлы чор баштан.
Соңгы тапкыр үрдә. Үр астында
Минем буын, минем чордашлар.
Үзем кебек авыл малайлары
Күз алдымда кинәт бар булды.
Хәтерләтте кызгылт сары җирнен
Киереп тарткан тальян гармоньны...
Төрле халык улларыннан торган

Зур бер буын җирдә... Туңа күк
Йөрәк кайчак... Бөгелмәде, түзде,
Җир бөгелеп килде дуга күк.
Минем буын, минем замандашлар,
Син шуларга карап туры бар,
Җир бөгелде, турайттылар җирне,
Кабердә дә алар турылар...

Мин шул үрдә чирек гасырдан соң.
Апрель. Җиргә яшел төс кергән.
Сау бул, Ерик, сау бул, Дуга кыры,
Кинәт блиндажым өстеннән
Автоматлы солдат кычкырды күк,
Тавышы тынды, сеңде таллыкта.
Танкистларның данын буыннарга
Сөйләр өчен баскан танк та
Кузгалды күк, үрмәли күк өскә
Танкларның авыр, салмагы,
Бик хәвефле итеп, шомлы итеп
Имәнлек тә шунда шаулады,
Бар почмагы хәрәкәткә килде,
Үзгәрде күк төсе Дуганың,
Бер минут та уйланмаган чагы,
Борчылмаган чагы юк аның.

Соңгы тапкыр үрдә. Сау бул, яшьлек,
Синең белән тагын ун утка
Керергә мин риза, кайт кына тик,
Бер генә сүз аңгырый: онытма...
Соңгы тапкыр үрдә. Карыйм шуннан
Кояшның мин баеп барганын...
Имәнлектән, ак тау буйларыннан
Низамнарның, Каекбайларның
Еллар аша тоньк тавышын ишетәм,
Дуга кырындагы тынлыкта
Ул авазлар куера. Үр астыннан
Үз тавышы җирнең. Онытма...

Сугыштым һәм яздым, уйламадым
Әсәрне дип кайда чикләрмен.
Тора Бурмак, шул Степан Бурмак,
Сарай белән соры чиркәүнең
Уртасында тора, сабыр, тыныч,
Илдә безнең андый ирләр күп.
Кул бирер дә, ул мин китү белән
Шул урында җиргә иңәр күк.
Бер вәкиле минем буынның ул,
Кайтып керми көн-төн Дугадан,
Сөрә, чәчә Бурмак, батырларның
Туфрагында үсеп туа дан...
Ни җитә бу мәшәкатьле җирдә
Бергә яшәп, бергә булмакка.
Сау бул, Бурмак! Үрдә сарай, чиркәү...
Ерактан кул болгыйм Бурмакка.

1968.

**Хәким Гыйлаҗев,**
Башкортстан язучылар союзы
идарәсе председателе

# ӘДӘБИЯТЫБЫЗ ТУРЫНДА БЕРНИЧӘ СҮЗ

Башкорт совет әдәбиятын еш кына гүзәл Агыйдел елгасына тиңлиләр. Әйе, бик дөрес. Җырларда җырланган бу елга матур Ирәмәл тауларыннан башланып, тирә-яктагы кечкенә елга, чишмәләрне үз кочагына җыя-җыя, тагын да зурая, тагын да гүзәлләнә. Ул кояшлы Башкортстанның урманлы таулары, киң далалары аркылы Камага, аннары мәгърур Иделгә барып кушыла. Башкорт совет әдәбиятының үсеш юлы да нәкъ менә шулай. Ярты гасыр вакыт эчендә ул зур әдәбият булып өлгерде, иҗади уңышлары ягыннан күп милләтле совет әдәбиятлары арасында үзенең хаклы урынын алды һәм халыкның рухи байлыгына әверелде.

Бөек Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы чорында туган башкорт совет әдәбиятының беренче нигез ташларын Мәҗит Гафури, Дәвыт Юлтый, Афзал Таһиров кебек күренекле язучылар салды. Алар, үз иҗатларында башта ук демократик юнәлештә булып, Октябрь революциясен беренче көненнән үк яклап чыктылар. М. Гафуриның «Кызыл байрак», «Безнең юл», «Татар егетенә», Д. Юлтыйның «Кызыл яу», «Кызыл йолдыз» дигән шигырьләре, А. Таһировның «Күчү чорында», «Беренче көннәр», «Ала-тау» исемле әсәрләре революция һәм гражданнар сугышы елларының ялкынлы авазлары булып яңгырады.

Халык талантларына зур мөмкинлекләр ачкан революциядән соң әдәбиятка күп кенә яшь көчләр килде. Гариф Гомәр, Шамун Фидаи, Ярлы Кәрим, Булат Ишемгол, Төхфәт Янәби, Имай Насыйри һ. б. лар гражданнар сугышы фронтларында, газета редакцияләрендә сугышчан тормыш сынаулары үттеләр. Алар шул елларның авыр шартларын дөрес сурәтләп, югары романтик пафос белән азат халыкның җиңүләрен данладылар.

Шулай итеп, башкорт совет әдәбияты Октябрь революциясе утларында, гражданнар сугышы кырларында туып, рус, татар һәм башка милләт әдәбиятларының уңай йогынтысында яңа чынбарлыкны сурәтләү юлында үзенең беренче битләрен ачты.

Егерменче елларда башкорт әдәбияты үсешенең яңа этабы башланды. Халык хуҗалыгын аякка бастыру, илне социалистик нигездә үстерү өчен көрәш, эшче һәм крестьян союзын ныгыту — бу еллар әдәбиятының төп тематикасы булып торды. Яңа чорның бөеклеге, совет халкының уй-хисләре һәм батырлыклары М. Гафуриның «Кызыл тәлгәшләр», Д. Юлтыйның «Истәлекләрем», С. Кудашның «Сабан җырлары», Г. Гомәрнең «Кызыл учмалар», Т. Янәбинең «Эш чуагы» дигән шигырь җыентыкларын-



*Башкортстан язучылар союзының VI съездыннан: (Сулдан уңга) казак шагыйре С. Мәуленов, С. Кудаш, М. Кәрим, литва язучысы П. Кейдошюс һәм украин шагыйре П. Дорожко.*

да ачык чагылды. Яңа кеше образын сурәтләгән М. Гафуриның «Эшче», Д. Юлтыйның «Шәриф», С. Кудашның «Тугайда», «Тимерлектә» дигән эпик поэмалары барлыкка килде.

Башкорт совет әдәбиятының үсешендә «Яңа юл» (1923), «Белем» (1924), «Яңалык» (1927), «Сәсән» (1927) исемле әдәби-политик журналлар зур роль уйнады. Алар үз тирәләренә яңадан яңа әдәби көчләр туплап, тәрбияләп үстерделәр.

Утызынчы елларда Башкортстанның экономикасы һәм культурасы гаять дәрәҗәдә югары күтәрелде. Язучыларның социалистик төзелешләр белән тыгыз бәйләнеше һәм аларның әдәби осталыклары үсә баруы эпик пландагы жанрларның да үсүенә зур этәргеч булды. Шулай ук 1932 нче елның 23 нче апрелендә әдәби оешмаларны яңадан кору турында партия Үзәк Комитеты чыгарган карар шушы юнәлештә зур роль уйнады. Совет язучыларының Беренче бөтен Союз съезды (1934) башкорт совет әдәбиятының алга үсүе өчен тагы да әһәмиятле вакыйга булды. Әдәбиятның үсешен билгеләүче беренче зур күләмле проза әсәрләре — А. Таһировның «Солдатлар», «Кызылармеецлар», «Кызыл гвардеецлар» трилогиясе, Д. Юлтыйның «Кан», И. Насыриның «Күзәй», С. Кудашның «Кушкаен» романнары барлыкка килде. Сәгыйт Агиш, Али Карнай кебек прозаикларның да иҗаты активлашты.

Бөтен совет әдәбиятыныкы кебек үк, башкорт әдәбиятының да төп бурычы — халыкны патриотик рухта тәрбияләү көче — Бөек Ватан сугышы елларында аеруча ачык күренде. Башкорт язучыларының күбесе каләм һәм штык белән фашистларга каршы көрәштеләр. Хәниф Кәрим, Әкрәм Вәли, Гайнан Әмири, Сәләх Кулибай, Мостай Кәрим, Нәҗәр Нәҗми, Әнвәр Бикчәнтәев, Тимер Арслан, Гыйлемдар Рамазанов һәм башка бик күп язучылар сугышның башыннан ахырына кадәр диярлек сугышта булдылар.

Сугышның беренче чорында башкорт әдәбиятында Ватан азатлыгы өчен көрәшкә өндәүче публицистика, агитацион лирика өстенлек алды. С. Кудашның «Ватан өчен», «Илне бирмәбез», Р. Нигъмәтинең «Туган илем өчен», «Үч ал, патриот», Г. Әмиринең «Кузгал, Урал», Б. Бикбайның «Коралга, иптәшләр» исемле шигырьләре әнә шундый ялкынлы публицистик лирика белән сугарылган иде. Аннары поэтик әсәрләрдә фронт һәм тыл геройларының патриотик тойгыларын, батырлыкларын тулырак чагылдырырга, конкрет образлар иҗат итәргә омтылыш башланды. Р. Нигъмәти, капитан Гастелло кебек, үз самолеты белән дошман самолетын бәрдергән летчикка багышлап «Герой турында поэма» әсәрен иҗат итте. «Синең киләчәгеңнең хатлары» дигән лирик поэмасында да фронтовик егет белән тылдагы кәләше образлары аша совет халкы-

ның изге теләкләрен тасвирлады. С. Кудаш «Ленин һәм солдат» балладасында совет солдатына иң авыр вакытта, фашистлар әсирлегеннән качып, партизаннарга кушылырга куәт бирүче тиңсез көч булган ленинизм идеяләренең бөеклеген җырлады. «Минем авылдашым» дигән поэмасында үз Ватанына турылыклы офицер-танкист образын иҗат итте.

Сугыш чорында совет кешеләренең фронтта һәм тылдагы батырлыклары турында байтак кына очерклар, хикәяләр язылды. Сәгыйть Агишның «Фронтка», Кирәй Мәргәннең «Башкортлар», «Егетләр», Баязит Бикбайның «Самолет алган Хәбирҗан» дигән китапларында башкорт солдатларының конкрет образлары сурәтләнде.

Башкорт совет әдәбияты авыр сугыш елларында да өзлексез үсте, чынлыкта, халык тормышына тагын да якынайды, халык белән бергә атлады, Европа цивилизациясен фашистлар таптавыннан коткаручы совет кешеләренең кайнар хисләрен, тирән уйларын образлы сурәтләүләр ярдәмендә чагылдырды.

Сугыштан соң башкорт әдәбияты тагын да яңа биеклекләргә күтәрелде. Фашизмны тар-мар итү, сугыш гарасатларыннан соң илне аякка бастыру, тыныч хезмәт батырларын данлау, тынычлык өчен көрәш — әдәбиятның төп идея эчтәлегенә әверелде. Башкорт язучыларының әсәрләре күп милләтле совет илендә генә түгел, чит илләрдә дә танылa башлады.

Бу чорда Башкортстан хезмәт иялəре тормышының мөһим этапларын чагылдырган киң полотнолы күп кенә әсәрләр дөньяга килде. С. Кудашның «Язны каршылаганда» дигән тарихи-биографик повесте Габдулла Тукай белән Мәҗит Гафуриның якты образларын сурәтләү, шул дәвернең социаль-тарихи шартларын җанлы итеп күз алдына бастыру ягыннан зур уңыш казанды. Бу әсәрне татар һәм башкорт укучылары гына түгел, рус, таҗик, казакъ укучылары да яратып каршы алды. Язучының «Хәтердә калган минутлар» исемле мемуар китабы исә башкорт совет әдәбияты үсешенә зур өлеш керткән үзенчәлекле әсәр булды.

Г. Гомәр «Дулкын өстендәге кала» дигән повестенда авыр сугыш көннәрендәге салчылар турында — тыл белән фронтның бердәмлеген, халыклар дуслыгын һәм аларның фидакарь хезмәтен гәүдәләндерде. Ә «Бусагадан түргә», «Җаңыл» дигән автобиографик повестьлары белән әдәбиятыбызга тагын да бер яңалык өстәде. Моңа чаклы мондый социаль югарылыктагы зур күләмле мемуар әсәрләр язылганы юк иде.

Сугыштан соңгы елларда башкорт әдәбиятында С. Агиш, Ә. Вәли, Һ. Дәүләтшина, К. Мәргән, Б. Бикбай, Ә. Бикчәнтәев, З. Биишева, Гали Ибраһимов, Д. Исламов, В. Исхаков, Я. Хамматовларның романнары дөньяга килде. Аларның әсәрләрендә башкорт халкы тормышының төрле чорлары чагылдырылып, әйтерсең лә шулай Башкортстанның әдәби тарихы төзелде.

Зур күләмле әсәрләр арасында тормыш күренешләрен киң колач белән, геройлар психологиясен, халыкның көнкүрешен, гореф-гадәтләрен җентекле сурәтләве белән Һәдия Дәүләтшинаның «Ыргыз» романы аеруча игътибарны үзенә тарта. Анда элеккеге Самара губернасындагы башкортларның язмышы, газаплы көнкүреше, изелүләре нәтиҗәсендә үлеп бетүгә йөз тотуы, фәкать социалистик революциядән соң гына азат тормышка чыгулары күрсәтелә. Романның төп герое Айбулат кагылган-сугылган батрактан аңлы революционер дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. Монда башкорт крестьяннарының рус большевиклары белән бердәмлеге, дуслыгы ышандырырлык ачыла.

Язучыларыбыз арасында Зәйнәп Биишева аеруча актив иҗат итә. Ул соңгы елларда «Бер гомернең тарихы» дигән трилогиясеннән «Кимсетелгәннәр», «Уяну» романнарын тәмамлады.

Тагын шунысы куанычлы, соңгы еллардагы күпчелек башкорт романнары бүгенге темага — безнең совет чынбарлыгын сурәтләүгә багышланган. С. Агишның «Нигез», Ә. Вәлинең «Беренче адымнар»ында егерменче һәм утызынчы елларда башкорт авылларының яңа тормышка борылышы һәм милли интеллигенция кадрларының ничек формалашуы сурәтләнә. К. Мәргәннең «Нарыштау итәгендә», Ә. Бикчәнтәевның «Аккошлар Уралда кала» романнарында республиканың нефть промышленностеның һәм шуның белән бергә техник интеллигенциянең үсүе тулы канлы күрсәтелә.

Баязит Бикбайның соңгы еллардагы әсәрләре үзләренең әдәби камиллеге, тирән идеяле һәм югары художестволы булулары белән аерылып тора. Аның «Акчәчән ташканда» романы колхозлашу чорындагы крестьяннарның тормышын, характерларын



*Такташ кабере янында. Уңда: башкорт шагыйре Наҗар Нәҗми.*

ачык сурәтләве белән зур әһәмияткә ия. Б. Бикбайның әдәби осталыгы, сюжетны җыйнак коруы, тел байлыгы күпләргә үрнәк булырлык.

Башкорт язучылары, партиянең бүгенге көндәге мөһим темаларны кыю яктыртырга дигән өндәвенә җавап итеп, байтак әсәрләр яздылар. Шундыйлардан Ә. Вәлинең «Май яңгыры», «Гөлҗимеш чәчкәсе», Ә. Бикчәнтәевның «Оҗмах вәгъдә итмим» романнары бүгенге көн тормышын, замандашлар образын үзәккә куеп, халкыбызны уйландырган зур проблемалар күтәрделәр.

Соңгы вакытта иҗат ителгән әсәрләрендә безнең язучылар геройларның эчке дөньяларына тирәнрәк үтеп керә, характерлар ачылышына тагын да ныграк игътибар итә башладылар. Шул җәһәттән Д. Исламовның «Юмарт җир» романы, З. Биишеваның «Уйлар, уйлар...», Ф. Исәнгуловның «Айбикә» һәм «Аккошым минем», Ф. Әсәновның «Вәгъдә» повестьлары, шулай ук Г. Әмири, Ш. Насыров, Гали Ибраһимов, Я. Вәлиев, Р. Габдрахманов һәм Р. Низамовның әсәрләре кызыклы. Һәрберсенең үзәгендә яңа гына мөстәкыйль тормышка аяк баскан яшь кеше образы тора. Барысы да коллектив хезмәттә үзләренең теләк-максатларына ирешү өчен көрәшәләр, тормыш каршылыкларында чыныгалар. Бу — яшь буынны коммунистик рухта тәрбияләүдә мөһим фактор.

Шулай ук Бөек Ватан сугышы темасы да башкорт язучыларының игътибарыннан читтә калмады. Гали Ибраһимов «Полкташлар», Динис Исламов «Мәскәү юлы» дигән романнарын яздылар. Бөек Ватан сугышы темасына күп кенә повесть һәм хикәяләр барлыкка килде. «Башкортстанның данлы уллары» дигән өч томлык очерклар китабы чыкты.



*Тукай-Кырлай авылы басуында. (Сулдан уңга) Шагыйрь Гайнан Әмири, язучы Афзал Шамов, язучы Баязит Бикбай.*

Совет кешесенең яудагы батырлыкларын, тыныч төзелештәге хезмәт җиңүләрен, тынычлык өчен көрәш, партия һәм халык мәнфәгатьләренең органик бердәмлеге мотивларын тасвирлаган дистәләрчә эпик, лиро-эпик поэмалар иҗат ителде. Р. Нигъмәтинең «Большевик», «Сакмар кызы», М. Кәримнең «Европа — Азия», Х. Кәримнең «Якты йолдыз», «Алтын башак», М. Сөндекленең «Макар Мазай», «Донбасс турында уйлар», С. Кулибайның «Яулардан соң», «Осталар», Т. Арсланның «Тау кызы», «Алтын чишмә», С. Кудашның «Зур адымлы кеше» кебек әсәрләрендә туган илгә чиксез мәхәббәт, хезмәт энтузиазмы уңышлы детальләр ярдәмендә гомумиләштерелә.

Партиянең XX съездыннан соң башкорт поэзиясе тагын да югарырак күтәрелде. Геройның рухи дөньясын бөтен тулылыгы белән яктырту, совет кешесенең әхлак бөеклеген җырлау юнәлешендә бик күп яңа әсәрләр язылды. Фашизмга каршы көрәш, совет сугышчыларының кыюлыгы һәм батырлыгы Мостай Кәримнең «Кара сулар», Нәҗәр Нәҗминең «Җыр турында баллада», Гыйлемдар Рамазановның «Әти янында» поэмаларында мораль-этик планда хәл ителде. Әнгам Атнабаевның «Замандашым» поэмасы бүгенге хезмәт кешесенең эчке дөньясын шактый уңышлы чагылдыруы белән аерылып тора. Шагыйрьнең замандашы — бала чаклары сугыш елларына туры килгән, яшьлек чорында да байтак авырлыклар кичергән, гомумән, тормышта барысын да татып үскән яңа буын кешесе. Ә. Атнабаев шул замандашының көрәш-төзелешләр кочагында кайнап үскән тормыш юлының аерым сәхифәләрен лирик планда тасвирлап бирә. Шулай ук С. Кулибай, К. Даян, Ш. Биккол, Марат Кәримов, А. Игебаев, Р. Гариповлар да бу темага үзләренең өлешләрен керттеләр.

Башкорт әдәбиятында, проза һәм поэзия жанрлары белән беррәттән, драма жанры да кыю рәвештә үсә. Соңгы елларда семья тормышындагы интригаларга нигезләнгән йомшак сәхнә әсәрләрен заман һәм замандашлар турында философик уйланулар, тирән гомумиләштерүләр югарылыгына омтылган әсәрләр акрынлап репертуардан кысрыклап чыгара бара. Мостай Кәримнең «Җырланмаган җыр» драмасында партия темасы безнең тормышның мөһим проблемасы итеп күрсәтелә. И. Абдуллинның «Йөрәк белән шаярмыйлар» драмасында да тамашачыларны уйландырырлык җитди проблема күтәрелә. Шулай ук Н. Асанбаевның «Рәйсә», Ә. Атнабаевның «Ул кайтты», Ә. Мирзаһитовның «Әниемнең чал чәчләре» кебек сәхнә әсәрләре игътибарга лаеклы.

Мостай Кәримнең «Ай тотылган төндә» трагедиясе башкорт драматургиясендә зур вакыйга булды. Бу әсәр Башкорт академия театрында гына түгел, Мәскәү, Казан, Ташкент, Рязань һәм башка бик күп шәһәрләрнең зур театрларында тамашачыларга күрсәтелә. Башкорт академия театрында бу әсәр буенча куелган спектакльгә 1967 нче елда К. С. Станиславский исемендәге РСФСР Дәүләт премиясе бирелде. Трагедия пафосы әсәрдәге һәр ситуациядә, һәр күренештә һәм образларда, аларның кискен бәрелешләрендә тасвирлана. Кешеләрнең үзләре урнаштырган тәртип һәм йолалар колы булып яшәүләре, шуның аркасында һәлакәткә дучар ителүләре трагедиядә зур художество осталыгы белән сурәтләнә. Кешеләрнең физик һәм әхлак азатлыгы, акыл көче һәм рухи сафлыгы өчен көрәш — әсәрнең төп идеясе. Әсәр хәзерге заман совет кешеләре өчен дә зур тәрбияви әһәмияткә ия.

Соңгы елларда әдәби тәнкыйть тә сизелерлек җанланды. Башкорт әдәбияты тарихы һәм халык иҗаты турында зур тикшеренүләр барлыкка килде. Тәнкыйть әдәби процесска активрак тәэсир итә башлады. Бу өлкәдә Ә. Харисов, К. Мәргән, Г. Рамазанов, Г. Хөсәенов, С. Сафуанов, М. Гайнуллин, К. Әхмәтҗанов һәм башка язучылар, әдәбият белгечләре уңышлы эшләп киләләр.

Башкорт язучылары Совет хөкүмәте һәм Коммунистлар партиясенең әдәбият һәм сәнгать алдына куйган яңа бурычларын тормышка ашыру өчен тагын да активрак, тагын да дәртләнебрәк яңадан яңа әсәрләр иҗат итәләр. Илле ел эчендә яшь башкорт совет әдәбияты зур юл үтте. Октябрь революциясенә кадәр үз язмасы да, әдәби теле дә булмаган башкорт халкының рухи хәзинәсе — әдәбияты бүгенге көндә СССР халыкларының тугандаш әдәбиятлары белән беррәттән тигез хокуклы, җитлеккән әдәбият булып өлгерде. Безнең сүз осталарыбыз Башкортстан Автономияле Совет Социалистик республикасы туган көнне зур яңа әсәрләр белән каршылыйлар.

---

Бу бүлектәге материалларны язучыларыбыз Фәнил Мансуров белән Хәсән Сарьян әзерләп һәм редакцияләп бирде.

## БАШКОРТСТАН АВТОНОМИЯЛЕ СОВЕТ СОЦИАЛИСТИК РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ 50 ЕЛЛЫК ТАРИХЫННАН

*1919 нчы ел*

*23 нче март.* Башкортстан Автономияле Совет Социалистик республикасы туган көн. Бу көнне Халык Комиссарлары Советы председателе В. И. Ленин һәм ВЦИК исеменнән М. В. Владимирский кул куйган документ нигезендә Башкортстан Совет Автономияле республикасы, РСФСР-ның Федератив өлеше булып, Оренбург губернасының төньяк көнчыгыш ягын, Уфа губернасының көнчыгыш өлешен, Пермь губернасының бернечә, Самараның бер волостен эченә алган Кече Башкортстан итеп төзелә. Башкортстан Автономияле Совет Социалистик республикасы РСФСРда иң беренче автономияле республика була, аны төзү тәҗрибәсе башка совет республикалары өчен гаять зур роль уйный.

*5 нче сентябрь.* В. И. Ленин башкорт хәрби частьларын Петроградны саклашырга җибәрү турында Башревкомга телеграмма суга. «Хәзер, Кызыл Армиянең Көнчыгыштагы хәлиткеч җиңүләре башкорт халкының ирекле үсешен тәэмин иткән бер вакытта, Республика Реввоенсоветының кайбер башкорт частьларын Петроградка җибәрү турындагы карары ифрат мөһим политик әһәмияткә ия» диелә бу телеграммада.

*26 нчы сентябрь.* 10 мең штыклы башкорт гаскәрләре Петроградка килә. Юденичны тар-мар иткәч, Петроград пролетариаты башкорт гаскәрләрен зур ихтирам белән озата. «Петроградская правда» газетасы: «Совет республикасының башкаласы өчен куркыныч вакытта башкорт гаскәрләренең шул кадәр сәләт, батырлык, ныклык күрсәтүе авыр хәлдән коткарып кына калмый, ә җиңелүне җиңүгә әйләндерде» дип яза. Петроград Советы башкорт гаскәрләренә истәлек итеп байрак тапшыра.

# Сәйфи Кудаш

## Яңа өй

**Өлгертергә бәйрәм көнгә чама белән,**
**Китерергә кунакларны чана белән —**
**Без җыелдык сызганышып күрше-күлән,**
**Өй салырга бер семьяга өмә белән.**

**Бәйрәм таңы ашыктырып, кысып килә,**
**Әйтерсең лә, бәхет кошы очып килә.**
**Каршыларга кирәк аны яңа өйдә,**
**Капкасына кызыл флаг элеп кенә!..**

**Октябрьда үзебез яулап алган җирдә**
**Таш нигезгә салынгач та тәүге иргә,**
**Без керештек бабайларның гадәтләрен**
**Җайлап кына үз шартына җиткерергә:**

**Дүрт почмакка салдык урак һәм чүкечле**
**Герб төшкән ун тиенлек дүрт көмешне.**
**Димәк, безнең нигез булсын нык, ырыслы[1],**
**Үзебезнең илебезнең нигезе төсле!..**

**Шул арада килеп җите май һәм икмәк,**
**Һич ярамый бу хөрмәтне үтү читләп!**
**Күбрәк кеше авыз итсен нигез маен,**
**Шунда мәгънә хуҗа өчен, шунда хикмәт!..**

**Бу икмәкне телсен каерып телгән кеше,**
**Майны яксын юмарт яга белгән кеше.**
**Димәк, өйдән туктамасын кунак-төшем,**
**Икмәк-тоздан өзелмәсен өстәл өсте!..**

**Эшне җайлап, нигез маен алгач майлап,**
**Бүрәнәләр койган сымак булып ятты.**
**Буш урында, ямьләндереп авыл очын,**
**Кич булганчы матур яңа бер өй артты.**

**Өрмәсен дип аркасыннан салкын җилләр,**
**Ниргәләрне калын итеп мүкләдек без,**
**Кермәсен дип бу семьяга ямьсезлекләр,**
**Йөрәкләрнең җылысы белән төпләдек без.**

**Яктыга бай булсын өчен өйнең эче,**
**Киң иттереп уйдык тәрәз урыннарын.**
**Зур бәхетләр кергән чакта сыйсын өчен,**
**Җәлләмәдек ишекләрнең зурлыкларын!**

**Күк читендә янган якты йолдыз төсле**
**Күзләрне һәм күңелләрне сокландырып,**

[1] **Ырыс — бәхет (ред.)**

Иң читтәге өйгә тормыш килеп керде,
Балкытылар тәрәзләрен, ут яндырып...

Октябрьда үзебез яулап алган җирдә
Таш нигезгә салып нык һәм котлы ниргә,
Күмәкләшеп үзебез төзегән яңа өйгә
Шатлык белән котлап бүген бәйрәм килә.

## Мостай Кәрим

### Ярлар кала

Бер пароход тети-тети
Агыйделдә дулкын яра.
Палубада
Түбәтәйле,
Чабаталы малай бара.

Малай бара. Кая бара
Капчык асып аркасына!
Белми әле кагылырын
Нинди язмыш капкасына.

Малай уйлый: «Ни гаҗәп бу,
Күзләремме шулай алдар!
Мин торамын. Ага таулар,
Ага ярлар, ага таллар».

Ул малай — мин. Еллар аша
Эндәшәмен: «Әй, дим, бала!
Без йөзәбез. Таулар кала,
Ярлар кала, таллар кала...»

Менә хәзер басып торам
Язмышымның корабында,
Чайкала ул тормыш-дәрья
Ярларының арасында.

Мин торамын. Дулкын үтә.
Үтә
Канат кага-кага.
Мин торамын. Көннәр ага,
Айлар ага, еллар ага.

Теге малай еллар аша:
«Әй, агай! дип сөрән сала.
Без йөзәбез. Көннәр кала.
Айлар кала, еллар кала...

Заман кала. Җавап бир син,
Көч китерми намусыңа:
Нинди бизәк, нинди куәт
Өстәдең син заманыңа!»

Йөрәгемдә шаңдау [1] тора:
Заманыңа... заманыңа...
Заманыңа...

[1] Шаңдау — кайтаваз.



*Композитор Заһир Исмәгыйлов*

*25 нче июль.* Эстәрлетамакта (ул вакытлыча башкала иде) Советларның I Башкортстан съезды ачыла. Съезд республиканың иң югары даими дәүләт органы булган Башкортстан Халык Комиссарлары Советын сайлый.

*1921 нче ел*

*Декабрь.* В. И. Ленин Советларның IX Бөтен Россия съездына килгән бер төркем Башкортстан делегатын кабул итә. Владимир Ильич алардан ачыгучыларга ничек ярдәм итүләрен, киләсе елга чәчүгә ничек әзерләнүләрен сораштыра. Съездан соң Совет хөкүмәте Башкортстанга 4 миллион пот икмәк һәм акча бирә.

*1922 нче ел*

*14 нче июнь.* Бөтен Россия Үзәк Башкарма комитеты Уфа губернасын Башкортстанга кушуны декрет белән раслый. Бу документ нигезендә Башкортстанның башкаласы Эстәрлетамактан Уфага күчерелә.

*1923 нче ел*

*Башкортстанга* СССР Үзәк Башкарма Комитеты председателе М. И. Калинин килә. Ул Уфа, Белорет, Иглин, Сермәндә була, эшче, крестьяннар белән очраша. Советларның IV Бөтен Башкортстан съездында СССРның эчке һәм тышкы хәлләре турында доклад сөйли.

*1924 нче ел*

*7 нче ноябрь.* Уфа каласы үзәгендәге Ильич скверына (элекке базар урынында яшьләр ясаган ял итү бакчасына) В. И. Ленин һәйкәле куела.

*1925 нче ел*

*27 нче март.* Советларның V Бөтен Башкортстан съезды Башкортстан Автономияле Совет Социалистик республикасының (Беренче) конституциясен раслый.

*1927 нче ел*

*Партия* Үзәк Комитеты Башкортстан өлкә комитетының отчетын тыңлый. Үзәк Комитет секретаре житәкчелегендәге махсус комиссия Белорет заводларын Урал трестларыннан аерып, Башкортстанны индустрияләштерү ихтыяжларын канәгатьләндерүгә тапшыра.

*1928 нче ел*

*Республиканың* эре һәм кустарь промышленносте сугышка кадәрге (1913 нче ел) күләмгә житә. Ә авыл хужалыгы шул ук дәрәжәгә якынлаша. Республикада 35 совхоз, 27 коммуна, 268 авыл хужалыгы артеле, 804 бергәләп жир эшкәртү жәмгыяте була. Тракторлар саны 399 га житә.

*1929 нче ел*

*Республикада* Жылаер, «Кызыл Башкортстан» һәм Аргаяш совхозлары төзелә. Июнь—октябрь айларында гына да колхозларның саны 683 тән 1789 га житә, көзгә крестьян хужалыкларының 70 проценты потребитель кооперативына әгъза булып керә.

# Нажар Нәжми

## Үземнеке...

«Кеше тәне ят йөрәкне кире кага»
(Газеталардан)

**Табигатьнең бөек камиллеге!**
**Искитмәле синең биеклек.**
**Кеше туа — гадәти бер нәрсә,—**
**Туу үзе нинди бөеклек!**
**Кеше туа үз йөрәге белән,—**
**Бу мәңгелек гади төшенчә,—**
**Үз йөрәге белән үлә кеше —**
**Табигатьчә, димәк, кешечә.**
**Ә тормышта табигатьчәме соң!**
**Кешечәме безнең кылганнар!**
**Үзләрен бит арыслан дип тоя**
**Куян йөрәк белән туганнар.**
**Буш йөрәген әдип йөрәгенә**
**Алыштырып юкка, тиктәскә,**
**Үзен генә түгел, кешеләрне**
**Интектерә күпме иптәшләр.**
**Мин белмимен, тормышыма фида**
**Кыла алдым микән жанымны!..**
**Тик ят йөрәк түгел, үземнеке**
**Алып китсен минем тәнемне.**

# Гайнан Әмири

## Карт имән

**Әйтерсең ул тора күкне тотып,**
**Иңбашлары белән калкытып;**
**Сыны горур, утлы карашлары —**
**Яфраклары балкый ялт итеп.**

**Дөнья булгач, бары дуслар гына**
**Алмагандыр урап аны да:**
**Имән тәнен суеп үткән бик еш**
**Дошманнарның үчле угы да.**

**Тик**
**Көрләнең аңа буе житми,**
**Һәм тешләре үтми укларның;**
**Давылуга да аның исе китми —**
**Якын йөретми ул чүп-чарны.**

**Бакчачы карт очрый:**
**«Беләсеңме**
**Ничәнче яшь аңа тулганын!»**
**Үзе жавап бирә:**
**«Әле Уфа**
**Жирдә юк чагында туган ул».**

Бу хәбәрдән китте чымырдап тән:
Җир тетрәтеп, шаулап-тасырдап,
Үткән шушы имән каршысыннан
Өер-өер еллар, гасырлар.

Яшәү шатлыгыннан кинәнә ул,
Гел яшь калуыннан кинәнә;
Бетми торган җиңү тантанасы —
Ул мәңгелек бәйрәм имәнгә!

## Зәйнәп Биишева

### Кешечә

Әйтмимен, иркә булдым, дип,
Яшәдем, дип, ваемсыз,
Ватанымның мәхәббәте
Булды, диеп, талымсыз.

Мактанмыймын, илем һәр чак
Сыйпады, дип, аркамнан,
Алдымда гел кояш булды,
Ай торды, дип, артымда.

Кирәгенчә сөйде илем,
Кирәгенчә өйрәтте.
Хәтта кайчак гаделсезлек,
Тигезсезлек йөдәтте.

Булды чатнама суыклар,
Кояшлы язлар булды.
Күңел кай чак шатлык белән,
Кай чак зар белән тулды.

Кай чак нәфрәттән бузарып,
Ал каным ургып акты.
Кай чак йөрәгем сөюдән
Янар ут булып какты.

Кешегә хас булды барысы.
Кешечә янды йөрәк.
Кешечә әрнеп, куанып,
Хезмәттә талды беләк.

Кешечә ашкынып очты
Җиһанга тынмас җаным.
Авырда җиргә таянып,
Яшәүнең тойдым ямен.

Кешегә хас горур, кыю,
Саф булды минем йөрәк.
Ят булды
Ярап яшәүне,
Җиңелне сөйгән теләк.

Кешечә бәхетле булдым,
Яндым, көйдем кешечә.
Туган илне, газиз җирне
Ярсып сөйдем кешечә.

Кешечә булды барысы,
Кешечә булды фәкать,
Канәгать, сабырлы килсен
Безнең дә соңгы сәгать.

*1930 нчы ел*

*5—11 нче июнь.* Партиянең XVI өлкә конференциясе беренче биш еллыкның ике елына йомгак ясый, калган өч елына үсеш перспективалары билгели. Конференция республикада аеруча кара һәм төсле металлар эшкәртергә, Ишембай тирәсендә нефть эзләүне җәелдерергә карар итә.

*1931 нче ел*

*Уфа* моторлар төзү заводын салу. Белорет һәм Тирлән заводларын реконструкцияләү эше башлана. Уфада ТЭЦ, Белоретта корыч-тимерчыбык аркан заводы эшкә керешә.

*1932 нче ел*

*Ишембайда* нефть чыгару эше башлана. 16 нчы майда 702 нче скважинадан нефть фонтаны бәрә. Черниковкада (хәзер Уфа шәһәренең Орджоникидзе районы) 1 май исемендәге шырпы фабрикасы сафка баса. Республикада марганец рудасы эшкәртү башлана.

*1933 нче ел*

*25 нче март.* Башкортстан колхоз ударникларының I съезды ачыла. Анда 400 делегат катнаша. Алар үзләренең чыгышларында колхоз төзүдәге уңышлары хакында сөйлиләр. Ә эшче делегацияләре колхоз ударниклары алдында үзләренең хезмәте турында рапорт бирәләр.

*1934 нче ел*

*15 нче март.* Башкортстан язучыларының I съезды ачыла. Съездга Мәскәү, Татарстан, Үзбәкстан, Казахстан, Чувашстан һәм башка туганлаш республика язучылары делегациясе килә. Афзал Таһиров житәкчелегендә Башкортстан язучылары союзы идарәсе сайлана.

*1935 нче ел*

*3 нче январь.* Культура сараенда (хәзерге Башкорт опера һәм балет театры бинасында) Советларның IX Бөтен Башкортстан съезды ачыла.

Съезд Уфа электр станциясенең куәтен 10 мең киловаттка житкерү, мотор төзү заводының ТЭЦын, Магнитогорск — Белорет электр тапшыру линиясен булдыру, нефть эзләү эшләрен җәелдерү, Уфада нефть куу заводы төзү турында карар чыгара.

*15 нче март.* Авыл хуҗалыгы һәм промышленность өлкәсендәге уңышлары өчен СССР Үзәк Башкарма Комитеты Башкорстанны Ленин ордены белән бүләкли.

*1936—37 нче еллар*

*Туймазада* тагы да нефть мәйданы табыла, Уфа — Ишембай нефть үткәргече, Ишембай нефть куу, Уфа крекинг заводлары төзелеп бетә.

*23 нче июнь.* Уфада Советларның гадәттән тыш X Бөтен Башкортстан съезды Башкортстан Автономияле Совет Социалистик республикасының Конституциясен раслый.

*1938 нче ел*

*16 нчы март.* ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Халык Комиссарлары Советы «Яңа нефть районнарын үстерү турында» карар чыгарып, бу документ нигезендә «Башнефть»кә ярдәм итү мәсьәләсе карала.

*1939 нчы ел*

*8 нче июнь.* Республика Верховный Советының Башкорстанның 20 еллыгына багышланган юбилей сессиясе ачыла. Сессиягә Татарстан, Казахстан, Үзбәкстан, Кыргызстан һәм башка тугандаш республика делегацияләре катнаша.

*1940 нчы ел*

*Республиканың* нефть промыселлары 1452 тонна нефть бирә. Авыл хуҗалыгында 124 МТС булып, алар чәчү мәйданының 88 процентында эшлиләр.

*Чапаев* дивизиясе Уфаны азат итәр өчен Агыйделне чыккан урында (Кызыл Яр авылында) В. И. Чапаев белән М. В. Фрунзе музее ачыла.

## Хәниф Кәрим

### Ташта эзләр калган...

Уфа урамыннан
Тукай белән
Бер чак атлап үткән Гафури.
Шул турыда минем йөрәгемдә
Күптән әйтелмәгән җыр йөри.

Ул чакта да Идел ярдан арткан,
Шомырт чәчкә койган, яз булган.
Әмма җәрәхәтле йөрәкләргә
Шифа, дәвалары аз булган.

Ничек булсын инде,
язмышында
Бәхет кошы оя кормагач!
Язлар гына дәва булмыйдыр ул,
Тормыш үзе яздан тормагач...

Уфа урамыннан
Тукай белән
Бер чак атлап үткән Гафури.
Ташта эзләр калган...
һәм бу хакта
Һаман әле тере җыр йөри.

Тик син ярсып, эзләп ул эзләрне
Йөгермәкче ерак урамга;
Нигә ерак урам...
йөрәгемдә
Шушы эзләр күптән булганда?..

## Гыйлемдар Рамазанов

### Революция дәвам итә

Кайберәүләр Октябрьга
Ерак тарих итеп карай,
Революция беткән, диләр,
Алынгач та Кышкы Сарай.

Мин тумас борын әтием
Ирек яулап яуга китә,
Димәк, бу — минем язмышта
Революция дәвам итә.

Тукмап аклар, яшелләрне,
Кызыл яучы якташларым
Куды илдән Зәкиләрен,
Дутовларын, Колчакларын.

Урал кыяларын ярып,
Яшен булып Блюхер үтә...

Чапаевның кылычында
Революция дәвам итә.

Тиде бер чак җир һәм бәхет
Үзебезнең өлешкә дә.
Эшлә генә! Эш җитәрлек
Уракка да, чүкечкә дә.

Сука түгел, тимер сабан
Иске ызаннарны тетә,
Бу — минем туган авылда
Революция дәвам итә.

Тыныч түгел тыныч көн дә,
Тынгылык төшкә дә керми,
Иске һәм яңа тартыша
Адым саен аяу белми.

Бүген дә бит алгы сызык
Меридианнар аша үтә,
Вьетнам яланнарында
Революция дәвам итә.

Октябрь ул — тарих түгел,
Ул һаман да дәвам итә,
Синнән, миннән батырлыкны,
Уяулыкны таләп итә.

## Шәриф Биккол

## Безнең як

*Җыр*

Таң калдыргыч безнең якның
Тугайлары, кырлары,
һәр якташның шат йөзендә
Балкый бәхет нурлары.
  Хезмәтне ихлас сөйгәнгә
  Эшләребез ал да гөл,
  Кырмыскалы, Кырмыскалы,
  Ярышларда алда гел.
Яу батыры Шаймөратов —
Безнең якның бөркете.
Үлмәс данны ил халкының
Йөрәгенә беркетте.
  Безнең якның җире юмарт,
  Кеше хезмәт яратса,
  Алтын Йолдыз тактырды ул
  Алтын куллы Банатка.
Безнең якта әзерләнә
Сыйларның иң шәпләре.
Ил табынын шатландыра
Карлыманның шикәре.
  Хезмәтне ихлас сөйгәнгә
  Эшләребез ал да гөл,
  Кырмыскалы, Кырмыскалы,
  Ярышларда алда гел.

*1941 нче ел*

*22 нче июнь.* Фашистик Германия илебезгә басып кергәч, сугышның беренче өч көнендә генә дә Уфа хәрби комиссариатына үзләрен фронтка җибәрүләрен сорап 1270 кеше гариза бирә. Сугышның беренче атнасында республиканың 10 меңгә якын коммунисты Кызыл Армия сафына баса. Соңрак ВКП(б)ның Башкортстан өлкә комитеты, Верховный Совет Президиумы һәм Халык Комиссарлары Советы Дәүләт Оборона Комитетына аерым башкорт гаскәри частьларын төзүне сорап мөрәҗәгать итә. Дәүләт Оборона Комитеты, бу үтенечне канәгатьләндереп, 112 нче һәм 113 нче башкорт атлы дивизияләре төзергә рөхсәт бирә.

*8 нче август.* Тау җиһазлары заводы эшчеләре ай саен бер көнлек хезмәт хакын оборона фондына бирергә карар итәләр. Тиздән алар үрнәгенә бөтен Башкортстан кушыла, ә бик күп предприятие эшчеләре ике көнлек хезмәт хакын бирергә булалар. Ел азагына бу фондка республика хезмәт ияләреннән 34 миллион сум акча керә. Шул елны Башкортстан фронтка 50 мең ат, 10 мең арба, чана, 10 мең автомашина һәм трактор бирә, хөкүмәткә 56,2 миллион пот иген тапшыра.

*1942 нче ел*

*Республика* колхозлары игенне үткән елга караганда 76 000 гектарга күбрәк чәчә. Моннан тыш 11 300 «оборона гектары» чәчелә. Башкортстанның промышленносте 1940 нчы ел белән чагыштырганда 2,5 тапкырдан күбрәк продукция бирә, ә паровоз ремонтлау заводы Дәүләт Оборона Комитетының күчмә Кызыл Байрагын ала.

*10 нчы февраль.* Язучы Сәгыйт Агиш, чәчән Сәет Исмәгыйлов, рәссам Галия Имашева һәм башкалардан торган делегация Башкортстан хезмәт ияләре җыйган ике эшелон бүләкне берсен 112 нче башкорт атлы дивизиясенә илтү өчен аерым поезд белән фронтка китә.

*23 нче февраль.* Великие Луки янындагы Чернушки авылы өчен

сугышканда Башкортстан комсомолы Александр Матросов дошман дзоты амбразурасын күкрәге белән каплый. Александр Матросовка, тиңдәшсез батырлыгы өчен, үлгәннән соң, Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

*1944 нче ел*

*23 нче март.* Башкортстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 25 ел тулу уңае белән республика хезмәт ияләре «БАССРның 25 еллыгы» исемле самолет эскадрильясы өчен 80 миллион сум акча җыялар.

*25 нче сентябрь.* Туймазада 100 нче скважина девон катламыннан нефть бирә башлый. Аның нефте Туймаза промыселының калган барлык скважиналарыныкыннан күбрәк була.

Елның беренче яртысында гына да Башкортстан предприятиеләренә 19 тапкыр Дәүләт Оборона Комитетының күчмә Кызыл Байрагы бирелә.

*1945 нче ел*

*16 нчы башкорт* гвардия дивизиясе Көнчыгыш Померания һәм Берлин сугышларына катнаша. Хәрби батырлыклары өчен дивизия Ленин, Кызыл Байрак, Икенче дәрәҗә Суворов һәм Икенче дәрәҗә Кутузов орденнары белән бүләкләнә. Дивизиянең 74 командиры һәм солдатына Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Сугыш башында Башкортстанда төзелгән 186 нчы укчы дивизия Суворов һәм Кутузов орденлы Брест дивизиясенә әверелә. Шушы елда Башкортстан егете Муса Гәрәевкә ике тапкыр Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

*1946 нчы ел*

*Октябрьский* поселогы шәһәргә әйләнә. Туймаза — Уфа нефть үткәрү трассасы төзелә башлый.

*1947 нче ел*

«Ишембайнефть»нең икенче промыселы Бөтен Союз ярышында икенче урынны ала. Яңа Уфа нефть эшкәртү заводы төзелә башлый. Башкортстанның иген уңышы сугышка

## Муса Гали

●

**Мин тауларга китсәм,**
**югалтмагыз,**
**Мин адашмам анда, адашмам.**
**Таулар йөзенә баксам, мин**
**халыкның**
**Нәкъ күзенә карап аңлашам.**
**Чал түбәләр сузып көй көйләсә,**
**Мин заманнар белән сөйләшәм.**
**Кыя таштан ак болытка күчеп,**
**Дөнья гизеп кайтам —**
**теләсәм.**

**Янымдагы һәрбер ташка сеңеп,**
**Кан-яшь аккан монда елгалап.**
**Ил күгенә килгән утлы кылыч**
**Түбәләрне үткән тамгалап.**
**Шул тауларга охшый сыман халкым,**
**Тарих та бар анда, хыял да.**
**Шуңа ярсып тауларыма китәм,**
**Уйларыма канат куям да.**
**Мин таулардан алдым күкрәгемә**
**Яу-ярларда туган ялкынны.**
**Биекләргә күтәрелгән саен,**
**Бөеклеген тоям халкымның.**
**«Тауларым! — дип сәрән салам**
**ихлас,—**
**Ташларыңа гамьсез һич басмам...»**
**Чакыра киңлек, томан,**
**ят сукмаклар,**
**Мин адашмам анда, адашмам.**

## Йосыф Гәрәй

### Ленин янында

**Уфа бакчасында,**
**Гөлләр арасында,**
**Утыра Ленин — бөек узаман [1],**
**Гүя үтеп барган чакта гына**
**Ял итәргә кергән урамнан.**

**Уйга чумган, бер ноктага текәп**
**Киләчәкне күрер күзләрен.**
**Белсәң иде нәрсә уйлаганын,**
**Күрсәң иде ниләр күргәнен...**

**Моңнарымны яки шатлыгымны**
**Алып киләм аның алдына.**
**Бик бәхетле итеп тоям шуңа**
**Мин үземне аның янында.**

[1] Узаман — хөрмәткә лаек акыл иясе.

Якын барып, уйны уртаклашам,
Сүзем тыңлап тора бирелеп.
Киткән чакта:
— Сау бул, Ата! — дисәм,
Кулын бирер сыман үрелеп.

## Кәтибә Кинҗәбулатова

### Чәй

Бакчасында читләрнең
Үскән чәйләре түгел.
Күршендә читләрнең
Кипкән чәйләре түгел.

Чын чынаяк чыңлатып,
Матур бизәк уйнатып,
Ак самовар кайнатып,
Радиолар җырлатып,
Яшел хәтфә келәмдә
Чәйләр эчеп утырам,
Эчкән саен йөрәктә
Илем җылысын тоям.

Башкортларым эчсен дип,
Кавказ үстергән икән,
Хуш исләрен түкми-чәчми
Безгә җиткергән икән.

Ничек өзгәннәр икән
Берәм-берәм яфрагын.
Әллә тәргәннәр микән
Кушып бергә ал таңын.

Әй чәйләрем, чәйләрем,
Телне йотарлык кына.
Пәһлевандай көч җыйдым,
Тәмләп утырып кына.

Арка терәр өем бар,
Тәмләп эчәр чәем бар.
Әй, илемә мең рәхмәт,
Таулы-сулы җирем бар.

## Рәми Гарипов

### Өйгә кайтканда

Һава шундый яхшы!
Ява яз кояшы!
Тышка чыксаң,
күзнең явын ала,
Өйгә керсәң,
күзең тышта кала...



*Уфа шәһәре. Яңа район.*

кадәрге дәрәҗәсенә җитә. 800 колхозчы орден һәм медальләр белән бүләкләнә.

*1948 нче ел*

*20 нче март.* Партиянең XXI Башкортстан өлкә конференциясе ачыла. Конференция сугыштан соңгы (1946—1950) бишьеллыкның барышын тикшерә.

*1949 нчы ел*

*СССР* Министрлар Советы «Башкортстан АССРында промышленностьны үстерү чаралары» дигән карар чыгара. Карар нигезендә Каридел елгасына (Павловка) электр станциясе төзү, Уфадагы 2 нче ТЭЦны зурайту, Туймазадагы ТЭСны эшләтә башлау кебек чаралар карала.

*1950 нче ел*

«Ишембайнефть» тресты планнан тыш 5066 тонна нефть бирә. Республикада нефть чыгару 1945 нче ел белән чагыштырганда 4,2 тапкырга арта. Промышленностьның тулай продукциясе 1940 нчы ел белән чагыштырганда 173 процентка җитә. Авыл хуҗалыгында сыер малы 1013 мең башка җитә (1945 нче елда ул 745 мең була).

*1951 нче ел*

*Башкортстан* хезмәт ияләре «Стахановча хезмәт коллективы» дигән исем өчен ярыш башлап җибәрәләр.

Тиздән бу хәрәкәткә Уфа предприятиеләрендә 39, Черниковкада 24 цех кушыла. Бу мактаулы исемне Туймаза нефть промыселының 1 нче бораулау тресты, Ишембай нефть промыселының төзелеш-монтаж конторасы яулап ала. Май аенда производство новаторларының гомум шәһәр җыелышы булып, анда социалистик ярыш барышына йомгак ясала.

*1952 нче ел*

*Коммунистлар* партиясенең XIX съезды директивасы нигезендә Башкортстанда машина төзү, төсле металл җитештерүне тагы да үстерү, нефть чыгаруны 3 тапкырга, иген игүне 40—50 процентка арттыру күздә тотыла.

*1953 нче ел*

*Магнитогорск — Сибай* тимер юлы төзелеп бетә. Магнитогорск — Сибай электр үткәрү линиясе эшли башлый. Шкапово нефть мәйданындагы 1 нче скважина мастеры Л. Г. Игнатьев шунда ук ташкүмер катламы да таба.

*1954 нче ел*

*100 дән артык* алдынгы коммунист район партия оешмасы секретаре, 500 коммунист МТС зоналарына инструктор итеп җибәрелә. Шушы елның язында авыл хуҗалыгында 1926 белгеч эшләгән булса, көзгә шәһәрдән тагы 3500 белгеч килә.

*1955 нче ел*

Яна *Уфа* нефть эшкәртү заводының яңадан 19 корылмасы һәм хуҗалык майлары эшләп чыгаручы, илдә иң зур технологик линиясе төзелеп бетә. Шкапово нефть мәйданында 23 скважина эшләп, шуларның 15 е нефть бирә башлый. «Октябрьскнефть» промыселында 20 скважина фонтан ысулы белән нефть чыгара. Моңардан тыш «Аксаковнефть» идарәсе төзелә. «Ишембайнефть», «Октябрьскнефть» идарәләре еллык планны срогыннан алда үтиләр. Нефть чыгару буенча Башкортстан Союзда беренче урынны ала.

**Чут-чут сайрап тамчы тама,**
**һәр тамчыда кояш яна!**
**Чылтыр-чылтыр килә кар суы,**
**Чү, уяна йөрәк ярсуы...**
**Күгәрченнәр...**
**Хәтта алар да**
**Яз иркенә буйсыналар.**
**Ни өчендер,**
**карлы суларда**
**Дулап-дулап коеналар.**
**Салкын кар-бураннар**
**аякларын**
**Кызарткан да кышның буена,**
**язып-җыеп алар**
**канатларын,**
**Хәзер шулай язга коена...**
**Хәтта бөтен халык алдында**
**Үбешәләр, язып акылдан!..**
**Ә җиде ят төрле кешеләр —**
**Гүя шул чак тату күршеләр!**
**Юлдан, төяп кирпеч,**
**шофер җилә,**
**шофер ашыга.**
**Тик бу хәлне күргәч,**
**көлә-көлә**
**туктый каршыга.**
**Бик ашыгыч булса да**
**аның эшләре,**
**Китми тора ул һаман,**
**балкып тешләре...**
**Белмәсәм дә аның исемен,**
**Белеп торам аның хисен мин:**
**Уртак — хисебез,**
**Уртак — көчебез.**
**Ул, син, мин — өчебез**
**Шушы яз өчен без!..**
**Нинди матур килә яз!**
**Килсен шулай гел аяз!**
**Эшлә, кешем!**
**Сөй**
**Көй!**
**Җыр яз!**
**Моң-сагыш та булсын бераз...**
**Әмма канга коенмасын өчен**
**Бу кешелек вәхши ауларда,**
**коен әйдә,**
**коен күгәрчен,**
**Дулап-дулап язгы суларда!..**

## Якуп Колмый

## Кирәк миңа тынычлык

**Телимен мин:**
**һәр яз утыртылган**
**Агачларның яфрак яруын,**

**Зәңгәр күктән җиргә җылы биреп,**
**Яз кояшы балкып торуын —**
**Шуңа кирәк миңа тынычлык!**

**Телимен мин:**
**Галәм киңлегендә**
**Ракеталар очып йөрүен,**
**Җир улының Зөһрә — Ай кызына**
**Бүләк итеп яулык бирүен —**
**Шуңа кирәк миңа тынычлык!**

**Телимен мин:**
**Туган җирдә тагын**
**Девон фонтаннары атуын,**
**Агыйделдән куәт алып, күбрәк**
**Ильич лампалары балкуын —**
**Шуңа кирәк миңа тынычлык.**

**Телимен мин:**
**Кеше гомере мәңге**
**Киселмәвен кургаш пулядан,**
**Танк түгел, тракторлар гөрләп,**
**Гел узуын чирәм үреннән —**
**Шуңа кирәк миңа тынычлык!**

**Телимен мин:**
**Көткән Бөек көннең**
**Балкыганын туган җиремдә,**
**Бар халыктай коммунизм йортын**
**Тизрәк төзисем килә минем дә —**
**Шуңа кирәк миңа тынычлык!**

## Абдулхак Игебаев

### Авылдашым

**Авылдашым, туган туфракларга**
**Олы юлдан урап кайтмадың.**
**Җилләр ничә кабат тәрәз какты,**
**Ә син кайтып тәрәз какмадың.**

**Зәңгәр күлнең зифа камышлары**
**Сыгылышып сине көттеләр.**
**Язын кошлар сине сагынып килеп,**
**Көзен тагы кире киттеләр.**

**Якташларың һич тә онытмыйлар:**
**Син — каһарман, син бит — ил күрке.**
**Канатларың белән ут сүндергән,**
**Ватаның син кыю беркете!**

*Май-июнь* айларында Мәскәүдә Башкорт әдәбияты һәм сәнгате декадасы була. Анда республикадан 800 кеше катнаша. Башкорт дәүләт академия драма театры артисты Арслан Мөбарәковка, опера һәм балет театры солисткасы Зәйтүнә Насретдиновага СССРның халык артисты дигән югары исем бирелә.

*1956 нчы ел*

*КПСС Үзәк* Комитеты һәм СССР Министрлар Советы Башкортстан хезмәт ияләрен дәүләткә иген сатуны срогыннан алда үтәүләре белән котлый. Республикада 2792 кеше СССР ордены һәм медальләре белән бүләкләнә. 7 кешегә Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелә.

*1957 нче ел*

*9 нчы июнь.* Башкортстанның Рус дәүләтенә үз иреге белән кушылуына 400 ел тулу көне тантана ителә.

*Республиканың* промышленность продукциясе 1913 нче ел белән чагыштырганда 129 тапкырга үсә. Башкортстан нефтьне патша Россиясенә караганда ике тапкыр күбрәк чыгара башлый. Республикада инде 13 шәһәр һәм шәһәр тибындагы 30 поселок була.

*1958 нче ел*

*Май аенда* Партия Үзәк Комитетының пленумы булып, анда химия һәм синтетик материалар эшләп чыгаруны үстерү мәсьәләсе карала. Яңа химия предприятиеләрен төзү өчен Башкортстанга 7 миллиард сум акча бүленә.

1950—1958 нче еллар эчендә промышленностьның тулай продукциясе 3,3 тапкырга арта.

*1959 нчы ел*

*Башкортстан* комсомол оешмасы химия объектлары төзүне шефка алып, Уфа, Эстәрлетамак, Салават төзелешләренә урта мәктәпне тәмамлаган 1750 комсомолны җибәрә.

*Уфада* Дәүләт телевидениесе үзәге эшли башлый.



*Якутов исемендәге паркта. Һәлак булган сугышчыларга һәйкәл.*

*1960 нчы ел*

*9 нчы январь.* Дәһли каласында уткәрелгән халыкара күргәзмәгә килгән Башкорт халык биюләре ансамбле йомгаклау концерты күрсәтә. Аны Һиндстанның Премьер-министры Неру, хөкүмәт министрлары, чит ил кунаклары да карый.

*«Туймазыбурнефть»* тресты Брюссельдә уткәрелгән Бөтен дөнья күргәзмәсендә электр һәм труба борауларының яңа үрнәкләрен күрсәтеп, алтын һәм көмеш медаль ала.

*1961 нче ел*

*«Туймазынефть»* трестының I нче бораулау конторасы мастеры Д. Михайлов бригадасы бораулау тизлеге буенча Бөтен Союз рекорды куя.

*1962 нче ел*

*Уфа* синтетик спирт, Эстәрлетамак синтетик каучук заводлары, Салават нефть-химия комбинаты продукция бирә башлый.

*1963 нче ел*

*Колхозларны* эреләндерү эше дәвам иттерелә. 1959 нчы елдагы 1138 уры-

## Равил Бикбаев

**Заман! Бирче пульсыңны.**
**Нинди ярсып суга тамырың.**
**Ә маңгаең кызу. Үзең һаман**
**Асфальт юллар буйлап ашыгасың,**
**Маңгаеңнан тирең тамызып.**

**Җил, гасырым, ак күбекле атым.**
**Яшәү — җилсәң генә күңелле.**
**Тик шунысы:**
**Атом тузаны тамагыңа утырып,**
**Йөткерәсең түгелме!**

**Заман әйтте:**
**— Юк, мин йөткермимен.**
**Тик һәр мәлне уяу карагыз.**
**Сез — замана балалары, диләр,**
**Юк, мин үзем — сезнең балагыз.**

**Бар язмышым — сезнең кулыгызда.**
**Хафаланып гасыр хакында,**
**Онытмагыз минут турында:**
**Бер минутта туа ялкыннар.**
**Гасырларны гасырларга бәйли**
**Бер минут.**
**Гасырларны юк итәргә мөмкин**
**Бер минут!**

**Заман! Бирче пульсыңны.**
**Шатмын тамырың ярсып типкәндә.**
**Ышанамын сиңа:**
**Күкрәгеңдә**
**Безнең йөрәк тибә икән лә.**

## Әсхәл Әхмәтхуҗин

### Һыбай[1] чыксам...

**Һыбай чыксам юлга,**
**ут йөрәгем**
**Тып-тып килә, нәкъ ат тоягы.**
**Мин үземне, аргымакны узып,**
**Алдан чапкан төсле тоямын.**

**Күңелләрем күккә күтәрелә,**
**Йәйгор[2] буйлап гүя җиләмен.**
**Әйтерсең, мин дуслар белән түгел,**
**Уйлар белән ярышып киләмен.**

---

[1] Һыбай — атка атланып.
[2] Йәйгор — Салават күпере.

Җил-давыллар алларыма баса,
Колагымда — дәвер шаулавы;
Минем җырым — ирлек турысында,
Бу тормыштан урын даулавым.

Нинди тау улы мин,
куркыр булсам,
Төпсез упкын, текә кыядан!
Кирәкме соң?!
Уктай атылам да
Очып үтәм шушы уядан [1].

Бик кирәксә — тап мин, атлы башкорт,
Йолдызларга тарих сөйлимен,
Кыя ташка басып, илгә карап,
Халкым рухын җырлап-көйлимен.

Я булмаса акбуз толпарымда
Уралымны җилеп урыймын,
Урыймын да көмеш кураемны
Баһадирлар көенә уйныймын.

Уйныймын мин, ничек Касым-түрә
Таш Парижны хәтта куркыткан,
Батыршалар, Салаватлар ничек
Сәмруг кошның йонын борхыткан;

Ничек Шаһибәрәк, Буранбайның
Кулларына богау эленгән,
Ничек Шаһит, Баһау... каршысында
Ак тәхетнең башы иелгән.

Уйныймын мин, ничек Күсимовлар
Калкан булган илем сагында...
Күрсен дөнья, белсен, белеп торсын
Атлы башкорт даны хакында!

## Рәшит Назаров

●

Мин батыр да түгел, җаным,
Мин тик гашыйк батырлыкка.
Мин матур да түгел, бәгырем,
Мин тик гашыйк матурлыкка.
Мин тапкыр да түгел, иркәм,
Мин тик гашыйк тапкырлыкка...
Ләкин миңа бер елмайсаң,
Бер дәшсәң, бер күз салсаң,
Миңа күчә —
тапкырлык та,
матурлык та,
батырлык та...

---

[1] Уя — тирән яр.

ныңа 599 колхоз кала. Колхоз һәм совхоз партия оешмаларында парткомнар оештырыла. Авыл хуҗалыгында эшләүче коммунистларның саны 46 500 гә җитә. Күп колхоз һәм совхоз җитәкчеләре итеп югары белемле белгечләр сайлана.

*1964 нче ел*

*Бохара—Урал* газ үткәргечен салышкан «Нефтепроводмонтаж» тресты Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә. Республикада 45 предприятие, 630 цех, 5 мең бригада «Коммунистик хезмәт коллективы» исеме яулап ала.

*Свердловск* шәһәрендә үткәрелгән «Социалистик Урал» күргәзмәсенә Башкортстаннан 26 рәссам катнаша. Күбесенең рәсеме Мәскәүдә булачак «Совет Россиясе» күргәзмәсенә тәкъдим ителә.

*1965 нче ел*

*Республика* шәһәрләрендә 4,2 миллион квадрат метр, авылларында 140 мең яңа торак йорты салына. 300 мең укучылык яңа мәктәпләр өстәлә.

*1966 нчы ел*

*6 нчы январь.* «Башнефть» һәм «Туймазынефть» бораулаучыларының 17 кешесе орден һәм медаль белән бүләкләнә. «Башнефтезаводстрой» трестының 4 кешесенә «РСФСРның атказанган төзүчесе» дигән исем бирелә.

*2 нче июль.* Эстәрлетамак каласының 200 еллыгын билгеләп үтәләр.

*25 нче сентябрь.* Хөкүмәткә иген сату планын арттырып үтәп, Башкортстан илгә 103 миллион 500 мең пот иген бирә.

*21 нче октябрь.* «Советская Башкирия» газетасы чыга башлауга 60 ел. Ул беренче рус революциясе дәверендә (1906) «Уфимский рабочий» исемендә чыга башлаган. Соңыннан «Вперед» (1917—1918), «Большевик» (1919), «Власть труда» (1920—1922), «Красная Башкирия» исемнәрендә чыгып, республикада социализм һәм коммунизм төзү эшенә актив ярдәм итә.

## Сәгыйт Агиш

# АЙЛЫ КИЧ

хикәя

— Авыл Советы председателе волостька хәлфә урынына мөгаллимә алырга киткән ди. Быелдан башлап балаларны хәлфә укытмый, мөгаллимә укытачак ди.

— Мөгаллимә дигәне хатын кеше ди, хатын гына да түгел, кыз кеше ди. Кәлчер авылына да бер мөгаллимә китергәннәр. Карап торуга башка кызлардан бер аермасы да юк. Тик күлмәге өзек: өске ягы ак ситсадан, аскы ягы кара ситсадан тегелгән. Аягындагы итегенең кунычы гына, җитмәсә — ярык, чишелеп китмәс өчен кара бау белән бәйләп куелган ди.

Бу хәбәр бөтен авылга таралды. Ышанмас идең, аны Совет председателе Арслан агайның хатыны Сәлимә, коега су алырга барган чакта, Гайшәгә сөйләгән. Ә Гайшә, өйләренә дә кайтып җитмичә, чиләкләрен урамда калдырган да Ногман хатыны Сакау Мәфтухага сөйләгән. Сакау Мәфтухага бер хәбәр генә булсын, ул аны булыр-булмас теле белән бөтен авылга таратып чыга.

Шуңа күрә кичен күп кенә кеше, Арслан агай кайтыр чакны чамалап, аның өе тирәсенә җыелды, әйтерсең, авылга кадерле кунак килеп төшә.

Кояш баерга дилбегә буе калгач, Арслан агайның башын ташлап юртып килгән кашка аты күренде. Күрмәгән кашка ат түгел, бөтен күзләр — тарантаста. Тарантасның түренә Арслан агай бер хатын кеше белән янәшә утырган. Кашка атның, авылга килеп кердеме, юртуын шәбәйтә торган гадәте бар. Кемдер капканы шар ачып куйды. Тиргә баткан кашка ат капкадан юртып кереп китте.

Ат туктауга, Арслан агай уң якка, теге мөгаллимә дигән кыз сул якка төште. Чынлап та, аягына биек күтәрмәле, баулы нәрсә кигән. Безнең авыл туфрагына беренче баскан ботинка шушы инде. Аңа кадәр безнең авылда ботинка юк иде, хәтта мулла абзыйның хатыннары да читек, галош кына кияләр иде. Башка хатыннарда — итек тә ката.

Тарантастан зур гына чемодан алдылар, аны Арслан агай үзе алып бирде. Мөгаллимәне Сәлимә үзе җитәкләп өйгә алып кереп китте.

Мөгаллимә дигәне ачык кына кыз икән, шул арада бөтен халык белән елмаеп исәнләшеп алды.

— Ай, нинди матул! — дип куйды теге Сакау Мәфтуха.

— Сәлимәне көнләштереп тә куяр әле,— дип салды берәү.

Кыюрак хатыннар өйгә үк керделәр. Яшь киленнәр, кызлар ишек алдында мескен генә булып калдылар. Мөгаллимә, өйгә кергәч тә, шәлен, өстенә кигән кыска пинжәген чишеп, чөйгә элде. Башында яулыгы юк, озын кара чәч толымнары билдән түбән төшеп тора. Каш-

ларының күзләренең шомырт кара икәненә бөтен кеше игътибар итте. Бер дә ятсынмый, бөтен кешегә дә туры карый. Авылга беренче төшкән киленнәр кебек, керфекләре дә күзләрен каплап бармый, елмайганда ап-ак тешләре ялт итеп кала. Сүзне ул:

— Утырыгыз, утырышыгыз! — дип үзе башлады. Хәтта сәке янындагы эскәмияне үзе иркенгәрәк чыгарып куйды.

— Минем исемем Хәдичә була,— диде ул.

— Мөгаллимә дигән булалар бит әле, кайсы кеше һич юкны сөйли инде,— дип куйды бер җиңгә.

— Хәдичәсе дә дөрес, мөгаллимәсе дә дөрес,— дип куйды Хәдичә.

Дөнья күргәнрәк бер хатын:

— Арслан агайны да Арслан дип тә әйтәләр, председатель дип тә әйтәләр, шуның кебек инде,— дип куйды.

— Мөхәммәтҗанны да Мөхәммәтҗан дип тә, секретарь дип тә йөртәләр, шуның кебектер инде,— диде икенче хатын.

— Укыган кешенең исеме бераү генә булмас инде,— дип куйды өченчесе.

Ул арада ишек алдындагы эшләрен бетереп, Арслан агай да килеп керде. Ул яңа килгән укытучы белән өйдәгеләрне тулырак таныштырды.

— Безнең волостька биш укытучы җибәргәннәр. Шуның берсен, менә Хәдичә Бакаеваны, безнең авылга тәгаенләделәр. Ул элекке хәлфә шикелле сәдакага, хәергә укытмаячак. Аңа хөкүмәттән жалунья чыгачак. Жалунья дигәне акча дигән сүз була. Сез дә, балаларыгызны укыткан өчен, бер кемгә дә, бер тиен дә түләмәячәксез. Потомушты декретта шулай әйтелгән. Декретны без белмибез инде. Сез түгел, ирләрнең дә барысы да төшенеп җитми әле. Бара-бара төшенерсез әле. Без үзебез дә элек бик күп нәрсәләрне төшенми идек. Ораторлар өйрәтте. Хәзер менә үзебез оратор булып киттек. Минем нәрсә сөйләгәннәр аңлашыламы, хатыннар?

— Аңламаска тагын, хатыннар дигәч тә, без дә башкорт ла,— дип куйды теге дөнья күргән хатын һәм:— Шушы ирләр бөтен нәрсәне үзебез генә беләбез дип йөриләр,— дип өстәде.

Өйгә кергән хатыннар озак кына тордылар, тик арадан бераү:

— Арып килгәннәрдер, чәй эчеп алсыннар. Монда барыбызга да урын да, чынаяк та җитмәс, — дигәч, теләр-теләмәс кенә тарала башладылар. Өйдән чыкканнарны тыштагылар түземсезлек белән көтәләр иде. Алар әнәсеннән-җебенә кадәр дигәндәй сораша башладылар. Кайсы яктан икәнен дә, күлмәгенең, күзенең нинди икәнен дә калдырмадылар. Бала-чага бик озак Арслан өе янында кит ә алмый торды. Киткәндә дә артларына — үзләрен көзгә укыта башлаячак укытучы кереп урнашкан өйгә борылып карый-карый киттеләр. «Нинди икән ул? Усал микән, элек малайларны укыта торган хәлфә сыман, тал чыбыгы белән суга, маңгаеңны күптергәнче чиртә, сабагыңны белмәсәң, борчакка тезләндереп куя микән? Нинди икән?»

Арслан өендә бик озак ут сүнмәде. Балалар яткач та, Арслан, Сәлимә, Хәдичә, самоварны кабаттан яңартып, озак итеп сөйләшә-сөйләшә чәй эчтеләр. Хәдичә өйгә килеп төшкән гади кунак кына түгел, ул бик күпкә, кем белә, бәлки мәңгегә килгәндер. Бәлки ул шушы авылда картаер. Аның озын кара чәч толымнары шушы авылда кыскарыр, шушы авылда агарыр.

Арслан өчен дә гади кич түгел иде бу. Ул граждannar сугышында шушы авыллар яхшырсын, шушы авылның мәңге нужа белән яшәгән кешеләре рәхәт яшәсен дип сугышып йөрде. Авылга кайткач, башка ярлылар, фронттан кайткан башка солдатлар белән совет төзеделәр. Җирләрне, тугайларны тигез итеп, җан башыннан бүлделәр. Җан

башыннан түгел дип әйтүчеләр дә булды. Алай эшләмәделәр, ни өчен дисән, дөрес булмаячак иде. «Син күпне күргән, шуның өстенә гадел кеше» дип, председатель итеп сайлап куйдылар. Менә хәзер мәктәп тә ачып җибәрәчәкләр. Анда да эш борынгыча түгел. Яңа тәртип белән алып барылачак. Кемдер әйтмешли, машина белән укытачаклар! Әле генә аның ишеге алдында чыр-чу килеп йөргән бала-чагаларның барысы да хатларны да, хатларны гына түгел, адресларны да үзләре язып җибәрә торган кешеләр булачак. Ә бит Николай заманында өч кенә кеше хат, тик бер генә кеше, ягъни писарь гына, адрес яза торган иде. Әле дә бик аз алар, алары да үзалларына өйрәнеп кенә язалар. Олыларны да укыта башлаячаклар, волостьта шулай диделәр. Бу эш тә шул ук Хәдичәгә, шушы Арслан өендәге кечкенә табында бер елмаеп, бер моңаебрак утырган Хәдичәгә тапшырылачак. Арсланның үзенә дә укырга туры киләчәк. Аның да белем ягы бик чамалы, чамалы гына түгел, волостьта эшләгәннәрнеке белән чагыштырып караганда бөтенләй юкныкы! Ул да чатай-ботай итеп хат яза ала да конверт тышына адрес яза белә. Адресны да тик үз авылларыныкын гына яза. Башка өяздәге кешеләрнең адресын яза белми ул. Протокол, карар, расписка-лар язарга бөтенләй кулы бармый. Газетага язылганнарның да барсын да төшенеп бетә алмый, күбесен секретарь Мөхәммәтҗан төшендереп бирә. Газеталарда бөтенләй теленне ватарлык авыр сүзләр килеп чыга. Кем белә, аңа да кулына каләм-кәгазь тотып, Хәдичә алдына утырырга туры килер.

Чәй эчкәндә дә, йокларга яткач та, Арслан әнә шуларны уйлады.

Сәлимәнең башына да моңарчы һич килмәгән уйлар килде. Аның да шушы өйгә килен булып төшүенә, бармак белән санасаң, ун ел була. Ул чит авылдан, Соран буеннан, төшкән кыз. Беренче кичтә, шушы Арсланның куенына беренче тапкыр килеп кергәнче, аның кем икәнен дә белми иде ул. Тик үзләренең авылларына сабан туена килеп көрәшеп йөргәнендә генә күреп калган иде. Аннан аңа кияүгә чыгарга ризамы, юкмы икәнен дә сорап тормадылар. Хәер, бөтен ил белән шулай, берәүдән дә сорап тормыйлар иде шул ул вакытта. Шулай да йола саклап, метрикага язар өчен ике кеше килеп, ишек аша гына: «Арслангәрәй Солтангәрәй улына кияүгә чыгарга ризасыңмы?» дип сорадылар. Сәлимә алдан җиңгәләре өйрәтеп куйганча: «Әтием биргән җиргә риза», дигән сүзне көч-хәл белән генә әйтте. Тегеләр ул сүзне ишеткәннәрме-юкмы, алдан өйрәтеп куелганча, муллага шул сүзләрне кабатладылар.

Ата-бабалардан килгән бөтен йолаларны, гореф-гадәтләрне бер тамчы да үзгәртмичә, Сәлимәне дә шулай өйгә килен итеп төшерделәр. Ул да сылу иде. Үзенең сылулыгын ул елгада да, көзгедә дә күргәне, үзенең ахирәтләреннән дә ишеткәне бар иде. Җиңгәләре дә: «Бигрәк сылусың, кем бәхетенә үсәсең икән?» дигән сүзне бик еш әйтәләр иде. Шушы Арслангәрәй бәхетенә үскән икән. Сәлимәнең бәхетенә Арслангәрәй дә начар кияү булмады. Каенанасы бик вак сүзле булып, Сәлимә турында һич колакка ятмаган чүбек чәйнәүгә карамастан, тырнак белән дә чиртмәде, акаеп та карамады. Ике балалары — әнә теге йоклап яткан Сәхибгәрәй белән Вәлимә тугач, герман сугышы башланды. Арслан беренче көнне үк солдатка китте. Гомергә күзендә яшь күрсәтмәс Арслангәрәй Сәлимәне лапас артына алып чыгып, үксеп-үксеп, йөрәк яргыч итеп елады. Өйдән чыккан чакта әнисе янына килеп:

— Зинһар, килененне какма, рәнҗетмә, ул бахыр, чит кеше баласы булса да, үз балаңның кәләше бит. Шул явыз герман патшасы булмаса, мин аны гомердә ташлап китмәс идем,— диде.

Кайчакта таш та эри икән: сүз юк, каенанасына улының бу сүзләре тәэсир итми калмады. Элеккегә караганда күп тапкыр йомшак булды.

Шул китүдән Арслан биш ел сугышта булды. Бернична тапкыр: «җәрәхәтләнеп госпитальдә ятам» дип тә, «үзебезнең патшага каршы сугышабыз», «большевикка язылдым» дип тә хаты килде. Сәлимә һәрбер капка, ишек шыгырдауны: «Арслангәрәем кайтып килмиме икән?» дип, түземсезлек белән көтте. Ирләрен сагынып чыгарган әллә никадәр бәетләр ятлап алды. Аулакта шулар белән моңланды. Үз кулы белән Арслангәрәенә кош теледәй бер хат та яза алмады, чөнки грамотасы юк иде. Авылдагы бөтен кеше Әзкәй дигән берәүдән генә яздыра иде. Үз кулын язу белмәгәч, кешегә әйтеп кенә ни яздырасың инде. Күңелең уйлаган бөтен нәрсәне чит кешегә әйтеп бирергә тел дә барып бетми бит әле.

Менә патша төшеп, революция чыккач, Арслан элеккедән дә матураеп, күкрәгенә дә, фуражкасына да йолдызлар тагып, кулына мылтык тотып кайтып төште. Кулы да бар, аягы да бар. Теле тагын да шәбәйгән: «значит»ларны чатнатып кына тора.

Арслан кайтып бер көн узуга, үткәндәге бөтен җәфалар, авыр көннәр онытылды. Тормыш өр-яңа, элеккедән дә матур юлга төште дә китте. Дөрес, кыенлыклар бөтенләй бетеп җитмәде, ләкин якын кешең белән бергәләп күтәргәч, һәр нәрсә җиңел була икән ул. Бигрәк тә балаларның аталарын килеп кочаклауларын, аталарының балаларының әле башларыннан сыйпап, әле аркаларыннан сөеп җибәрүләрен карап тору үзе бер гомер иде.

...Тик кинәт бер куркыныч уй килеп төште. Сәлимә, нишләптер, бер минутта Хәдичәнең матур кара күзләреннән куркып та китте. «Арсланымны тартып алып куймагае?» дип куйды ул.

Ә Хәдичәнең уйлары бөтенләй башка иде.

Менә ул аңа ят, ләкин йөрәккә җылы бирә торган өйдә. Әнисе, туганнары читтә калдылар. Белергә иде, хәзер алар нишләп утыралар икән? Бәлки алар да шулай, Хәдичәне телгә ала-ала чәй эчәләрдер, яки йоклый алмыйча йөдәп ята торганнардыр. Бәлки әнисе «Чүлмәк әни» дигән әкиятен йөзенче тапкыр сөйлидер.

Озакламый Хәдичә килгән бу авылда да мәктәп ишеге ачылачак. Илдәге башка бик күп мәктәпләргә беренче булып барып кергән укытучылар сыман, Хәдичә дә барып керәчәк. Аның каршысына моңарчы һич таныш булмаган балалар килеп утырачак. Аларның бик әйбәтләре, шулай ук начарлары да булыр. Курста чакта педагогика укытучысы Харрас абый шулай дигән иде бит. Ничек дигән иде әле? «Сезнең алда кесәл ярлары эченнән сөт елгасы гына агып торачак түгел», дигән иде. «Кесәл»нең нәрсә икәнен берәү дә белмәде. Харрас абыйга аңлатып бирергә туры килде. Кесәл — бай кешеләр генә ашый торган җимеш боткасы икән ләбаса!

— Ярый, кунак та арыгандыр, йоклыйк инде,— диде Арслан.

Хәдичәгә сәкенең уң ягыннан, өйдәге иң йомшак, иң җылы дип исәпләнгән нәрсәләрдән урын җәйделәр. Мич кучкарында пыскып кына янган өчле лампаны Арслан үзе сүндерде. Хәдичә дә акрын гына барып, үзенә билгеләнгән урынга ятты. «Лампаны өреп сүндерсәгез дә, мине өреп сүндерә алмассыз!» дигән сыман, өйгә тәрәзәдән ай нурлары килеп капланды. Айны Хәдичә ничәмә тапкыр күргәндер, ләкин бу авылдагы ай нурларына да коенырга теләгәндәй, акрын гына тәрәзә төбенә килеп утырды. Өйләрдә утлар сүнгән иде инде. Эреле-ваклы өйләр күбә кебек кенә булып күренә. Ерактан акрын гына уйнаган гармун моңы җәелде, ул җайлап кына Арслан өенә таба килә. Акрын гына тавыш белән, гармунга кушылып, егетләр җырлый. Хәдичәгә таныш, бик таныш көйгә җырлыйлар.

Бүген бер төрле дә бәйрәм-фәлән түгел. Яңа килгән мөгаллимә кыз Хәдичәнең йөрәген үз сәнгатьләре белән сокландырырга булганнардыр.

Бу — аларның Хәдичәгә булган бүләкләре, бүгенге тел белән әйтсәк, ул килүгә багышланган концертлары иде. Алар кыз кешенең ут сүнгәч тә йоклап китмәячәген акыллары, уйлары белән генә түгел, йөрәкләре, күңелләре белән сизгәннәр. Ай, шаян егетләр! Хәдичәнең кашлары кара икәнлеген дә белеп торганнар. Юри, мәктәп тормышына бәйләбрәк, аның кашларын китаптагы «Х», «Б» хәрефләренә охшатып җырлыйлар.

Кашың кара «Хи» кебек,
Әлептәге[1] «Би» кебек.
Җырламыйбыз чит итеп,
Без җырлыйбыз тиң күреп.

Бу җырларның баштагы ике юлын Хәдичә яхшы белә, аны аларның авылында да җырлыйлар, ә соңгы юлын егетләр үзләре әле генә чыгарганнар. Әле бик шомарып та җитмәгән бу җыр бик ошады Хәдичәгә.

Арслан да, Сәлимә дә йокламаган икән. Арслан бер тапкыр урамга чыгып: «Кунакка йокы мазасы бирмисез», дип әрләп алмакчы иде дә, начар уй белән җырламаганнарын тоеп, ул уеннан тыелды.

Сәлимә бая, Арслан белән Хәдичә арасында нинди дә булса якынаю булмаса иде дип, шикләнеп куйган иде бит. Бу егетләрнең тавышын ишеткәч, тынычланып китте һәм эчтән генә: «Шундый егетләр барда, ике балалы Арсланга исе китмәс әле», дип уйлады.

Хәдичәне бөтен авыл яхшы каршылады.

## Вәзих Исхаков

# ӘТИЕМ УТЫРТКАН ӨЯНКЕ

хикәя

### I

Шулай инде ул: һәркемнең сере, һәрнәрсәнең үзенчә бер тарихы була торгандыр. Мөгаен, шулайдыр. Әнә безнең өянке дә... Ындыр артында — елга буенда үсеп утырган бер өянке минем өчен кадерле бер истәлек ул. Әтием истәлеге!..

### II

Ул көнне һич оныта алмыйм. Җәй урталары иде. Төннең иң кыска мәле. Без тезелешеп сәкедә йоклап ятабыз. Таң сарысы беленер-беленмәс кемдер иплэп кенә тәрәзә шакыды. Әнием, безне уятмаска теләптер инде, тавыш-тынсыз гына торды да, аяк очлары белән генә басып, тәрәзәгә барды. Өй тәбәнәк, бәләкәй булгангамы, чак кына кыштырдау да җитә кала. Без дә шакмаклы юрган астыннан бер-бер артлы башларыбызны калкыттык. Ә бит башка вакытта әнием безне уята алмый иза чигә иде. «Гафләт йокысы баскандыр инде, юкса бу кадәр ятмас идегез!» дип ачулана торган иде. Бу юлы уяндык. Беркем берсүз әйтмәсә дә уяндык! Әнием тәрәзәгә капланды.

— Кем бар?

---

[1] Әлепбидәге гарәпчә «Х» һәм «Б» хәрефләре сыман, дигән мәгънәдә. Бу ике хәреф тә сызылып киткән кашка охшап тора. *(Автор искәрмәсе.)*

Аның тавышы йомшак һәм бик акрын чыкты. Тыштагы кеше:

— Танымыйсыңмыни? Бу мин...— дип җавап бирде. Аның сүзләрен без чак-чак кына ишеттек. Без, нидер сизенеп, кош балалары сыман авызларыбызны ачып, күзләребезне тырный-тырный урыннарыбыздан кузгалыша, баш очына салып яткан күлмәкләребезне, чалбарларыбызны капшана, эзли башладык. Әниебез исә, ни диярга дә белмичә, баскан җирендә катып калган иде.

— Ач инде, я!..— диде тыштан килгән тавыш. Ул бераз таләпчән тоелса да, әгыйфь ишетелде. Шулай да әниемнең каушавы хәттән ашкан иде. Ахырда:

— Ай аллакаем, менә тагын! — дип һушына килгәндәй булды. Ул шунда гына, безнең дә торуыбызны күреп, ят бер тавыш белән кычкырып елап җибәрде.

— Балакайларым, әтиегез кайтты бит!..

Әтине без әнә шулай каршыладык.

## III

Бөтен ил купкан, афәтле һәм халык зур кайгы-хәсрәт кичергән Бөек Ватан сугышы еллары иде бу.

Әтиемне сугышка ничек озатуыбызны, ул киткәндә әниемнең түгелеп елап калуларын сөйләп тормыйм. Чыны шул: ул вакытта мин, унөч яшьлек малай, бик шат идем. Әйе, әтием фронтка китә, анда фашистларның кирәген биреп, герой булып кайтыр әле дип горурлана, куана гына идем. Алай гынамы! Әниемә кушылып елаган бәләкәй энемә ачуым килеп, аның аркасына бер-икене тондырып та алган идем. Нәрсә син балавыз сыгып торасың, янәсе. Җитмәсә әнә, дәү әтием дә, сиксән алты яшьлек башы белән, туктаусыз борын тартып, әледән-әле күз яшьләрен сөртеп ала. Ул тамырлары бүртеп чыккан һәм сөякләре калкып калган зур кулларын әтиемнең кулбашына салган да бер өзлексез диярлек пышылдый да пышылдый:

— Карт көнемдә... бар икән күрәсекәйләрем. Менә бу сабыйлар хакына исән-имин урап кайтырга язсын инде...

Урамда чыр-чу, тавыш. Дугалардагы җиз кыңгыраулар чыңлавына тальян моңы, җыр, үксеп-үксеп елау тавышлары кушыла. Ал яулыклар, ак алъяпкычлар, кызыл тасмалар. Кара шәлләр, әбиләрнең укалы яшел камзуллары, яшь җиңгәләрнең чуар күлмәкләре — һәммәсе бергә буталып, бергә кушылган иде ул көнне.

Бер безнең авылдан гына да сугышка әллә никадәр кеше китте. Ләкин миңа бигрәк тә әтием белән бергә алынган Гыйльметдин, Солтан абыйлар якынрак иде. Ерак юлга чыккан бу кешеләргә кул болгап, күзләребез талганчы карап озатып калдык.

Әтием китүгә ярты ел үттеме-юкмы, мин дә бу елау-сыкрануларның мәгънәсенә төшенә башладым. Күптән түгел генә кәләш алган күршебез Гыйльметдин абыйның үлгән хәбәре килде. Ул, Ерак Көнчыгыштан кайткач, авылда нибары бер ел яшәде. Арьякның иң сылу кызы Нәфисә апаны килен итеп төшергәч, аның әнисе безне тәмле кәнфитләр белән сыйлаган иде. Хәер, Гыйльметдин абый үзе дә юмарт кеше иде. Тегеләй вакыт армиядән кайтканында да, Амур күчтәнәче дип, күпме прәннек өләшкән иде ул. Ә миңа исә, күрше дигән булып, шлемын киеп, каешын буып карарга да биргән иде. Чик буенда сак торуын, анда күргәннәрен сөйләп, безне авызына карата иде. Хәзер әнә шул кешене юк диләр... Ышанасы килми. Ничек юк булсын ди ул?.. Гыйфриттәй таза Солтан абый да югалган икән... Сабан туйларында аңа чыгар батыр булмый торган иде. Ике потлы гер ташын сыңар кулы белән һавага очыра торган иде ул.

Әнә нинди кешеләр иде алар!..

Этием белән киткәннәрнең әле берсе, әле икенчесе турында менә шундый шомлы хәбәрләр безне дә шөбһәгә салды. Кәкре муенлы почтальон агайны күрү белән йөрәк каты тибә башлый, ирексездән эчтә нидер җу итеп киткәндәй була иде.

Шуннан — менә безнең эти кайтты...

## IV

Ни хикмәт, ни булган бу этиебезгә? Мин күзләремә ышана алмый торам — безнең этиме соң бу? Арслан кебек таза ир иде бит ул! Типсә тимер өзәрлек, сукса тартә сындырырлык куәтле кеше иде. Әле аягына да басып торырлык хәле юк. Тәнендә чыкмаган җаны гына...

— Каһәр генә суксын инде бу сугышны!..— диде ул әниемә. Соңыннан безгә барысын да сөйләп бирде. Алар атна буе чолганышта калганнар. Ашау ягы беткән, салкын кыш... Өстәвенә — яра. Этиемә салкын тия. Сугыш яланыннан этиемне күтәреп алып чыгалар. Шуннан госпиталь... Тик инде соң була, чир өстенлек алып өлгерә. Этиемне вакытлыча кайтарып җибәрәләр.

Бер ай ятты этием...

Килмәгән врач, чакырмаган кешебез калмады. Күз йомып булса да, әби-чәбиенә дә әйтә идек. Этине генә терелтсеннәр... Әмма ул аягына баса алмады. Аның хәле көннән-көн авырая гына барды. Этием инде, күрәсең, үз хәлен үзе аңлый иде. Бер ноктага төбәлгән килеш озак кына эндәшми ята да, бөтен күңеле белән пошынып, көрсенеп куя.

— Тегендә калганнар бәхетлеләр, сугыш кырында, ичмасам...

Әнием аны юатырга тырыша:

— Терелерсең әле, этисе, терелгәч, син дә барырсың. Хәзер немесне куа башладылар...

Этиемнең сүзне озайтырга хәле юк иде.

— Юк инде, Гакифә,— ди дә күзләрен йома.

Сизеп торам, әнием дә тыныч түгел. Ул, безгә белдермәскә теләп, йомыш тапкан булып, бәләкәй якка кереп китә. Озак кына учак-казан тирәсендә була. Теге вакытта үксеп-үксеп еласа да, хәзер ул безгә үзенең йомшаклыгын күрсәтмәскә тырыша.

Сугыш заманы, ил язмышы әниемне кырысландырып җибәрде. Ул да күзгә күренеп ябыкты. Аның бәләкәй генә гәүдәсе тагын да кечерәеп киткәндәй булды. Тик ул эһ тә итми иде хәзер. Этиемә көн буена җитәрлек итеп иртүк аш-фәлән әзерләп куя да көн озын басуда була. Ә без өйдә катык, бәрәңге ашыйбыз...

Этием янында булу безгә, бигрәк тә миңа, тапшырылган иде. Ул, хәле авыр булса да, ыңгырашмаска тырыша. Ара-тирә генә берәр сүз әйтеп куя иде. Энем белән сугышып-нитеп китсәк, ымлап мине чакырып ала да бармагын селкегән була. Әрләми. Тик кенә утырырга куша. Кайсы чакта барыбызга да эндәшеп, чәчләребездән сыйпап ала. Күрәсең, этиемнең бик тә безне иркәлисе килгәндер инде.

Бер көнне ул:

— Безнең өянке ничек, улым, үсәме? — диде.

Менә ничәнче тапкыр инде этием миннән шул өянке турында сораша. Бу юлы миңа уңайсыз булып китте. Этиемнең сүзләренә колак салмыйм түгелме соң?! Нигә әле мин аңа күптән җавап бирмим икән? Ул өянкене без этием белән икәүләп сугыш башланыр алдыннан гына утырткан идек. «Безнең өйдә һәркемнең үз өянкесе бар, монысы синеке булыр, улым,— дигән иде этием ул чакта.— Син бит баш бала...»

— Үсә, эти, үсә! — дигән булдым мин, ашыгып. Нигәдер тыным кысылгандай булды.

— Һәй, шуны бер генә барып карыйсы иде...

Ләкин этием аны күрә алмады.

V

Еллар бер-бер артлы үтеп торды. Иртә, бик иртә ирләр булдык без. Авыр туфрагың җиңел булсын инде, эти! Вакытсыз киттең син, яшьли киттең. Ләкин моңа син гаепле түгел. Юк, түгел!.. Әнә син калдырган, син утырткан өянкегә карыйм да сине уйлыйм. Кем белә, бәлки башкаларның да үз каены, үз миләше, сирене яки тирәге бардыр. Ә син миңа сыгылып торган яшь өянке калдырдың. Ул инде үсте, ныгыды. Мин аңа карап кына торам. Ул бит — синең төсең.

Туган йортыма аяк бастым исә, шул өянкене күрәсем килә, шуның ягына ашыгам. Аны кочаклаган, үземчә иркәләгән булам. Ул, яфракларын кыштырдатып, шыбыр-шыбыр нидер сөйләгәндәй итә. Ә мин тыңлыйм. Әтиемнең тавышын ишеткәндәй булам. Аны һәм аның белән киткәннәрне сагынам.

Нинди яшь иде бит алар! Әле дөбердәтеп яшәр, җимереп эшләр чаклары иде. Хәзер инде мин алардан өлкәнрәк булып барам. Мин сине узып киттем инде, әти.

Сугыш әнә күпме гомерне өзде. Беләм, син дә шуның бер корбаны булдың. Син дә әле ир уртасы гына кеше идең. Балаларыңны сөеп туймас вакытың иде.

Агачлар елый белми, диләр. Дөрес түгел. Кайсы чакта, бөрчү көннәрдә, өянкебезнең тавышсыз гына күз яшьләрен тамызып утырганын күргәнем бар: «Тып-тып... Тып-тып...» Аңа да әллә шул елларның сагышы йогып калдымы икән?

И-их!.. Әтиләр утырткан өянкеләр елап утырмасын икән ул! Балалар ятим, хатыннар тол калмасын икән!..

## Ногман Мусин

# НӨГЕШ БУЙКАЙЛАРЫ БӨДРӘ ЧАУКА[1]...

хикәя

I

Мәгъфүрә әби өйдә ялгызы гына каңгырап йөри. Бүтән көннәрне алар бу вакытта инде тамак туйдырып, йокларга ята торганнар иде. Ләкин карты кичә, авылны аклар басып алыр алдыннан гына, кызылларга олауга китте. Ә төпчек кызлары Рәшидә җиңгәсе белән иртә таңнан Нөгеш буена качып киттеләр. Авыл берничә тапкыр кулдан-кулга күчкәнлектән, белеп бетергәннәр: аклар, бигрәк тә офицерлары, чибәр хатыннарны, кыз-кыркынны бер дә аяп тормыйлар. Әнә үткән юлы үз авылларыннан Сәлмән байның акларда йөргән һадие дә Мәгъфүрә әбиләрнең өенә килеп, Рәшидәгә бәйләнеп аптыратты. Шуңа күрә Мәгъфүрә әби бүген кызын таң белеү белән үзе уятты.

[1] Чаука — яшь каенлык. (*Ред.*)

— Нөгеш буендагы, әтиең дегет кайнаткан базны беләсең бит. Бу мөртәтләрне күз яздырып тору хәерле, үзебезнекеләр килгәнче, җиңгәң белән шунда яшеренеп торыгыз,— дип киңәш бирде.

Менә хәзер ул ни ятарга, ни утырырга белми йөри. Самавырын кайнаткан иде дә — тамагына аш үтмәде.

— И илаһым, бу боламалар кайчан басыла инде? — дип көрсенде дә, яргаланып беткән учын какча битенә терәп, уйга чумды... Карты хәзер кайда икән? Кире кайтканда акларга тап булмаса ярар иде инде. Олы юлдан йөрмәм, Үркәч сырты аша борынгы арба юлыннан кайтырмын дип киткән иде дә бит, юл эшен каян беләсең...

Мәгъфүрә әби бизәкләре уңган күлмәгенең итәге белән күз яшьләрен сөртеп алды да күмере сүнеп беткәнлектән өзек-өзек кенә ыңгырашып утырган самавырын бушатып кагар өчен урыныннан торды. Тик шул вакыт капка шыгырдап ачылганын ишетеп, тәрәзәгә йөгереп килде. Караңгы ныклап төшеп килүгә карамастан, ул чолан ишеге ягына үткәннәрнең берсен шундук таныды: Сәлмән байның улы Һади иде бу. Мәгъфүрә әби: «И ходаем, тагы даниләр генә сөйләп, башымны каңгыртыр икән инде!» дип, көяләнеп торган арада чандыр гәүдәле Һади, башын ия биреп, ишектән килеп тә керде.

— Саумы, Мәгъфүрә әби? Имин генә тордыгызмы?

Һадиның шулай бик ачык эндәшүе Мәгъфүрә әбинең күңеленә бераз җылы төшерде, шуңа күрә ихлас кына:

— Әйдүк, түрдән уз, Һади улым, караңгы булса да,— дигән булды.— Ут алырга кәрәчин юк шул.

Һади урындыкка килеп утырды. Яулык очы белән авызын каплап торган Мәгъфүрә әби, күз бәйләнгән чак булса да, аның өй эчен сөзеп карап чыгуын абайлап алды: «Әллә берәр кешене яшереп торалар дип курка инде». Ирьегет бер котын алганнан соң, Һадиның ялгыз йөрергә шүрләвен, әле дә солдатлар алып килеп, аларны капка төбендә калдырып керүен Мәгъфүрә әби белми иде.

— Нигә безнең әти карттан барып алмыйсыз соң кәрәчинне? — диде Һади.— Болай караңгыда интегеп утырганчы.

Мәгъфүрә әби аның бу сүзенә ни дип җавап бирергә дә белмәде.

— Әллә инде, заманы да ут алып эш эшли торган булмагач...

Сөйләшүне ничек ялгап алып китәргә кыймагандай, бераз сүзсез утыргач, Һади сорап куйды:

— Бабаем кая китте соң?

Мәгъфүрә әби бу сорауны баядан бирле көтеп тора иде, җавабын да әзерләп куйган иде инде:

— Сорама инде, Һади улым. Кеше сүзен тыңлый торган адәмме! Болама заманда йөрмә, дидем. Саткан тана өчен Әүҗәндәге белешемнән алачак акча бар иде, шунда барып кайтам дип, чыкты да китте. Исән-аман гына йөреп кайтса ярар иде инде, ходаем.

Үзе шушы сүзләрне сөйләгәндә Һадиның авыз чите белән генә көлеп утыруын күрмәде Мәгъфүрә әби. Сөйләвеннән туктап, менә хәзер аның Рәшидә турында сораша башлавын көтте, аңа җавап бирергә әзерләнде. Һади чынлап та озак көттермәде:

— Әллә Рәшидәне дә үзе белән бергә алып киттеме?

Өйгә бераз якты төшсен дип учакка утын яндырып маташкан Мәгъфүрә әби башын күтәрми генә җавап бирде:

— Рәшидә кичә иртүк Тирмән-Таштагы апаларына киткән ие, шуннан әйләнеп кайтмаган әле.

Мәгъфүрә әби көчәнеп утка өрде. Ут капыл дөрләп китеп, өй эченә саран яктылык сибелде. Шушы яктылыкта Һадиның мыскыллы елмаеп

утыруын күргәч, Мәгъфүрә әбинең йөрәге бөреште, өнсез калып, аның тагы ни әйтерен көтте. Һади урынынан торды, чандыр гәүдәсен төз тотып, ишек катына барып әйләнде, аннары ялтыр итек кигән аякларын аерып, әбинең алдына ук килеп басты.

— Мәгъфүрә әби,— диде ул бөтенләй ят, калын тавыш белән,— син мине маңка малайга, я йолкыш Ирьегеткә исәплисеңме әллә?

— Юк, нигә алай исәплим,— дигән булды кинәт коелып төшкән Мәгъфүрә әби.

Һади басып торган урыннан һаман кузгалмады.

— Ярый, күп сөйләнмә син, әби. Картыңның кызылларга олаучы булып киткәнен беләбез. Син миңа Рәшидәнең кая киткәнен әйт.

— Алай димәле, Һади улым. Ул ни...— Мәгъфүрә әбинең сүзе яртысында өзелде.

— Рәшидәңне кая яшергәнеңне әйт! — дип җикерде Һади.

Әби нишләсен, ык-мык итте дә сүзсез калды. Аның үз серен түгел, кеше серен дә чишмәвен, бер карыштымы, чыгымчы ат кебек булуын Һади белә иде. Белми ни — карты белән гомер буе аларда ялланып эшләп йөрделәр лә. Шуңа күрә ул әбинең җаен икенче төрлерәк тартып карамакчы булды:

— Мәгъфүрә әби, синең белән сөйләшүе кыен инде,— диде ул, тавышын йомшатып. Шуннан баягы урынына барып утырды.— Ильяс бабаем өйдә булса, аның белән ирләрчә сөйләшеп, тиз үк килешер идек тә бит... Син шуны аңла, Мәгъфүрә әби: кызылларны бөтенләйгә дөмектердек инде. Алар монда кабат әйләнеп килмәячәк. Кукраеп йөргән йолкыш Ирьегет тә хәзер курае-ние белән гүрдә ята. Рәшидәне миннән яшерүдән ни файда? Шуны да онытма: кызыллар белән киткән Ильяс бабай да авылга әйләнеп кайтмый булмас, ә кайткач — күз күрер...

Ни әйтсен инде Мәгъфүрә әби — аның сүзләрен тыңлап, аңгы-миңге уйга бирелеп утырды-утырды да яшьләнгән күзләрен яулык очы белән сөртергә тотынды. Һади торды.

— Менә шулай, Мәгъфүрә әби. Мин иртә якта тагын кереп чыгармын, уйлый тор,— дип, ишеккә таба атлады.

## 2

Зур тау итәгендәге уйсу җир. Анда-санда учаклар төти. Кайсы бер кызылармеецлар шул учаклар тирәсендә кайнаша, икенче берәүләре, кичә аклар белән Нөгеш буенда булган каты сугыштан, төн буе чигенүдән арганлыктан, инде саргая башлаган иген өстенә ятып черем итә. Ерак китеп бармасыннар өчен, тезгеннәре аякларына бәйләнгән иярле атлар да шунда ук күшәп йөри иде.

Берәү читтәгерәк түмгәк өстенә утырган да, ияген учларына терәп, уйга баткан. Киң кулбашлары гимнастеркасына сыеша алмый тора. Аның ниндидер бер мөһим эшне хәл итә алмавын җыерылган киң кашларыннан да, кысыграк күзләренең гел бер ноктага текәлеп торуыннан да күреп була иде. Шушы полкның эскадрон командиры Ирьегет иде бу. Кичәге бәрелештә арсландай сугышу, төнге чигенү никадәр йончытмасын, аңарда ял итү кайгысы юк. Авылда торып калган Рәшидәсе хәзер ни хәлдә икән? Акларның авылны басып алган гаскәре белән бергә, мөгаен, Һади да бардыр. Рәшидәсе, үткән юлы авылны басып алгач, Һадиның үзенә бәйләнеп аптыратканын сөйләп зар елаган иде. Ярый ла ул чакны аклар авылны бер көннән артык тота алмадылар. Кызыл атлылар икенче көнне үк авылга бәреп керделәр. Ирьегет бер кулына ялангач кылычын, икенче кулына наганын тотып, көтелмә-

гән һөҗүмнән котлары очкан, юньләп киенмичә дә чыгып качучы ак гвардиячеләргә ата-ата, иң алдан җилеп барды. Ул акларның командирлары Сәлмән бай өендә булуына шикләнми иде. Атлыларына:

— Минем арттан! — диде дә шунда ташланды. Алар барып җитмәс борын Сәлмән бай капкасыннан берничә җайдак атылып чыкты да авылның теге очына чабып киттеләр.

— Их, өлгереп булмады! — дип ачынды Ирьегет.

Ә Сәлмән байның капкасы төбенә килеп җиткәч, күлмәк-ыштаннан гына көенчә берәүнең баскычтан сарай башына ашыгып менеп барганын күреп калды.

— Тукта, атам!

Ләкин теге кеше туктамады, сарай кыегы эченә кереп югалды. Ирьегет ачык капкадан җилдереп керде дә, наганын әзер тотып, тегенең артыннан үрмәләп менеп китте.

— Кем син? Төш монда! — дип кычкырды ул. Котын алу өчен бер атып та җибәрде.

Тавыш-тын бирүче булмагач, саклык белән генә кыек эченә кереп, тирә-ягына күз салды. Әһә, аргы баштагы печән кыштырдый түгелме?

— Чык, югыйсә печән аша атам!

Печән өеме әкрен генә күтәрелеп, аннан ак күлмәк күренде. Ирьегет аны караңгыда да таныды: Һади иде ул.

— Әһә-ә, атаңның өендә рәхәтләнеп йокларга уйлаган идеңме?

Тегесе дә аны таныды. Ярыйсы ук тыныч тавыш белән әйтте:

— Ирьегет, чын солдат булсаң, коралсыз кешегә наганыңны төзәмә.

Ирьегет читкәрәк тайчанып аңа юл бирде.

— Сөйләнмә, төш әйдә!

Ирьегет аны өч-дүрт кызылармеец белән өйләренә алып керде, киендерде, коралларын кызыл армеецларга алып бирергә кушты, шуннан соң Сәлмән картның үз келәтләренә яптырып, сак куйды. Иртәгәсен иртүк шул келәт эчендә үк аңардан үзе сорау алды: «Авылда торган акларның көче күп идеме?» «Планнары нинди иде?» «Каян, күпме өстәмә көч килүен көтәләр иде?..» Һади алдашмыйча диярлек җавап бирде. Бу минутта аңа үз җаны кыйммәт иде. Азактан үтенечле күзләрен Ирьегеткә төбәп, калтыранган тавыш белән:

— Ирьегет, тиңдәш, бергә үстек, дуслар булып йөрдек, яклаш бер юлга,—диде.— Бездә ялчы булып торсаң да, минем сиңа зыяным тимәде. Моннан соң мин аклар яклы булып сугышмам. Иптәшләреңнең кулына бирмә, үзең генә хәл ит. Син бит — командир... Мин сиңе...

— Җитте, юхаланма! — диде Ирьегет. Шуннан кинәт бер карарга килеп өстәде:— Эшләгән этлекне төче телләнеп кенә юып төшереп булмый. Мин сине атам — үз кулларым белән атам!

Һади капыл бөршәеп төште, күзләрен зур ачып Ирьегеткә текәлде.

Отряд кичке якта кузгалырга тиеш иде. Төш аугач, Ирьегет куллары артка каерып бәйләнгән, чырае качкан Һадины Нөгеш буена таба алып китте. Ике чакрым чамасы араны үткәнче, Ирьегетнең башыннан әллә нихәтле уйлар үтте.

Әйе, Ирьегет белән Һади — тиңдәшләр. Икесе дә бер үк елның бер аенда дөньяга килгәннәр. Тик язмышлары гына ике төрле булды. Һади майда йөзеп яшәде, чит мәдрәсәләрдә укып кайтты. Ә Ирьегеткә бәләкәйдән үк ачы тирен түгеп тамак туйдырырга туры килде. Әтисе япон сугышында башын салгач, карындык тәрәзәле өйдән башка нәрсәсе булмаган әнисенә балаларын тәрбияләп үстерү бик кыенга туры килде. Ирьегет унике яше тулар-тулмастан шушы Сәлмән байга елкы көтәргә ялланды. Тамак ялына эшләп йөрү авыр иде. Ләкин нишлисең — бүтән эш юк.

Алар Һади белән дуслашып киттеләр. Һади көн саен аның елкы көткән жиренә килер иде. Ике малай ялан жиргә чыгып алырлар да жан-фәрманга ат чабыштырырга тотынырлар иде. Ләкин аларны дуслаштырган нәрсә курай булды. Ирьегет унике яшендә инде чын курайчы булып житешкән иде. Ул уйнап жибәрдеме, урманнарын яңгырап кыяларың чыңлап торыр иде. Ул бигрәк тә «Нөгеш буйкайлары бәдрә чаука» көен уйнарга ярата иде. Һади аның уйнаганын йотылып тыңлый, ияр каешына тагып китергән савытыннан аңа кымыз эчерә, итен ашата, үзен курай уйнарга өйрәтергә куша иде... Герман сугышына китәр елны да әле алар һаман бергә булдылар, тик бу чакта араларына шәүлә төшә башлаган иде инде: алар икесе дә Ильяс картның кече кызы Рәшидәгә гашыйк булганнар иде. Рәшидә ит кунмас гәүдәле Һадины якын да китерергә теләмәде, ә имәндәй нык, бөркет карашлы Ирьегет янына үзе ашкынып тора иде. Ирьегет герман сугышына китәр төнне алар вәгъдә бирештеләр.

...Ирьегет үзеннән ике-өч адым гына алда барган Һадига карап: «Менә хәзер без нинди хәлгә килеп життек!» дип уйлый. Аннары тагын үткән көннәре күз алдына килә.

Ирьегет авылдан: «Нигә берәүләр тир түгеп эшләмәсә дә бай, ә без, көн-төн эшләп тә, адәм рәтле көн күрә алмыйбыз?.. Тап-таза була торып, нигә Һадины солдатка алмыйлар икән?..» дип, әллә күпме сорауга җавап таба алмыйча, башы катып чыгып киткән иде. Фронтта ул төрле кешеләр белән очрашты, большевиклар үткәргән митингларда булды, шунда гына теге чактагы сорауларга җавап тапты.

Октябрь революциясе көннәрендә Киевта Вакытлы хөкүмәтне яклаган ак казакларга каршы сугышты, Нарва янында немец гаскәрләрен тар-мар иттеләр. Колчак фетнәсе башлангач, кызыл гаскәр сафында авылына кайтып керде. Шул чак ул Һадиның Рәшидәне берничә тапкыр соратуын, Рәшидә риза булмагач, көч белән алырга жыенып йөрүен, ә инде болама башлангач, ак чехлар белән бергә Колчак армиясенә китүен белде һәм аның, туганнан бирле, үзенә дус түгел, ә кан дошманы икәнлеген ныклап төшенде.

...Менә ул, Һади, абына-сөрлегә, башын түбән иеп, аның алдыннан атлый. Эндәшми. Жибәр дип тә үтенми. Белә: Ирьегет белән аның юлы бер түгел.

Менә аръягында үркәчләнеп Бәштин тавы сузылган Нөгеш тә күренде. Ирьегет Һадины шунда атып үтерү уе белән чыккан иде. Әле нишләптер, үткәннәрне хәтерләп, күңеле йомшара төшкәндәй булды. Ни әйтсәң дә, Һади курай моңын ярата иде... Һади барган жиреннән капыл туктады да, артына борылып карамый гына:

— Чак кына сабыр ит, Ирьегет, Бәштинемә азрак карап торыйм әле,— диде.

Ирьегет тә туктады. Һади Бәштин тавына, Нөгеш буйларына байтак карап торгач, өзеп кенә әйтте:

— Ярар, ары алып барып йөрмә, Ирьегет... Шушында гына...

Ирьегет менә әле һаман ул чакта үзенең нинди акыл белән эш иткәнен аңлый алмый. Яшьлек хатирәләре тәэсир иттеме, Һадиның туган яклары белән шулай хушлашуы күңелен йомшарттымы, шап-шап атлап дошманы янына килде дә куллары бәйләнгән бауны чишәргә тотынды. Башын иеп торган Һади аңа әйләнеп карамады.

— Бар кит, тик кабат күземә күренәсе булма! — диде Ирьегет. Һади артына әйләнеп караганда, ул инде эре адымлап авылга таба китеп бара иде.

Шуннан соң күп тә үтмәде, Ирьегет Һадиның яңадан акларга барып кушылуын, офицер булып алып, яңадан Совет властена каршы

сугышырга тотынуын ишетте. Һади хезмәт иткән аклар дивизиясе кичә үзләрен авылдан кысрыклап чыгаргач, Ирьегетнең ачуы көчәйгәннән көчәйде.

Озак утырды Ирьегет уйланып. Ахырда полк командиры янына китте. Хәлне кыскача гына аңлатып, үзен авылга җибәрүен сорады, иртәгә иртүк әйләнеп кайтачагын әйтте.

— Дуамалланма, бер бай улын үтереп кенә дошманны җиңеп булмый,— диде командир. Ирьегет:

— Мин шул уңайдан разведка да ясап кайтырмын,— дигәч кенә, ризалыгын бирде.

— Тик разведканы үзеңнең төп бурычың итеп сана. Үзенә бер-ике иптәш тә ал,— диде.

Кояш баеганда Ирьегет ике иптәше белән авыл зираты янындагы чаукалыкта яшеренеп ята иде инде.

Аның бил каешына өч гранат белән наган тагылган. Аркасына — кая барса да үзе белән йөрткән кумталы[1] кураен аскан. Эңгер төшкәч тә, иптәшләрен чаукалыкта калдырып, кача-поса, Ирьегет авылга китте. Аның уе — башта Ильяс картларга барып, Рәшидәсенең хәлен белешү, шунда ук Һадиның кайту-кайтмавын, әле кайда булуын сорашу иде.

Менә ул киртә артлап кына Ильяс картлар өе турына килеп житте. Тиздән Рәшидәсе белән очрашачагын уйлап, йөрәге ярсып тибә башлады. Рәшидәне әллә үзе белән алып китәргәме?.. Шулай уйланып торганда Рәшидәләрнең капкасы шыгырдап ачылуын ишетеп, коймадагы ярыкка текәлде, ә инде аннан чандыр гәүдәле, хәрби киемле кеше килеп кергәч, тәннәре чымырдап китте: Һади үзе!

Ирьегет урам ягына күз салды. Ул-бу тоелмагач, койма буйлап кына килде дә посып кына чоланга керде. Ныклап ябылмаган, какшап беткән ишек аша өйдә ни сөйләшкәннәре ап-ачык ишетелеп тора иде. Ул, һич кичекмәстән өйгә кереп, Һадины буып ташларга да уйлап куйды. Ләкин тыелды. Мәгъфүрә әби әйтерме-юкмы дип көтте ул. Ә сүзләре бер җайга төшкәч, тынычланып тыңлавында булды. Һади: «Ирьегет тә хәзер курае-ние белән гүрдә ята» дигәндә, хәтта елмаеп та куйды.

Һадиның чыгып килгән аяк тавышларын ишеткәч, ишекне шар ачып җибәреп, бусага аша атлады.

— Урыныңнан кузгалма, эт!

Һади берничә секундта исен җыеп та өлгерде һәм капка төбендә калган солдатлары ишетерлек тавыш белән:

— А-а, синме бу, Ирьегет! — диде. Үзе кулын кабурасына якынайтты.

Бу юлы ачуы чигенә җиткән Ирьегет тә әкрен дәшә алмады.

— Үрелмә кабураңа! Инде котыла алмассың! — дип кычкырды.

Капка төбендә торган солдатлар, өйдәге шау-шуны ишетү белән, ярдәмгә ашыктылар. Ирьегет тә эшнең нәрсәдә икәнлеген аңлап алды һәм, солдатлар кереп үзен тотып алганчы, ике патронын берьюлы Һадига атып өлгерде.

...Исенә килгәндә, ул ниндидер караңгы, салкынча җирдә ята иде. Башы ярылып сызлый, күкрәгенә ниндидер авыр әйбер бастырып куйгандай, аяк-кулларын капкын кыскандай тоела иде. Торырга теләсә дә, булдыра алмады. Шунда гына ул үзенең аяк-кулын бәйләп ташлаганнарына төшенде. Кайда ятканлыгын белергә теләп, тирә-ягына күз салды, тик кан сауган, шешенгән күзләре берни дә күрмәде. Ул тагы һушыннан язды.

[1] Кумта — тартма, савыт, кап. *(Ред.)*

Икенче кабат исенә килгәч, кайда ятканын шундук белеп алды: Сәлмән бай келәте, кайчандыр үзе Һадины бикләп куйган таш келәт иде бу. Тимер рәшәткә кагылган бәләкәй тәрәзә аша әз генә яктылык төшә. Ирьегетнең башына килгән беренче уй: «Ул этне үтерә алдым микән?» дигән уй булды. «Әгәр тере калып, теге чактагы минем кебек, миннән сорау алырга тотынса?»

Шул чак келәт ишеге ачылды да, аның уен дөреслэгән сыман, Һади килеп керде. Аның сул кулы муенына асылган иде. Ирьегет башын читкә алып күзләрен йомды. Һади кемнедер чакырып алып, аның кулларын чишәргә кушты. Хәтта:

— Кем бәйләргә кушты аны сезгә? — дип җикеренеп тә алды.

Ирьегет, бу тагы нишләргә уйлый икән дип, ята бирде. Һади йомшак итеп, ләкин мыскыллавы сизелеп торган тавыш белән дәште:

— Шуннан, тиңдәш? Тагы да очраштык бит! Торып утыр.

Ирьегет, кысык күзләреннән очкын чәчеп, Һадига текәлде:

— Үзара кан дошманнар икәнлегебезне беләсең, Һади. Сорау алып маташма. Революция солдаты, синең шикелле куркак җан кебек, илен сатмый. Башка сүзем юк,— диде.

Һади урыныннан торды.

— Мин дә тиле инде, сиңа ашарга да бирмәгәннәрдер әле. Хәзер җибәртермен,— дип, ишекне ябып чыгып китте.

Күп тә үтмәде, итле аш белән чәй китерделәр. Хәтта бер стакан аракысы да бар иде. Ирьегет ашамаска булды, ләкин соңыннан башына икенче фикер килде. Нигә әле ул бу дөнья белән вакытсыз хушлашырга җыена? Өметсез — шайтан ди. Һәм ул торып утырды да ашарга тотынды.

3

Мәгъфүрә әби бу төндәге мәхшәрне гомеренә оныта алмас. Һади яралы кулын учактагы ут яктысында бәйләтеп чыгып киткәч тә әле, башы аңгы-миңге килеп, урыныннан кузгала алмый утырды. «Йа раббем! Тагы ниләр генә күрәсем бар икән? Аталары да тизрәк кайтып житми, ичмасам...» дип, йокысыз төн үткәрде.

Кояш чыккач кына, сыер саварга, аннан соң кызы белән килененә ашарга илтә барырга кирәклеге исенә төште. Тик ул бу көнне өеннән чыгып китә алмады. Һади: Ильяс карт кайтып төшсә кулга алырга, Рәшидә күзгә чалынса, үзенә хәбәр итәргә кушып, аларның өе янына сак куйдырган иде. Солдатлар капка төбеннән китмәделәр, берсе өйгә кереп су да эчеп чыкты.

Мәгъфүрә әби, бу каһәр суккырларына ни житмәгән инде дип, сукрана-сукрана көнен үткәрде. Солдатлар ярты төн авышкач кына киттеләр. Шунда гына Мәгъфүрә әби икмәк, сөтле шешә салынган төенчеген култыгына кыстырып, киртә артына чыкты да туктап калды. Мондый караңгы төндә, шушы яшенә житеп, урманга аяк басканы юк иде әле. Өч чакрым җиргә ничек барыр? Алай адашуын адашмас, тик эт-кош очрамасмы? Ләкин, ачыгып, караңгыда зарыгып көтеп утырган кызы белән киленен күз алдына китергәч, житмәсә яктырганчы әйләнеп кайтырга кирәклеген уйлагач, бөтен куркулары онытылып китте.

Дегет базының янына барып житкәч:

— Килен, кызым,— дип тавыш бирде.

Рәшидә җиңгәсеннән алда йөгереп чыгып, аның күкрәгенә сарылды.

— Нинди яхшы хәбәрләр алып килдең, әнием?

Мәгъфүрә әби ни дип әйтергә дә белмәде. Үткән төнне булган хәлләрне кызы белән киленнә сөйләргәме, юкмы?

— Хәбәр-ни дип... Куй инде, балам,— диде дә сулкылдап елап та җибәрде.

Рәшидәнең башыннан әллә күпме уй үтте. Әтисенә бер-бер хәл булды микән әллә? Әллә аклар берәр якын туган-ыруларына кул тигергәнме?..

Мәгъфүрә әби елаудан туктады, барыбер бер әйтергә туры килер дип, үткән төнне булган хәлне сөйләп бирде. Рәшидә, Ирьегет белән вәгъдә куешуларын белдермәскә тырышып йөрүен дә онытып, үксеп еларга тотынды.

— Мин синең белән авылга кайтам, әни. Ирьегетне ничек булса да коткарырга кирәк. Бәлки минем ярдәмем тияр...

— Юкны сөйләмә,— диде әнисе.— Харап булып куярсың.

— Булсын, миңа барыбер ансыз яшәү юк.

Тик әнисе:

— Мин иртәгә төнен тагы килермен, кызым. Ирьегетнең дә хәлен белешермен, шуннан күз күрер,— дигәч кенә, Рәшидә тынычлана төште.

Ләкин Мәгъфүрә әби кызына Ирьегетнең хәлен барып әйтә алмады. Иртәгәсен төштән соң авылга туп тавышлары ишетелә башлады. Бераздан аңа мылтык, пулемет тавышлары кушылды. Атыш якынайганнан якыная иде. Ә кич кырын, «ура» кычкырып, авылга кызыллар килеп керде. Командирлары, халыктан сорашып, Ирьегетнең нинди хәлгә таруын белгәч, Сәлмән картның йорт-курасын астын өскә китереп тентетте. Тик Һадины да, Ирьегетне дә таба алмадылар. Ирьегет эскадронындагы бер солдат, ярсуын тыя алмыйча, намаз укып утырган Сәлмән байны сәкесеннән сөйрәп төшереп, якасыннан алгач, Сәлмән:

— Минем малай унлап солдат белән Ирьегетне авылдан алып чыгып китте,— диде.

Шул таңда Ильяс карт та кайтып төште. Корткасының елый-елый сөйләгән хәбәрен тыңлагач, шул җиккән атын да тугарып тормастан, кызы белән киленен алырга китте.

...Рәшидә, кайту белән, Ирьегетнең хәлен ныклап белешер өчен күрше-күләнгә йөгерде. Барысы да бер үк хәбәр әйтте аңа: Һади Ирьегетнең кулын артка каерып, аякларын өзәңгегә бәйләп, унлап солдат белән авылдан алып чыгып киткән. Әйтүләренә караганда, Эстәрле яланнарына турыдан илтүче урман юлыннан киткәннәр.

Рәшидә төш җитә язганчы ары сугылып, бире сугылып йөрде дә кинәт бер карарга килде: Ирьегетнең үзен, я мәетен табып алып кайтырга. Ул шыпырт кына юлга җыена башлады. Чормага яшереп куелган ау мылтыгы белән берничә патрон алып төшеп, сарай артына чыгарды да, шуннан лапастагы йөгәнне алып, кача-поса урманга юнәлде. Урман читендә ашанып йөргән бер атны тотып йөгәнләгәч, урман юлына җилдерде.

## 4

Туп тавышлары авылга ишетелә башлагач, Һади байтак баш ватты. Акылсыз кеше түгел иде ул. Акларның хәлсезләнә, кызылларның көче арта баруын белеп йөрде. Өлкән офицерларның сөйләшүеннән ул кызылларның хәл иткеч һөҗүмгә күчүен, акларның бу якларга кабат килүе икеле булуын да белде. Әлбәттә, аклар белән китү өчен күп акыл кирәкми. Ләкин аның туган туфрагыннан һич тә аерыласы килми иде. Тик менә кызыллар килгәч, аның моңа тикле кылган гөнаһларын кичерерләрме?..

Мылтык тавышлары авылга бөтенләй якынайгач, ул Ирьегет янына кабат керде. Тоткынның кысыграк күзләрендә әүвәлгечә очкын уйнап

торуын күргәч, ишек төбендә туктап калды. Ирьегетне ул теләсә кайсы минутта атып үтерә ала. Ләкин аны бу адымнан бер нәрсә тотып тора иде: ул Ирьегетнең теге вакытта үзен атмавын һич оныта алмый. Хәтта хәзер, шул чакта акларга яңадан кушылып, җинаятен тагы да тирәнәйтүенә үкенеп тә куйды.

Ирьегет, бөркет күзләрен Һадига кадап, тантаналы тавыш белән әйтте:

— Җеназаңны укый башларга вакыт җитте, Һади! Ишетәсеңме безнекеләрне?!

Һади, йөзенә бернинди үзгәреш чыгармыйча, эчкәрәк үтте. Ит чаба торган бүкән өстендә бераз сүзсез утыргач, ишек төбендәге ике солдатка читкәрәк китәргә кушты да Ирьегеткә карамыйча гына сүз башлады:

— Ирьегет,— диде,— бик болама заманда яшибез, кемнең ни өчен сугышканын белми ялгышып киткән чаклар да була...

Ирьегет аның сүзен бүлде:

— Ә мин үземнең ни өчен сугышканымны белеп сугышам.

— Тукта әле,— диде Һади,— җайлап кына сөйләшик әле. Менә синең язмышың минем кулда. Ни теләсәм — шуны эшли алам. Ләкин бит «егетлек җирдә ятып калмый» дигән мәкаль бар. Теге чактагы егетлегеңне мин дә онытмыйм, шуңа мин сине башка ак офицерлар кулына бирүдән саклап калдым да...

— Кыскасын әйт, сиңа миннән ни кирәк?

Һади, икеләнеп, байтак сүзсез утырды. Аннары:

— Ирьегет, әгәр гомереңне саклап алып калсам, үзегезнекеләр килгәч, мине яклашырсыңмы? — дип сорады.

— Соңлабрак акылга утыргансың, Һади,— диде Ирьегет.— Мин сине үз кулларым белән теге дөньяга озатачакмын! Бу юлы аяу булмаячак!

Ирьегетнең кычкырып сөйли башлавын ишетү белән, ишек алдына берничә солдат килеп тә җитте. Битләренә тимгел-тимгел кызыллык бәреп чыккан, иреннәре калтыранган Һади, аларга карап:

— Бәйләгез! — дип бер генә сүз әйтте дә келәттән чыгып китте. Кая барасын, нишләргә уйлавын атасына да сөйләп тормыйча, атларны иярләргә кушты. Аның миен тик бер генә уй төйгечләп тора иде: кызыллар килеп басмас борын, Ирьегетне алып чыгып китәргә... Юлда ул аңардан рәхәтләнеп үч алыр да, Воскресенскийга чыгып, Ырымбур даласына качар. Аннан күз күрер әле...

Бите-башы канга буялган Ирьегетне күтәреп ияргә утырттылар да аякларын өзәңгегә тарттырып бәйләделәр. Атының тезгенен Һади менәчәк атның койрыгына тактылар. Һади атка менәргә җыенгач, Ирьегет аңа күтәрелеп карамый гына дәште:

— Сиңа бер үтенечем бар: әйт, кураемны кумтасы белән аркама ассыннар. Үтергәч тә, алдырып ташлатма.

Һади аның кумталы кураен алып килеп, Ирьегетнең муенына асарга кушты. Урам очына җиткәч, Ирьегет күңеленнән генә авылы белән хушлашты, кабат әйләнеп кайта алмасын, бигрәк тә Рәшидәсеннән мәңгегә аерылуын уйлап, йөрәге кысылды. Әйе, авылы кала, түгәрәк ак йөзле, сөйкемле Рәшидәсе кала... Үкенерлек тагы нәрсәсе кала соң әле Ирьегетнең? Эшләргә теләгәннәренең барысын да эшләп бетердеме соң әле ул? Юк. Акларны җиңгәч, авылдашлары белән теттереп яңа тормыш төзисе бар иде... Бу дөньяда үз гомерен дәвам итәрлек җан иясе калдырырга да өлгермәде бит әле ул...

Таң атуга, урман алдында берничә алачыгы гына торып калган җәйләүгә килеп җиттеләр. Бу җәйләү олы юллардан ерак иде. Шуннан ары китәргә ашыкмады Һади. Хәвефле, озын юл үткән чакта моннан башка ял итәр урын әллә була, әллә юк. Азрак черем итеп, хәл җыеп,

тамак туйдырып алырга кирәк. Аннары Ирьегетне дә әллә кая алып барып йөреп булмый бит инде — шушында гына эшен бетерергә кирәк.

Ирьегетне иярдән чишеп алып, үлән өстенә салдылар да, бер егетне янына сакка куеп, үзләре йокларга яттылар. Ирьегет үз язмышын хәзер ап-ачык белә иде инде. Шуңа күрә ул хакта артык уйламады. Һәм аяк-кулы бәйле көе төн буе ат өстендә йончыганлыктан, үлән өстендә иртәнге зәңгәр күккә карап ята торгач, оеп китте. Ыңгырашып уянса, тирләп лычма су булган. Кояш инде төшлектән авышкан иде.

Бераздан аның янына Һади килде.

— Шуннан, уяндыңмы, каһарман егет? Кайчандыр без монда икәүләп ат чабыштыра торган идек. Хәзер менә шушында ук аерылырга туры килер.— Шуннан ул солдатларына ымлады.— Әй, килегез әле, күтәреп әнә теге алачыкка кертегез дә мичкә бәйләп куегыз.

Ирьегетне аяк-кулы бәйләүле килеш алачыкка күтәреп алып керделәр дә мичкә кысып бәйләп куйдылар. Аяк астына утын өя башлагач, Ирьегет барысын да аңлады: яндырачаклар! Әллә инде Һадиның шундый ерткычлык уйлап табуына ярсудан йөрәге дөрселдәп тибә башлады, күз аллары караңгыланды. Ләкин — үлемне ирләрчә каршылау өчен бөтен гайрәтен җикте.

Алачыкка Һади килеп керде. Аның карашы коры, хәрәкәте салмак иде.

— Я, дөнья белән бәхилләш, Ирьегет!

— Бәхилләшеп торасы юк,— диде Ирьегет.— Шулай да сиңа бердәнбер үтенечем бар: соңгы тапкыр курай уйнарга рөхсәт ит. Кураемны үзем белән бергә яндырырсыз.

— Кулларын чишегез! — дип боерды Һади солдатларга.

Ирьегеткә кураен китереп тоттырдылар. Ул бер солдаттан кураеның эченә су бөркеп бирүен үтенде. Бу теләген дә үтәделәр. Ирьегет кураен тешенә терәп, уйнарга кереште. «Нөгеш буйкайлары бөдрә чаука...» Бу көйне заманында Ирьегет кенә түгел, Һади да ярата торган иде...

Тыныч кына яткан җәйләүдә көтмәгәндә ишетелгән курай моңына һавадагы кошлар туктап, төз карагайлар башларын иде, һәрвакыт шыбырдашкан агач яфраклары да тынып калды. Әйтерсең лә, үлем алдыннан уйналган бу көй табигатьтәге һәр җан иясенә барып кагыла да төпсез киңлеккә — мәңгелек яшәүгә омтыла иде.

Көй уйналып бетте. Алачыктагылар ләм-мим сүз кузгатмый тора бирделәр. Ә Һади бер ноктага төбәлеп каткан иде. Ирьегетнең:

— Ягез, кураемны тоткан көе бәйләгез дә...— дип әйтүе тынлыкны бозды.

Солдатлар, сискәнеп китеп, Һадига карадылар.

— Чишегез дә, кулларын бәйләп, тышка алып чыгыгыз,— дип, Һади ишеккә юнәлде.

Ирьегетне тышка алып чыккач, аңа туры карамый гына әйтте:

— Шәп тартасың курайны, Ирьегет. Синең шул моңыңны тыңлап кына яшәргә иде дә бит... Шуңа күрә мин баштагы карарымны үзгәртәм: атып кына үтерәм мин сине. Кураең белән бергә җирләрбез. Әнә теге юан карагайны күрәсеңме, шуңа карап атла.

## 5

Рәшидә, бер-ике чакрым җир киткән саен тукталып, ат тоякларына күз сала-сала, атын куалый бирде. Кемнеке булгандыр инде, тотып менгән аты да бик җитез хайван булып чыкты — җилдерә генә иде.

Кызулыгы белән ул чак кына җәйләү янына барып чыкмады. Лапас астында торган атларны, шуннан ерак түгел җирдә бер-ике солдат йөргәнен шәйләп өлгерде. Атын бер агачка бәйләп, урман читенәрәк чыкты да алачык тирәсен күзәтә башлады. Ирьегете, я Һади күренмәсме? Бу солдатлар кемнәр: алар белән китүчеләрме, әллә бөтенләй икенче кешеләрме?..

Шул вакыт аның колагына курай уйнавы ишетелде. «Нөгеш буйкайлары бөдрә чаука...» Ирьегет уйный бит! Димәк, ул исән! Рәшидә башта куанса да, тора торгач күңеленә шик төшә башлады. Әллә Ирьегет Һади белән бергә аклар ягына китәргә булганмы? Шулай булмаса, үлемгә дучар ителгән кеше нигә иркенләп курай уйный?

Курай тынды. Тиздән Рәшидә алачыктан Һадиның килеп чыгуын күреп калды. Күп тә үтмәде, аның артыннан Ирьегет белән берничә солдат та чыкты. Тик шуннан соң гына Рәшидәнең йөрәгенә үрмәли башлаган шикнең эзе дә калмады: Ирьегетнең куллары артка каерып бәйләнгән иде. Бераздан Ирьегет нәкъ ул яшеренеп яткан җиргә таба килә башлады. Бераз ара калдырып, аның артыннан Һади да китте.

«Нишләргә уйлый ул?» Рәшидә төбенә шомырт агачлары үскән карагай артына посты. Ирьегет килде-килде дә, карагайга бер утыз адымлап калгач, туктады. Рәшидә Һадиның: «Иә, берәрсенә васыять-фәлән әйтәсең юкмы?» дип сораганын ап-ачык ишетте. Башта ул югалыбрак китте, ләкин шундук исен җыйды. Кыю хәрәкәт белән мылтыгын алып, көбәген бер шомырт ботагына салды. Алга күз ташлаган уңайга, Ирьегетнең тагы алга таба китүен, ә Һадиның кобурасын ычкындыра-ычкындыра аның артыннан килүен күрде. Менә, карагайга бер егерме адымнар калгач, Һади туктады. Моны Ирьегет тә сизде, күрәсең, туктады да Һадига йөзе белән әйләнде. Һади наган тоткан уң кулын әкрен генә күтәрә башлады. Аның кулы күтәрелгән саен, Ирьегетнең башы югарырак чөелде.

...Шул чак мылтык тавышы бөтен урманны яңгыратып җибәрде. Һадиның наган тоткан кулы капыл түбән салынды, ул киселгән агач шикелле әкрен генә җиргә ауды.

Ирьегет аны-моны абайлаганчы, Рәшидә йөгереп барып, аны кочаклап та алды. Ирьегет, тиз генә аңына килеп:

— Анда солдатлар, чиш кулларымны,— диде.

Алачык янындагы солдатлар, ау мылтыгы тавышын ишетеп, йөгереп килеп җиткәндә, яңак сөяген аю ата торган ядрә җимереп үткән Һади җан биргән, ә Ирьегет белән Рәшидәне урман үз кочагына яшергән иде инде.

Нөгеш буендагы биек кыя башында ике кеше басып тора. Битләре яраланган, имәндәй нык гәүдәле егетнең аркасында сунар мылтыгы, кулында — курай. Менә ул кураен әкрен генә авызына китерде дә уйнап җибәрде. Аңа янындагы түгәрәк йөзле, уйчан карашлы кызның гаҗәеп матур тавышы кушылды, һәм бөтен Нөгеш буен илаһи бер моң күмде. «Нөгеш буйкайлары бөдрә чаука...»

Бераздан алар, житәкләшеп, еракта ишетелеп торган туп тавышлары ягына юнәлделәр. Ирек һәм бәхет өчен көрәшүчеләр сафына яңадан басарга, Нөгеш буйларына олы җиңү белән кайту өчен, мәңге бергә яшәү өчен киттеләр алар.

Болар — Ирьегет белән Рәшидә иде.

**Фәрит Исәнгулов**

# ГАФЛӘТ

*Сатирик портрет*

Гастроном директорының кабинет ишегендә үземә бик таныш фамилия язылган тактаны күргәч, аптырап киттем. Бу — һичшиксез минем авылдашым Гафләт кордаш иде. Шунда ук малай чаклар искә төште.

Күмәкләп җыелып алсаң, хәбәр сөйләшә башлыйсың бит инде. Әйтик беребез:

— Без бүген утынга бардык,— дисә,

Гафләт:

— Без ботка пешереп ашадык,— дип сала.

Укытучы тактага чыгарып, чагыштыру рәвеше кергән җөмлә язарга кушса, ул һич икеләнеп тормый, симез хәрефләр белән: «Кишер шалканнан тәмлерәк» дип шартлатып яза да бирә.

Бер ел күрше Аттояк авылында бик зур янгын булган иде. Шунда чаптык. Ут сүндерешеп йөргән арада, кинәт Гафләтебез юкка чыкты. Янып үлмәгәе дип, эзләргә, кычкырырга керештек. Ә ул яныбызда гына булган икән. Сәрви агачы артына посып алган да яна башлаган өйнең чоланыннан эләктереп чыккан бер чүлмәк каймакны учлапучлап сыпыртып яткан көне.

Үсә төшеп, мәҗлесләргә йөри башлагач, Гафләтнең белгән бердәнбер җыры:

Ашап эчик, эчеп ашыйк,
Фани дөнья бер генә,—

дигән җыр булды.

Мин калага укырга киткәндә, ул колхозда ферма мөдире булып калган иде. Бер авылдашым: «Гафләтне төрмәгә утырттылар» дигән хәбәр китергәч, исем китеп:

— Ни өчен?! — дип сорадым.

Авылдашым:

— Күп ашаган өчен,— дип кыска гына җавап бирде.

Тик бәхете бар икән егетнең: төрмәдә яхшы эшләп бер елдан ук чыгарганнар.

Шуннан кайтышлый минем тулай торакка сугылып китте.

— Ну, ничек? — дип соравыма:

— Анда срок тулганчы да пулный яшәргә була иде. Ашау ару...— дип җавап бирде.

Шуннан соң Гафләт гаип булды. Унбиш елдан артык бер генә хәбәрен дә ишеткәнем булмады. Бактың исә, бүген мин килеп төшкән шушы калада зур гына бер гастрономның директоры икән.

Аны тизрәк күрәсем килеп, кабинет ишегенең токкасына үрелмәкче булдым. Ләкин шунда ук бер хезмәткәр, калкандай булып, юлыма аркылы басты:

— Тсс!.. Ул ашый!..

Зөлфәр Хисмәтуллин

# КИҢӘШ

— Алло, Хөрмәтуллин иптәшме бу?

— Әйе, Хөрмәтуллин тыңлый.

— Саумысыз, Хөрмәтуллин иптәш. «Агыйдел» колхозыннан Таһиров бу. Сезгә киңәш бар иде. Шефлар күпер салырга килгәннәр.

— Бик хуп.

— Мин дә шулай уйлаган идем. Күпер булса, район үзәгенә барып йөрергә дә рәхәт. Югыйсә елның-елы көймә белән җәфа чигәбез.. Язлыкөзле паром ремонтлаудан бушамыйбыз. Тик...

— Нәрсә тик? Салырга булгач, салырга кирәк.

— Мин дә шулай дигән идем. Тик кайбер кешеләр каршы килә. Күпер булса, хатыннарны тотып булмаячак, көн дә чиләк асып алырлар да базарга чабарлар, диләр.

— Дә-ә-ә, ул ягы да бар икән шул. Алай, хәзергә салмый торыгыз. Соңыннан күз күрер әле.

— Мин дә шулай уйлаган идем. Гомер буе күперсез яшәп килдек. Яшәр идек әле. Күпер булгач, шәһәрдән балык тотарга, җиләк-гөмбә җыярга килүчеләр дә башны каңгыртачак.

— Шулай шул. Менә шуңа күрә әйтәм дә инде: хәзергә салмый торыгыз, дим.

— Мин дә шулай уйлаган идем. Ләкин үткән ел, җәфаланып-интегеп дигәндәй, проект төзеткән идек бит әле.

— Ай алла, исең киткән икән. Проект төзетсәң — ашарга сорамый бит, ята бирсен. Бәлки берәр заман берәр аһмагы да табылыр. Синең белән миңа гомер буе җитәкче урында утырырга димәгән.

— Мин үзем дә шулай дигән идем. Проект белән генә эш бетсә, бәлки шулай эшләгән дә булыр идек. Без ул проект буенча тимер конструкцияләр, тимер-бетон изделиеләр дә әзерләп өлгергән идек шул.

— Алай булгач, нигә миннән киңәш сорыйсың соң? Төзе, вәссәлам!

— Мин дә шулай уйлаган идем. Хәтерегездәме, үткән ел сабан туена килгән берничә җулик, эчеп-исереп, безнең кешеләрне канга батырып тукмап кайтып киттеләр. Хәзер алар атнасына ике ял итәләр. Ул атнасына ике сабан туе булу белән бер бит.

— Анысы шулай инде. Ике ялга кучкәннән бирле мин үзем дә көннең чамасын югалттым. Ә нишлибез соң алай булгач? Хәйләсез дөнья файдасыз, дигәндәй, берәр хәйлә табып туктатып тор бу эшне.

— Мин дә шулай уйлаган идем. Тик кайбер кешеләр каршы килә. Бүредән курыккач, урманга йөрергә кирәкми, диләр.

— Дөрес.

— Нәрсә дөрес?

— Салдырт әйдә.

— Ярар салырбыз, алай булгач.

— Тик...

— Нәрсә тик?

— Салыгыз да ярга җиткәнче туктатыгыз. Ник салып бетермәдегез? дисәләр, бетерербез әле, диярсез. Ә нигә күпер саласыз, кирәкмәс иде дисәләр, аннан барыбер йөреп булмый бит диярсез. Аңладыңмы?

— Аңладым, Хөрмәтуллин иптәш.

## Рәдиф Гатауллин

# Өстәлемдә торна тора

Өстәлемдә
ничә еллар инде тора
сувенирга дуслар биргән
ялгыз торна...
Әйтә миңа: кешем, тыңла,
бәхет турында уйласаң,
ялгыз булма,
минем кебек ялгыз торма! —
Өстәлемдә статуэтка-кош тора.

Ялгыз торна —
тормышта ул
күптән парын табалгандыр,
бии-бии арыгандыр
шатлык-туйда.
Диңгез кичеп, илләр үтеп
китә-кайта,
һаман-һаман
җиремә минем пар-пар торна.
Ә бүлмәмдә —
ялгыз торна — пластмасс торна
боек тора.
(Ә сәнгатьтә — сыңар кош — ул
матур образ;
парын сагынып үлгән аккош,
саңрау торна,
дуадак каз...)

Мин ялгызлык дусы түгел,
Күңелем минем —
пессимизм кошы түгел.
Яшәгәндә дуслар кирәк,
ярлар кирәк.
Сиңа исә — ялгыз торна —
иптәшкә мин
сыңарыңны —
үз парыңны табам бүген:
Статуэтка булсаң да —
боек торма!
Ялгыз торна,

# Тел ачкычлары

Балачакның бер ядкаре —
Карт әбекәмнең теләкләре;
Һаман истә тотам берсен:
— Дөнья бездән калыр, бәбкәм,
инде тегесендә менә —
тел ачкычлары бирсен! —
Сиңа, миңа...

Тел ачкычы! Газиз әбекәм,
Шушы сүзең
Күңелемдә күпме еллар яңгырап торды.
Белсәң иде — андагысын уйлаган юк,
бу дөньяда — оныгыңа
ачкыч күпме кирәк булды!
Күпме яшерен серләр, сүзләр...
Чит телләр, я чит күңелләр...
Шигырь өчен
кирәкле сүз таба алмый,
җан ачалмый, аңлаталмый,
йолдызларның,
я гөлләрнең
телен белми җәфа чиктем.
(О, табигать! Серләреңә ачкыч кайда?..
Сизәм, ачыл! — диимме?
Миңа читен!)
Күпме ишек, күпме йозак!
Кешеләр дә —
я лабиринт, я табышмак...
Тормыш гүя бер сфинкс,
гел җавабын торды сорап...
О, сез яшәү баскычлары...
Һәр адымда
кирәк икән ачкычларың!
Кирәк икән...
Телсезләрне телле итәрлек,
денсезләрне юньле итәрлек,
чукраклар да ишетерлек,
авыруларны терелтерлек —
сөйләр идем! —
иртә-кичен.
(Әбекәм, синең доганң миңа
шул тел ачкычларын бирсен.)
Әмма
мәкер-хыянәттә,
халкым бәхетен урларга
дошман кора калса авын;
мин белмәсәм алдым-артым,
сер ачарга
әзерләнсәм —
бирә белгән — күрә белсен —
ачкычларын кире алсын!

## Иртән язылган кичке шигырь

Була —
шигырьләрнең яшьлек вакыты.
Яшь күңелнең бары «яшен» вакыты,
акыл җимешенең яшел вакыты!

Гүя Кеше барысын да белеп туган,
гүя коеп куйган, бөек булган,—
ул — дөньяда алла итеп сизә үзен,
көмеш урынына сибә сүзен!
Күңел —
яшь бер әтәч төсле
һәйкәлләргә очып-очып куна;
Шекспирлар белән ярсып бәхәс кыла.
Фәкать үзе генә хаклы кебек,
Нәрсә әйтсә, барысы яхшы кебек,
ул — әй тыныч, горур тора,
үзенә ышана,
бүтәннәрне — ышандыра...

О, яшь вакыт! Күперләрне
яккан вакыт,
җимерергә һәвәс,
күпне ваткан вакыт.
Синме — әллә үз-үзеңне тапкан вакыт?!
Ә бит бер көн
синең өнең басыла, бетә.
Акыл көне,
үз-үзеңә тәнкыйть көнең җитә.
(Тик кешеләр —
яшьлегеннән барыбер ваз кичмиләр!
Яшь көенчә китә кайчак кешеләр,
күпләр
шул чорда да бөек эш эшлиләр!)
Шигырь шул көн
исәннәрдән гафу сорар,
үлгәннәрнең ядына җыр багышлар,
туфрагына яшен кояр,
чәчәк куяр.
Ә мин әле — нигә бу турыда бүген уйлыйм?
Кич турында иртән сөйлим?
Гөнаһларым артык күптер бәлки?
Әллә акылга баш иягә
вакыт җитә?
Миңа —
Әле иртә бугай... Иртә.

●

*Лирик аллитерация*

Җил, исмә! Исмә, җил,
каенга кагылма.
Караңгы — каеннар,
каеннар — кайгыда.

Каеннар катында
калгандыр эзләре.
Калгандыр — каенга
эленеп — сүзләре.

Эземе, сүземе,
калгандыр кайсысы? —
Бары да кадерле;
калгандыр кайгысы —
аерылу кайгысы!
Җил, исмә... исмә, җил!—
Каенга кагылма.

Шунсында бары да:
Эзләр дә, сүзләр дә,
иң авыр кайгым да.
Кагылма каенга —
кагылма
кадерле кайгыма!

●

«— Якын килмә!
Янган утларымны сүндерерсең,
ялгыш
саксыз өрә күрмә!
Якын килмә,
миннән еракта бул.
Күкрәгемдә түгел,
булсаң йөрәктә бул!
Миңа кирәк —
яшерен яну, сагыну-утлар;
юкса, куркам:
давыл тынар,
хис-хәрәкәт бетеп туктар.
Якын килмә...»

Юк, ышанма!
Бу ясалма сүзләрне мин —
сине югалттым, дип, өзгәләнгән көндә
үз-үземне алдау өчен әйткән идем.
Кил! Һәм терелт тизрәк
хәлсез каләмемне минем!

## Разил Вәлиев

# Вәгъдә

Оҗмах вәгъдә итмим сиңа...
Бик тар әле чикләрем.
Бар байлыгым — шигырьләрем
Һәм дә кара икмәгем.

Күкне бирә алмам сиңа...
Йолдызсыз да итмәмен.
Айны бөтен көе саклап,
Сине, ахры, көткәнмен.

Шатлыкларым тулы килеш,
Кайгымны да түкмәдем.
Йортым тәбәнәк булса да...
Биек әле күкләрем.

Бәлки, бәхетле булмассың...
Бәхетсез дә итмәмен...
Оҗмах бирәм, димим сиңа...
Тәмугка да кертмәмен.

## Энҗе Мөэминова

# Россия тудырды

Патшалар, җәлладлар хаклыкны буарга
Ажгырып ташланган чагында,
Җиңелме богаулар божрасын өзгәләү
Жандарм, шымчылар, төрмәләр
сагында?
Бәхетеңне, иркеңне, юлыңны бикләргә
Дошманнар мең йозак, мең тозак
корганда,
Җиңелме иң авыр, иң ерак юл сайлау,
Үлем һәр адымны сагалап торганда?
Хисапсыз борчылу, газаплар китереп
Иң якын, кадерле кешеңә,
Җиңелме үзеңне мәңгегә багышлау,
Халкыңа, азатлык һәм бәхет эшенә?
Бармы соң дөньяда шундый ир? —
Күңеле саф, рухы нык баһадир?

Бер тубал чәчүлек. Әремле, кантар җир...
Сабанга иелгән хәлсез ир,
Күз яше, тир белән буразна чылатып,
Ялварып, аллага табына.
Җиңелме шул ирдә ышаныч уяту,
Мул тормыш, трактор, электр хакында?
Ач, ятим балалар «бер телем икмәк»
дип,
Ят капка шакыган чагында,
Җиңелме белемгә омтылыш уяту
Сан саный белмәгән мужиклар аңында?
Салкын һәм шыксыз өй. Карындык
тәрәзә.
Бер кабым ризык юк табында.
Җиңелме яшәүгә ышаныч уяту,
Ач үлем тешләрен шакыган чагында?
Искелек үлмәскә, җан-фәрман
тырмашып,
Җан кыйган, кан койган чагында?
Җиңелме яңага омтылыш уяту,
Тез чүкмәү дошманнар алдында?

Башкарыр өчен бу авыр һәм зур эшне
Россия тудырды даһины — Ильичны!

## Я җыр итеп аны ишетәм

*«Ленин терелэрдән тере».*

*В. Маяковский*

Ленинны мин күреп белгәнем юк.
Аны минем бабам, әткәм күргән.
Ләкин Ленин җанлы, тере булып
Һәр адымда килә минем белән.

Мин еш кына клуб залларына
Тантанага, җыелышларга киләм;
Бусагадан атлап керү белән
Очрашам мин анда — Ленин белән!

Ул — сын булып баса минем алга,
Бер минутка туктап калган сыман.
Я сәхнәдән миңа карап тора,
Эшләремнән хисап алган сыман.

Я художник аны полотнода
Илһам көче белән терелтә.
Я мин аны күрәм экраннарда,
Я җыр итеп аны ишетәм.

Гасыр буе халык үз Ленинын
Үзе өчен шулай
Мәхәббәте белән терелтә!

## Иң олы мәхәббәт

Дөньяда языла бер китап! —
Языла музейлар залында.
Анарда
мең төрле кул белән,
йөз төрле тел белән,
иң олы мәхәббәт языла.

Гадәти булмаган бу китап,
шуңамы,
һич чыкмый хәтердән.
Музейлар залында ул китап!
Ул китап гаҗәп тә, матур да!

Ул сөйли Ленинның
бар дөнья халкына
кадерле булуы хакында —
мин беләм —
мең төрле йөрәктән,
йөз төрле тел белән!

## Гөлшат Зәйнашева

### Яшәгән бу җирдә бер ана

Яшәгән бу җирдә бер ана,
Күп сулы киң Идел буенда.
Шул ана Ленинны тудырып,
Кадерләп үстергән куенында.
Иң бөек, иң даһи кешене
Тудырып үстергән ул ана.
Бу хакта уйласам нигәдер
Күңелем нечкәрә, моңлана.
Канатсыз кош түгел, анасыз
Бер бала идем мин, бер ятим.
Мәктәптә бер вакыт сорадым;
— Әнием дип, кемгә мин әйтим?...
Укытучы — яшь кенә бер апа —
Туктатты шулвакыт дәресен,
Күрсәтте миңа ул кадерләп
Китаптан Ленинның әнисен.
Һәм әйтте: — Бу безнең иң изге
Анабыз — синең дә, минем дә.
Дөньяда ятимнәр булмасын,
Кайгырт син, дигән ул Ленинга.
Шул көннән алып мин ничектер
Беркайчан ятимлек тоймадым.
Укытучы апаны иң якын,
Бертуган апам дип уйладым.
...Яшәгән бу җирдә бер ана,
Һәм яши әле ул бүген дә.
Онытылмас җыр булып, моң булып,
Җанлана ул безнең күңелдә.

### Миңнәхмәт батыр

Элек заман циркларда
Карәхмәт батыр булган.
Пәһлеван көрәшчеләрне
Ыргытып атыр булган.
Миңнәхмәт исемле батыр
Бар хәзер безнең якта.
Карәхмәт дигән батырдан
Көчлерәк булыр хәтта.
Циркта, сабантуйларда
Көрәшми бу Миңнәхмәт,
Көрәшү кагыйдәләрен
Белмидер дә ул рәтләп.

Күкрәкләре дә киң түгел,
Гәүдәгә җыйнак кына.
Юк-бар сүзләргә катнашмый,
Холкы да тыйнак кына.
Циркта түгел, кырларда
Батыр Миңнәхмәт батыр.
Мул уңыш бирә ул чәчкән
Йөз түгел, мең гектар кыр.
...Яргаланган кулларыңны
Кысыйм әле, Миңнәхмәт!
Ак күмәч белән сыйлыйсың,
Рәхмәт сиңа, мең рәхмәт!

**Юныс Әминов**

# ӨТИ БАЛАК

## 4 ПӘРДӘЛЕ КОМЕДИЯ

КАТНАШАЛАР:

Гөлүзә Сабирова — сыер савучы.
Мәүлидә — Гөлүзәнең анасы, колхозчы-пенсионер.
Мәрван Вафин — зоотехник.
Нури Кашапов — ферма мөдире.
Мәрьям Исмәгыйлова — сыер савучы.
Ситдыйк — көтүче.
Миндар Миңлеәхметов — ферма малларына ат белән азык ташучы.
Сәкинә — Миндарның хатыны.

## *Беренче пәрдә*

Сыерлар җәйләве. Терлекчеләр өчен күчмә торак-вагон. Карт тирәк астында агач өстәл, эскәмияләр. Бер читтә авызлары аска каратып куелган сөт бидоннары, чиләкләр. Юганнан соң кибәргә элгән сөлгеләр. Ике багана. Берсендә стена газеты, икенчесендә күрсәткечләр тактасы. Арткы планда тал-куаклык. Пәрдә күтәрелгәндә, Нури тактага эш күрсәткечләре яза. Ерактан Ситдыйк тавышы ишетелә.

Ситдыйк *(сыер чакыра)*. Куян, түвәй, түвәй... Куян. *(Керә.)*
Нури. Тагы качтымы?
Ситдыйк. Сыер дисәң дә сыер! Үземнеке булса, билләһи, тугыз җиреннән суяр идем.
Нури. Кыңгыравын таккан идеңме?
Ситдыйк. Балак югалткан бугай инде аны.
Нури. Көтүгә Куянны кыңгыраусыз алып чыгасы булма, дип әйттемме мин сиңа?
Ситдыйк. Куян бит ул. Койма аркылы сикерде дә чыкты.
Нури. Бозаулaсы сыер. Сазга батып үлсә, кара аны.
Ситдыйк. Эзләшергә кешеләр бир.
Нури. Бирмим. Син көтүче, син югалткансың, син тап.
Ситдыйк. Саттар сыртын гына карыйм да...
Нури. Сүз сөймим. Сөйләмә. Биш минуттан Куян каршымда булсын.
Ситдыйк *(ачу белән, честь биреп)*. Тыңлыйм, иптәш генерал! *(Китә.)*
Нури. Солдат кына булсам да өйрәтермен мин сезне. *(Бидоннарны тикшерә башлый.)* Чиста... *(Туктальп.)* Төбендә балчык. Бу җирәнгечне кайсы кабахәте бирегә куйган?.. *(Эндәшеп.)* Мәрьям, Мәрьям...
Мәрьям *(вагон тәрәзәсеннән башын чыгарып)*. Тыңлыйм, Нури.

Нури. Чебен кертәсең. Тәрәзәне яп.

Мәрьям. Аңлашылды. *(Тәрәзәне яба.)*

Нури. Мәрьям, Мәрьям... *(Тәрәзәне ача.)*

Мәрьям. Чебен кертәсең. *(Тәрәзәне яба.)*

Нури *(тәрәзә кагып)*. Синең белән шаярмыйлар, понимаешь!!

Мәрьям *(вагоннан чыга, Нуриның дөбер-шатыр тәрәзә кагуын карый)*. Ватсаң үзең төзәтерсең, понимаешь.

Нури. Нигә шаярасың?

Мәрьям. Мин кыз, син егет. Нигә шаярмаска?

Нури. Култыклашып йөргәндә генә егет белән кыз без. Ә монда, хезмәт фронтында...

Мәрьям *(аның фикерен дәвам иткән рәвештә)*. Син солдат кына, ә мин командир дип тә җибәр инде.

Нури *(күкрәгенә төртеп)*. Әйе, мөдир шул! Барыгыз өчен дә минем баш җавап бирә. *(Күрсәтеп.)* Бу бидоннар Балакныкымы?

Мәрьям. Минеке.

Нури. Нигә юмадың?

Мәрьям. Син әйткәнне көттем.

Нури. Кеше күргәнче ю.

Мәрьям. Күрсә, ояты миңа ич, җаным.

Нури. Сиңа ояты гына шул. Ә мине эшемнән үк өрерләр, понимаешь.

Мәрьям. Әллә минем өчен борчыламы дигән идем... *(Тирән сулап куя.)* Поняла!.. *(Күккә карап.)* Кыр үрдәкләре!.. Кайсы күлгә барып төшәрләр икән?

Нури. Бидоннарыңа кара.

Мәрьям. Алар янында күбәләк уйный. Матур...

Нури. Күбәләкләр эштән соң.

Мәрьям. Кичә гыйбрәтле кино булды. Ситдыйк та чыккан иде.

Нури. Синең арттан калмый ул.

Мәрьям. Уңган егет. *(Пауза.)* Нури, солдатка киткәнче син дә әйбәт идең, хәтта зәңгәр күкне дә, андагы якты йолдызларны да күрә идең. Ә хәзер... аягың белән рәттән торган чәчәкләргә дә исең китми.

Нури. Мин эш кешесе. Йолдыз санарга вакыт юк.

Мәрьям. Комачауламыйм. Эшлә. *(Вагонга юнәлә.)*

Нури. Үпкәләсәң дә, кара аны, солдатка озатканда миңа биргән вәгъдәңне онытма.

Мәрьям. Көтәрмен дидем — көттем. Башка вәгъдәм юк. Ә бидоннар — Гөлүзәнеке. *(Вагонга уза.)*

Нури. Ялгыз булсаң, өйләнер дә идем. Артыңнан, кашыгын күтәреп, сукыр этиең дә килә дип тора шул. *(Кычкыра.)* Гөлүзә!.. Өти Балак!..

Миндар керә. Ямаулы чалбар, якасы беләүләнгән күлмәк кигән.

Миндар. Миңа да шул Гөлүзә кирәк иде. Катырак кычкыр әле, энем.

Нури. Минем тамак бетте. Син кычкыр, Миндар абый.

Миндар. Юк, иләк белән су китерергә куш — ташыйм, әмма аның исемен телемә алмыйм. *(Муенын кашып куя.)*

Нури. Муеныңда нинди тырнак эзләре ул?

Миндар. Йокыга гына китеп бара идем, хатын нитеп алды. Ярый әле, өйалдына йөгереп чыгып, ишекне теге яктан терәп котылдым.

Нури. Ни өчен?

Миндар. Шул хәерсез Гөлүзә инде. Авылга кайтып, Миндар абыйны хатыныннан аертам дип йөргән. *(Муенын кашый.)* Чакыр инде шул нине. Комбиазык китергән идем. Бүтән кызлар үзләренә

тиешлесен алдылар. Анықы гына арбада калды. Су нитәргә утын да алып чыгасы бар, аты кирәк.

Нури. Ашыккач, Балакка дигәнен үзең бушат.

Миндар. Нигә анықын бушаттың дип, хатын тагын муеннан нитсә? Анықын әллә үзең бушатасыңмы, энем!

Нури. Мин — мөдир!

Миндар. Булсаң соң, синең хатының юк ич.

Нури. Мәрьямгә әйт. Нури кушты диген.

Миндар. Мәрьям тыңлар ул. *(Вагонга керә.)*

Нури. Сыеры көтүдән качкан, бидоны юмаган, азыгы алмаган, кайда булыр бу Балак?

Миндар белән Мәрьям торактан чыгалар.

Аты кирәк, елт булыгыз.

Мәрьям. Син кушкач, утына да керәбез инде, жаным.

Китәләр, еракта әкрен генә кыңгырау тавышы ишетелә. Шуны тыңлый-тыңлый Ситдыйк керә.

Ситдыйк. Куян кыңгыравы!

Нури. Балак таккан ич.

Ситдыйк. Такмаган иде.

Нури. Такмаган кыңгырау ничек шылтырасын? Карап тор: сыерны менә ничек табалар! *(Китә.)*

Ситдыйк *(ул баскан эзгә карап)*. Шул чәчәкләрне бөтен кеше әйләнеп уза иде — имгәтте.

Чәчәкләр өзә. Мәрьям керә.

Мәрьям. Чәчәкләрне кемгә өзәсең?

Ситдыйк. Яңа танкеткаларыңны котлап! Мә. *(Чәчәк бирә.)*

Мәрьям. Күлмәгемне дә котла инде, яңа бит.

Ситдыйк. Узган ел гына алдым диген.

Мәрьям. Барысын да күзәтеп кенә торасың.

Ситдыйк. Күзеңдә ничә керфек икәнен дә беләм.

Мәрьям. Ничә?

Ситдыйк. Бер йөз алтмыш дүрт.

Мәрьям. Тәк кенә әйтәсең.

Ситдыйк. Ышанмасаң, санап күрсәтәм.

Мәрьям. Юк, башта синекен саныйк.

Ситдыйк. Рәхим ит.

Мәрьям *(санап)*. Бер, ике, өч... Кирәкми лә, күзгә күз карарга туры килә икән.

Ситдыйк. Куркак.

Мәрьям. Хыялыңда йөрткән кыз түгел инде.

Ситдыйк. Ул булса!.. Бер нәрсә күрсәтәм.

Чыга, чыбыктан үрелгән тирбәлгеч урындык күтәреп керә.

Үзем эшләдем. Утыр әле.

Мәрьям *(утырып)*. Уңайлы. Тирбәтеп тә җибәр инде. *(Ситдыйк тирбәтә.)* Дулкыннар өстендәге кебек. Кемгә язган урындык икән?..

Ситдыйк. Әтиеңә бу, Мәрьям.

Мәрьям. Әтигә?

Ситдыйк. Үзең өйдә вакытларда аны бакчага алып чык. Аркасын терәп, тирбәлә-тирбәлә авыл шавын тыңласын.

Мәрьям. Әти бигрәк олыгайды шул. Күзләре генә бераз күрсә дә... Үзе, мине картлар йортына илт, кызым, ди дә...

Ситдыйк *(сынау өчен)*. Монда да эшең күп. Илт.

Мәрьям. Бу акылыңны хыялыңдагы кызың бирдеме?

Ситдыйк. Ул андый түгел.
Мәрьям. Ниндирәк соң ул?
Ситдыйк. Кара чәчле, кара кашлы, көләч... ачулана да, үпкәли дә. Ә берсендә, кешеләр үзен юкка рәнҗеткәч, ул елады.
Мәрьям. Аны кызганып син дә еладыңмы?
Ситдыйк. Юк, мәнә болай чәченнән генә сыйпап тордым. *(Мәрьямнең чәченнән сыйпап күрсәтә.)*
Мәрьям. Телең белән генә аңлат. *(Ситдыйкның кулына сугам дип ялгыш битенә суга.)*
Ситдыйк *(битен каплап)*. Ай, күземне чыгардың.
Мәрьям *(коты очып)*. Ситдыйккаем, ялгыш бит, ялгыш...
Ситдыйк *(йөзеннән кулларын алып)*. Ха-ха-ха...
Мәрьям *(шатланып, Ситдыйкны кыйный-кыйный)*. Үтерәм...
Ситдыйк *(аны туктатып)*. Кулыңны авырттырырсың.
Мәрьям *(кулындагы чәчәккә карап)*. Бал корты!.. Безнең авылныкымы икән?
Ситдыйк. Булачак киявең Нури умартасыннан.
Мәрьям *(битен тотып)*. Чакты, тизрәк угын ал.

Ситдыйк ук ала. Нури керә. Бу күренештән «үбешәләр» дигән фикергә килә, кыңгыравын шалтырата. Мәрьям сискәнә.

Мине корт чакты.
Нури. Нәкъ үптерә торган җирдән чаккан икән.
Мәрьям. Авыртыр инде, әйеме, Ситдыйк?
Ситдыйк. Авыртмасын иде инде. *(Нурига.)* Куянны тапмадыңмыни?
Нури. Табарга, качкын сыер егет көтеп вагонда утыра торган кыз түгел бит ул.
Мәрьям. Көтәрдәй егетне нигә көтмәскә? *(Вагонга керә.)*
Ситдыйк *(кояшка карап)*. Кыздыра.
Нури. Кыздырса, сиңа салкынча булсын дип, костюмым белән кояшны каплап тора алмыйм бит инде.
Ситдыйк. Сөт кимемәсен дип кенә әйтүем.
Нури. Көтүеңне куләгәдәрәк тот.
Ситдыйк. Киңәшең өчен рәхмәт. Сыерларны тал ышыгына куып кертәм дә, койрыкларыннан тотып тик утырам. *(Китә башлый.)*
Нури. Ни өчен сыерларны өченче төбәккә күчермисең? *(Тактага күрсәтеп.)* Һаман шулай ун кило белән утырырбызмыни?
Ситдыйк. Барлык төбәкләрне дә бер айда таптатып, соңыннан сигез килога тәгәрикме?
Нури. Йөрер җирең булмагач, 20 гектар көтүлекне боздырып үлән чәчтермәсләр.
Ситдыйк. Шул 20 гектарга каңыгып аптырадың инде. Кайда булыр бу Куян? *(Китә.)*
Нури *(бидонга күзе төшеп)*. Кайда булыр бу Балак?

Торактан Мәрьям чыга.

Мәрьям, бүген артистлар бит. Билетны да мин алырмын. Балакны гына тап әле.
Мәрьям. Билетны кыстырмасаң, мине эзләмәс дип уйлыйсың инде. *(Күреп.)* Кем килә?
Нури *(карап)*. Газеттан хәбәрче түгелме? *(Мәрван керә. Өстендә ак күлмәк, утюкләнгән чалбар, сары туфлиләр.)*
Мәрван. Исәнмесез?
Нури *(сүзне үзенә алырга теләп)*. Ял итәбезме, дус кеше?
Мәрван *(җавап бирмичә)*. Урыныгыз матур икән...
Нури. Үзем сайладым!

Мәрван. Утарларыгыз гына кәй күренә — баганалары кыйшая башлаган.

Нури. Көзгә таш баганалысын җиткертәм.

Мәрван. Әйбәт булыр. *(Бидоннарны карый башлый.)* Бидоннарыгыз...

Нури *(Гөлүзә бидонын газет белән каплап)*. Бер генә тузан кунсын, шунда ук яңадан юдыртам. *(Тактага борылып.)* Монда күрсәткечләр. Үзем язып барам.

Мәрван *(карап)*. Исмәгыйлова Мәрьям — көнгә уңдүртәр кило!

Нури. Мәрьям — минем ферманың маягы!

Мәрван. Гөлүзә дигәнегез сигезәр генә кило ала икән. Яшь савымчымы әллә?

Нури. Нинди яшь! Бүген үк кияүгә биреп җибәрсә иде шул Әти Балакны.

Мәрван. Кемне дидегез?

Нури. Әти Балакны дим. Безнең якта үз балагын да юа алмаган хатын-кызны Әти Балак дип йөртәләр.

Мәрван. Сыерларны аерым рацион буенча туйдырасызмы?

Нури. Бөтенесен дә төпченәсең, син кем соң, дус кеше?

Мәрван. Танышыйк. Исемем Мәрван, фамилиям Вафин. Сезнең колхозга зоотехник булып килдем.

Нури. Шулаймыни! Мин — Нури Кашапов. Мөдир!

Мәрван. Бу юылмаган бидон кемнеке?

Нури. Әнә шул Әти Балакныкы инде.

Мәрван. Утарыгызның да бер бүлеме чистартылмаган.

Нури. Анысы да Балакныкы.

Мәрван. Бер сыерыгыз көтүдән качкан димә?

Нури. Анысы да Балакныкы.

Мәрван. Көтүегез кай тирәдә?

Нури. Әнә анда. Ат белән генә барабызмы?

Мәрван. Мин тәпиләп кенә. Үз эшегезне карагыз. *(Китә.)*

Нури. Генералларча сөйләшә.

Мәрьям. Куркак солдатка ефрейтор да генерал булып күренә, ди.

Нури. Совет Армиясендә куркак солдат юк, иптәш Исмәгыйлова. Елт кына Гөлүзә утарын чистарт.

Мәрьям. Аның өчен мин эшләргә тиешме?

Нури. Утарын үзем чистартам, бидонын син ю.

Мәрьям *(күреп)*. Әнә, үзе дә килә.

Китә. Гөлүзә керә. Толымнары ярым сүтелгән, аягында чүәге тишек. Нурига игътибар итмичә вагонга юнәлә.

Нури *(ачу белән)*. Исәнмесез, мәмзел?

Гөлүзә *(мыскыллап)*. Исәнмесез, сэр.

Нури. Сэр түгел, мөдир!

Гөлүзә. Булсаң ни!

Нури. Кайда яттың дим?

Гөлүзә. Ятмадым, су буенда бер егет белән утырдым.

Нури. Кила инде синең янына егет...

Гөлүзә. Чакырсам, үзең дә килерсең.

Нури. Синең кебек кызга караганчы, биш бала анасы яхшырак.

Гөлүзә. Бирсен ходай: биш балалы хатынга өйлән.

Нури. Тфү... *(Күрсәтеп.)* Синең бидоннармы?

Гөлүзә. Укалары коелганмы әллә?

Нури. Ю.

Гөлүзә. Эчләре чиста аларның.

Нури. Тышлары да чиста булсын.

Гөлүзә. Тышына сөт салынмый.
Нури. Сыерларыңның аслары да чистартылмаган.
Гөлүзә. Чуэгемнең башы сүтелгән икән. Бармакларым күренеп тора.
Нури. Бармагыңны карау өчен чакырмадым мин сине.
Гөлүзә. Карама.
Нури. Куяның югалган
Гөлүзә. Югалса ни.
Нури. Эзлә.
Гөлүзә. Рәхәт булса, үзең эзлә.
Нури. Әйткәнне тыңлыйсыңмы, юкмы?
Гөлүзә. Тыңлап торам бит инде.
Нури. Комсомол секретаре: «Эш белән төзәлер ул», дип, кайлардан муеныма китереп такты үзеңне? Иртәгә үк куам.
Гөлүзә. Кусәгеңне бүген әзерләп куй.
Нури. Яңа зоотехник килде. Ничек эшләгәнеңне белсә...
Гөлүзә. Белсә ни.
Нури. Ул — егет кеше.
Гөлүзә. Булса ни.
Нури. Тфү!.. *(Кычкырып.)* Утарыңны чистарт!
Гөлүзә. Акырмасана.
Нури. Өти! Балак!
Гөлүзә. Кушаматым исемемнән матуррак. Башка белән бутамыйлар.
Нури. Яшен дә сукмый бит үзеңне.

Китә. Мәрьям керә.

Мәрьям *(хәрәкәтсез утырган Гөлүзәгә)*. Нинди уйга баттың?
Гөлүзә. Җиң төбем ертылган.
Мәрьям. Яма.
Гөлүзә. Төшеп калмас әле.
Мәрьям. Бидоннарың...
Гөлүзә. Әйттеләр. Юмыйм.
Мәрьям. Мин булышыйм алайса. *(Юа.)*
Гөлүзә. Үзең юып, мине оялтырга телисең, янәсе.
Мәрьям. Нигә үзең эшләмисең?
Гөлүзә. Ә ни өчен эшләргә?
Мәрьям. Әйтик, акчасы булыр.
Гөлүзә. Акча нигә кирәк ул?
Мәрьям. Кием алырсың.
Гөлүзә. Ә кием нигә кирәк?
Мәрьям. Нигә дип... кием кешене матурлый.
Гөлүзә. Ә матурлык нигә кирәк?
Мәрьям. Кызык син. Егетләрне гашыйк итәрсең.
Гөлүзә. Ә егетләр нигә кирәк?
Мәрьям. Тормышка чыгарсың.
Гөлүзә *(Мәрьям фикерен дәвам итеп)*. Ана булырсың, картаерсың. Үләрсең. Күмәрләр. Тормыш дигән кәмитнең шулардан гына торуын белсәм, туып азапланмас идем. Яшәүнең мәгънәсен күрмим. Шуңадыр инде, эшкә дә кул бармый. Ник тудым икән мин?
Мәрьям. Кеше бәхетле булыр өчен туа, ә моның өчен эшләргә кирәк.
Нури тавышы. Мәрьям, Мәрьям...

Мәрьям китә. Кыңгырау тотып Ситдыйк керә.

Ситдыйк. Монда икәнсең.
Гөлүзә. Монда шул.

Ситдыйк. Нигә кыңгыравыңны такмадың?

Гөлүзә. Үземә кирәк. Агач ботагына эләм. Җил искән саен, ул— дин-даң, дин-даң... Поклап китүе рәхәт тә инде. Бүген кем алды дисәм... Бир әле...

Ситдыйк. Куяның сазга баткан.

Гөлүзә. Батса, сөйрә дә чыгар.

Ситдыйк. Үлгән ул.

Гөлүзә. Котылганмын икән. Урыны оҗмахта булсын.

Ситдыйк. Оҗмахта түгел, сазда.

Гөлүзә. Ул имгәккә сазы да әрәм.

Ситдыйк *(аптырап)*. Беребезгә дә охшамагансың.

Гөлүзә. Охшамам да. Синең кебек урта мәктәп бетерсәм, монда көтүче булып ятыр идемме соң, дивана.

Ситдыйк. Шул сүзеңне телгә алма дип, ничә мәртәбә әйттем.

Гөлүзә. Нинди сүзне? Ә, дивана дипме?

Ситдыйк. Рәтләп кенә сөйләшик әле, Гөлүзә.

Гөлүзә. Әйдә. *(Озын пауза. Сүз юк.)* Яраткан кызың да үзең шикелле дивана булырмы икән синең?

Ситдыйк. Тагын!.. Сыер муенына кыңгырауны менә болай тагалар.

Гөлүзә. Кит, кит...

Ситдыйк аның муенына кыңгырау тагып китә. Гөлүзә аны чишәргә азаплана. Мәүлидә керә. Кыңгыраулы кызына гаҗәпсенеп карый. Гөлүзә аны күрми. Кыңгыравын шалтырата-шалтырата эскәмиягә барып утыра.

Мәүлидә. Эстәгафирулла! Нишләп кыңгырау киден?

Гөлүзә. Кимәдем, тактылар.

Мәүлидә. Ферманы ташлап качмасын дигәннәрдер инде.

Гөлүзә. Чиш әле, әни.

Мәүлидә. Киявең булачак кеше чишсен.

Гөлүзә *(хәтере калып)*. Минем андый кешем юк.

Мәүлидә. Ә Миндар абыең? Ирем белән бутала дип, хатыны урам тутырып сине сөйләп йөри.

Гөлүзә *(читкә борылып)*. Ну бу Кандаланы! Җанын алам.

Мәүлидә. Фермага семья бозу өчен килдеңмени?

Гөлүзә. Мин сыерлар савам.

Мәүлидә *(күрсәткечләрне карап)*. Савам дип әйтерлек кенә савасың шул.

Гөлүзә. Сыер дип биргәннәре кәҗә генә булгач...

Мәүлидә. Халатын да ямамаган кызга мин кәҗәсен дә бирмәс идем. Нигә рәтләп эшләмисең?

Гөлүзә *(тырыша торгач кыңгыравын чишеп)*. Кызыгы юк.

Мәүлидә. Ике ел буена бер күлмәк тә алып бирмәдемме!

Гөлүзә. Бирмәсәң ни.

Мәүлидә. Эшләмәсәң, баш яулыгы да өмет итмә.

Гөлүзә. Берегездән бер нәрсә өмет итмим. Кирәге дә юк.

Мәүлидә. Бел, бала: моннан да кусалар, мәҗбүр итеп эшләтә торган җиргә озаттырырмын.

Гөлүзә. Озаттырсаң ни.

Мәүлидә Гөлүзәгә сукмакчы була, Гөлүзә, өйрәнелгән гадәт буенча, борылып өлгерә.

Мәүлидә. Бу бала ятимлек сизмәсен дип, уналты яшеңә кадәр чәчеңне дә үзем тарап үстердем. Кулъяулыгыңны да мин юдым. Беркемнән дә, хәтта укытучыларыңнан да бер сүз әйттермәдем. Хәзер сиңа уңкидә. Беләгеңдә көчең бар. Тормыш дәрьясын үзең кич. Я йөзеп якты ярга чык та, рәхәт гомер кичер, я бат, бет!

Китә. Миндар керә. Гөлүзәне күреп, китәргә тели.

Гөлүзә. Кая ашыгасың, Миндар абый?

Миндар. Нурины эзли идем дә...

Гөлүзә. Сазга йөгерде. Сиңа монда көтәргә кушты.

Миндар. Атым нитә... *(Китәргә тели.)*

Гөлүзә *(җибәрмичә).* Мөдир кушкач, көтәсең. *(Утырта, үзе янәшә утырырга тели.)*

Миндар. Син теге якка утыр инде, миннән силос исе нитә.

Гөлүзә. Таныш ис. *(Карап.)* Нишләп син Камали абыйның мич чыгаргандагы чалбарын киден?

Миндар *(чалбар ямавын кулы белән каплап).* Син, нәрсә, Камали чалбарын кияргә мин... Үземнеке!

Гөлүзә *(Миндар кулындагы балтага карап).* Бу балтаңны күлмәк якаңа кайрадыңмы?

Миндар. Ни дә инде син... *(Китәргә тели.)*

Гөлүзә. Аер Кандаланны.

Миндар. Шундый ипле хатыннымы?

Гөлүзә. Барыбер бергә яшәтмим.

Миндар. Ни өчен?

Гөлүзә. Минем гайбәт белән авыл тутырып йөргәне өчен.

Миндар *(чигенеп).* Минем хатын гайбәт сөйли торган ни түгел. Авызыңны ул чәп ач, яме! *(Китә.)*

Гөлүзә *(Миндар кесәсеннән төшеп калган акчаны алып).* Акча! Кичә шул кесәсеннән папиросын төшереп калдырган иде. *(Уйлап.)* Миндары акча алган көнне Кандаласы килми калмас.

Китә. Сөйләшеп Мәрван белән Нури керәләр.

Мәрван. Мин әйткән сыерларны бүгеннән башлап көтүгә чыгармаска. Утлап ашый алмыйлар.

Нури. Үлән чабып туйдырыргамыни?

Мәрван. Әйе.

Нури. Булмас эш белән баш катырганчы, кулыңнан килсә, әнә, саву аппараты тик ята. Башта шуны көйләп күрсәт.

Мәрван. Анысын да көйләрбез. Кайбер сыерларның имчәкләре, тешләп кенә тартмасаң, бармакка эләккечле түгел. Нәселлеләрне алырга кирәк.

Нури. Ал, ал. Мин каршы түгел.

Мәрван. Шушындый көтүлекләр белән районда үндүртенче урында ятырга...

Нури *(мыскыллап).* Иртәгә үк беренче урынга чыгабыз, иптәш Вафин.

Ситдыйк керә.

Ситдыйк. Тапмадым.

Нури. Ну бу Балакны!..

Гөлүзә керә.

Куяныңны таптыңмы?

Гөлүзә. Мин аны эзләмәдем дә. *(Мәрванга карап.)* Зоотехник дигән адәмегез шушымыни инде?

Нури *(Мәрванга).* Ферманы җан-фәрманга арткa сөйрәүче бәндә менә шушы инде.

Гөлүзә. Дөрес, стена газетына да шулай дип язганнар.

Ситдыйк. Гөлүзә, Куянны эзләш әле.

Гөлүзә. Миңа нәрсәгә ул. Үлсә — Нури белән син җавап бирәсе. Сез эзләгез.

Нури. Нигә бу кадәр әшәкеләнәсең?

Гөлүзә. Сине яратканга.

Нури. Ирең булсам, тәнеңнен кара янмаган жирен калдырмас идем. *(Ситдыйкка.)* Әйдә, кешеләр бирәм.

Нури белән Ситдыйк китәләр.

Мәрван *(кул биреп)*. Танышыйк: минем исемем Мәрван.

Гөлүзә. Минеке Өти Балак.

Мәрван. Андый исем булмый.

Гөлүзә. Әй, булмаска, безнең авыл — кушаматлар бакчасы. Сиңа да берне табыйммы?

Мәрван. Тырышып карагыз.

Гөлүзә. Әй, андый эшкә күп тырышлык кирәкми. *(Мәрванны әйләнеп чыга.)* Тәти!

Мәрван. Ни өчен Тәти?

Гөлүзә. Күлмәгең дә тәти, чалбарың да тәти.

Мәрван. Сез тәтине яратмыйсызмыни?

Гөлүзә. Дөньясын утка очырыр идем. Берегезне бер күрәсем килми.

Мәрван. Сез ничек яшисез?

Гөлүзә. Яшәмим мин. Аптыраганнан тик йөрим шунда.

Мәрван. Ә шулай да дөнья матур, Гөлүзә.

Гөлүзә. Сыер, тирес... Шулмы матур дөнья?

Мәрван. Дөнья ул үзенең кешеләре белән матур, сеңелем.

Гөлүзә. Кешеләр?.. Кайда соң алар? Һәр узганга бакырып кала торган Нури кешеме? Урта мәктәп тәмамлап та, чыбыркы шартлатып йөргән Ситдыйк кешеме? Төннәрен дә сыер белән саташа торган Мәрьям апа кешеме? Юк, кешеләр юк бу дөньяда.

Мәрван. Үзегез дә кеше түгелме?

Гөлүзә. Мин дә кеше түгел, син дә кеше түгел, эштәге хайваннар гына без.

Мәрван. Кешеләр без, Гөлүзә. Чәчләрегезне тарап жибәрегез дә, әнә, көзгегә карагыз: шунда ук кеше иканегезгә, чибәр иканегезгә ышанырсыз.

Гөлүзә. Чибәр... Килеп житмәс борын кызлар алдында койрык болгый башладың. Шома булырга охшыйсың.

Мәрван. Алама агач кына ботакка үсә.

Гөлүзә сыер имчәкләре сөртергә баудан сөлге ала.

Сөлгегез юмаган түгелме соң?

Гөлүзә. Юган.

Мәрван *(сөлгене алып карый)*. Юмаган.

Гөлүзә *(сөлгене кире тартып алып)*. Материалы гына шундый аның. *(Китә башлый.)*

Мәрван. Эш урыныгызны миңа да күрсәтегез әле.

Гөлүзә. Эч поштырып йөрмә. Сыер сөзәр.

Мәрван. Сөзсә дә барам, сөзмәсә дә барам.

Гөлүзә. Тик торырга чыдамасаң, ал әнә ул бидонны.

Мәрван. Дорфа сөйләшмәгез.

Гөлүзә. Моны да тупас дисәң... Безнең ызгышканны тыңлап торсаң менә — ирләр колакларын томалап читкә чабалар! *(Бер генә бидон күтәргән Мәрванга.)* Алыптай гәүдәң белән, оялмыйча, берне генә күтәреп йөрерсең икән. Икесен дә ал!

Мәрван. Беренче юлга берсе дә житәр. *(Китә.)*

Гөлүзә. Минем кебек тискәрегә тегелгән нәрсә икән.

Икенче бидонны үзе ала, китә. Сәкинә керә. Кулында төен. Пехтә киенгән. Утыра, туфлиен салып бармакларын уа.

Сәкинә. Бу терлекчеләрнең аягы ничек чыдый? Аена бер киләм, анысына да түзәр хәл юк.

Миндар керә.

Миндар. Карчыгым килгән икән әле.
Сәкинә *(аягын сузып)*. Бармакларымны у әле.
Миндар. Киләсеңне ниткән булсам, ат белән кайтып алыр идем.
Сәкинә. Каты басма, авырттырасың.
Миндар. Юк, мин җайлап кына. Өф, өф... *(Уа.)*
Сәкинә. Җитәр, кидер.

Миндар туфли кидерә. Сәкинә, төен күрсәтеп.

Сиңа! Нәрсә икәнен белмәсән, кире алып китәм.
Миндар. Майлы бәрәңге... Чикмәнле бәрәңге... Ярып пешергән бәрәңге...
Сәкинә. Кәтлит!
Миндар. Кәтлит?! Столовойдан ниттеңмени?
Сәкинә. Шуннан алдым. Ә монысы! *(Чирек литр аракы күрсәтә.)*
Миндар. Әт-тә-тә... Монда бик азын гына нитәм дә, калганын өйгә кайткач...
Сәкинә. Бетереп эч. Иренә ел буена йөз грамм да күрсәтми дип мырламасыннар.
Миндар. Хәерле булсын алайса. *(Шешәгә сузыла.)*
Сәкинә *(бирмичә)*. Акча алдыңмы?
Миндар. Алтмыш сум!
Сәкинә. Исереп югалтканчы миңа биреп куй.
Миндар. Кырыгын бирәм, карчык, егермесе миндә калсын.
Сәкинә. Мамык шәл өчен йөз сум түлисе бар.
Миндар. Миңа егерме сумы гына.
Сәкинә. Ул кадәр акча сиңа нәрсәгә?
Миндар. Күлмәгең каткан, диләр. Камали чалбарын кигәнсең, диләр. Көләләр.

Гөлүзә керә, бәхәсне тыңлый.

Сәкинә. Кем көлә?
Миндар. Гөлүзәсенә кадәр көлә.
Сәкинә. Менә кем өчен киенергә телисең икән син! Акчаны бир дип бер әйттемме?
Гөлүзә. Акча кирәк булгач, үзең эшлиләр аны.
Сәкинә. Кысылма, сытылырсың.
Гөлүзә. Мин эшләп яшим, ә син менә, чыннан да, кысылып кына. Тиенен дә бирмә, Миндар.
Миндар. Ни диген, абый диген.
Гөлүзә. Минем өчен Миндар инде син, Миндар. Төкер, малай, Кайдаланның чирек литрына. Кичкә үзем яртыны алам.
Миндар. Тукта әле...
Гөлүзә. Сине Нури чакырды. Әйдә! *(Култыклый.)*
Сәкинә. Нигә аңа култыгыңны бирәсең? *(Миндарны тартып ала.)*
Гөлүзә. Култыгын гына түгел, үзен дә алам. *(Миндарга.)* Шулай бит, җаным. *(Миндарны үбеп тә ала.)*
Сәкинә. Шул Балакка өйләнәсеңме?
Гөлүзә. Нигә өйләнмәсен! *(Миндарга.)* Мин сине яратам. Син дә мине яратасың, бәгырем. *(Сәкинәгә.)* Алдагы атнага туебыз.
Сәкинә. Юри мырлыйсың. Сине гомердә алмаячак ул.

Гөлүзә. Сине, дүрт ирдән калган хатынны алганны, нишләп минем алмасын ди?!

Миндар *(Сәкинәгә)*. Ул болай гына, нитеп кенә... Синеке генә мин, Сәкинә, синеке генә...

Гөлүзә. Аныкы булгач, нигә аңа акчаңны бирмисең, ә?

Сәкинә. Дөрес шул. Акчаңны бир.

Миндар. Тиенен дә калдырмый бирәм, карчык. *(Акча эзли.)*

Сәкинә *(акчасын таба алмаган Миндарга)*. Тизрәк мыштырда.

Миндар *(таба алмыйча)*. Ниткән бугай бу, карчык...

Гөлүзә. Югалганмы?

Миндар. Югалган шул. *(Сәкинәгә.)* Үзең кесәсен ямамадың да...

Сәкинә. Ялганлама, югалмаган, Балагыңа биргәнсең.

Гөлүзә. Дөрес. Менә бу кесәмә салдым.

Миндар. Болай итеп, хатынымнан яздырасың бит, Гөлүзә.

Гөлүзә. Яздырасың дип, моңа кадәр өйләнәм дип йөрдең дә, көне җиткәч кенә өйләнмәс идеңме әллә? *(Сәкинәгә.)* Миндарның акчасы миндә. Элек безгөнаһы яманатымны саткан идең, хәзер инде курыкмыйча сөйлә. Акчасы да минеке, үзе дә аягы-тоягы белән минеке. Минеке! *(Китә башлый.)*

Сәкинә *(Гөлүзәне толымыннан эләктереп)*. Акчаны бир!

Гөлүзә. Җибәр чәчтән! *(Сәкинәнең битен тырнап ала.)*

Миндар *(алар тирәсендә йөгергәләп)*. Сугышмагыз... Ярамый... Үтерешәләр!

Тавышка Нури, Ситдыйк, Мәрван һәм Мәрьям керәләр.

Ситдыйк. Нишлисез? *(Аера.)*

Сәкинә *(Мәрванга)*. Күзем чыкмаганмы?

Мәрван. Теге тирәкне күрәсеңме?

Сәкинә. Күрәм.

Мәрван. Димәк, чыкмаган.

Мәрьям *(Гөлүзәгә)*. Нәрсә кыландыгыз?

Гөлүзә. Нигә соң үзе, уйнашчы дип, минем исем белән урам тутырып йөри!

Читкә китә, күрсәтми генә күз яшен сөртә.

Нури *(Гөлүзәгә)*. Андый сүзе булса, башта миңа әйтерләр. Мин комсоргка әйтер идем. Комсорг парторгка җиткерер иде. Ә аннары колхоз председателе, авыл советы председателе беләчәк. Ә аннан соң милиционерга...

Гөлүзә *(бүлдереп)*. Иде, иде... Кандаланың каныңны эчкәнен бүген генә ишеттеңмени? Нигә авызыңа каз мае кабып йөрдең? Хәер, миңа ни әйтсәләр дә бата шул. Үзегезгә генә кагылмасыннар. *(Яшьләрен күрсәтмәс өчен ашыгып чыга.)*

Сәкинә *(көзгегә карап)*. Чыраемның карар җирен калдырмаган. *(Миндарга.)* Кәтлите синә төс түгел, аракысына да ия табылыр. *(Төенен бәйли, китә башлый.)*

Миндар. Карчык...

Сәкинә *(артыннан ияргән Миндарга)*. Кит әле янымнан!.. *(Миндар читкәрәк китә.)* Бөтенләй кит!

Мәрьям. Иреңне рәнҗетәсең, Сәкинә апа. Борынгылар әйтмешли, алла орыр.

Сәкинә. Ору түгел, муенымны борса да өйгә кертмим мин ул жәфаны. *(Миндарга.)* Икмәк пычагының кайрап куелганын беләсеңме?

Миндар. Беләм инде, тавык суйдыртам дип кайраткан идең...

Сәкинә. Әҗәлсез үләсең килмәсә, кайтма, Балагың белән тор. *(Китә.)*

Миндар *(башын тотып)*. Кайларда кунармын?

Ситдыйк. Безгә кайтырбыз, Миндар абый.

Миндар. Өенннән хатыны куып чыгарган дигән гарьлеге дә бар бит әле анын...

Мәрьям. Үзем ташлап чыктым диярсен.

Миндар. Авыл советына чакыртып, хатынынны ник ташлап чыктын дип тирги башласалар?

Ситдыйк. Тиргәмәсләр. Көйләрбез.

Миндар. Аңламыйсыз. Сәкинә кыз бала. Ялгыз йортта ялгыз башы. Курыкса, йоклый алмаса?

Нури *(уйлап торганнан соң)*. Сугышны беренче булып кем башлады?

Миндар. Ни инде, Гөлүзә инде.

Нури. Минем фермада сугыш чыгарып, мине хур итте. Семья бозды. Бидонын юмый, утарын чистартмый, шул дәрәҗәгә төшеп житте ки, хәтта югалган сыерын да эзләми. Ферма советының дүрт члены монда. Тавышка куям. Балакны куарга дигәннәр кул күтәрә.

Мәрьям. Башкалар да куды, без дә кусак, кая барыр ул бала? Башта шунысын уйла. *(Китә.)*

Ситдыйк. Комсомол секретарена «Гөлүзәне карармын, ярдәм итәрмен»,— диден бит. Сүзеңдә торуын шулмыни? *(Китә.)*

Нури. Миндар абый нәрсә әйтер?

Миндар. Нәрсә әйтер дип, ни инде...

Нури. Ни?

Миндар. Кусан да ни инде, кумасаң да ни. Үзең кара инде, энем. *(Китә.)*

Нури. Я, зоотехник, нишләтәбез бу Балакны?

Мәрван. Кешене жәлләргә кирәк.

Нури. Балак шикеллесен дәме?

Мәрван. Аннан яманракларын да яратыйк.

Нури. Яратыйк?! *(Уйлый, үзенчә нәтиҗә ясап.)* Гөлүзәнең кашы да кара инде анын...

Мәрван. Кашы да кара, буе да зифа.

Нури. Әллә үзенә өйләнеп үк җибәрәсенме?

Мәрван. Сез аңа өйләнерсез.

Нури. Ни өчен син түгел?

Мәрван *(җавап тапмыйча)*. Мин өйләнгән кеше...

Нури. Үзең өйләнгән кеше, үзен яратам дисең. Ничек инде бу?

Мәрван. Мин кешеләрне яратыйк дим.

Нури *(үзенчә аңлап көлеп җибәрә)*. Ха-ха-ха... Аңладым, аңладым. Өйләнгән ирләргә Балак кебек кызлар да ярап тора шул.

Мәрван *(әрнеп, кире мәгънәдә)*. Дөрес аңлагансыз.

Нури. Ачуланма, дус кеше. Үтенечегезне канәгатьләндерәм. Балакны монда калдырам. Әмма үзе өчен дә, сөте өчен дә син җавап бирәсен.

Китә. Гөлүзә керә, яңа гына юган чәчен кесә көзгесенә карап тарый.

Гөлүзә *(көзгедән үзенә караган Мәрванны күреп)*. Нәрсә миңа без белән тишкәндәй текәлдең?

Мәрван. Бүген сезнең белән спектакльгә чыгам.

Гөлүзә. Кит аннан...

Мәрван. Китмим. Сезнең белән чыгам.

Гөлүзә. Башка егеткә вәгъдә куйдым.

Мәрван. Сезнең егетегез юк.

Гөлүзә. Синең генә ул кызын юк.

Мәрван. Бар. Ул — сез.

Гөлүзә *(карап торганнан соң)*. Син миңа ошамыйсын.

Мәрван. Нәрсәм ошамый.

Гөлүзә. Колакларың болай иттереп тора.

Мәрван. Сезнең дә күзләрегез пыяла ватыгы кебек зәңгәр.

Гөлүзә. Күк йөзе кебек зәңгәр диген.

Мәрван. Үзегезне матур дип әйтергә телисезме?

Гөлүзә. Матур шул. Мин синең ише генә түгел.

Мәрван. Миннән әллә ни артык җирегез дә юк. Бер сүз белән генә әйткәндә, без пар килгәннәр.

Гөлүзә *(эче елмаеп)*. Пар килгәннәр?.. Кызык кеше син. Ярар, спектакльгә миңа ияреп чыгарсың. Тик кара аны: клубта бүтән кызларга да күз уйнатсаң, холкым начар, нәрсә туры килсә, шуның белән бирермен.

Мәрван. Әгәр үзегез ялт-йолт карана башласагыз?

Гөлүзә. Озак уйлап торма. Бер кулың белән толымымнан урап тот та, икенчесе белән күземнән тубал очыр.

Мәрван. Үпкәләштән генә булмасын. Спектакльгә барганда нинди күлмәк киярсез икән?

Гөлүзә. Синең ишеләр өчен шушысы да бик таман.

Мәрван. Чынлап торып бер әкәмәт ясыйк әле, Гөлүзә. Мин дә фатир хуҗамның карачкысын чишендерәм. *(Көләләр.)*

Гөлүзә *(уйлап торган булып)*. Нинди күлмәгемне киим икән соң? *(Мәрванга, булмаган күлмәкләрен санап.)* Ефәгемнеме, йоннымы, капроннымы, нейлонныммы?

Мәрван. Крепдешинын.

Гөлүзә. Крепдешинның ни төслесен? Буйлысынмы, шакмаклысынмы, чәчәклесенме, яфраклысынмы, борчаклысынмы?

Мәрван. Борчаклысын.

Гөлүзә. Ә аякка?

Мәрван. Анысын белмим шул...

Гөлүзә. Ак оекбаш белән биек үкчәле туфли!

Мәрван. Сез кием сайларга бик оста икәнсез.

Гөлүзә. Алтынчы класста «Беренче театр» дигән пьеса укыган идек, шуннан өйрәнеп калдым. Үзең дә галстук тагарга онытма. Кызлар белән чыгасың бит.

Мәрван. Сөйләшкәндә бер-беребезне хөрмәт итеп «сез» дип сөйләшик.

Гөлүзә. Онытмасам шулай диярмен. Мине спектакльгә барышлый өйгә үзең кереп алырсың.

Мәрван. Нишләп?

Гөлүзә. Кыяфәтеңне әни дә күрсен. Алам-салам кеше белән йөргәнен әле дә атлатмый ул.

Мәрван. Әгәр мин ана салам гына булып күренсәм?

Гөлүзә. Беренче сортка үтмәсәң дә, икенче сортка үтәрсең әле. *(Кул биреп.)* Кичкә җидедә.

Мәрван. Җидедә. *(Китә.)*

Гөлүзә *(тантана белән)*. Гомерең буена егет карамас дип мыскыллыйлар иде. Күзләре маңгайларына менсен әле. Үч итеп, авыл егетләренә сәлам дә бирмим бүген.

Мәрьям керә.

Мәрьям апа, миңа борчаклы крепдешин күлмәгеңне биреп тор әле. Спектакльгә чыгарга. Кәтүк үкчәле туфлиең белән ак оекбашыңны да.

Мәрьям. Ул күлмәкне үзем киярмен дигән идем. Сиңа чия төслесен биримме?

Гөлүзә. Мәрьям апакаем, зинһар, борчаклысын. Теге тәти белән таныштым бит.

Мәрьям. Булмас ла.

Гөлүзә. Чәчрәпләр китим. Бүген барам дисәм, бүген үк ала.

Мәрьям. Исәбең чыгаргамы соң?

Гөлүзә. Берәр атна сынап карыйм әле.

Мәрьям. Ошаса чыгармын, ошамаса юк диген.

Гөлүзә. Аның кебек егет сезгә туры килсә, берегез дә ошаса дип тормас иде әле. Тавышы ук башка. «Сез» дип кенә сөйләшә. Синең Нурыеңа минем Мәрванымa житәргә кая ул!

Мәрьям. Беренче очрашудан соң ук башыңны җуйгансың.

Гөлүзә. Икебез дә бик башлы. Күлмәк кенә юк менә.

Мәрьям. Мәхәббәте чын булса, шушы күлмәгең белән дә яратыр ул сине.

Гөлүзә. Ул яратса да, мин моның белән чыкмыйм. Крепдешин кирәк миңа. Борчаклысы. Бир!

Мәрьям. Бирмим, Гөлүзә.

Гөлүзә. Мәрванны мин эләктердем. Шуңа эчең ут яна. Күлмәгеңне дә шул ачудан бирмисең. *(Китә.)*

Мәрьям *(башын чайкап)*. Акылыннан язган!

## *Икенче пәрдә*

Гөлүзәләр өе. Җиһазга таманрак булса да, чиста җыештырылган. Пәрдә күтәрелгәндә ачык сандык янында Мәүлидә. Кулына кызлар күлмәге тоткан килеш уйга талган.

Мәүлидә. Аңа дип алган булдым. *(Сандыктан туфлиләр алып.)* Җаннары гына юк бит. *(Шыгырдап капка ачылган тавыш.)* Кайтты.

Киемнәрне сандыкка бикли. Гөлүзә керә.

Гөлүзә. Уф...

Мәүлидә. Артыңнан кудыларммы әллә?

Гөлүзә. Үзем теләмәсәм, куганга гына йөгерә торган кешемени мин. *(Чишенә-чишенә.)* Ашау әзерме?

Мәүлидә. Плитә өстендә.

Гөлүзә ашыгып кашык, тәлинкә ала. Чүмечен, ялгышып, идәнгә төшереп җибәрә.

Итәгеңә ут капкандай кыланасың.

Гөлүзә. Уты да капты, карын да ачты. *(Аш салырга чыга.)*

Мәүлидә. Нәрсә булган моңа?

Гөлүзә *(аш күтәреп чыга)*. Ай, кулым пеште, пеште...

Мәүлидә *(өсталгә икмәк куеп)*. Ат белән капка төбендә көтеп тормыйлар үзеңне. Кабаланма. *(Карап.)* Ярты чүмеч аш белән... Өстим әле.

Гөлүзә *(тәлинкәсен бирмичә)*. Кирәкми. Күп ашасаң, йөргән чакта чап-чоп иттерә. *(Тончыга.)*

Мәүлидә. Ашыга торгач, тончыгып үләрсең әле, каһәр суккыры. *(Йомшак кына кундырып ала.)*

Гөлүзә *(тәлинкәсен этеп)*. Туйдым, рәхмәт. *(Тора.)*

Мәүлидә. Чәй эчмисеңмени?

Гөлүзә. Әллә балың бар?

Мәүлидә. Кайдан килсен ул безгә?

Гөлүзә. Варенье да алмагансыңдыр инде?

Мәүлидә. Акча калдырдыңмы соң?

Гөлүзә *(көзге каршында толымын сүтә, чәч тасмаларын әнисенә сузып)*. Үтүк белән бастыр әле, әни.

Мәүлидә. Элек бастырганнарым өчен дә үкенәм әле.

Гөлүзә *(тасмаларын урындык аркасында шомартып)*. Безгә яңа зоотехник килде.

Мәүлидә. Ниндирәк кеше?
Гөлүзә. Күмер күз, дуга каш, чәчләре дулкын-дулкын...
Мәүлидә. Чибәр икән.
Гөлүзә. Чибәр генә дә түгел, ифрат чибәр.
Мәүлидә. Алайса, озак эшләмәс, кияүгә китәр.
Гөлүзә. Ул егет кеше, әни.
Мәүлидә. Егет кеше?
Гөлүзә. Килү белән ферманы да карады, көтүлекләрне дә әйләнде. Аяклары Нуриныкы кебек камыт та түгел, Миндар абый кебек болай-болай да атламый. Китә инде туры гына басып, тып-тып атлап...
Мәүлидә. Әйбәт икән.
Гөлүзә. Әйбәт кенә дә түгел, ифрат әйбәт! Үзен күрү белән бөтен кызлар телсез калды.
Мәүлидә. Синең генә телең ачылган.
Гөлүзә. Шул егет бүген безгә киләчәк.
Мәүлидә. Монда нәрсә калган аңа?
Гөлүзә. Спектакль карарга барабыз. Үзем чакырдым.
Мәүлидә. Кызның өйгә егет чакырганын кайда күргәнең бар?
Гөлүзә. Юк белән бер тапкыр гайбәтемне тараттылар — житте. Кем белән киткәнемне, кая киткәнемне белеп тор.
Мәүлидә. Киләм дидеме?
Гөлүзә. Йөгерә-йөгерә киләм диде.
Мәүлидә. Акылга үзең кебегрәктер. Чакыргач, өеңдә күрсәтер нәрсәң булса иде.
Гөлүзә. Түшәм-идән сап-сары, моржа ап-ак.
Мәүлидә. Әниең кулы бит алар.
Гөлүзә. Булса ни. Гөлләребез дә шау чәчәктә.
Мәүлидә. Төпләренә берәр кашык су сипкәнең бармы соң?
Гөлүзә. Мондый тәрәзә пәрдәләре дә бездә генә.
Мәүлидә. Анаң кешедән сатып алгач.
Гөлүзә. Әмин аларның бөтенесен дә үзем эшләдем дип әйтермен.
Мәүлидә. Синнән алданрак мин әйтермен әле аңар.
Гөлүзә. Әни, миңа дип алган күлмәгең юкмы?
Мәүлидә. Юк.
Гөлүзә. Туфлиләрем дә юк.
Мәүлидә. Чистартып, чүәгеңне ки.
Гөлүзә *(чүәгеннән аяк бармагын күрсәтеп)*. Сүтелде дип кичә үк әйттем бит инде. Әни, оегынны гына бир әле.
Мәүлидә. Син эш кешесе, акча табасың. Үзең сатып ал. *(Кашыксавыт алып кухняга чыга.)*
Гөлүзә *(оек үкчәсе тишегеннән кул бармагын чыгарып)*. Ак оекбаш! *(Чүәкләрен карап.)* Биек үкчәле туфлиләр! *(Күлмәген карап.)* Борчаклы крепдешин!.. Авырдым дип бармый калсам?.. *(Ишек шакыйлар.)* Килеп тә житте... *(Башына сөлге урый, хәлсез тавыш белән.)* Керегез.

Миндар керә, башын марля белән чорнаган, кухнядан Мәүлидә чыга.

Мәүлидә *(карап)*. Нишләп икегез дә чалмалы?
Гөлүзә. Башым сызлый, спектакльгә чыкмыйм.
Мәүлидә. Сиңа нәрсә булды, Миндар?
Гөлүзә *(көлеп)*. Кандаласы балта белән баш сөяген җимергән.
Миндар. Юк инде, балта белән түгел инде...
Гөлүзә. Кисәү агачы белән генәмени?
Миндар. Баскычтан төшкәндә абынып киттем дә, шунда гына ниtте ул.
Мәүлидә. Йомышың бар идеме әллә, Миндар?
Миндар. Йомыш дип инде, сүз генә.

Гөлүзә. Сүзең булса, хатының белән бергә килегез.

Миндар. Ярый инде алайса... *(Ишеккә юнәлә.)*

Мәүлидә. Килгәч сөйләмичә китмә инде, Миндар.

Миндар. Мәүлидә түти, Гөлүзәгә әйт әле: безгә барып, Сәкинәне тынычландырып кайтсын.

Мәүлидә. Борчыган кешесе тынычландырсын.

Гөлүзә. Мин борчыдым аны. Сугыштык! Пыр тузып!

Миндар. Шуннан соң Сәкинә белән арабыз нитте дә китте. Эштән кайтып керүем булды — чөйдәге чүмечне алды да... *(Башын күрсәтеп.)* Менә. Чүмечнең сабы сынды.

Гөлүзә. Кайгырма. Кандалана үзем яңа чүмеч алып бирермен. Сабы сынмый торганын.

Миндар. Чүмече чүмеч, менә Сәкинәне әйт син. Елады, елады да пружиналы караватына бөгәрләнеп ятты. Йөрәгемә ябышты, бүтәкәм сызлый, үләм, диде, аннан сикереп торды да мине өйдән үк куып чыгарды. Мәүлидә түти, син олы кеше, фермада әйткәннәрем ялгыш булды, дип, Сәкинә янына Гөлүзә үзе барып кайтсын әле. Мине өйгә кертер иде.

Мәүлидә *(Гөлүзәгә)*. Нигә ир белән хатын арасын бозасың?

Гөлүзә. Тормасын андый үләт белән.

Миндар. Хатын табулары бик кыен бит.

Гөлүзә. Исең китмәсен, алсаң үзем чыгармын.

Мәүлидә. Кемнән сорап?

Гөлүзә. Хәзер бераү дә сорап чыкмый инде.

Мәүлидә. Менә сиңа! *(Гөлүзәгә сукмакчы була, тегесе борылып өлгерә.)*

Гөлүзә. Кандаласы әллә ниләр сөйләп йөргәч...

Мәүлидә. Ул сөйләсә дә, син сөйләмә.

Миндар *(китәргә җыенып)*. Ярар инде, минем өчен нитмәгез.

Мәүлидә. Миндар абыеңнан хәзер үк гафу үтен.

Гөлүзә. Башта хатынының телен тыйсын, аннан үтенермен.

Сәкинә керә, ялан баш, халат сәдәпләре рәтләп каптырылмаган.

Сәкинә *(берәүгә дә сәлам бирмичә)*. Чыгып китүен күргәч тә, Балаларга бара бу дип калган идем. *(Миндарга.)* Ай, җәфа...

Миндар. Алай итмә әле, жаным...

Сәкинә. Эндәшмә дип бер әйттемме мин сиңа!

Мәүлидә. Иреңнең безгә килүендә гөнаһ юк, Сәкинә.

Сәкинә. Кызың гөнаһ чүлмәге. Кәнтәйләнеп, законлы хатынның законлы ирен ул аерта. Ул аздыра. Ул мине иремнән тукмата. *(Миндарга күрсәтеп.)* Кызың чакырганга килеп, шулай җәелеп утырган ул.

Гөлүзә *(Миндарга)*. Мин чакырганга килдеңмени син?

Миндар. Юк инде, ни инде...

Мәүлидә. Кызым турында мондый сүзне тагын бер әйтсәң, иманды менә, газеткә бастырам. Ә хәзер — әнә ишек!

Сәкинә. Акчаны бирми китмим.

Мәүлидә. Нинди акча?

Сәкинә *(Миндарны күрсәтеп)*. Менә бу мәләвинне хәйләләп, Балагың аның акчасын алган.

Мәүлидә. Юк инде, юк. Ансын сөйләмә дә, ышанмыйм да.

Гөлүзә. Ышанма, әни. Миндар абыйның миңа бер тиен дә акча биргәне юк.

Сәкинә. Өйдә үзе әйтте. Бирдем, диде.

Миндар. Ниттем генә дидем бит мин.

Сәкинә. «Ниттем» — бирдем дигән сүз инде ул.

Миндар. Юк, «ниттем» — югалттым дигән сүз.

Мәүлидә. Минем кызыма синең акчаң нәрсәгә?

Сәкинә. Ничек нәрсәгә? Башына дисәң башына, өстенә дисәң өстенә юк. Коеп куйган ар як хәерчесе бит.

Мәүлидә. Аллага шөкер, башына да, өстенә дә бар. Менә дигәннәре.

Гөлүзә. Акчага да сездән байрак яшибез, әйеме, әни?

Мәүлидә. Шулай булмый ни, кызым!..

Сәкинә. Акчамны бирмәсәгез, милициягә барам.

Мәүлидә. Гомерең милиция юлында үтсен.

Гөлүзә. Тырыша торгач, төрмәсенә үк илтеп кертсен.

Мәүлидә *(Гөлүзәгә)*. Я, я, син тагын, язмаганны... *(Сәкинә белән Миндарга.)* Сау булыгыз.

Миндар. Әйдә, жаным.

Сәкинә. Синең аркада шушы көнгә калдым мин. Капкадан да керәсе булма. Балта белән башыңны чабып өзәрмен. *(Китә.)*

Миндар. Ситдыйкларда кунарга туры килер инде. *(Китә.)*

Мәүлидә. Миндар сиңа акча бирдеме?

Гөлүзә. Бирмәде.

Мәүлидә *(көянтә күтәреп)*. Дөресен әйт, юкса бәреп үтерәм.

Гөлүзә. Бирмәде.

Мәүлидә. Йөри дипданың чыкты, карак дип даның чыкты. Тагын ниләр генә ишетәсем бар икән син ләгънәт аркасында. *(Гөлүзәгә берничә тапкыр эләктереп тә ала.)*

Гөлүзә. Авырта бит!..

Мәүлидә. Сиңа киткән чыбык, утын итсәң, кыш ягарга житәр иде. Ни өйрәттем, ни өйрәттем, һаман акылга килмәдең. *(Кычкырып.)* Сөлгеңне сүт!

Гөлүзә. Хәзер инде башым чынлап авырта. Елыйсым да килә.

Мәүлидә. Таш белән аткан саен аш белән атарлар дип уйлаган идеңме әллә? Явызланган саен күбрәк еларсың.

Гөлүзә *(еламсырап)*. Кандала...

Мәүлидә. Берсе Кандала, берсе Дивана, син үзең генә әллә кем!

Гөлүзә. Дөресен әйтсеннәр.

Мәүлидә. Киемең юк, дусларың юк, телең — урам теле, эш сөймисең, нәрсәсе дөрес түгел?

Гөлүзә. Барысы да дөрес. *(Кульяулыгын ала.)*

Мәүлидә. Яулыгын гына кара син аның!

Гөлүзә. Юармын әле.

Мәүлидә. Көннәр буе су буенда ятып... Сиңа әйткәнче эткә әйтсәң... *(Суга китә.)*

Гөлүзә *(уйлап торганнан соң)*. Дөньясыка ачу итеп шушы өтек киемнәрем белән чыгам.

Тишек оегын кия. Мәрьям керә. Кулында төен.

Мәрьям. Исәнмесез.

Гөлүзә. Исән.

Мәрьям. Кеше кешене болай каршыламый.

Гөлүзә. Мин кеше түгел.

Мәрьям. Кеше булмыйча, кеше син.

Гөлүзә. Кеше булганыма күрә күлмәгеңне биргәнсең икән.

Мәрьям. Тормышта кием кирәклеген дә аңласын дидем.

Гөлүзә. Анысын аңладым. Калганнарын башка вакытта аңлатырсың. *(Бүлмәгә юнәлә.)*

Мәрьям *(төенен биреп)*. Мә.

Гөлүзә *(төенне сүтеп)*. Мин сораганнар... Рәхмәтнең ниндиен әйтим икән? Үз кызыма да синең исемне кушармын, Мәрьям апа.

Мәрьям. Әллә кайсы кирә. Киен инде.

Гөлүзә күрше бүлмәгә керә. Нури керә, кулында чиләк.

Нури. Исәнмесез... дисәм, кеше юкмыни?

Мәрьям. Кеше юк, мин генә бар.

Нури. Балак кайда?

Мәрьям. Күрше бүлмәдә.

Нури. Шулаймы. *(Бүлмәгә юнәлә.)*

Мәрьям. Ярамый. Киенә. Бу нинди чиләк?

Нури. Балакныкы. Үз искесен фермага илтеп ташлаган да аннан яңаны чәлеп киткән.

Мәрьям *(карап)*. Бу — ферма чиләге.

Нури. Ферманыкыларның кыналарына игәү белән берәр сызык сыздым. Моның сызыгы юк.

Мәрьям. Онытылып калгандыр.

Нури. Калмаган. Балак алыштырган.

Мәрьям. Аермачык беләсеңме?

Нури. Шул хәерчедән башка бүтән кем урласын?

Мәрьям. Гөлүзә спектакльгә җыена, чиләгең белән кәефен бозма.

Нури. Кәеф дип... Җәмәгать милкен сыерларны саклагандай саклarга тиешбез. Ул бер чиләкне, син икенче чиләкне...

Мәрьям. Җитте. *(Чиләкне өй алдына чыгарып куя.)*

Нури. Аннан алып китәрләр.

Мәрьям. Алсалар, хакын үзем түләрмен.

Нури. Хак дигәннән, менә билетлар. Уникенче рәт. Сиксәнешәр тиен. Бер сумлыклары беткән иде.

Мәрьям. Мин кергәндә бар иде *(күрсәтеп.)* Менә.

Нури *(Мәрьям билетын карап)*. Бер сумлык шул! Болай булгач, сиксән тиенлекнең берсен кире кайтарырга туры килә инде. *(Билетын кесәсенә сала.)*

Мәрьям. Спектакльгә нигә костюмыңның яңасын кимәдең?

Нури. Акча түләп билет алгач, искесе белән дә кертерләр әле.

Мәрьям. Син ай-һай сакчыл да соң.

Нури. Өй җиткерәсе бар бит. *(Кәгазь күрсәтеп.)* Егерме кубометр агач бирделәр.

Мәрьям *(Нуриның сынау өчен)*. Леснигын җайласаң, егерме кубометрны егерме биш тә итәрсең әле.

Нури. Ике яртыны алып кайтып куйдым инде.

Мәрьям. Тозлаган кыяр да тапсаң...

Нури. Табам. Бер-ике кило балык та кыстырам. Агачын гына кызганмасын, хе-хе-хе... Нигә тәрәзә янына киттең, Мәрьям?

Мәрьям *(тәрәзәдән карап)*. Кояш битен болыт каплады.

Нури. Нигә каплады?

Мәрьям. Синең балык белән кыяр турында сөйләвеңә оялды, күрәсең.

Нури. Икебез яшисе йорт бит.

Мәрьям. Андый вәгъдәм юк.

Нури. Мин сиңа өйләнәм, Мәрьям.

Мәрьям *(әрнеп)*. Чиләгеңне алып киттеләр.

Нури *(ишекне ачып чиләкне ала)*. Китмәгәннәр бит.

Бүлмәдән киенгән Гөлүзә чыга, Нури хәйран кала.

Гөлүзә!

Гөлүзә *(биленә таянып)*. Тыңлыйм, сэр.

Нури. Ай, мәмзел, ай, Өти...

Гөлүзә. Сиңа борылып та карамам дигән идең дә, күзең үгезнеке чаклы булды.

Нури *(ачуланып)*. Үгезнеке!.. Куянның турында идарәгә әйттем. Табылмаса, бәясен Ситдыйк белән икәүләп түлисез.

Гөлүзә. Сез һәрвакыт күңелле хәбәрләр генә китерәсез, сэр.
Нури. Фермага, төнге дежурлыкка да син төшәсең.
Гөлүзә. Фатыйма апа чираты.
Нури. Ул авырый.
Гөлүзә. Бер үк нәрсә турында ике сөйләргә яратмыйм. *(Мәрьям каршында бөтерелеп.)* Матур дисең инде?
Нури. Әйтү белән эшкә йөгерсәң, тагын да матуррак булыр идең.
Гөлүзә. Матурлыкка мохтаҗ кеше йөгерсен. *(Бетерелеп).* Егетем көтә.
Нури. Әйтерсең, егет өчен генә яратылгансың.
Гөлүзә. Билгеле, сыер өчен түгел инде. Болай итик: фермага үзең бар. Мин бер төнгә монда синең өчен мөдир булып торырмын.
Нури *(ярсып).* Син китмәдең инде, фермадан үзем китәм.
Гөлүзә. Китсәң ни, мондагылар синнән башка да эшли алырлар, менә син бездән башка яшәп кара. *(Бүлмәгә уза.)*
Мәрьям. Гөлүзә спектакльгә чыксын, Нури.
Нури. Ә фермага кем барыр?
Мәрьям. Әгәр үзең барсаң? Мөдирнең шундый адым ясавы кешеләр каршында дәрәҗәңне дә күтәрер иде.
Нури. Таң белән урман кисәргә китәм.
Мәрьям. Бер көн соңрак барырсың.
Нури. Ул кварталдан алтмышлап кешегә агач бирелгән. Шомасын сайлап бетерсәләр, миңа чатлы-ботлысы гына калса?
Мәрьям. Ярар. Кешедән алданрак син бар. Шомаларын сайлап син кис. Кәкре-бөкресе башкаларга калсын. Фермага мин төшәм.
Нури. Яшә, Мәрьям! Минем өчен җанын да жәлләми торган чын коммунизм кешесе син.
Мәрьям. Шулай булмый ни, кеше чистартмаган утарны мин чистартам, кеше сава алмаган сыерны мин савам, кеше бармаганга мин барам.
Нури. Син корыч! Син машина!
Мәрьям. Машина... Кешегә исәплисеңдер дигән идем. Туры әйтүеңә рәхмәт.
Нури. Сөзешмик инде. Мөгезебез юк бит.
Мәрьям. Мин мукләк тә түгел.

Бүлмәдән Гөлүзә чыга. Ситдыйк керә.

Ситдыйк. Дусларым, бөтенебез өчен дә сөенче!
Нури. Идарә акчалата бүләк биргәндер.
Ситдыйк. Булмады. *(Мәрьямгә.)* Синеңчә?
Мәрьям. Фермабыз унөченче урынга күтәрелгәндер.
Ситдыйк. Батмады. *(Гөлүзәгә.)* Синеңчә?
Гөлүзә. Миңа үгез үлсә — ит, арба ватылса — утын.
Ситдыйк. Үзем әйтәм. *(Нурига.)* Бер яртыны куясыңмы?
Нури. Ике сум сиксән җиде тиен тора ул. Бер пачка «Север» да житәр сиңа.
Ситдыйк. Ундүрт тиенгә дә риза. *(Мәрьямгә.)* Синнән нәрсә?
Мәрьям. Миннән? *(Кулъяулык бирә.)* Мә.
Ситдыйк *(карап).* Чиккән. Рәхмәт. *(Гөлүзәгә.)* Синең сандыктан нәрсә чыгар.
Гөлүзә. Анда синя түгел, үземә дә юк әле.
Ситдыйк. Сабыең бар.
Гөлүзә. Сабыем? Китсәнә, хыялый.
Ситдыйк. Куяның бозаулаган. Шуңа күрә качып йөргән икән. *(Шатланып.)* Барлык бозауларны да исән-сау алдык.
Нури *(кулын селтәп).* Әй, мин тагын...

Ситдыйк. Андый бозауны төшегездә дә күргәнегез юктыр. Аяклары кыска, юан, күзләре йодрык кадәр...

Гөлүзә *(йөзен чытып)*. Матур икән...

Ситдыйк. Сыер гына түгел, май чүлмәге булачак, карап кайтасыңмы?

Гөлүзә. Дежур кеше карар әле.

Мәрьям. Мин дежур. Киттек, Ситдыйк.

Нури *(көнләшеп)*. Ситдыйк дус, фермага син дә барасыңмыни?

Ситдыйк. Төнгә Дамир чыга. Тәҗрибәсез. Көтүе таралып, игенне таптатмасын иде дим. Әйдә, Мәрьям.

Нури. Мәрьям, әтиең дә авырый. Син клубка гына чык булмаса. Фермага үзем барам.

Мәрьям. Төнегез имин үзсын.

Нури чиләген ала, Ситдыйк белән чыгалар. Нури кире керә.

Нигә борылдың?

Нури *(билетлар биреп)*. Икесен дә сиңа бирим әле. Алучы булса сатарсың, булмаса, акчасын кире кайтарып алырсың.

Мәрьям. Аңладым. *(Китәләр. Мәүлидә судан кайта, кызына карап тора.)*

Гөлүзә. Килешәме, әни?

Мәүлидә. Кеше киеме кештәк кенә. Үз киемең тәнгә җылырак булыр иде.

Гөлүзә. Булыр иде дә, юк бит.

Мәүлидә. Булганын ки.

Гөлүзә. Затлы түгел.

Мәүлидә. Бүгенгә кадәр затын тикшерми иден.

Гөлүзә. Ә менә бүгеннән соң тикшерәчәкмен. Киенәчәкмен. Күлмәк тә алам, туфлиләр дә...

Мәүлидә. Акчасын кайдан алырсың?

Гөлүзә. Эшләрмен. Акчасына була эшләрмен. Кием дип кешегә ялынмас өчен эшләрмен.

Мәүлидә. Җаным тыныч түгел. Теге кешең читтән дә килгән булгач, кызык итеп кенә...

Гөлүзә. Мин үзем кызык итү өчен йөрим. Моңа кадәр авыл егетләре мине хәтта танцага да чакырмадылар. Менә Гөлүзәне күрсеннәр инде!..

Мәүлидә. Акылы ничегрәк соң?

Гөлүзә. Әй, әни, клубка чыгып кайту өчен бите булгач, акылы нәрсәгә! *(Тәрәзәдән күреп.)* Килде.

Мәүлидә. Башта үзем сөйләшим әле. Теге якка чык.

Гөлүзә *(чыгышлый)*. Исеме Мәрван.

Мәүлидә. Мәрван?.. Исеме дә кешенеке төсле түгел икән.

Гөлүзә *(теге яктан башын чыгарып)*. Аның белән «сез» дип сөйләшәләр. *(Югала.)*

Мәүлидә *(ишек шакыганны ишетеп)*. Кер, улым.

Мәрван керә.

Мәрван. Исәнмесез, апа.

Мәүлидә. Бер килеш.

Мәрван. Минем исемем Мәрван. Зоотехник.

Мәүлидә. Алай икән. Ни йомыш?

Мәрван. Миңа Гөлүзә кирәк иде.

Мәүлидә. Авылда Гөлүзәләр бишәү. Безгә ялгыш кергәнсендер

Мәрван. Мин эзләгән Гөлүзәне шушы йортта тора, диделәр.

Мәүлидә. Син эзләгәне нинди Гөлүзә сон ул?

Мәрван. Үткен сүзле. Шаян, чая. Сыер сава ул.

Мәүлидә. Иптәшләре аны ялкаурак та дип сөйлиләр. Шуны әйтәсеңме?

Мәрван. Кеше ни сөйләмәс, апа.

Мәүлидә. Синең анаң бармы?

Мәрван. Бар.

Мәүлидә. Ул синең өчен борчыламы?

Мәрван. Бик борчыла.

Мәүлидә. Мин дә ана. Мин дә балам өчен бик борчылам.

Мәрван. Тыныч булыгыз, апа. Мин явыз түгел. Үзе кайда соң?

*Мәүлидә бүлмәгә уза, Гөлүзә бүлмәдән чыга.*

Гөлүзә. Мәрван...

Мәрван. Исәнмесез. Хәерле кичләр.

Гөлүзә. Мин сине... сезне болай иртә килерсез дип уйламаган идем.

Мәрван. Кергән кешегә башта урын тәкъдим итәләр.

Гөлүзә. Утыр... утырыгыз.

Мәрван. Урынны түрдән бирү әйбәтрәк була.

Гөлүзә. Бигрәк күп өйрәтәсең. *(Урындыкны күчереп.)* Утыр.

Мәрван. Рәхмәт. *(Утыра.)*

Гөлүзә. Тагын нишләргә кушасың?

Мәрван. Килгән кунакка самовар куялар.

Гөлүзә. Анысын үзем дә беләм. *(Самоварга тотына.)*

Мәрван. Эчмим. Рәхмәт.

Гөлүзә. Эчәбез. Вареньe белән.

Мәрван. Нинди варенье?

Гөлүзә. Ниндиен яратасың соң? Карлыганныкынмы, бөрлегәннекенме, чиянекенме, алманыкынмы?

Мәрван. Хөрмәнекен.

Гөлүзә. Безнең бакчада хөрмә үсми шул. *(Самоварны кире куя.)*

Мәрван *(карап)*. Гөлләрне үзегез үстерәсезме?

Гөлүзә. Үзем булмыйча... Бала-чага кебек ич мин. Гөл күрдемме әсәрләнергә җитәм.

Мәрван. Тәрәзә пәрдәләрегез! Сатып алгансыз, ахры.

Гөлүзә. Сатып алырга, гарип түгел бит мин. Сандыкта моннан матурраклары да бар әле.

Мәрван. Идән, мичләрне дә чиста тотасыз икән.

Гөлүзә. Фермадан кайту белән, котырган кебек, шуларга ябышам.

Мәрван. Фермада да эшлисез. Өегез дә күзгә кебек. Китаплар караштырырга вакыт каламы соң?

Гөлүзә. Кала. Күзләрем чемердәгәнче укыйм.

Мәрван. Иң яраткан китабыгызның исемен белергә мөмкинме?

Гөлүзә. «Зәңгәр шәл». Ун тапкыр укыдым. *(Сүзне башкага бору өчен.)* Бу почмакка кием шкафы алып куям әле.

Мәрван. Ул почмакка түгел, менә бу почмакка куегыз.

Гөлүзә. Барысына да ул хәтле үк тыгылмагыз инде. Үз әйберемне үзем теләгән җиргә куярмын.

Мәрван. Килгәч, мин аны барыбер бу почмакка күчерәм.

Гөлүзә. Чакырсам килерсез.

Мәрван. Мин чакырмыйча да килә алам.

Гөлүзә. Бигрәк тагын... *(Борылып китә.)*
Мәрван. Шаярттым гына... Өегез бик әйбәт.
Гөлүзә. Фермада гына әйбәт түгел менә.
Мәрван. Группагыздагы сыерларны әйтер идем инде... Төзәлмәслек булып бозылганнар. Иткә генә тапшырасы бар үзләрен.
Гөлүзә. Сөтләре дә артмасмыни?
Мәрван. Бик тырышсагыз, группагыздан көнгә егерме литр артым алырсыз.
Гөлүзә. Унбиш сыерга егерме литр — аз бит.
Мәрван. Сезнекедәй сыерлар өчен күп әле ул. *(Сәгатенә карап.)* Безгә кузгалырга вакыт.
Гөлүзә. Ашыгасың. Күңелсезмени?
Мәрван. Кайчаннан бирле сөйләшәбез, бер көлмәдегез дә.
Гөлүзә *(юри).* Хи-хи-хи...
Мәрван *(үчекләп).* Ха-ха-ха... *(Чынлап көлеп җибәрәләр.)* Йорт мәшәкатьләрегез беткәндер бит?
Гөлүзә. Кайту белән бөтенесен ялт иттердем.
Мәрван. Сез мактаныбрак җибәрмисезме?
Гөлүзә. Сүземә ышанмаган кеше белән сөйләшәсем килми.
Мәрван. Нәкъ мин әйткән киемнәрне кигәнсез.
Гөлүзә. Боларны да үзеңнеке түгел диярсең әле.
Мәрван. Нишләп алай дим! Әниегез белән икәү генә яшисезме?
Гөлүзә. Әтием мин беренчедә укыганда авырып үлде.
Мәрван. Тормыштан зарланмыйсызмы?
Гөлүзә. Әни колхоздан пенсия ала, мин сәламәт. Зарланмыйбыз. Кулъяулыгыгызны күрсәтегез әле.
Мәрван. Кулъяулыкны?.. Менә. *(Күрсәтә.)*
Гөлүзә. Яңаны бирмәкче идем дә, үзегезнеке дә ак икән.
Мәрван. Тик мин аңа ислемай сөртергә онытканмын.
Гөлүзә. Хәзер сөртәбез. Борынны яра торганын. *(Эзләнә.)* Ай, хәерсез, магазинда андыйлары юк, зинһар, бирсәнә дип, Мәрьям апа алып чыккан иде.
Мәрван. Ислемаегыз чынлап та юкмы әллә?
Гөлүзә. Ансыз да торырга! Менә миндә никадәр акча! *(Миндар акчаларын күрсәтә.)*
Мәрван. Бай сез.
Гөлүзә. Башкалар хәерче дип сөйләгәч тә... Урам буйлап ничек барырбыз икән?
Мәрван. Ничек телисез соң?
Гөлүзә. Култыклый беләсезме?
Мәрван. Беләм.
Гөлүзә. Белсәгез, күрсәтегез әле һөнәрегезне! *(Култыгын бирә.)*
Мәрван. Рәхим итегез. *(Култыклый),*
Мәрван. Ни булды?
Гөлүзә. Ай!.. *(Читкә сикерә.)*
Гөлүзә. Кеше кулы тигәч, минем тән әллә ничек тартылып китә икән.
Мәрван. Моңа кадәр култыклашканыгыз булмадымы әллә?
Гөлүзә. Нишләп булмасын! Кино саен егетләр мине озату өчен сугышырга җитәләр. Тик алар авылча гына озаталар. Култыклашмыйча гына. Без дә шулай гына барыйк.
Мәрван. Рәхим итегез. *(Ишекне ача.)*
Гөлүзә *(шаярып).* Рәхмәт, сэр. *(Китәләр.)*

## Өченче пәрдә

Беренче пәрдә күренеше. Нури тактага күрсәткечләр яза.

**Нури** *(канәгатьләнеп).* Әкрен булса да үргә! *(Кибәргә элгән халатларны карый.)* Чиста... *(Туктап.)* Бишенче номер. Гөлүзәнеке

*Гөлүзә керә.*

**Гөлүзә.** Һаман халат итәге иснәп йөрисеңме?

**Нури.** Өстән икенче сәдәбе юк. Биш минуттан тагылган булсын *(Халатны Гөлүзәгә ыргыта.)*

**Гөлүзә.** Бирсәң кулың белән бир, сәр. *(Халатны кире ыргыта.)*

**Нури.** Түбәнчелек белән сәдәп тагыгызчы дип ялынабыз, хөрмәтле мәмзел.

**Гөлүзә.** Адәм рәтле итеп сөйләшә дә белмисең. *(Халатны ала.)*

**Нури.** Ситдыйк янына бардыңмы?

**Гөлүзә.** Чәчелгән үләнгә көтүен кертмәгән.

**Нури.** Сиңа: «Кертсен!» — дип әйтергә җибәрдем бит мин.

**Гөлүзә.** Ә мин: «Чәчелгәнгә зоотехник та кертергә кушмады»,— дидем.

**Нури.** Фермага Мәрван башмы, минме?

**Гөлүзә.** Мәрван күбрәк белә.

**Нури.** Сүз саен Мәрван да Мәрван. Алла диярсең.

**Гөлүзә.** Ул синең кебек карга гына түгел инде. Белеп сөйли. *(Вагонга юнәлә.)*

**Нури.** Ситдыйк янына яңадан бар. Чәчелгәнгә кертсен.

**Гөлүзә.** Сәдәп тагасым бар. *(Вагонга керә.)*

**Нури.** Менә Өти! Ферма белән идарә итә башлады бу.

*Мәрван керә.*

**Мәрван** *(блокнотына карап).* Минем исәпләүләр буенча...

**Нури.** Айга күпме акча тиясен хисаплыйсыңмы?

**Мәрван** *(тыныч кына).* Әйе.

**Нури.** Ул акчаны кая куярсың икән?

**Мәрван** *(шаяртып).* Хатынга җибәрәм. Малай үстерәм ич.

**Нури.** Алай икән. Ситдыйкка Балак аркылы нинди сүз әйттерден?

**Мәрван.** Беренчедән, ул кыз Балак түгел, ә Гөлүзә. Икенчедән, Ситдыйкка бер сүз дә әйттергәнем юк.

**Нури** *(тәрәзәгә килеп).* Гөлүзә, чык әле!

**Гөлүзә** *(тәрәзәдән).* Синең дә сәдәп төштемени? *(Мәрванны күреп.)* Мәрван! *(Вагоннан чыга.)* Нигә чакырдыгыз?

**Мәрван.** Ситдыйкка нинди сүз әйттең, Гөлүзә?

**Гөлүзә.** Нинди дип, кичә икәү сөйләшкән идек бит, чәчелгән үләнгә көтү кертмәбез дип. Шуны гына әйттем.

*Ситдыйк керә.*

**Нури.** Ни өчен көтүне чәчкәнгә кертмәдең?

**Ситдыйк.** Мәрван да кертергә кушмаган бит.

**Нури.** Син мин кушканча эшлә.

**Ситдыйк.** Синең фермада беренче елың, минем дүртенче елым. Кайдагы үләнне кайчан ашатырга кирәклеген синнән яхшырак беләм. *(Китә.)*

**Нури** *(артыннан кычкырып).* Белмисең, берни дә белмисең.

Гөлүзә. Ситдыйк та синнән күбрәк белә.
Нури. Инде син дә Нурины өйрәтәсеңме?
Мәрван. Хакы бар.
Нури. Өйрәтү өчен акыл да кирәк.
Мәрван. Акылы да кешенекеннән ким түгел.
Нури. Гөлүзәне ни өчен яклаганыңны беләм.
Мәрван. Белсәң бик әйбәт. Көтүлекнең иң начар участогын бозып чәчелгән егерме гектар үлән инде үл. Шул үләнне хәзер ашатсак, җәйге челләдән дөньясы саргаеп көйгәндә сыерларга нәрсә бирербез?
Нури. Идарә җаен табар әле.
Мәрван. Җаен без табарга тиеш аның. Чәчелгәнгә биш көнсез мал кертмәскә.
Нури. Ә план? Көнгә уналты кило бит! Аның өчен идарә каршында син җавап бирерсеңме соң?
Мәрван. Бирермен.
Гөлүзә *(Нурига)*. Ферма өчен Мәрван җавап биргәч, син нигә кирәк?
Нури. Бидоныңны юарга өйрәтергә, янында каравыл торып, сәдәбеңне тактырырга кирәк мин. Аңладыңмы?
Гөлүзә. Аңладым. Гаҗәп тә кирәкле кеше икәнсең.
Нури *(Мәрванга)*. Икебез ике якка сөйрәсәк, эшләр алга бармас, дус кеше. Икебез дә минем якка каерыйк.
Мәрван. Кая барганыгызны аңламыйм. Юлыгыз юк кебек сезнең.
Нури. Килгәнеңә ике атна. Зоотехник булып син дә әллә ни куандырмадың.
Мәрван. Узган елга караганда көнгә бер центнер артык савабызмы?
Нури. Ике йөз сыерга көнгә бер центнер...
Мәрван. Көнгә центнер, елга утыз алты тонна! Иртәгәдән тагын дүрт сыерны утарда калдырабыз.
Нури. Кем сыерларын?
Мәрван. Берсе Гөлүзәнеке, икесе...
Нури *(бүлдереп)*. Аңлашылды.
Гөлүзә. Нәрсә аңлашылды?
Нури. Утарда асрагач, сөт артканын сиздең, җаен да табасың.
Гөлүзә. Бөтен гарип-гораба, җитлекми туганнарын миңа тутыргач! Ачуымны китерсәң, берсен дә көтүгә чыгармам.
Нури. Печәнен тапсаң — чыгарма.
Гөлүзә. Юк инде, сәр, печәнен син табарсың.
Нури. Нервамны кузгатма.
Гөлүзә. Синдә генә нерва, миндә юк. Уйлап кара, беткән баш, мин районда иң артта бит. Бер сүз әйттенме, торасың да печән, торасың да печән.
Нури. Юрганыңа күрә аяк сузасың.
Гөлүзә. Юрганның яңасын, бөтен буйга сузылырдаен тегегез миңа.
Нури. Тегүен тегәрбез. Башта юрганыңа җитәрлек итеп ефәген тукы.
Гөлүзә. Баш саны тулсын өчен генә калдырылган имгәкләр беләм тукырсың менә. Ни өчен аларның бөтенесе дә миңа гына? Бер өлешен миннән алып башкаларга да бирик. Башкалардан алып, миңа да рәтлерәк сыерлар беркетегез.
Нури. Менә Мәрван нәселле сыерлар карарга барам, ди. Кайтсыннар гына. Бөтен группасы синә.

Гөлүзә. Кайтасы сыер тумаган бозау әле ул. Миңа бүген ук...
Нури. Зоотехник сиңа егерме кило артыграк саварга була димеме?
Гөлүзә. Дисә, унбишен саудым бит инде.
Нури. Калган бишен дә сау әле, аннан сөйләшербез. *(Китә.)*
Мәрван. Сиңа да җан керә башлады.
Гөлүзә. Элек үле идеммени.
Мәрван. Сыерына да, сөтенә дә борчылмый иден.
Гөлүзә. Борчылмас инде! Нури белән көненә унар талаша идем.
Мәрван. Шуның өчен куарга теләгәндер инде ул сине.

Гөлүзә. Куу дигәне гайбәт кенә. Фермадан үзем китәм ди идем. Ул Нури ялына! «Син китсәң, Өзек Койрык, Сыңар Мөгезләрне кемгә бирермен? Гөлүзәкәем, бәгыркәем, зинһар, китмәсәнә», ди. Ул ялынган саен, мин ялындырам. Китәм, мин әйтәм. Ха-ха-ха... *(Мәрванга карап.)* Әллә ышанмыйсыңмы?

Мәрван *(Гөлүзәгә карап торганнан соң)*. Ышанам, Гөлүзә. Күзләреңнән күрәм: син алдаша белмисең. Шулай бит, алдаша белмисең бит?

Гөлүзә. Шулай шул. Һәрвакыт чат дөресен генә сөйлим. *(Пауза.)* Мәрван, безгә килгәч, ябыгып киттең син.

Мәрван. Кайбер төннәр йокысыз уза, Гөлүзә, уйландыра.
Гөлүзә. Кемне уйлыйсың, абый? *(Пауза.)* Ферманыдыр инде?
Мәрван. Ферманы да, әнине дә...

Гөлүзә. Ибрай Сабирасы: «Зоотехникның колагы бигрәк бәләкәй»,— дип әйтә икән.

Мәрван. Бәлки чыннан да бәләкәйдер.

Гөлүзә. Бәләкәй дә түгел, зур да түгел, бик матур колак. Шул сүзе өчен Сабираны бер керендерәм әле.
Мәрван. Миңа әйткәнгә син нигә борчыласың, Гөлүзә?
Гөлүзә. Синең хакта кешеләрнең чүбек чәйнәвен теләмим. Сөйләсәләр яхшы итеп кенә сөйләсеннәр.
Мәрван *(шаярыруга күчәләр)*. Синең өчен дә авылдашларың: «Гөлүзә» дип өзелеп торсыннар иде.

Гөлүзә. Бөтен егетләр дә миңа гына гашыйк булсыннар идеме?
Мәрван. Көн саен унар егеттән унар яучы килсен иде.
Гөлүзә. Бердән генә, яратканымнан гына килсен.
Мәрван. Килер, Гөлүзә, килер.
Гөлүзә. Чынлапмы? Килерме?
Мәрван. Синең кебек уңган кызга килмим дигәне дә килми түзә алмас. Тырыш кына.

Гөлүзә. Бик тырышам инде. Исемем дә такта түрендә булсын иде дим. Булыш әле.
Мәрван. Минем урында профессор булса да, бу сыерларың белән урын алыштыра алмыйсың.

Гөлүзә. Әгәр алыштырсам, берәр бүләк бирерсеңме?
Мәрван. Иң кыйммәтле ислемай.
Гөлүзә. Миңа шәл булсын иде. Зәңгәр шәл! Театрдагы кебеге.
Мәрван. Ул пьесаны чынлап яратасың, ахры?
Гөлүзә *(уйланып)*. Егете кызын сагынып кайта. Кызы да егетен сагынып көтә. Күрешәләр. Алар күрешкәндә, минем елыйсым килә. *(Җырлый.)*

Ак яулык, зәңгәр шәл,
Базарларда сатыла торган
Маллар кебек безнең хәл...

*(Туктап.)* Маллар кебек... Сыерларны яңадан бүлешик әле.

Мәрван. Башта теге биш килоны савып ал әле. *(Китә.)*

Гөлүзә. Кыландырмаганым калмады. Ничек кенә алырга соң аны? *(Уйланып.)* Сыерның сөте телендә диләр. Әгәр болай итсәм...

Миндар керә. Яңа киемнәрдән.

Миндар. Гөлүзә, комбиазык алып килгән идем. Сыерларыңа нит әле.

Гөлүзә. Хәзер. *(Ак халатын салып, карасын кия.)*

Миндар. Ферманың шифасы тиде сиңа. Йөреш-торышың ук икенче хәзер.

Гөлүзә *(килүче Сәкинәне күрә, шаяруын көчәйтә).* Мактаган өчен бер үбим әле үзеңне, Миндар җаным.

Миндар. Кит, кит!..

Сәкинә керә.

Сәкинә. Оятсызланасыңмы?

Гөлүзә. Үбешүнең нәрсәсе оят булсын, Сәкинә апа. *(Миндарга.)* Яратам, җаным. Әрәмәдән утын да алып чыгасың бар, әйдә әле.

Сәкинә. Эшегезне бүлдердем, ахры?

Гөлүзә. Әйе шул.

Сәкинә. Киттем алайса.

Гөлүзә. Хәерле юл.

Миндар. Бар әле, Гөлүзә, үзең нит әле, кит әле.

Гөлүзә. Утының вакытында чыкмаса, үпкәләрмен, җаным. *(Китә.)*

Сәкинә. Оятымнан утка керимме, суга төшимме?

Миндар. Утынын алып чыкмыйча уты булмас инде аның, суы дисән — әнә генә.

Сәкинә. Үзем дә исән калырмын дип уйлама. *(Таяк күтәрә.)*

Миндар. Үзең күтәргән таяк белән үз башыңны нитәрмен! *(Таякны тартып ала.)*

Сәкинә. Кыюлангансың.

Миндар. Аерган хатынга кыйнаттыра торган күлмәкләр нитте инде. Яңаларын алдык. *(Курсәтеп.)* Кәчтүм, күлмәк!..

Сәкинә. Җыенысы егерме сумлыкмы?

Миндар. Әйе, егерме сумлык. Ә менә синең, мин киткәннән бирле, егерме тиенлек тә әйбер алганың күренми.

Сәкинә. Киләчәктә булачак.

Миндар. Киләчәктә минем хатын да булачак. Гөлүзәгә өйләнәм.

Сәкинә. Ул сиңа бала гына.

Миндар. Үзе яраткач! Әй, утын алып чыгарга кушкан иде бит әле. *(Китәргә җыена.)*

Сәкинә. Исәнме дип каршыламадың, кул биреп саубуллашмыйсың.

Миндар. Сау бул, сау бул.

Сәкинә. Хуш. Мин дә кияүгә чыгам.

Миндар. Кияүгә?! Кемгә?

Сәкинә. Инженерга!

Миндар *(аптырап кала).* Ул ни дидеме соң?

Сәкинә. Алам, диде.

Миндар. Син дә ни дидеңме?

Сәкинә. Барам, дидем.

Миндар *(борчылуын сиздермәскә тырышып)*. Колхозчыга дисән, ышанырга да була, ну инженерга... Комнан ишелгән бау бу. Алмас.

Сәкинә. Ала. *(Күрсәтеп.)* Әнә, мотоцикл белән таудан үзе төшеп килә. Су буенда очрашырга вәгъдә куйдык.

Миндар. Вәгъдәләшкәч бар инде.

Сәкинә. Әллә куркып торыр дисеңме?

Миндар *(артыннан карап)*. Инженеры да кызыгыр, ихлас матур шул шайтан.

Мәрьям керә, авылдан килеше.

Мәрьям *(халатын киеп)*. Сәкинә апа нигә килгән?

Миндар. Ярамаган киңәш бирдегез миңа. Ташлыйсы калмаган. Кияүгә китәм, ди.

Мәрьям. Ялынсаң китмәс. Бергә яшәрсез.

Миндар. Холкы искечә калганда, яшәве ай-яй шул аның белән.

Мәрьям. Алайса ялынма.

Миндар. Йөрәк нитә шул.

Мәрьям. Аныкы да сыза. Бурычларын түләү өчен узган базарда күлмәген саттырган. Шикәр алырлык та рәте юк, ди.

Миндар. Кияүгә дә шикәргә аптыраганнан гына чыга торгандыр инде алайса...

Мәрьям. Ашаган савытын да юмый торган хатынны кем алсын? Егете дә юк. Сине үртәү өчен генә әйткән лә ул.

Миндар. Билләһиме?

Мәрьям. Артыннан бар да карап тор.

Миндар *(балта ала)*. Егете белән тотсам, икесен дә турап суга нитәм!

Кита. Нури керә.

Нури *(сәгатен күрсәтеп)*. Эшкә кичектең.

Мәрьям. Әтинең кәефе кирегә китте.

Нури. Син комсомолка. Әтиең интересын ферма интересыннан югары куйма.

Мәрьям. Өй интересын?.. Үз бураңа нигә чыршы да нарат кына кистең? Арасына бер усак та кыстырмадың?

Нури *(җанланып)*. Анысы икебез яшисе йорт. Агачы житә, акчасы гына... Син бу айда йөз егермене аласың икән.

Мәрьям. Әйе, никахлангач, өеңне күтәрербез.

Нури. Узган ай акчасын да тотып бетермәгәнсеңдер әле.

Мәрьям *(күлмәген күрсәтеп)*. Соңгысына менә моны алдым.

Нури. Бөтен акчаң чүпрәккә, атна саен яңа күлмәк!

Мәрьям. Яңамы шушы күлмәк? Җай итеп җөйләгәнгә генә гишелгәне беленми. Үзең яратам дисең, үзең киемемә дә күз салмыйсың. Минем хакта уйламыйсың да син.

Нури. Уйлыйм. Группаңа тагын биш сыер өстик әле.

Мәрьям. Нигә?

Нури. Район буенча иң күп сыер савучы син булырсың. Синнән үрнәк алып, башкалар да группаларындагы сыерлар санын арттырырлар. Даның республикага таралыр! Орден, медаль...

Мәрьям. Боларын савып та беләкләрне кыймылдатыр хәл юк.

Нури. Аның каравы — дәрәҗә!

Мәрьям. Көчем житмәскә көчәнеп, үз үрнәгемдә бүтәннәрне дә газапларга теләмим. *(Кита.)*

Нури. Араны өзү өчен сәбәп эзли.

Миндар керә.

Миндар. Юк икән, энем, берние дә юк икән.
Нури. Ние юк?
Миндар. Егете юк. Барды да карама төбенә утырды. Янына эт тә килмәде.
Нури. Эт җеннән курка бит ул. *(Китә.)*
Миндар. Хәзер үзен ялындырам инде.

Сәкинә керә.

Сәкинә. Рәхәтләнеп тә сөйләштек соң! Бүген үк китик, ди.
Миндар. Миннән фатыйха.
Сәкинә. Сине кызганам.
Миндар. Кызганма. Алам дип торучы барында юлыңны кара.
Сәкинә *(үйлаган булып)*. Миннән булсын яхшылык: килешик.
Миндар. Юк, килешмибез, кирәкми.
Сәкинә. Мин әйдә дип торганда киреләнмә, өйгә кайт. Тик кара аны: кадеремне беләрлек булсаң гына.
Миндар. Кадереңне дә беләсем килми, кайтасым да килми.
Сәкинә *(Миндарның битеннән сыйпап)*. Яңагың сөяк тә тире генә.
Миндар. Шешләре бетте. Баскычтан егылмый башладым. Эшкә нитәсем бар, җибәр җиңнән.
Сәкинә. Алайса... өйне сиңа калдырып китәм, миңа акча бир.
Миндар. Үз өемне үземә калдырган өчен акча бирергә, фермада эшләгәч тә мине бозау дип белдеңме әллә?
Сәкинә. Йөз генә сум.
Миндар. Инженерыңнан сора. Хатынлыкка чыккан өчен диген.

Гөлүзә керә. Миндар юри аның янына килә.

Йомышың миндәмени, Гөлүзә?
Гөлүзә. Әйе, сине прокурорга чакыралар.
Сәкинә. Ни өчен икән?
Гөлүзә. Әрәм тамак хатынымны өемнән куып чыгарыгыз дип, Миндар исеменнән үзем гариза язган идем.
Сәкинә. Мине куарга?!
Миндар. Сине кумыйча, мине кумаслар инде.
Гөлүзә. Бүген үк бар. Милиционер белән әйләнеп кайтырсың да булган чүп-чарларын тәрәзәдән атарбыз.
Сәкинә *(Миндарга)*. Ул котырта дип котыра күрмә тагын.
Миндар. Котырып җиткәч инде! Безгә дә өй кирәк бит, әйеме, Гөлүзә.
Гөлүзә. Шулай булмыйни! *(Култыклашып китәләр.)*
Сәкинә. Куарлар, өеңнән дә куарлар. *(Узып барган Нурига.)* Нури, кара әле...

Нури керә.

Нури. Карадым.
Сәкинә. Монда миңа да бер җиңел генә эш табылмасмы?
Нури. Сыер сава беләсеңме?
Сәкинә. Маен ашый беләм дә, сөтен савып караган юк шул. *(Елмаерга тырыша.)*
Нури *(елмаюга игътибар итмичә)*. Бозаулар көтүлә.
Сәкинә. Бозау — яшь нәрсә. Чапса-нитсә артыннан ничек житешермен.
Нури. Безнекеләр йөгереп житешәләр. *(Күреп.)* Нишли ул Балак? *(Китә.)*
Сәкинә. Менә син, агай, ә! Ялгыштым Миндарымны куып. Ай саен акчасы да килеп тора иде.

Китә. Кәгазь капчыкка салынган комбиазык күтәреп Нури, аның артыннан Гөлүзә керә.

Нури. Мәрванны чакыр.
Гөлүзә. Кирәк булса үзең чакыр.
Нури. Беренче атналарда сөткә су кушып аптыраттың, хәзер инде урлашыргамы? Чакырам, чакыра-ам... *(Китә.)*
Гөлүзә. Карап торганын ничек күрмәгәнмен? Бу күзләрнең берсе нигә арт якта булмады икән!

Мәрьям керә.

Мәрьям. Эшкә кичегеп килүемнән файдаландыңмы?
Гөлүзә. Нигә?
Мәрьям. Минем сыерларга дигән азыкны үзеңнекеләргә салгансың.
Гөлүзә. Күрдеңме?
Мәрьям. Күрдем.
Гөлүзә. Күргәч нигә тотмадың?
Мәрьям. Хайван хакына ничек кулың барды?
Гөлүзә *(аптырап)*. Соң... гөнаһлы булсам, мена, газетка яз, судка бир...
Мәрьям. Сине намусың хөкем итсен. Хыянәтче кулларыңа күзен төшкән саен үзеңне кая куярга белми җәфалан.

Нури керә.

Нури *(капчыгын җиргә куеп)*. Сыерларың ураза тота, Мәрьям.
Мәрьям. Азыкны күбрәк кайтарт.
Нури. Кайтканын урлатмыйча ашат.
Гөлүзә. Минем урлаганым юк.
Нури. Кара, кара, күзен дә йоммый...
Мәрьям. Гаебе булмагач.
Нури. Бурны яклыйсың.
Гөлүзә. Шушы сүзне тагын бер әйтсән, унбиш тәүлеккә җибәртерәм.
Нури. Син урлаган өчен мин китәргә тиешме? Ха!

Мәрван керә.

Мәрван. Ни булды?
Нури. Балагың Мәрьям сыерларының азыгын урлаган.
Мәрван. Булмас ла.
Нури. Менә капчыгы. Кулыннан тартып алдым. Сәрвәр шаһит.
Мәрван *(Гөлүзәгә)*. Дөресме?
Гөлүзә. Мәрьям апа үзе соңлагач, сыерларына азыгын салыйм дип шушы капчыгын алдым.
Нури. Шуннан, шуннан?..
Гөлүзә. Шуннан... Мәрьям апа капчыгын күтәргән килеш, үз сыерларым янына барып кергәнмен. Шаклар да каттым.
Нури. Беләгеннән мин китереп каптыргачмы?
Гөлүзә. Син каптырганчы ук каткан идем инде.
Нури. Сөйләмәсәнә ачу китереп! Мәрьям сыерлары бу башта, синекеләр теге башта.
Гөлүзә. Мин башларын уйлап тормадым инде.
Нури. Моның өчен, беләсеңме, сине нишләтергә кирәк!
Гөлүзә. Ай, исең киткән икән, атыгыз.
Нури. Аткач, күмәсе дә була шул аны. *(Озын пауза.)*
Мәрван. Син ялгыш кына ялгышкансың, шулай бит Гөлүзә?
Гөлүзә. Шулай шул, Мәрван, валлаһи менә, ялгыш кына ялгыштым.
Нури. Алдаша. *(Гөлүзәгә.)* Әйт әле...
Мәрьям *(бүлдереп)*. Тимә инде шул балага.

Нури. Тиям!

Мәрьям. Газапла инде алайса.

Нури. Урлашмасын. Иптәшләр, төптән уйлап караганда, Балак ул Өти генә түгел, зәһәрле дошман да! Ул, Мәрьямнең азыгын урлап, мәкерле рәвештә безнең маягыбызны сүндерергә маташкан. Төптән уйлап караганда, бу җинаятьнең тамырлары капитализмга ук барып тоташа.

Гөлүзә *(гарьләнүдән күлмәк якасын куллары белән тотып).* Җитәр, күлмәгемне умырам.

Нури. Умыр әле. Күңелем бушап китәр, ичмасам.

Гөлүзә. Үз күлмәгемне ертып, сине тынычландырырга юләрмени мин.

Нури. Күңелең керсез булса, урламадым дип ант ит, давай.

Мәрван. Ант ит, Гөлүзә.

Гөлүзә. Ант ит?! *(Ант итәсе килми.)* Миңа син дә ышанмыйсыңмыни, Мәрван?

Мәрван. Димәк, Нури хаклы.

Нури *(күкрәгенә сугып).* Нури нахакка сөйли торган егет түгел!

Гөлүзә *(бик кыеннан).* Ант итәм: урламадым.

Мәрван. Менә бит! Шундый кыз сон!..

Нури. Гөлүзәне син мактарсың инде.

Мәрьям. Мин мактыйм аны. Менә бидоннары — күзгә кебек, халаты врачка кидергечле.

Нури. Ә тактада иң артта.

Мәрван. Анысы Гөлүзә гаебе генә түгел.

Гөлүзә. Мәрьям апа, үз сыерларыңның яртысын миңа бир дә, мин сиңа үз сыерларымның яртысын бирим әле.

Нури. Ферма горурлыгы булган группаны таркатыргамы? Юк!

Гөлүзә. Таркатмыйча да була. *(Мәрьямгә.)* Заводларда да алдынгы бригадирлар сөйрәлүче бригадаларга күчәләр икән. Әллә группаларны ук алмашабызмы, Мәрьям апа?

Нури. Кеше сыерына атланып күтәрелмәкче?..

Гөлүзә. Үземнекеләр күтәрә алмагач. *(Үтенеп.)* Мәрьям апа...

Мәрьям. Ярый, уйлап карармын әле.

Нури. Редакциядән килеп, иң алдынгы савучыны күрсәт дисәләр, сине күрсәтә идек. Районда ферманы синең исем белән телгә алалар. Группаңны Гөлүзәгә бирсәң, сине кем, кайсы ягың белән телгә алыр?

Мәрьям. Тел өчен эшләмим. *(Нуридан капчыгын тартып ала, китә.)*

Нури *(Мәрьям артыннан).* Араны өзәргә җай эзли. *(Гөлүзәгә.)* Ярый, монысы болай гына үтте, ну моннан соңгылары — шалишь, брат! *(Китә.)*

Гөлүзә *(торак тәрәзәсеннән кружка белән җиләк алып).* Җиләк ашыйсыңмы, Мәрван.

Мәрван *(ачу белән).* Рәхмәт.

Гөлүзә. Мондый рәхмәтне әйтмәскә дә ярый.

Мәрван *(өстәлгә сугып).* Ант итәргә ничек намусың җитте?

Гөлүзә *(өстәлгә катырак сугып.)* Кемгә өстәл сугасың? Мин синә хатыныңмы әллә?

Мәрван. Теләкләреңә гадел юл белән ирешерсең дип уйлаган идем.

Гөлүзә. Кулыңны кесәңә тыккан килеш читтән генә уйланып торуыңнан миңа ни файда? Шул биш литрны ничек алыйм дип мең сорадым бит.

Мәрван. Биш литры ник чәнчелми, кулың чиста булсын иде.

Гөлүзә. Күңелем чиста.

Мәрван. Түгел. Синә ышанычым кимеде.

Гөлүзә. Нинди ышанычың?
Мәрван. Мәрьям дә сыерларын бирмәс, биш литрыңны да ала алмассың. *(Китә.)*
Гөлүзә. Тагын шул биш литр!.. *(Уйлап.)* Тукта әле, баткан аяк чыланган, чукындырып алам.

Вагонга керә, ике чиләк су күтәреп чыга, Нури белән очраша.

Нури. Бу кадәр су нәрсәгә?
Гөлүзә. Җилен юарга.
Нури. Бигрәк чиста булып киттең. Икешәр чиләк белән юасың.
Гөлүзә. Миннән су да җәлләр идеңме әллә? *(Китә.)*
Нури. Ике чиләк...

Мәрьям керә, кулында кыр чәйнеге.

Мәрьям. Нури, Әюп чишмәсе кайдарак ул?
Нури. Моннан өч километрда.
Мәрьям. Әти: «Шул чишмәнең суын эчсәм, аягыма басар кебек тиям, кызым»,— ди.
Нури. Өч километрга чиләнеп йөргәнче, әнә Туктар чишмәсе. Ал да кайт. Сукыр килеш чишмә суын чишмә суыннан аера алмас әле. *(Китә.)*
Мәрьям. Кеше диген инде моны да.

Ситдыйк керә.

Ситдыйк. Нишләп болай торасың?
Мәрьям. Хыялындагы кызга ошарга телим.
Ситдыйк. Чыраең йокы күрмәгән кешенеке төсле.
Мәрьям. Әти төнге икедә уяна да, мин дә йоклый алмыйм.
Ситдыйк. Алай икән... Бу нинди чәйнек?
Мәрьям. Әти Әюп чишмәсенең суын сораган иде.
Ситдыйк. Алып кайтып биримме?
Мәрьям. Әти: «Үз кулың белән алып кайт, кызым»,— диде.
Ситдыйк. Савып бетер дә бергәләп барырбыз.
Мәрьям. Рәхмәт.

Китәләр. Бераздан бидон күтәреп Нури, аның артыннан чиләк тоткан Гөлүзә керә.

Нури. Моннан соң фермада эзең дә булмасын.
Гөлүзә. Юк белән җәфалама, эшемне калдырасың.
Нури. Гөнаһыңа күрә җәзаң, җаның чыксын. *(Эндәшә.)* Мәрван, Мәрван!..

Мәрван керә.

Баш беткеч эш: сөтенә су кушты. Чиләген менә болай итеп алды да...
Мәрван *(бидондагы сөтне карап.)* Ике сыерныкымы?
Гөлүзә. Миләш белән Баланныкы.
Мәрван. Аларның майлылыгы өч тә сигез.
Нури. Ике дә калмаган монда. Хәзер тикшерәм. *(Вагонга уза.)*
Гөлүзә. Ант итәм.
Мәрван. Итмә. Җир йотар.
Гөлүзә. Сөйләшмибез.
Мәрван. Сау булыгыз. *(Китә башлый.)*
Гөлүзә. Саубуллашырыңны күптән сизгән идем. Мин Әти Балак кына шул.
Мәрван. Мескенләнгәнне сөймим.
Гөлүзә. Сөймәгәнеңне дә белә... Мине бала-чага итеп кенә йөрисең, шефка алып кына.
Мәрван. Больницадагы авыруларга, балалар бакчасындагы са-

быйларга китәсе сөткә су кушарга! Моны җинаятьченең дә теләсә кайсысы эшли алмый.

Гөлүзә *(ихлас рәнҗеп.)* Һаман ышанмыйлар. Фермагызны әчегезгә бәйләгез. Китәм.

Мәрван. Китә алмассыз. Намусыгыз рөхсәт итмәс.

Гөлүзә. Миндә намус юк. *(Биреп.)* Менә китабың. Шактыен укыдым. Рәхмәт. Ә мин китәм дигәч китәм.

Мәрван. Көннән-көн җыйнаграк йөрүең, тактадагы саннарга карап уйга калуың мине куандыра иде. Иртәрәк сөенгәнмен. Кит, хәзер үк кит.

Гөлүзә. Китмим.

Мәрван. Син ферма советы карары буенча китәрсең.

Гөлүзә. Карарның яшелле-зәңгәрлесен чыгарсагыз да китмим. Утар киртәсе буена ятып үлсәм үләм, әмма китмим.

Мәрван. Китәрсең. *(Китә.)*

Гөлүзә. Су кушарга теләгән дә идем, кулым бармады, булдыра алмадым дип, нигә турысын гына әйтмәдем соң? Ну бу Нурины! Нахак бәласе өчен ничегрәк итеп адәм көлкесенә калдырырга соң? *(Уйлана.)*

Мәрьям керә.

Мәрьям. Ситдыйкны күрмәдеңме?

Гөлүзә *(уйлаганын табып).* Күрдем. Кулында чәйнеге дә бар иде. Мәрьямгә әйт, әнә теге карама төбендә көтәрмен, диде.

Мәрьям. Нигә монда гына көтмәде икән? *(Китә.)*

Гөлүзә. Ситдыйгын тапсам, өсләренә Нурины гына җибәрәсе кала.

Ситдыйк керә, кулында чәйнек.

Хыялындагы кызның кайда икәнен мин беләм.

Ситдыйк. Син белмәгән аз булыр. Кайда соң ул?

Гөлүзә. Әнә теге карама төбендә көтәм, диде.

Ситдыйк. Ә ни өчен карама төбендә?

Гөлүзә. Анысын белмим инде. Елаган бугай ул.

Ситдыйк. Нигә елаган?

Гөлүзә. Каян белим. Янына бармаслык булсаң, көтмә дип әйтеп килдәм.

Ситдыйк. Су кушмыйсыңмы икән? *(Китә.)*

Гөлүзә. Зарар юк. Кайчагында суыннан да май чыга. *(Нури торактан чыга.)* Я, ничә булды, сэр?

Нури. Өч тә сигез, мәмзел. Бу юлы кушмагансың икән.

Гөлүзә. Гөлүзәгә ялгыш яла якканмын дип, хәзер үк Мәрваннан гафу үтен.

Нури. Син бигрәк тагын... Мәрьям утардамы?

Гөлүзә. Юк, әнә теге карама төбендә. Ситдыйк белән кочаклашып утыралар.

Нури. Кочаклашып?!

Гөлүзә. Чат-чот үбешәләр.

Нури. Үбешәләр?! Алдасаң иманыңны укытырмын, бала. *(Китә.)*

Гөлүзә. Бутавын бутадым да, үзем өчен начар бетсә?

Кулына төен тотып Мәүлидә керә.

Әни?..

Мәүлидә. Сөтегезне шул тактага язалармы әле?

Гөлүзә. Әйе. Монысы минем исем. Нишләп килмәкче иттең, әни?

Мәүлидә. Әле генә радиодан комсомол секретаре сөйләде. Яшьләрнең фермада эшләве турында. Сине дә мактады. Сөтен арттырды, ди.

Гөлүзә. Аны үзем дә әйткән идем бит.

Мәүлидә. Син әйтү белән радио әйтү бер түгел. *(Кабат карап.)* Дөрес шул. Артымың унбиш кило. *(Түенен сутә.)* Сиңа чуәк алып килгән идем. Менә, күбәләкле.

Гөлүзә. Рәхмәт, әни.

Мәүлидә. Киеп җибәр әле.

Гөлүзә яңа чуәкләр кия, Мәүлидә искеләрен төйни.

Гөлүзә. Искеләрен нигә төйнәдең, әни?

Мәүлидә. Яңалары белән йөр.

Гөлүзә. Җәл бит.

Мәүлидә. Эшләгән кешегә җан да җәл түгел, кызым.

Гөлүзә *(ни әйтергә белмичә)*. Әни, идәнне дә бүген үзем юармын, ямә?

Мәүлидә. Мин сәламәт чакта идән өчен кайгырма. Мондагысын кара. Мин киттем.

Гөлүзә. Нишләп бик тиз?

Мәүлидә. Эшең бүленмәсен.

Китә. Гөлүзә аны озата чыга. Шау-шу ишетелә. Алдан, йөгереп диярлек, Нури керә, аның артыннан Ситдыйк белән Мәрьям.

Нури. Шаһит булыгыз: Мәрьям яулыгы.

Тавышка Мәрван да керә.

Ситдыйк *(яулыкны тартып алып)*. Аңа кагылырга ни хакың бар?

Мәрьям *(араларына кереп)*. Кирәкми, Ситдыйк, тавышланмагыз. *(Нуригә.)* Баштан яулыкны тартып алып нәрсә әйтергә телисең син?

Гөлүзә керә, тыңлап тора.

Нури *(Мәрьямгә)*. Мин солдатка киткәндә көтәргә вәгъдә бирдеңме?

Мәрьям. Бирдем дә, көттем дә.

Нури. Бүген куак астында Ситдыйкны үптеңме?

Мәрьям. Үптем.

Нури *(Ситдыйкка)*. Моңа кадәр без дуслар идекме?

Ситдыйк. Дуслар идек.

Нури. Дус булгач нигә минем кызга үптердең?

Мәрьям. Мин үпкәнгә ул гаепле түгел. Карама төбенә шуышып килгәнеңне күрдем. Кешедән еланга әйләнүеңә хурландым. Шуңа ачу итеп үптем Ситдыйкны.

Ситдыйк. Үзем дә аптырап калган идем аны.

Нури. Ничек кенә үпсәң дә үбү — үбү инде ул. Тамыры тирәнгә китә. *(Бөтенесенә дә.)* Иптәшләр! Көпә-көндез карама астында үбешеп яту — таралган яктан моралу ...әй мораль яктан таралу. Мондыйлар фермабызның дәрәҗәсен төшерәләр.

Гөлүзә. Әле иртән генә: «Мәрьям кебекләр ферманың дәрәҗәсен күтәрә»,— дигән идең бит.

Нури. Анысы иртән, монысы көндез. Гөлүзә, Мәрьям группасындагы сыерларның яртысы синә.

Мәрван. Бу ничек була инде?

Нури. Әхлак ягыннан бозык кешеләргә сыер кадәр сыерны ышандыра алмыйм.

Ситдыйк. Моны ферма советы гына хәл итә ала.

Мәрьям. Анысы кирәкми. Гөлүзә, сөтләрен киметмәссеңме?

Гөлүзә. Йөз генә граммга киметсәм дә, иртәгә үк аларны миннән кире алырсыз.

Мәрьям. Үз ризалыгым белән бөтен группамны сиңа бирәм, Гөлүзә.

Ситдыйк. Моны кем өчен шулай эшләдең инде, Мәрьям?

Мәрьям. Гөлүзә өчен. Үсәргә ала. Үссен. *(Ситдыйкка.)* Киттекме?

Нури. Минем рөхсәттән башка бер кая да китмисез.

Ситдыйк *(Нурига честь биреп).* Эюп чишмәсенә генә барып килергә рөхсәт итегезче, иптәш мөдир.

Мәрьям. Киттек лә, Ситдыйк. *(Китәләр.)*

Нури *(артларыннан карап).* Чишмә суы сәбәп кенә. *(Китәргә тели.)*

Мәрван *(аны туктатып).* Иптәш мөдир, председатель шалтыратты. Хәзер аның белән нәселле сыерлар карарга совхозга күрше республикага китәбез.

Нури *(игътибарсыз гына).* Иртәгә кайтып житегез! *(Мәрьямнәрне күрсәтеп.)* Баралар бит тегеләр! Култыклашып баралар, әшәкеләр. *(Артларыннан китә.)*

Мәрван. Сау бул, Гөлүзә. Китәм. *(Кул бирә.)*

Гөлүзә. Китәсең?.. Син?.. Ә соң мин?

Мәрван. Син монда каласың.

Гөлүзә. Кайтырсың бит, Мәрван?

Мәрван. Кайтырмын.

Гөлүзә. Ә син... син борчылма. Мин көтәрмен... сыерларны.

Мәрван. Көт.

Гөлүзә *(акча биреп).* Юлда кирәк булыр. Ал әле. Өч сум.

Мәрван. Өч сум? Ярты литргамы?

Гөлүзә. Юк ла, үзең әйткән иң яхшы ислемайга.

Мәрван. Үземнекеләр дә житәрлек.

Гөлүзә *(акчаны Мәрван кесәсенә ирексезләп тыга).* Ал әле. Азыклы ат армас, диләр.

Мәрван. Рәхмәт. Хуш. Күрешкәнче, Гөлүзә.

Гөлүзә. Күрешкәнче генә саубуллашабыз, яме. *(Кул бирә.)*

Мәрван. Билгеле, шулай. Күрешкәнче генә.

Саубуллашалар. Мәрван китә. Гөлүзә кул болгый.

## *Дүртенче пәрдә*

Шул ук урын. Мәрьям белән Гөлүзә күрсәткеч такта янында.

Мәрьям *(тактага карап).* Киметмисең бит, Гөлүзә!

Гөлүзә. Миңа рәнжемисеңме, Мәрьям апа? Син үстереп биргән сыерлар бит алар.

Мәрьям. Мин дә башта кеше үстергәнне саудым. Киләчәктә син дә башкаларга үстереп бирерсең. Тормыш шулай инде ул. *(Юлга караган Гөлүзәгә.)* Күзеңне юлдан алмыйсың.

Гөлүзә. Үзеңне бер тапкыр да үпмәгән кешенең яратуы мөмкинме, Мәрьям апа?

Мәрьям. Мөмкин.

Гөлүзә. Мөмкин шул. Мөмкин генә дә түгел әле! *(Юлга текәлеп.)* Кайтса, йөзенә дә борылып карамыйм.

Мәрьям. Атна үтми киногә да чыкмыйсыңмы?

Гөлүзә. Ай буена чыкмыйм. Йөрсен шунда...

Мәрьям. Кайтыр, сыерлар да алып кайтыр.

Гөлүзә. Үзем дә юлы уңсын дип телим инде. *(Кинәт.)* Шул нәселле сыерларны, их, миңа бирсәләр!..

Мәрьям. Минекеләргә генә күңел канәгать түгелмени?

Гөлүзә. Юк, Мәрьям апа, барыгыздан да күбрәк савасым, барыгыздан да уңганрак буласым килә минем. *(Күреп.)* Нури абый килә.

Мәрьям. Нури?! Сөлгеләрне үтүклим әле.

Вагонга уза. Нури керә, кулында газет.

Нури. Сәлам, мәмзел.

Гөлүзә. Вәгаләйкемәсәллам, сәр.

Нури *(газеттагы рәсемне күрсәтеп)*. Үзеңне танысыңмы? *(Укый.)* «Сигез килодан унбиш килога! Гөлүзәдән үрнәк алыгыз». Район газеты. Мин яздым.

Гөлүзә. Сине мактап сүз әйтсәм, телем корсын дигән идең дә...

Нури. Яңадан туасыңны кем белгән! *(Газетны тактага беркетә, карап.)* Күзләрең шомырт...

Гөлүзә. Умырып карама. Күз тидереп чирләтерсең.

Нури. Нишлим соң, яратам... шул күзләрне.

Гөлүзә. Нәселле сыерларны миңа бирсәң, яратуыңа ышаныр да идем.

Нури. Үзең миңа булсаң, нәселлеләр сиңа.

Гөлүзә. Нәрсәмә кызыктың?

Нури. Акчаны күрәп аласың. Син — маяк!

Гөлүзә. Мәрьям апа да маяк иде.

Нури. Сүнде ул. *(Кулын Гөлүзә җилкәсенә сала.)*

Гөлүзә. Кулыгызны алыгыз әле, сәр. *(Нури алмый, Гөлүзә аның кулын читкә этәрә.)* Кызлар җилкәсе утар киртәсе түгел.

Нури. Күңелең башкада икәнен беләм. Тик ул сине сөйми.

Гөлүзә. Мин дә сөям, ул да сөя, икебез дә сөябез.

Нури. Валлаһи, минем чаклы эт тә сөйми сине.

Гөлүзә. Әй, син бөтенләй ярата белмисең лә. Мәрьям апа да шуңа ташлады бит үзеңне.

Нури. Аны мин үзем ташладым.

Гөлүзә. Буең җитмәгәчме? *(Китә башлый.)*

Нури. Нәселле сыерлар кирәкмимени?

Гөлүзә. Аларны миңа ферма советы бирер, Мәрьям апа бирер. *(Китә.)*

Нури *(кабатлап)*. Мәрьям апа ташлады... Аерган хатының белән ташлаган кызыңнан каберең ерак булсын икән. *(Мәрьям торактан чыга.)* Нәрсә трай тибеп йөрисең, мәмзел?

Мәрьям. Сөлгеләр үтүклэдем, Нури абый.

Нури. Сөлге!.. Сөт турында уйла. Гөлүзәдән соң җиде литр арттырдың да шып туктадың. Арык ат кебек бер урында таптанасың.

Мәрьям. Гаеп миндә генә түгел.

Нури. Синдә генә! *(Күрсәтеп.)* Чиләгеңне нигә янечтең?

Мәрьям. Яңа чакта ук янчелгән иде. Башкалар алмагач, миңа бирден. Шул чиләк ич ул.

Нури *(карап)*. Бидонын төбенә нишләп марля кыстырдын?

Мәрьям. Сатып алынганына егерме ел икән. Егерме беренчесенә чыдамады. Тишелде.

Нури. Башкалар утыз ел чыдаталар. Мал кадерен белмисең. *(Бидонны әйләндергәләп.)* Тышы тузан. Балак урынына син калдың хәзер.

Мәрьям *(кулъяулык ала, бидонын сөртә)*. Күр! *(Кулъяулыгын җәеп.)* Керсез, чиста!

Нури. Юләр генә үзен мактар. Иртәгә контроль саву. Көтүчеләрнең мал йөртүен күзәтергә төнгә син чыгарсың.

Мәрьям. Нәүбәт Гөлүзәдә бит.

Нури. Сөтне күп сауганнар ял итәләр.

Мәрьям. Әтинең хәле дә...

Нури *(бүлдереп)*. Ун елдан бирле үлә алмый аптыраган этиеңне сыер арасына кыстырма. Тапталыр.

Мәрьям. Үзенне суга батканда коткарып калган карт турында шулай дип әйтергә!.. Телең черер...

Нури. Борчылма, синнән тел сорамам.

Мәрьям. Солдаттан кайтуынны шушы сүзләрне ишетү өчен көткәнмен икән.

Нури. Үзеңә бер егет тә карамагач, яткансың инде сатылмый торган товар кебек.

Мәрьям. Теләсәм, атна эчендә кияүгә чыгам.

Нури. Чыгарсың инде! Эш рәте белсәң, мин дә ташламый идем сине.

Мәрьям. Ташлау өчен башта ул кызны үзеңә карату кирәк бит.

Нури. Алам дисәм, йөгерә-йөгерә чыга иде дә...

Мәрьям. Алам дип әйткәнең булмадымы әллә?

Нури. Булмады.

Мәрьям. Бер тапкыр да әйтмәдеңме?

Нури. Бер тапкыр да әйтмәдем.

Мәрьям (аптырап торганнан соң). Ха-ха-ха...

Нури. Көлмисең. Елыйсың.

Мәрьям. Анысы булмас. Бөтен барлыгың күз яшемнең тамчысына тормый.

Нури (кычкырып). Вымпелны чыгар.

Мәрьям. Үзең кереп ал.

Нури. Алам шул. (Вагоннан вымпелны алып чыга.) Кулдан ычкындырасың килмәгәч, тырышыбрак эшлиләр аны.

Мәрьям (төргәк биреп). Солдаттан язган хатларың. Арада төпле фикерләр дә бар. Укы. Үзеңне аңларга тырыш.

Нури. Үзеңә җитмәгән акылны миңа бирмә.

Мәрьям. Синдә минем хатлар юкмы?

Нури. Аларны укыдым да ерттым. Бер нәрсә дә юк.

Мәрьям. Әйе, синдә бернәрсә дә юклыгын тәмам аңладым. Синең өчен кеше — акча суга торган машина. Әгәр ул ватылып акча сукмый башласа, мәхәббәтең дә сүнәчәк.

Нури. Техниканы бераз беләм. Машинаның да ватылмый торганын сайлармын.

Мәрьям (паузадан соң). Нигә көттем икән дип уйлыйм да... Еракта чагында сине уйларым, хыялларым белән бизәдем. Мин бизәгән саен, син сөйкемлерәк була бардың. Кайттың. Каршымда менә бизәксез килеш торасың. Вәгъдәне яшьлек белән биргәнмен. Бетте ул вәгъдә. Син ирекле. Акыллы кыз туры килсен үзеңә. Йөрәгеңдә чын мәхәббәт дөрләтсен ул. Минем көчем җитмәде, сине ул олы йөрәкле кеше итсен. Бәхет телим. Кит.

Нури. Китмә дисәң дә китәм. (Тукталып.) Сорасалар, сезгә айлык акча артыннан чаптым. (Китә.)

Мәрьям. Әчми, тартмый иде. Чибәр иде... Йөрәктә ямьсез эзләр генә калдырды.

Ситдыйк керә.

Ул китте...

Ситдыйк. Ул китсә, мин килдем.

Мәрьям. Стена газетында хурлаганнар, тактада иң артта. Вымпелны алдылар.

Ситдыйк. Хыялымдагы кыз да газапны татырга тиеш иде.

Мәрьям. Еларга да тиешме?

Ситдыйк. Әйе, тиеш.

Мәрьям. Кызы елаганда егете нишләргә тиеш?

Ситдыйк. Менә болай чәченнән сыйпарга...

Мәрьям. Һәм битеннән үбәргә. Шулаймы?

Ситдыйк. Әйе. Яратып кына, иркәләп кенә...
Мәрьям. Шул турыда гына уйлыйсыз шул сез.
Ситдыйк. Юк, кыз елагач, мин дә елыйм. *(Күзен сөртә.)*
Мәрьям. Үртәвеңме бу?
Ситдыйк. Елавымны ошатмасаң, җырлыйм.

Һаваларда йолдыз, суларда кондыз,
Газизәкәй балдыз, елама...

Мәрьям. Зинһар, тукта!
Ситдыйк. Кызга берсе дә ошамаса, мин китәргә тиеш.
Мәрьям. Кит.
Ситдыйк. Ул кит дисә, мин янәшә утырырга тиеш. *(Утыра.)*
Мәрьям. Кайчагында бала-чага кебек син.
Ситдыйк *(җитди)*. Мәрьямкәй, колхозыбыз тарихында 2600 килоны беренче булып син саудың. Ике ел кулыңнан вымпел төшмәде. Дөрес яшисең.
Мәрьям. Син үзеңнән канәгатьме, Ситдыйк?
Ситдыйк. Канәгать. Чәчкән үлән турында уйланып килә идем. Егерме гектары бер айга җитте. Әгәр көтүлекнең дүрт йөз гектарына чәчсәк, егерме айлык үләнебез була.
Мәрьям. Елда унике генә ай. Егерме айлыкны ничек ашатып бетерербез?
Ситдыйк. Сыерлар санын арттырырбыз, керем дә артыр.
Мәрьям. Башың әйбәт синең. Яхшылык кына уйлый торган баш...

Мәрван керә.

Мәрван. Сәлам!
Мәрьям. Сау гынамы?
Ситдыйк. Кайтуың белән.

Күрешәләр. Гөлүзә керә.

Гөлүзә. Мәрван бит бу!
Мәрван. Мәрван. Мәрван шул. *(Ике куллап күрешәләр.)*
Ситдыйк *(Мәрванга)*. Безгә бер генә кул биргән идең.
Гөлүзә. Бөтенесен дә күреп торма әле.
Мәрьям. Кайтса, сөйләшмим дә дигән идең бит.
Гөлүзә. Кара, юри генә әйттем бит мин аны. Юлың уңдымы, Мәрван?
Мәрван. Егерме баш.
Гөлүзә. Кайда соң алар?
Мәрван. Хәзергә әле совхозда. Ул сыерларны тәрбияләү тәртибе белән танышсын өчен, бер савымчыны совхозга җибәрергә туры килер.
Мәрьям. Сөтләре ничек?
Мәрван. Ун көн буена үзем ашатып, үзем саудым. Егерме ике килодан да ким биргәне юк. Берсе егерме алтыны куа.
Гөлүзә. Ул сыерлар кемгә булыр икән?
Мәрван. Мәрьямгә дигән идем мин.
Мәрьям. Алмыйм.
Ситдыйк. Нигә?
Мәрьям. Шулай уйладым. *(Китә.)*
Гөлүзә *(Ситдыйкны җибәрәсе килеп.)* Ситдыйк абый, Мәрьям апа китте бит.
Ситдыйк. Кулыңны бирмәсәң, урынымнан кузгала алмыйм.
Гөлүзә. Теләсә кемгә кул бирергә бигрәк тагын...
Ситдыйк. Мәрван югында елмаебрак сөйләшә идең.

Гөлүзә. Кайчан, кемгә елмайдым?
Ситдыйк. Кыстама, әйттерерсең.
Гөлүзә. Әйтмичә җибәрмим дә. Әйт, әйт...

Ситдыйк китә.

*(Аның артыннан карап.)* Егет башы белән...
Мәрван. Шаярды гына.
Гөлүзә. Мәрван, совхоз кызлары чибәрме?
Мәрван. Синең ише генә түгел инде.
Гөлүзә. Егетләре дә яшен шул аларның.
Мәрван. Ятларны мактаган өчен! *(Зәңгәр шәл чыгара.)*
Гөлүзә *(исе китеп.)* Зәңгәр шәл!.. *(Сокланулын сиздермәскә тырышып.)* Арзанлысын алгансың.
Мәрван. Үзең өч кенә сум биргәч!
Гөлүзә. Башка егетләр миңа мондыйны бер тиенсез дә алып кайталар иде.
Мәрван *(яулыкка үрелеп).* Яратмагач, ертам.
Гөлүзә. Минем әйберга кагылма. *(Яулыгын башына төрлечә ябып.)* Ошатмадым... Әйбәтен алмагансың. *(Эскәмиягә сикереп менә, яңадан җиргә төшә, такмаклап.)* Матур түгел, килешми... *(Җырлап җибәрә.)*

Башларым ялангач икән,
Салыйм зәңгәр шәлемне,
Чит җирләрдә озак йөрден,
Белә алмадым хәлеңне.
Ак яулык, зәңгәр шәл,
Үткән гомерем бигрәк җәл,
Килер көннәр якты булсын,
Яхшы булсын безнең хәл...

Мәрван. Сүзләрен үзгәрттең.
Гөлүзә. Хәлем үзгә. *(Кинәт.)* Мәрван, минем киләчәгем ничек булыр икән, ә?
Мәрван. Әйбәт булыр.
Гөлүзә. Алай ике сүз белән генә әйтмә. Озын итеп, тәмле итеп сөйлә. Әйтик, менә минем сөйгәнем мине сөярме?
Мәрван. Матур итеп сөйләшсәң, сөяр.
Гөлүзә. Сөйләшәм! *(Уйлап торганнан соң).* Көмеш кошым, кыйгач кашым, иреннәрең кызыл буяуга манган кебек! *(Сикергәләп.)* Булдымы, тәмлеме?
Мәрван *(Гөлүзәне дәвам итеп).*

Сикерәсең туда-сюда,
Сүзеңнең һич рәте юк...

Гөлүзә. Без шаярып кына сөйләшәбез бит, әйеме?
Мәрван. Әйе.
Гөлүзә. Кайчан чынлап сөйләшербез икән.
Мәрван. Акыл кергәч.
Гөлүзә. Әй, миңа акыл кергәнен көтсәң... Мин көттем...
Мәрван. Сыерларнымы?
Гөлүзә. Син бигрәк тагын акыл кермәгән дигәч тә... Кашыңның бер бөртеге озын булып тырпаеп тора. Йолкам.
Мәрван. Йолыкма.
Гөлүзә. Йолкам. *(Мәрванның башын култык астына кыстыра.)*
Мәрван. Кочакладың бит.
Гөлүзә. Минме?.. Булмаганны... *(Оялып читкә борыла.)*
Мәрван. Китапны укып чыктыңмы?
Гөлүзә. Тышына кадәр ашап бетердем.

Мәрван. Нәрсә ул актиномикоз?

Гөлүзә. Йокмый торган чир. Гөмбә авырулы азык ашатканда була. Шуңа күрә малларга азыкны пешекләп бирергә кирәк.

Мәрван. Буразнаң дөрес.

Гөлүзә. Нәселләләр дә дөрес буразналыга булырга тиеш.

Мәрван. Бөтен яхшы сиңа гына булмас бит.

Гөлүзә. Миңа дигәч тә, берсен дә өемә алып кайтып сандыгыма бикләмим лә.

Мәрван. Комсызлана башладың кебек.

Гөлүзә. Кешене хезмәт бизи дисез. Минем Колхозчы ударниклар съездына Казанга, Мәскәүгә барасым килә. Газетта рәсемнәрен генә күргән кешеләрнең үзләрен күрәсем, сүзләрен ишетәсем килә. Яңа сыерлар миңа булсын инде, Мәрван.

Мәрван. Алар иң тәҗрибәле савучыга — Мәрьямгә булырлар.

Гөлүзә. Күңелең дә Мәрьям апада синең.

Мәрван. Ул акыллы.

Гөлүзә. Акыллы кыз сиңа чыкмас та.

Мәрван. Акылсызын чыкса да алмыйбыз.

Гөлүзә. Алыр идегез дә, без чыкмыйбыз. Шулай бит, зәңгәр шәл?

Мәрван. Ачуга калса, чыгуыгызны сорап та тормабыз, култык астына кыстырырбыз да алып та китәрбез.

Гөлүзә. Мин песи баласы түгел, иптәш Вафин.

Килеп туктаган мотоцикл тавышы. Нури керә.

Нури *(Мәрванга)*. Кайтуың белән!

Мәрван. Рәхмәт. Ни эш бетерү?

Нури. Акча артыннан чаптым. Кассирсыз гына өләшергә. Имза куясың да, үз исемең язылган конвертны аласың. *(Өстәлгә конвертлар ташлый.)*

Мәрван. Акча ни өчен конвертта?

Нури. Санаганда ялгыш артык алулары бар. Гөлүзә, сиңа бүләк алып килдем. Менә! *(Конфетлар бирә.)*

Гөлүзә *(Мәрванны көнләштерер өчен бөтен игътибарны Нурига бирә.)* Мәрванның мине сыйларга акылы җитми иде. Рәхмәт инде, башлап үзең авыз ит әле.

Нури *(конфет суырып)*. Кызлар кулыннан тәмле дә соң!..

Гөлүзә *(үзе дә конфет суырып, Мәрванга)*. Акыллы егетләр сөйкемле кызларга менә нинди конфетлар китерәләр.

Мәрван. Конфетка кызыккан кызлар үзләре конфет кәгазе бәясе дә тормыйлар, ди.

Гөлүзә. Акыллы кызлар конфетын ашыйлар да кәгазен ташлыйлар, ди.

Мәрван. Кәгазен ташлыйм дип, конфетын ташлый күрмә тагын.

Гөлүзә. Дипломыбыз булмаса да, конфеты белән кәгазен бутамыйбыз.

Мәрван. Күрербез. *(Китә.)*

Гөлүзә *(шатланып)*. Ул көнләшми!

Нури *(үзен күрсәтеп)*. Яраткан кеше генә көнләшә.

Гөлүзә. Ручкаңны бир әле. *(Ведомостька карап)*. Миңа 100, сиңа 120 сум! Өеңне ике айда күтәреп керә алабыз икән.

Нури. Өйне уйлыйсың икән дә, мине дә уйлыйсыңмы соң?

Гөлүзә. Нигә, Нури абый, өең бар, бураң бар, минем дә яшем җиткән. Алам дисәң, барам.

Нури. Нәселле сыер өчен генә хәйләлисең.

Гөлүзә. Нәселсез дә чыгам. Нигә аптырадың?

Нури. Моңа чаклы синнән юньле сүз ишетмәгәч...

Гөлүзә. Аларны сине сынау өчен генә әйттем бит мин. Минем кыланышларыма, синең урында икенче берәү булса, күптән инде ботымнан тотып, башым белән ташка бәрер иде. Холкың кулъяулыгына төреп йөрткечле. Хәтәр шәп кеше син.

Нури. Син Мәрванны яратасың.

Гөлүзә. Аның хатыны, баласы бар икән. Әле әйтте.

Нури. Миңа чыккач ферманы ташламассынмы?

Гөлүзә. Ташламам.

Нури. Ант ит.

Гөлүзә. Ялына дигәч тә, өйләнмәс борын тезләндермә инде. Мин дә адәм баласы бит.

Нури. Сыерлар синә, үзең миңа. *(Кул биреп.)* Мә бишне.

Гөлүзә. Ун булсын. *(Кул бирә.)*

Нури. Ферма советының кайбер членнарын алдан көйләп куйыйм әле.

Сәкинә керә.

Сәкинә *(Нурига)*. Мин эш булмасмы дип...

Нури. Булмас. Болай да штатны кыскартырга куштылар.

Гөлүзә. Монда килсәң, көнозын минем белән ызгышып ятыр идең бугай, кырчылыкка бар.

Сәкинә. Синең белән сөйләшмим. Тыгылма.

Нури. Сәкинә апа, әдәплерәк сөйләш. Бу синә үз өең түгел, бу — сыер фермасы!

Сәкинә. Икебез җайлап кына сөйләшкәндә, нигә кысыла?

Нури. Кысылсын, Гөлүзә ферма маягы. Моннан соң фермама килеп, Гөлүзәмне борчып йөрисе булма. *(Китә.)*

Сәкинә. Монысын да кулга ияләштергәнсең икән.

Гөлүзә *(биленә таянып)*. Көнләшәсеңме?

Сәкинә. Явызлыгың чыраеңа чыккан.

Гөлүзә. Син ул явыз. Гомерең буе кеше сырты кимереп яшәдең. Нәрсәң үзеңнеке? Таккан сәдәбеңә кадәр кешенеке бит. Кемгә кирәк син, нәрсәгә кирәк?

Сәкинә. Синең кирәгең дә кишер яфрагы кадәр генә...

Гөлүзә. Мин чиләкләрне юу өчен, менә бидоннарны сөт белән тутырыр өчен кирәк. Әйе, мин — кирәк! Ә син? Бүген дә Миндар абыйдан акча таммасмы дип кенә килгәнсең. Әмма юкка.

Сәкинә. Ничек юкка? Ана акча тимимени?

Гөлүзә. Тия дә, тик аның конвертын менә мин алам. *(Конвертны кесәсенә сала.)*

Сәкинә. Үзенекен үзе алсын.

Гөлүзә. Минем кесә ышанычлырак. *(Эндәшә.)* Миндар абый!..

Миндар керә.

Миндар *(Сәкинәне күрмичә)*. Нигә эндәштең?

Гөлүзә. Синә хат. *(Конвертны күрсәтә.)* Башта үзем укыйм әле. *(Укый.)* Миндар бәгырем, алларына тезләнеп...

Миндар. Әй... *(Кулын селтәп.)* Хатыннан икән.

Гөлүзә. Өзелеп чыгарга җитеп яратам дигән.

Миндар. Өзелеп чыкса да кирәге юк. *(Конвертны ыргыта, аны Гөлүзә ала.)*

Сәкинә. Конверт эчендә акча.

Миндар. Алтын бирсәң дә кирәгең юк.

Гөлүзә *(акчаларны күрсәтеп)*. Хезмәт хакын. *(Сәкинәгә.)* Мә.

Миндар. Бирмә, бирмә! *(Конвертны үзе ала.)*

Гөлүзә. Ведомостька кул куй. *(Миндар имза куя.)* Миндар абый, мине нәселле сыерлар янына җибәрәбез дип торалар бит әле.

Миндар. Барасыңмы соң?

Гөлүзә. Утырышта мине яклап кул күтәрсәң, барам.

Миндар. Синең өчен ике кулымны да күтәрәм.

Кечкенә чемодан тотып Мәүлидә керә.

Мәүлидә. Исәнмесез.

Гөлүзә. Әни, син нишләп?..

Мәүлидә. Бүген ферма советы дигән идең. *(Күрсәткечләр тактасына карап.)* Гөлүзә — беренче урында. *(Кызына карап.)* Кирек әле.

Гөлүзә. Нигә?

Мәүлидә. Нигә икәнен соңыннан белерсең. *(Торакка узалар.)*

Сәкинә *(Миндар кулындагы конвертка карап)*. Ничә сум?

Миндар. Ничә булса да үземнеке! *(Акчаны кесәсенә тыга.)*

Сәкинә. Ачуланма инде. Йөзен булса да күрим дип килдем.

Миндар. Йөзе түгел, сумы да, тиене дә юк.

Сәкинә. Акча турында әйтмим. *(Гафу үтенгәндәй.)* Моннан соң үзеңне кадерләп кенә тотар идем.

Миндар. Синекедәй кадернең булганнан булмаганы хәерлерәк. Эшлим, ашыйм, җаным тыныч. *(Китәргә тели.)*

Сәкинә. Миндар үтерде дип язу калдырам да күлгә ташланам.

Миндар. Муеныңа таш асарга онытма.

Сәкинә. Онытмам. *(Елап җибәрә.)*

Миндар *(каты әйтүенә үкенеп)*. Я инде, мин бит... бакадан курыккан хатын суга сикермәс дип кенә бит. *(Иркәләп.)* Син хәзер үк эш сорап гариза нит.

Сәкинә. Нури эш юк диде.

Миндар. Нуридан олырак ферма советы бар. *(Тәрәзә аша кәгазь белән ручка алып.)* Җайлап кына утыр әле. *(Әйбәтләп утырта.)*

Сәкинә. Рәхмәт.

Миндар. Менә шулай. Бергә эшләгәч күңелләшмәссең дә, эштән соң ызгышасың да килмәс. Күзеңә кояш төшә икән.

Костюм чабуы белән кояшны каплый. Мәүлидә белән Гөлүзә вагоннан чыга. Гөлүзә өстендә Мәүлидәнең сандыкка салып куйган киемнәре.

Мәүлидә. Мин киттем, кызым.

Гөлүзә. Рәхмәт, әни. *(Озата китә.)*

Сәкинә *(Гөлүзә артыннан карап калган Миндарга)*. Кәгаземне җил уйната. Бу яктан капла. *(Миндарны Гөлүзәгә җилкәсе белән торырлык итеп куя.)*

Гөлүзә керә.

Гөлүзә *(Миндар каршына килеп)*. Миндар абый, бу киемнәр әни бүләге. Килешәме?

Сәкинә. Күлмәк күрсәтергә Миндардан бүтән кеше беткәнмени?

Миндар. Тик кенә тор. *(Гөлүзәне әйләнеп чыга, киемнәренең кайбер төшләрен төзәтеп тә куя.)* Борынгылар әйтмешли, киемең чүплек башына, үзең кияү куенына.

Гөлүзә. Сәкинә апа мактамады.

Сәкинә. Кояш, күзем чагыла.

Сөйләшеп Нури, Мәрван,Ситдыйк керәләр.

Нури. Миндар абый, беркая да китмә. Хәзер ферма советы.

Миндар *(Сәкинәнең гаризасын алып)*. Беләм.

Нури *(кешеләрне барлап)*. Мин монда, син — бар... Бишебез дә монда. Сәкинә апа, син совет члены түгел, кит.

Миндар. Аның, энем, йомышы бар, читтән генә нитсен инде.

Нури. Тавышка куям. Кем дә кем, Сәкинә апа читтән торып кына киңәшмәгә катнашсын ди, шулар кул күтәрә... Бер тавыштан.

Гөлүзә. Член булмасам да, мине дә катнаштырыгыз әле.

Нури. Син үз кеше. Тавышка куеп тормыйм. Катнаш. Көн тәртибе — узган айга йомгак ясау, егетләр. *(Мәрьямгә кәгазь биреп.)* Беркетмәне бөртекләп яз. *(Тамак кырып.)* Беренче көн тәртибе буенча сүз үземә бирелә, иптәшләр. Халыкара империализм котырынып сугышка әзерләнгәндә, сыерлардан сөт алуның әһәмияте бер поттан да артып китә, иптәшләр. Так, менә шулай. Узган айга караганда бу айда без һәр сыер башыннан көн саен яртышар килограмм артык алдык. Тырышлыгыбыз, кайнар мәхәббәтебез аркасында. Так, менә шулай. Моның төп сәбәбе — чәчелгән үләнне минем чаптырып ашатуым аркасында.

Мәрван. Сез көтү генә кертик дигән идегез.

Нури. Кертик дисәм, керткән булыр идек. Мин мөдир! Берегез дә миңа каршы тора алмас иде. Так, менә шулай. Көтүлектәге алла биргән белән генә канәгатьләнеп ятырга хакыбыз юк. Беренче булып мин, үләне аз була торган ике йөз гектар көтүлеккә үлән чәчәргә, шул үлән хисабына сыер санын кимендә илле башка арттыруны үтенеп, идарәгә мөрәҗәгать итик дим.

Мәрьям. Бу тәкъдимне беренче булып Ситдыйк әйтте.

Нури. Кызлар белән сөйләшкәндә генә әйтелгән сүз — сүз түгел. Үлән тәкъдимен, беренче булып, авторитетлы рәвештә менә мин кертәм. Моңа каршы килүче булмас. Тавышка куймыйм. Так, менә шулай. Фермабыз бу айда уникенче урыннан... әй, ундүртенче урыннан уникенче урынга күтәрелде. Арабызда мәңге сүнмәскә маяк кабынды. Ул — син, Гөлүзә. Ура!.. Ура, иптәшләр! Так, менә шулай. Вымпелны да Гөлүзәгә бирәм. *(Гөлүзәгә.)* Мә. Нык тот. Җаның чыкса да кулыңнан ычкындырма.

Гөлүзә. Рәхмәт. Бигрәк тә сиңа, Мәрьям апа.

Нури *(үзен күрсәтеп)*. Мондый чакта житәкчене дә онытырга ярамый. Гөлүзә өчен район газеты тар. «Татарстан» газетына язарга кирәк аны. Бу хәтәр җаваплы эшне җәмәгатьчелек тәртибендә үз өстемә алам, иптәшләр. Так, менә шулай. *(Мәрьямгә.)* Бөтенесен дә мин сөйләгәнчә язасыңмы?

Ситдыйк. Нәрсә син атлаган саен Мәрьямгә абынасың?

Нури. Абынмыйча, уты юк. Янмый. Янмагач, күренми дә. *(Мәрьямгә.)* Фермабызның койрыгында сөйрәлеп баручы син. Алдынгылар рәтенә күтәрелә алмадың. Арттагылар рәтенә тәгәрәп төшеп калдың. Адәмнән оялмыйча. Без моның белән килешә алмадык. Әнә, исемен кара тактага язып хур иттек .*(Мәрьямгә.)* Ачуың килмәсен. Тәнкыйтьне яратырга өйрән. Беркетмәгә дә шулай дип яз.

Мәрван. Алай язма, Мәрьям. *(Башкаларга борылып.)* Мәрьямнең намуслы эшче. Совхозга да аны җибәрик.

Нури. Юк, совхозга вымпеллы кеше — Гөлүзә барырга тиеш.

Мәрван. Юк, Мәрьям барырга тиеш.

Гөлүзә. Нури абый, Мәрьям апа, мине җибәрегез. Үтенәм...

Мәрьям. Гөлүзәнең теләге дә бар, кулыннан да килә. Барсын.

Ситдыйк. Ә үзең?

Мәрьям. Мин совхозга бармыйм.

Гөлүзә *(Мәрьямгә, гаепле кеше сыман)*. Мин барам дигәнгә кәефең кырылдымы әллә, Мәрьям апа?

Нури. Уч тутырып акча алганда, кая кушсаң шунда йөгерә иде. Хәзер әйткән бер сүзгә карыша. Фермага мәхәббәт юк синдә. Сыер сөймисең.

Мәрьям. Үз аршының белән үлчәмә. *(Пауза.)* Минем газиз атам бар. Ул мине карап үстергән. Мин дә аны тәрбия итәргә тиеш. Сыер гына түгел, сыер чаклы алтын бирсәгез дә аны ялгыз калдырасым юк.

Ситдыйк. Гаҗәеп кеше син, Мәрьям. Юкса, кайвакытта без я

Куянга, я бер чибәргә гашыйк булабыз да ата-аналарыбызны, дусларыбызны онытабыз. Син андый түгел, син башка!

Гөлүзә. Мәрьям апа, совхозга да бармагач, миңа биргән группаны кире үзеңә ал.

Мәрьям. Юк. Мин синнән алган кәҗәләр группасын сыерга әйләндерергә телим.

Гөлүзә. Ничек инде бу?

Мәрьям. Күчеп китүче Шәриф абый үз сыерын сатмакчы. Аны колхозга алырга кирәк. Иткә диган таналарның дүртесен җибәрмибез. Шулай итеп, минем иң начар биш сыерым яхшыраклар белән алышына. Көнгә группамнан унар кило гына артык саусам да, айга өч йөз кило! Нәселле сыерлар — кызыклы инде алар, әмма үзең тәрбияләгәннәр белән нәселлеләрне куу тагын да кызыклырак. Шулай, кәҗәләр белән калам.

Ситдыйк. Хыялымда йөрткән кыз син икәнсең, Мәрьям.

Нури (*киная белән*). Яратам дип тә җибәр инде.

Ситдыйк. Әйе, яратам.

Нури. Сиңа өйләнәм дип тә өстәсәң...

Ситдыйк. Нигә? Атаңны да бергәләп карарбыз. Чык, миңа, Мәрьям.

Нури. Монсы көн тәртибенә кергән нәрсә түгел.

Ситдыйк. Кешенең кешелеге һәрвакыт көн тәртибендә. Мәрьям, вәгъдә бир.

Мәрван. Үзем башкода булам. Мәрьям, бирегез, кулыгызны.

Нури (*кычкырып.*) Җыелышны туйга әйләндердегез.

Мәрван (*Ситдыйк белән Мәрьямнең кулларын тоташтырып*). Ситдыйк белән Мәрьям никахын расларга диганнәр кул күтәрә. Бертавыштан!

Сәкинә. Болай булгач, Гөлүзә группасын кемгә бирерсез икән?

Миндар. Минем хатынга бирсәгез, менә ние дә бар. (*Гариза бирә.*)

Нури. (*Сәкинәгә*). Эшләрсеңме?

Сәкинә. Минме?.. Мин бер тотынсам, Гөлүзәң кебек кенә дә эшләмәм әле.

Гөлүзә. Сөтләрен киметмәссеңме?

Сәкинә. Киметмәм инде, киметмәм.

Миндар. Нитүенне ташларсыңмы?

Сәкинә. Йөрмәсәң — көнләшмәм.

Гөлүзә. Минем белән талашмассыңмы?

Сәкинә. Иремне эсәртсәң — талашу гына түгел, сугышырмын да.

Нури. Маягыбыз тыныч эшләсен өчен, Сәкинә апаны алмаска.

Сәкинә. Алмаска дип, эшләмәгәч нәрсә ашап яшим? Урлашырга кушасыңмыни?

Мәрван. Тавышка куй.

Нури. Сәкинә апаны алмаска диганнәр кул күтәрә. (*Ялгызы.*) Ярар, алдык инде, Сәкинә апа.

Сәкинә. Беркетмәгезгә: «Хатыны төзәлү сәбәпле, ирен өенә кайтарырга»,— дип тә языгыз инде.

Миндар. Ашыкма, карчык. Башта берәр ай чүгәләп, менә болай нитеп күрсәт әле. (*Сыер савып күрсәтә.*) Шунда гашыйк итсәң, яңадан туй ясап алам үзеңне.

Нури. Болай булгач, совхозга Гөлүзә бара булып чыга инде, егетләр.

Мәрван. Тавышка куй.

Нури. Гөлүзә диганнәр кул күтәрә... Бер тавыштан. (*Гөлүзәгә мәгънәле карап.*) Так, менә шулай. Хәзер, иптәшләр, иң соңгы мәсьәлә. Идарә безгә: «Сезгә зоотехник кирәкме, әллә ферма мөдиреме?

ЮНЫС ӘМИНОВ ◆ ӨЧ ВАЛАК ◆

Икесенең берсен акылыгыз белән кыскартыгыз да, фикерегезне безгә җиткерегез».— диделәр. Син нәрсә әйтерсең, Миндар абый?

Миндар. Ни инде... Шулай инде... Әйе.

Нури. Нәрсә «ни»?

Миндар. Икегез дә ни... Кыскартсак та ни, кыскартмасак та ни. Бүтән сүзем юк.

Нури. Үзең нәрсә әйтерсең, Мәрван?

Мәрван. Халык әйтсен.

Нури. Әйтәм. Иптәшләр, мин эшемне зоотехниксыз да во! алып барам. Зоотехникның кирәген дә тапмыйм. Мәрван үзе дә китәм, ди. Тавышка куям.

Гөлүзә. Мәрван китәм димәде бит ул. Шулай бит, Мәрван?

Нури. Ул китәм димәсә соң, әллә мине куарга чамалыйсыңмы?

Гөлүзә. Син кумыйча гына кит, Нури абый. Мәрван монда калсын.

Нури. Ни өчен мин китәргә тиеш?

Гөлүзә. Сиңа монда эш юк.

Нури. Ничек инде «эш юк»?

Гөлүзә. Сыерны синсез дә савабыз. Чиләк-сөлгеләрне син кушмасаң да юабыз. Монда артык кеше син.

Нури. Димәк, сиңа Мәрван кирәк?

Гөлүзә. Әйе, миңа Мәрван кирәк. Ул ятып торган сыерның да кайсы аягы авыртканын белә. Авызын ачып карамыйча да ничә теше бар икәнен белә. Утлыкларына күз төшерү белән кайсысына нәрсә җитмәгәнен әйтә. Укулар үткәрә, нәселле сыерлар алып кайтты. Ул килгәч сөт тә артты. Мәрван кирәк безгә.

Нури. Мәрван дип, мин китсәм, мөдирсез ферма буламыни?

Мәрьям. Мәрван мөдир дә, зоотехник та булыр.

Ситдыйк. Әйе шул. Мөдирнең белемле кеше булуы яхшырак. Тавышка куй.

Нури. Туктагыз әле. Аңлап җиткермәдегез сез, иптәшләр.

Миндар. Чыннан да, Нури энем, син нит инде.

Нури. Нитим?

Миндар. Әйе, син кит инде.

Гөлүзә. Аңлашылды. Нури абыйга үзен-үзе тавышка куюы уңайсыз. Шуңа күрә мин кул күтәртәм. Кем дә кем Нури абыйны эшеннән үз теләге белән...

Нури *(бүлдереп)*. Теләмимі..

Гөлүзә. Үзе теләмәсә дә эшеннән азат итәргә, аның урынына Мәрванны билгеләргә ди, шулар кул күтәрә. Кемнәр каршы? *(Нури ялгызы.)* Берәү. Үзе.

Нури *(Гөлүзәгә)*. Мин сине фермага алып кеше иттем...

Гөлүзә. Син түгел.

Нури. Бергә яшәрбез диден.

Гөлүзә. Мин шаярып кына.

Нури. Миңа чыгарга вәгъдә бирден, анысы да шаярыпмы?

Гөлүзә. Нури абый, мин башканы яратам.

Нури. Мәрваннымы? Ул өйләнгән!

Гөлүзә. Өйләнгән дигәнен дә юри генә әйттем.

Нури. Чыны өйләнгән. Хатыны, баласы бар икәнен Мәрван үзе килгән көнне үк әйтте.

Миндар *(Мәрванга)*. Син, энем, әллә чыннан да ниме?

Сәкинә. «Ниме» дигәне — өйләнгәнме дигән сүз инде аның.

Мәрван. Өйләнгән булсам, нишләр идегез? *(Озын пауза.)*

Миндар *(аптырап)*. Ничек булды соң бу ни?

Ситдыйк. Безнең якларда кызлар белән болай шаярмыйлар, иптәш Вафин.

Сәкинә *(Гөлүзәгә күрсәтеп)*. Син дә минем хәлгә калдыңмы, ха-ха-ха...

Мәрван. Көлмәгез. *(Тынлык)*. Әгәр мин Гөлүзәне кардәшем, туганым урынына күреп яратсам? Без — кешеләр. Кешеләрне яратырга тиешбез. Сез дә аларны хөрмәт итәргә өйрәнегез. Тәмам беткән кешедә дә бер яхшы як була. Үстерергә кирәк шул яхшы якны. Кеше бөтен ягыннан да яхшыга әйләнсен. Бу безнең бурычыбыз.

Мәрьям. Кешене хөрмәт итү — бер нәрсә, ә семьялы килеш яшь кызны гашыйк итү, аның йөрәге белән шаяру...

Гөлүзә *(бүлдереп)*. Мәрван абыйга сүз әйтмәгез. Ул шаярмады. Мине сеңел итеп, кешегә исәпләп, кешечә киңәшләр генә бирде. Өти Балактан Гөлүзәгә әйләнүемне теләде. Изгелек эшләде. Изгелек өчен кешене тиргәмәгез. Мәрван абыйны ачуланучыга гомерем буе рәнҗиячәкмен. *(Өстәл янына килә.)* Иптәш мөдир...

Мәрван. Тыңлыйм, Гөлүзә.

Гөлүзә *(өстәлгә куеп)*. Менә минем халатларым, сөлгеләрем, бидоннарым, чиләкләрем, вымпел. Совхозга да башка кеше билгеләгез. Мин китәм.

Нури. Китмә. Монда кал. Син миңа кирәк.

Гөлүзә. Савым сыер, эш аты, түшәк кирәк сиңа. Берсе булырга да теләмим. Чөнки мин үзем кеше. Начар кеше, ләкин кеше!

Мәрьям. Юк, син әйбәт кеше, Гөлүзә.

Гөлүзә. Гаепле, гөнаһлы кеше мин. Үз сөтем артсын өчен сыерларның азыгын урладым. Синең группаңны үземә алу өчен, сезне карама төбенә җибәреп, Нури абый белән арагызны боздым. Кичер, Мәрьям апа. *(Нурига.)* Син дә кичер, Нури абый. Нәселле сыерларга хуҗа булу өчен тормышка чыгарга вәгъдә куеп, сине дә алдадым. *(Сәкинәгә.)* Миндар абыйны яраткан кыланып, кәефеңне күп боздым. Кичер, Сәкинә апа. Аннан шуны үтенәм: Миндар абыйны яратыгыз. Ул әйбәт кеше. Сине генә ярата. Син дә кичер, Миндар абый. Кесәңнән төшеп калган акчаңны вакытында бирмичә, күп күңелсезлекләр китердем. *(Акча бирә.)* Кичегеп кайтаруым өчен ачуланмагыз. *(Барысына да.)* Кешеләр, барыгыз каршында да гаепле мин. Кичерегез мине, кешеләр!

Мәрван. Кичерерлек гаебең юк бит.

Гөлүзә. Бар. Күпләр үз бәхетләрен тормышта хаталар ясамыйча, турыдан-туры табалар. Ә менә минем кебекләр үз бәхетләренә бик бормалы, үтә әйләнмәле юллар аша киләләр. Алар үз бәхетләрен мең абынып, мең егылып, мең газап белән генә табалар. Хата арты хата ясадым. Явызландым, киреләндем, әмма сез мине ташламадыгыз, һаман кул бирдегез. Рәхмәт сезгә, кешеләр! Барыгызга да мең рәхмәт. Ә хәзер юл бирегез. Мин китәм.

Мәрван. Китеп кая бармакчы буласың?

Гөлүзә. Кая барсам да, кайсы юлдан барсам да Өти Балакка әйләнмәм. Мәңге Гөлүзә булып калырмын. Моннан соң минем өчен борчылмагыз. Хушыгыз.

Мәрван. Мин сине яратам бугай. Китмә. Мин өйләнмәгән. Мин егет кеше.

Гөлүзә. Егет кеше?.. *(Артка чигенеп.)* Әт-текәсмнән... *(Балкып.)* Ә мин сине яратмыйм...

Мәрван. Яратмасаң инде... хәерле юл, Гөлүзә.

Гөлүзә *(йөгереп килеп өстәлдәге әйберләрен бер-бер артлы ала.)* Китмим, китмим, кусагыз да китмим...

Мәрван *(бер читтәрәк калган халатны Гөлүзә җилкәсенә сала)*. Ак халатлар матур да итә соң уңган кызларны, Гөлүзә...

# ӘМИРХАН ЕНИКИГӘ 60 ЯШЬ



## Гали Халит

# ТАЛӘПЧӘН ҺӘМ ЭЗЛӘНҮЧӘН ТАЛАНТ

Әмирхан Еники — киң катлау укучыларга аеруча сугыш вакытындагы һәм аннан соңгы хикәя-повестьлары белән танылып киткән язучы. Ул әсәрләрнең күбесе үз вакытында укучыларның җылы игътибарына да, тәнкыйтьнең каты хөкеменә дә очрады. Әмма заман сынаулары һәм җәмәгатьчелек мөнәсәбәте — барыннан да югары, объектив критерий. Бу күптән билгеле хакыйкать булса да, Ә. Еники иҗатына карата сүз башлагач, аны тагын бер мәртәбә искә аласы килә. Чөнки аның иҗаты тирәсендә барган бәхәсле сүзләр күп кенә очракларда бер яклырак булдылар, аларга объективлык җитеп бетмәде. Шуңа күрә тормыш һәм әдәбият тәҗрибәсе ноктасыннан караганда, хәзер инде ул бәхәс һәм хөкемнәрнең билгеле бер өлеше үзеннән-үзе кире кагылуы да, бөтенләй яңадан бәяләнүе дә табигый һәм урынлы.

Ә. Еникинең беренче тапкыр каләм тибрәтә башлавы 1926—1927 елларга туры килә. Ләкин сугышка кадәр аның сан һәм күләм ягыннан зур булмаган әсәрләрен иҗади ашкыну һәм эзләнүләрнең әле җитлекмәгән үрнәкләре дип кенә карарга мөмкин. Дөрес, аларда киләчәктә ачылып китәчәк талантка хас матур яралгыларны табуы кыен булмас иде. Әммә язучы үзе дә һәм укучылар да аның иҗатындагы тирән борылыш һәм үсешнең билгеләрен сугыш елларында тоя башладылар.

1

Бөек Ватан сугышы еллары татар язучылары иҗатында зур сыналыш һәм җитлегү дәвере булды. Әйе, сыналыш, дибез, чөнки илебез һәм халкыбыз өстенә ябырылган мәрхәмәтсез фашизм белән көрәш безнең барлык материаль, физик һәм рухи көчләребезне гаҗәп киеренке тарихи сынау алдына китереп бастырды. Ниһаять, социалистик җәмгыять һәм совет кешесе сугыш утында сыналып кына калмады, ә үзенең тоткан юлы какшамас һәм рухы сынмас икәнлеген тагын бер мәртәбә бөтен дөнья алдында күрсәтте. Совет кешесе, явызлык һәм вәхшәт белән аяусыз, канлы бәрелеш кырларына чыгып, социалистик гуманизмның, ирекле кешелек идеаллары белән рухланып яшәүнең көче никадәр тирән тамырланганын исбатлады.

Ә. Еники дә, безнең күпләгән язучыларыбыз шикелле, фронтка китә һәм, солдат булып, совет халкы белән бергә чигенү михнәтләрен дә, һөҗүм итү һәм җиңү шатлыкларын да йөрәге аша кичерә. Сугыш еллары бу язучыбыз өчен дә драматизм белән тулы зур тормыш мәктәбе булып, аның иҗатында совет халкының рухи батырлыгына һәм матурлыгына соклану белән тулы гуманизм идеясен киң итеп ачып җибәрделәр. Аның иҗаты тарих, тормыш һәм кеше язмышы турында җитди уйланулар белән сугарыла башлады.

Сугышка багышлы теге яки бу әсәр турында сөйләгәндә, без бигрәк тә «сугыш темасы» дигән төшенчә белән хөкем итәргә гадәтләнгәнбез. Гомумән алганда һәм урыны белән алай сөйләү, бәлки, җайлыдыр да. Әмма Ә. Еники иҗатына карата ул төшенчә абстракт булып тоела шикелле. Чөнки аның сугыш темасына бәйле әсәрләрендә туры мәгънәсендә без укырга күнеккән сугыш вакыйгалары, ягъни хәрби операцияләр юк. Ниһаять, аның геройлары сугыш эчендә аеруча батырлык күрсәтү белән дә калкып тормыйлар, чөнки язучы андый максатны куймый.

Ә. Еники, барыннан да элек, сугыш чынбарлыгының һәм драматизмының кеше рухында, психологиясендә ничек чагылышына игътибар итә. Сугыш шартларында совет кешесенең эчке дөньясы, үзенең шатлыгы һәм кайгылары белән, нинди сынаулар кичерә — менә шул ноктаны тотарга һәм сәнгать фокусының үзәгенә куярга омтылыш язучының төп иҗади максаты булып тора. Нәкъ шул ноктада «сугыш һәм кеше язмышы» дигән теманың гуманистик мәгънәсе күренә дә инде.

Сугыш дәһшәте белән дөньяның асты өскә әйләнгән бер вакытта, анасыннан аерылып калган кызчыкны солдат Зариф күтәреп алып китә. Кетмәгәндә бала белән ана очрашалар («Бала», 1941). Бик гади һәм очраклы булып күренгән бу вакыйганы сурәтләүдә кешегә бетмәс мәхәббәт җылылыгы тупланган. Әнә шунда гуманизм һәм батырлык орлыгы шытып ята да инде. Ул җылылык һәм орлык укучы йөрәгенә дә күчте. Язучының «сугыш темасы» белән бәйле беренче әсәре иде бу.

«Ялгыз каз» һәм «Мәк чәчәге» кебек этюдларда да болай бик гади булып күренгән хәлләр һәм образлар сугыш вәхшәтенә каршы безнең гуманизмның аерата конкрет чагылышы булып тоелалар. Аларда да үлемгә нәфрәт, өяшәүгә мәхәббәт белән алга, фашизмны тар-мар итәргә ашкынучы совет кешесенә дан җырлана. Мәк чәчәгенең совет солдатларына төбәлгән соңгы сүзләрендә тирән мәгънә ята, һәм аларны китерми калып булмый: «Сез көнбатышка таба барасыз! Сезне анда канлы сугышлар көтә булыр, һәр адымыгызны бәлки үлек гәүдәләр, кара кисәүләр аша атлап үтәргә туры килер. Ләкин мин — дөньяның матурлыгыннан туймаган, һаман да аны матур итәргә теләгән ялгыз мәк — сезнең һәр үткән адымыгыз артыннан чәчәкләр үсеп калуын теләр идем... Көл һәм каннан яралган чәчәкләрнең рәхмәте сезне мәңгелек дан һәм бәхеткә илтсен! Хуш, кеше, хуш! Ак юл сезгә!»

«Ана һәм кыз» хикәясе дә көчле гуманистик идея белән сугарылган. Авыру ананың армиядәге улын сагынып көтүе һәм кызы Рәхиләнең энесе солдат Хәсән турындагы кайгылы хәбәрдән соң үзләре өстенә төшкән рухи авырлыкны, газапны батырлык белән кичерүе — болар миллионнар башыннан үткән хәлләр булып, үзләренең мәгънәләре белән зур гомумиләштерү дәрәҗәсенә күтәрелгәннәр. Бу драматизмда безнең кешеләрнең искиткеч рухи чыдамлылыгы һәм тыйнаклыгы гәүдәләнеп калган. Әйтергә мөмкин ки, сугыш елларында безнең әдәбиятның актив, үзәк геройларыннан берсенә әверелгән, һәртөрле авырлыкларга чыдам һәм тырыш татар хатынкызлары образының әнә шундый гүзәл кешелекле сыйфатларын тирән психологик драматизм һәм нечкә лиризм белән беренче буларак күрсәткән әдипләребез арасында Ә. Еники, һичшиксез, үзенең тиешле урынын алырга хаклы. Моның бәхәссез икәнлеген исбатлаучы тагын бер әсәр — «Бер генә сәгатькә» хикәясе.

Солдат Гомәрне никадәр ашкынып көтүләр, күрешүләр һәм аерылышулар — бер генә сәгатьлек киеренке вакыйганы сюжет итеп алган бу кечкенә әсәрнең киң психологик мәйданына әвереләләр. Хәтта әсәрдә бик аз гына, соңга табарак кына күренеп калган Заһидә драмасы да зур мәгънәгә ия: Гомәр сөйгән кызын да күреп китәрмен дип өметләнә бит әле. Ләкин Заһидә соңгара, егет китеп тә бара. Матур очрашу булмый. Димәк, кешеләр язмышы һәм теләкләре гел бертөрле тигез юллардан гына бармый икән. Монда да шулай ук гаҗәп бер психологик конкретлык һәм сәнгатьчә тәгаллек белән тормыш контрастлары бирелгән. Әмма боларның һәммәсен бер ноктага җыйган зур идея бар. «Иң мөһиме: мин, бер ана кичерешләре белән генә чикләнмичә, башка кешеләрнең дә күңелендә солдат егетнең кыска гына арада күренеп китүеннән туган уй-хисләрен күрсәтергә теләдем,— дип язган иде Ә. Еники үзенең бер мәкаләсендә.— Шулай итеп, мин совет кешеләренең рухи ныклыгын, патриотик хисләрен үземчә тулырак ачарга тырыштым» [1].

---

[1] Язучылык хезмәте турында. Казан. 1958 ел. 178 бит.

«Сугыш һәм кеше язмышы» дигәч тә, «Тауларга карап» (1948) хикәясенең аеруча фәлсәфи мәгънәсе күзгә ташлана. Сез иң элек Локман картның гаҗәп бер язмышына игътибар итегез: ул үзеннән соңгы берничә буын гомеренең җанлы шаһите генә түгел, ә аларның тарихи бәйләнешен, бетемсезлеген символлаштырган халык вәкиле дә. Локманның бердәнбер улы Тимерҗан элекке империалистик сугышта югала, ә аннан калган оныгы Батырҗан Ватан сугышыннан кайтмый. Ләкин Батырҗанның да нәселе бетми. Локман карт икенче буын оныгын күрү бәхетенә дә ирешә. Ул инде Газизҗанны да үзе тәрбияли.

«Әйе, кулөгәләр шуып үтә, тормыш бетми, һаман, һаман дәвам итә»,— дип тәмамлана хикәя. Бу, әлбәттә, артык гомумән әйтелгән билгеле хакыйкать, ә Еники әсәренең эчтәлеге бу хакыйкатьне күп тапкыр конкрет, фәлсәфи тирән һәм әдәби бай итеп күрсәтү көченә ия. Әсәрнең сәнгатьчә чынлык мәйданында авторның теләге киңрәк булып чагылган. Дөньяның, тарихның нинди генә трагедияләрендә дә Локманның нәселе бетми. Алай гына да түгел, тарих үзенең мәрхәмәтсезлеге белән дәвам итә, ә тарихны тудыручы һәм кешелекне алга алып баручы яңа буыннар һаман яшиләр, килечәккә баралар, аларның язмышы үзе тарихка әверелә. Әйе, бу — яхшылыкка тирәнтен ышаныл, аның фаҗигасенә дә оптимистларча карау фәлсәфәсе. Кешеләр язмышы күпме генә авыр, күңелсез булмасын, әмма кешелек һәрвакыт җиңә һәм һич тә үлми. Тарих аралыгының ике чигендә торган Локман карт һәм аның оныгы Газизҗаннар арасындагы өзелмәс мөнәсәбәт, бәйләнешләр шул турыда сөйлиләр. Шуңа күрә дә әйтергә мөмкин ки, Ә. Еники иҗатында олы һәм яшь буыннар арасындагы мөнәсәбәтне күрсәтү үзенең идея-эстетик концепциясе белән яхшы ук төз һәм принципиаль проблема булып тора.

Бу яктан килгәндә, ата-ана образларының роленә һәм аларның күп кенә очракта безнең әдәбиятка хас традицион сыйфатларны дәвам иттерүләренә аеруча игътибар итмичә булмый. «Бер генә сәгатькә»дәге Галимҗан абзый белән Мәрьям абыстай, «Тауларга карап»тагы Локман карт, «Ана һәм кыз»дагы Хәмидә җиңги һәм, ниһаять, «Әйтелмәгән васыять»тәге Акъәби белән Миңлебай бабай — болар һәммәсе кешелекле матур сыйфатларга ия булган һәм язучы иҗат концепцияләренең үзәгендә торган геройлар дияргә мөмкин. Локман карттан соң зур гомумиләштерү планында эшләнгән һәм үзенең әдәби-мәгънәви көчен тирән психологик җирлектә ачкан типлардан берсе — Акъәби дисәк, һич тә артык булмас. Бу типта, һичшиксез, зур идея йөкләмәсе бар.

«Әйтелмәгән васыять» турында тәнкыйтьтә яхшы ук каршылыклы фикерләр булды. Әмма аның «яңа, катлаулы заманның драматик күренешләренә бәя бирә торган» [1] әсәр булуын инкарь итүче күренмәде шикелле. Шушы хакыйкатьне икърар иткән хәлдә, шулай да кайбер әдипләр Ә. Еникинең бу әсәрен җитди идея кимчелекләреннән азат түгел дип карарга теләделәр. «Әйтелмәгән васыять» хикәясендә,— ди, мәсәлән, Мирсәй Әмир,— автор бүгенге тормышыбызда әйдәүче урын тоткан буынны инде картлыкка чыккан буынга каршы куя... Тагын да аянычлырак: картлар ягына, әсәрдә сурәтләнгәнчә, инде бетүгә хөкем ителгән, төзәлмәс чиргә мөбтәла булган, хәтта инде үлеп ук киткән Акъәбиләр яки, өрәге бу дөньяда булса да, үзе кеше буларак инде күптән сафтан чыккан Миңлебай картлар ягына кушыла... Нәтиҗәдә укучыны алга әйдәү урынына, аны артка, иске авылга, тизәк яккан учаклар, сәләм түбәләр, читәннәр авылына йөз юнәлдертергә тырышу килеп чыга. Туган ил төшенчәсен тарайтып аңлата» [2].

Сүз дә юк, гаҗәп каты гаепләү бу. Әмма, барыннан да бигрәк, әдәбиятны үзенең күп еллык иҗат тәҗрибәсе аша бөтен нечкәлекләре белән аңлаган олы язучыбызның «Әйтелмәгән васыять»кә бу кадәр чамадан тыш берьяклы, утилитар һәм дидактик караштан бәя бирүе гаҗәбрәк, әлбәттә.

Безнең фикеребезчә, «Әйтелмәгән васыять»нең һәм аеруча Акъәби образының эчке, фәлсәфи мәгънәсе һәм сәнгатьчә әһәмияте байтак тирәндә ята. Ул, бөтенесеннән дә элек, үткәнгә, халыкка һәм туган илгә мөнәсәбәт белән бәйләнгән. Язучы шул мөнәсәбәтнең бүгенге көндә дә кискен драматизм булып мәйданга чыгуын күрсәтүне максат итә. Әсәрдә бу зур максатның ачык булып ятканлыгын укучы турыдантуры сизеп торуына шикләнү мөмкин түгел. Бу хакта тәнкыйть үзе дә икеләнмәде

---

[1] Гариф Ахунов. Язучы һәм заман. «Казан утлары» журналы. 1967 ел. 5 сан. 108 бит.

[2] Мирсәй Әмир. Укучы өчен язабыз. «Казан утлары» журналы. 1967 ел. 6 сан. 125—126 битләр.

шикелле. Мәсьәләнең каршылыклы һәм нечкә ягы — әнә шул максат җирлегендә ике буын мөнәсәбәтен һәм шунда автор позициясен билгеләүгә кайтып кала.

Чыннан да, Акъәби язмышы гына, аның, яхшымы-яманмы, үз халкының, туган якларының гореф-гадәт, йолаларын изге дип карап, шул хакта нәсел-нәсәбенә васыятен әйтә алмыйча үлеп китүе генә кызганыч түгел, ә аны аңлап һәм ихтирам итеп җиткерә алмаган икенче буын кешеләреннең бер төркеме шулай ук кызганыч та, гаепле дә.

Яңаның, яшь буыннарның искедән, олы буыннардан аерылу һәм ераклашу процессы ул һәр чорда үзенең билгеле бер драматик кискенлегеннән, каршылыкларыннан башка була алмый. Бу — хакыйкать инде. Аны күрми китү бигрәк тә әдәбият шикелле нечкә рухи дөньяда гомумән мөмкинме икән? Сүз монда безнең замандагы олы һәм яшь буыннарны бер-берсенә капма-каршы позицияләрдә яки моның бөтенләй киресе итеп күрсәтү турында бармый, әлбәттә. Нәрсә турында бара соң? Әсәрнең башында ук автор: «Тик менә бик бәхетле булып киткән балалары аңардан (Акъәбидән.— Г. Х.) ничектер шактый ераклаштылар»,— дигән искәртүне ясап китә һәм менә шул ераклашуның эчке, психологик драмасына керүне максат итә.

Акъәби балалары һәммәсе дә үзләренең тормышларын матур итеп корганнар. Алар, чын мәгънәсендә совет кешеләре буларак, аналарын да ихтирам итәләр. Әмма ана белән балалар арасында үткәнне һәм бүгенгене аңлауда зур аралык та ярылып ята. Әнә шул аралыкка язучы текәлеп карарга омтыла һәм шунда яткан драматизмның тагын да кабарып, үсеп китүе өчен борчыла.

Әйе, борынгы традицияләрнең, гореф-гадәтләрнең һәм йолаларның искергән өлеше яңа заманнарда бетүе һәм яшь буыннарга чит булуы табигый. Ләкин яшь буыннарның һәм яңа гадәтләрнең дә үзләренә хас кимчелекләре, чирләре булуын шулай ук онытмаска кирәк. Ә. Еники әнә шуларга каты итеп тәртеп күрсәтә. Билгеле, бу тәртү, гел яхшылык һәм матурлык иллюзияләренә генә исереп, әдәбиятта да шуларны гына күрергә гадәтләнгән кешеләрне кинәт сискәндереп тә җибәрергә мөмкин. Әмма заманның, чынбарлыкның ачы хакыйкатенә каршы бару бик кыен. Монда Акъәби кебек типларның традицион-мелодраматик стильдә, ә аның балаларының билгеле бер күләмдә ирония белән сурәтләнүе әсәр үзәгендә торган драматик чынлыкны да һәм авторның аңа карыс карашын да алмаштыра яки каплап калдыра алмый.

Үткән белән бүгенгене бәйли торган мәңгелек бөек йола һәм традицияләр бар: болар — халыкка, ватанга мәхәббәт һәм шул мәхәббәтне изге дип санаган олы буынга ихтирам. Менә шул идея, югарыда искәртелгәнчә, «Әйтелмәгән васыять»нең үзегеннән үтә һәм Акъәби образының гомумиләштерүче символик ана образы булуын да куәтли. Акъәби әйтә алмый калган васыятьнең дә төп, асыл мәгънәсе шуңа кайтып кала бит:

«Әйе, сез зур кешеләр булдыгыз, илгә, дәүләткә кирәкле, файдалы кешеләр булдыгыз, хәзер шуның әҗерен күрәсез, рәхәтен чигәсез!.. Ләкин сезне менә без, Сәлимҗан белән Акъәби дигән гади башкорт кешеләре, дөньяга китердек, Юлкотлы дигән кечкенә башкорт авылы сезне үзенең туфрагында үстерде, башкорт халкы сезне бүгенге югарылыкка күтәрде,— сез шуны онытмагыз, балаларым, ишетәсезме? Сезнең онытырга хакыгыз юк, аңлыйсызмы?.. Бу минем күңелем түреннән чыккан иң кайнар, иң зур, иң соңгы васыятем сезгә!»

Әнә шундый зур уй-тойгылар белән дөньядан китүче ана образы ул Акъәби. Ул — ничәмә гасырлар аша үсә килгән халыкчанлык һәм ватанчылык хисләренең җанлы тарихи тупланышы. Аның кабере өстендә шагыйрь дә шуны сөйли: «Әйе, ул барыбызның да уртак әсәебез иде. Алай гына да түгел, мин, һич икеләнмичә, аны башкорт халкының изге җанлы анасы дияр идем...»

Шул рәвешчә, Локман карт образы белән янәшә куеп караганда, Акъәби образының да эчке зур фәлсәфи мәгънәсе бик ачык: ул олы һәм яшь буыннарның үзара тарихи өзелмәс бәйләнешен символлаштыра. Яшь буын исә шул бәйләнешне һәрвакыт аңларга һәм онытмаска тиеш. Ә моны белмәүче һәм онытучы кешеләр җир өстендә булып торган чакта, Акъәби васыятьләренең гыйбрәтле якларына игътибарсыз калу мөмкинме икән?

«Әйтелмәгән васыять»тә язучы куелган теманың мораль җирлегенә аеруча игътибар итеп, ватанга һәм халыкка мәхәббәтнең традицион сыйфатларын гореф-гадәт һәм йолаларга мөнәсәбәт белән конкрет итеп бәйләп күрсәтергә тели. Бу теләк, бәлки, ана образын сентименталь буяулар белән беркадәр куертып сурәтләүдән дә азат түгел-

дер, һәм шуның аркасында үткәннең традицияләрен әзмы-күпме идеаллаштыру сыман бер тойгы да туа торгандыр. Ләкин ничек кенә булмасын, Ә. Еники иҗатындагы Ана образы үзенең зур гуманистик сыйфатыннан бервакытта да мәхрүм түгел. Ул үзенең кешегә, туган илгә һәм халыкка тәбәлгән якты йөзе белән, һәрвакыт тыйнак татар хатыны булып, әмма үзенең эчке матурлыгын яшермичә горур басып тора һәм һәрчак үзенә ышанычта булырга чакыра. Мондый Ананы идеаллаштыру хокукыннан язучыны мәхрүм итү, әлбәттә, дөрес булмас иде.

Һичшиксез, сугыш елларының тәҗрибәсе һәм шул җирлектә туган әсәрләре, образлары Ә. Еникинең тормышка, кешегә һәм иҗат эшенә аеруча җитдилек, таләпчәнлек һәм җаваплылык белән карап алга баруы, талантының җитлегеп үсүе турында сөйләделәр. Бигрәк тә шул еллардан башлап аның әсәрләре заман һәм замандашлары турында кискен итеп һәм борчылып уйланулар белән дә үтәдән-үтә сугарыла барды. Бигрәк тә кешенең җәмгыятьтәге урынын мораль җаваплылык ноктасыннан аңларга һәм күрсәтергә омтылыш көчәйде.

Беренче нәүбәттә әнә шул яктан язучының «Рәхмәт, иптәшләр!» (1951—1952) шикелле повесте үз вакытында ук инде татар прозасы үсеше өчен әһәмиятле генә бер тәҗрибә итеп бәяләнгән иде. Әмма шуның белән бергә үк, 50 еллар башындагы тәнкыйтьтә, конфликтсызлыкка каршы көрәш бик нык кызган бер чорда, бу повестьның да әнә шундый конфликтсызлык бәласеннән азат түгеллеге турында сөйләнүләр булды кебек. Турысын әйтергә кирәк: бу авыруны, бармы-юкмы, шул елларның һәрбер әдәби әсәрендә күрергә, табарга теләү үзе бер чиргә әйләнгәнлектән, аның конкрет эчтәлеге, чамасы нидән гыйбарәт икәнлеген ул вакытларда да һәм аннан соң да төгәл итеп күз алдына китерү кыенрак булды. Күрәсең, безнең тәнкыйть һәрбер әсәрдә искелек белән яңалык көрәшен гел иҗтимагый, социаль конфликт итеп кенә аңларга, шунда уңай һәм кире типларның туктаусыз бәрелешүен, «сөзешеп» торуын күрергә теләгәнлектәнме, «Рәхмәт, иптәшләр!»не бәяләгәндә дә, язучының иҗади үзенчәлегеннән килә торган эчке яңалыгын үз вакытында төсмерләп җиткермәделәр булса кирәк. Югыйсә бу әсәрнең үзәгенә алынган кеше проблемасы, аның эчтәлеге мораль җаваплылык ноктасыннан тирән бер психологик күренеш буларак хәл ителүе читләтелмәгән булыр иде. Һәм заман үтү белән нәкъ шул яктан язучының позициясе хак булуына ныграк ышанасы килә.

«Рәхмәт, иптәшләр!» повесте колхоз терлек фермасы мөдире Нургали Мингалиевнең, эчке каршылыкларны кичереп, ничек итеп үзенең коллектив алдындагы җаваплылыгын аңлауга килүен күрсәтә. Ул башта «мин-минлеге бик кимсетелгән, үзен чыннан да хаксызга рәнҗетелгән дип ышанган, шунлыктан һәркемгә ышанмыйча, шикләнеп карый башлаган кеше» булып алга баса. Нургали бер яктан җитди, ә икенче яктан гаҗәп наив уй-тойгылар арасында чайкала. Үз-үзен яратучанлык, мин-минлек һәм үзенә генә ышанучанлык хисе аңарда җәмәгатьчелек тәнкыйтеннән һәм таләпләреннән читләшү, хәтта шикләнү кебек эгоизмны кабызып җибәрә. Шунлыктан Нургали авыл советы сессиясендә ферма эшен тәнкыйтьләүне бик авыр кичерә: авыл советы председателе Сөләймановның таләпчән мөнәсәбәтенә шомланып, мәкерле ният белән эшләнә бу дип карый, һәртөрле вәсвәсәләргә бирелеп, аңардан көнләшә һ. б. Болар һәммәсе — Нургалидәге психологик конфликт нигезендә яткан бер сыйфатның тышкы чагылышы. Ә аның эчке ягында исә, коллектив эше өчен янып-көеп йөрүдән башка, әле коллектив алдында үзеңнең шәхси һәм иҗтимагый җаваплылыгыңны вөҗдан белән, туры, айнык итеп аңлап җиткерә алмау ята. Нургали, әлбәттә, социалистик җәмгыять кешесе, әмма аның психологиясендә мещанлык индивидуализмы калдыклары да утырып тора әле. Шуңа күрә ул үз-үзе белән дә, коллектив белән дә билгеле бер каршылыкка керергә мәҗбүр. Ләкин Нургали — пассив кеше түгел, ә актив яшәүчән һәм кыенлыклардан чыгу юлын эзләүче кеше. Бу, әлбәттә, совет кешесенә хас беренче кыйммәтле сыйфат. Һәм әнә шул сыйфат Нургали характерында торган саен өстенлек ала, аның психологиясендәге минминлек кирелеген кысрыклап чыгара башлый, гражданлык хисләренең һәм мораль җаваплылыкны аңлауның ныгый баруын тәэмин итә. Әмма бу хәл үзлегеннән генә, стихия белән генә бармый. Нургалинең көндәлек эшендә һәм уйлануларында авыл советы председателе Сөләйманов, колхоз председателе Шәйхи абзый һәм укытучы, парторг Дускаев кебек, акыллы, булдыклы кешеләр киңәше һәм йогынтысы зур роль уйный. Нургали барыннан да элек аларның

үзенә булган яхшы карашын һәм мөнәсәбәтен аңлау нәтиҗәсендә мәгънәсез килеп кергәннән читләшә барып, җәмәгатьчелек алдындагы җаваплылык бурычының зурлыгын төшенә һәм яңа дәрт белән эшкә җигелә.

Дөрес, Нургалинең үсеш, үзгәреш процессын күрсәткән нокталар һәр очракта да тиешле тулылык белән һәм ышандырырлык итеп сурәтләнгән дип булмый. Бигрәк тә азакка таба Шәйхи абзый белән соңгы очрашудан һәм хатынының шелтәле сүзләреннән соң, Нургалинең кинәт кенә уянып, сискәнеп китүе, ягъни үзен кулга алып, шикшәбһәләрне ташлап эшкә тотынуы, аның тирәсендәге барлык кешеләрнең дә гел яхшылык теләп кенә торулары — болар геройның психологик конфликтын һәм үсешен беркадәр схемага әйләндерәләр, эчке каршылыкларының киеренкелегенә туры килеп бетмиләр. Әсәрнең ахырында Нургалинең барлык «гонаһларыннан тәүбә иткән», ягъни тәмам пакьләнгән герой итәргә теләү кебек дидактизм, яхшы мораль уку күзгә бәрелә. Бу, бәлки, укучының әдәби әсәрдән чыгара торган үз объектив нәтиҗәсенә, хөкеменә ышанып җитмәүдәндер, бәлки, догматик тәнкыйтькә бер ташлама ясаудандыр. Ничек кенә булмасын, мондый беркатлы тенденция «Рәхмәт, иптәшләр!» повестеның сәнгатьчә җитдилеген киметә. Әмма шулай да ул кимчелекләр повестьның төп эчтәлеген тәшкил иткән уңышлы якларын, яхшы максатын һич тә каплап калдыра алмыйлар. Ә. Еники иҗатында «Рәхмәт, иптәшләр!» әсәре сугыштан соңгы тыныч хезмәт шартларында совет кешесе кичергән уй-тойгыларның һаман да киеренке булып, билгеле бер тормыш каршылыклары аша, эчке көрәш һәм конфликтлар белән үсә, формалаша барганлыгын күрсәтү юлында әһәмиятле тәҗрибәләрдән берсе булып калачак.

## 2

Совет кешесенең мораль җаваплылыгы һәм мораль йөзе темасын сурәтләүне аның шәхси-интим дөньясыннан читтә күз алдына китерү кыен икәнлеге һәм хәтта мөмкин түгеллеге мәгълүм нәрсә инде. Татар совет әдәбиятының ярты гасырлык бай мирасында моның байтак гүзәл үрнәкләре бар.

Шәхси-интим дөнья дигәч тә, без монда аның аеруча мәхәббәт һәм семья мәсьәләләре белән бәйле ягын истә тотабыз. Болай гына караганда, бу теманы гадәттә әдәбият өчен мәңгелек чыганак дип тә атарга мөмкин. Әмма һәр чорда аның да эчтәлеге бөтенләй башкача булуын һәм хәл ителүен кем генә белми икән! Юкка гына һ. Такташ үзенең «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасында:

> Мәхәббәт —
> Ул үзе иске нәрсә,
> Ләкин
> Һәрбер йөрәк аны яңарта,—

димәгән бит. Шулай һәрбер заман, һәрбер буын һәм һәрбер кеше мәхәббәт тойгыларын да, семья мөнәсәбәтләрен дә үзенчә яңарта. Шуңа күрә ул тойгы һәм мөнәсәбәтләр — гаҗәп төрле һәм катлаулы дөнья. Әдәбият өчен, һәрбер язучы өчен дә аларны күрсәтү, аңлату һәм сурәтләү кырлары бер яссылыкта гына, һәммә кешегә бертөрле һәм ачык күренгән такырлыкта гына була алмый. Ә безнең әдәбият практикасында кешенең эчке дөньясын, аның интим-шәхси мөнәсәбәт һәм кичерешләрен әнә шундый яссылыкка куеп сурәтләү, хөкем итү аз булдымыни... Әмма шуны әйтәсе килә: сугыш еллары интим-мәхәббәт темасын яктыртуда да безнең әдәбиятка тирән төп үзгәреш китерделәр. «Сугыш һәм кеше язмышы» ноктасыннан аңлаганда, бу теманың да искиткеч бер драматик дөнья булуы ачыла. Аның М. Җәлил һәм Ф. Кәрим поэзиясендә гәүдәләнешен күз алдына китергәндә генә дә, мәхәббәт тойгыларының героик заман белән, совет кешесенең батырлык һәм патриотик идеаллары белән никадәр тыгыз бәйләнгән югары, изге теләк һәм мәңге сүнмәс гуманизм күренеше икәнлеге ачык аңлашылыр.

> Тик бер теләк: сөю уты белән
> Канатланса иде күңелләр,
> Сөю дымын эчеп бер тамырдан,
> Чәчәк атса иде гомерләр,—

ди М. Җәлил «Бер кызга» шигырендә (1943, май). Һәм аның юлларыннан мәхәббәт идеалының, интим хисләр дөньясының тарих драмасын кичергән кеше язмышы белән, аның рухи ныклыгы белән аерылмас булуы, тормышны, кешене һәм дуслыкны сөю тойгыларының үлемгә, явызлыкка каршы куелган эчке гүзәллеге бәреп тора. Мәхәббәтнең ләззәтле газапларыннан чорның кайнар яшәү һәм көрәш сулышы бөркелә. Әйе, монда барыннан да элек тарихи трагедияләрне кичерү белән бергә кешелекнең якты идеалларыннан нур алган мәхәббәткә табыну газаплары үзләренең эзләрен

калдырганнар. Шул рәвешчә, сугыш елларындагы әдәбиятыбызда совет кешесенең мәхәббәт һәм семья мөнәсәбәтләренә караган уй-тойгылары тагын да тормышчанрак һәм драматик кискенрәк булып гәүдәләнделәр.

Ә. Еники иҗатында да мәхәббәт һәм интим мөнәсәбәтләр темасы зур урын алып тора. Бу аеруча да язучының сугыштан соңгы әсәрләрендә көчәеп китте. Сугыш авырлыкларын кичереп, тыныч тормыш шартларына җиңү һәм бәхет байрагын күтәреп кайткан совет кешесенең яшәү матурлыгына сусавы да, соклануы да һәм сагышы да бар кебек бу темада. Моның беренче көчле аккордларын бигрәк тә «Кәккүк ни диде» (1947) хикәясендә күрергә мөмкин. Анда шулай ук заман кешесенең мораль йөзен билгели торган тормышчан фәлсәфә дә, мәхәббәтне канатландырган романтика да бар. Ул фәлсәфә явызлыкны җиңеп кайткан совет кешесенең бетмәс мәхәббәткә хокукын даулый, ул романтика шул кеше мәхәббәтенең матурлыгына һәм бөеклегенә дан җырлый.

Мәхәббәт һәм семья темасы язучының күпләгән әсәрләрендә теге яки бу аспектта ниндидер күләмдә яктыртылышын таба. Һәр очракта да без ул теманың кеше тормышында, кеше язмышында һәм кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрендә нинди әһәмияте, нинди мәгънәсе бар, дигән сорау аша бәяләнүен, хөкем ителүен сизә алабыз. Ә бу сорауга җавап күп төрле һәм хәтта бик катлаулы да булырга мөмкин. Ә. Еники гомумән тормышта һәм конкрет кешеләр мөнәсәбәтендә мәхәббәт-семья мәсьәләләренең әнә шундый төрле сораулар, төрле җаваплар белән тулы каршылыклы якларын күрергә омтыла. Мисал өчен берничә әсәрен искә төшереп китик.

Суд каршында ир белән хатын басып торалар («Яшьлек хатасы»). Алар инде бергәләп байтак гомер иткәннәр һәм балачага үстергәннәр. Әмма шулай да бүген аерылырга мәҗбүрләр.

Хатынын яратмаучы ир генә түгел, хатын үзе дә әнә шундый авыр хәлгә каршы тора алмый. «Ни өчен?.. Чөнки яратмаган ирне көчләп, ирексезләп торуның үзенә дә, семьяга да газаптан башка берни дә китермәгәнлеген ул, ниһаять, аңлаган. Ләкин бик соңга калып, гомерен заяга уздырып, рухи тәмам сүнеп беткәч кенә.— Я, бу искиткеч зур фаҗига түгелмени?! Юк, Хатирә апа, теләсәгез ни әйтегез, шулай да мин ир-хатын тормышының бердәнбер таза нигезе — мәхәббәт дип саныйм»,— дип җавап бирә хикәяләүче «мин» халык утырышчысы булган һәм ир белән хатынны ничек тә аермаска теләгән Хатирә апага.

Әлбәттә, Хатирә апа яхшы ният белән, балалар хакына, ир белән хатынның инде олы булулары хакына семьяны сакларга тели. Ләкин бер-берсен яратып, рухи аңлашып гомер итә алмаган кешеләр язмышын хәл итүдә бу теләк көчләү генә булыр иде. Чөнки ул теләк кешеләрнең реаль рухи мөнәсәбәт һәм ихтыяҗларыннан ерак тора. Кешеләрнең үзара нык мөнәсәбәте очраклы корыла алмый, ә ул аларның бер-берсен аңлаудагы рухи ихтыяҗ-таләпләреннән этик матурлык булып үсеп чыгарга тиеш. Шулай булмаганда, кешеләрнең интим-шәхси мөнәсәбәтендәге драмалар, фаҗигаләр котылгысыз. «Яшьлек хатасы» әнә шул хакта сөйли.

Тамара Сергеевна («Ялгызлык»), беренче ире сугыш вакытында югалганнан соң, үзеннән яшьрәк егет Петя Котов белән танышып, икенче тормыш башлый. Әмма тирә-юньдәге кешеләр бу хәлнең эчке мәгънәсен һич тә аңларга теләмиләр. «Ләкин, кабатлап әйтәм, мәсьәлә тирәнрәк һәм катлаулырак...— ди хикәяләүче зат.— Ялгызлык, әйе, ялгызлык? — Менә нәрсә, минемчә, аңлатса кирәк Тамара Сергеевна кичергән тирән йөрәк фаҗигасен... Юк, аңа ир генә түгел, кеше кирәк булган, дус кирәк булган. Кемнеңдер гел янында булуын теләгән ул, кемнеңдер аның тормышына кереп урын алуын теләгән ул».

Әйе, Тамара Сергеевна икенче мәртәбә чын мәхәббәт белән тормыш корырга тели. Ләкин егет, үзенең юньсезлеге аркасындамы, әллә мәхәббәте булмауданмы, корыла башлаган тормышны җимереп ташлый. Тамара Сергеевна бу урынны калдырып, икенче ерак җиргә китә, анда да тырышлыгын күрсәтеп, намуслы хезмәт белән яши. Ләкин аның эчке дөньясы ялгызлыктан һәм мәхәббәт драмасыннан азатмы соң? Әлбәттә, юк. Аның тормышына иң кыйммәтле бер нәрсә — мәхәббәт дигән рухи көчнең һәм матурлыкның туктаусыз янып торуы җитми.

«Мәхәббәт бит ул — мөкатдәс бит ул, олы бәхет бит ул!» — диелә «Кәккүк ни диде»дә. Шуңа күрә мәхәббәт белән шаярырга ярамый, чөнки ул — вөҗдан, намус бурычы. Аңа җавапсыз һәм саксыз караш көтелмәгән драмаларны китереп чыгарырга мөмкин. Кешелек тарихының буеннан-

буена бу куңелсезлек һәм бәхетсезлек кабатланып тора. Дөнья әдәбиятының ничәмә гасырлар буена тудырылган иң яхшы үрнәкләрендә, шул чынлык драмасы миллион төрле вариантларында күрсәтелеп, мәхәббәтнең изгелеге, бөеклеге җырланган һәм расланган, хәтта мәхәббәт культы, романтикасы барлыкка килгән.

Ә. Еникинең «Йөрәк сере» (1957) повестен укыгач, ничектер менә шул традицияләрнең безнең шартларда никадәр тотрыклы булып дәвам итүләрен, безнең заман кешеләренең интим мөнәсәбәтләрендә мәңгелек хисләрнең искелеген дә, яңалыгын да күрәсең һәм моның шулай ук гаҗәп түгеллеген дә аңлыйсың. Ләкин бу әсәр тирәсендәге фикерләр арасында аны башкачарак, дөресрәге — искечәрәк итеп аңлатканнары да булмады түгел. «Мәхәббәтне бүгенге шартлардан, хезмәткә, җәмәгатьчелеккә мөнәсәбәт мәсьәләләреннән аерып алу һәм аны бөтен нәрсәдән өстен бер көч итеп кую»[1] турында сөйләүләр «Йөрәк серен» искечә аңлаудан башка нәрсә түгел иде, әлбәттә. Нәкъ менә шундый карашларда әдәби әсәрдәге заманчалыкны, заман рухын коньюктура ноктасыннан, чикле регламентлар белән генә үлчәргә маташу үзенең бөтен шәрәлеге белән күренде дә инде. Ләкин без әсәрнең үз эчтәлегенә һәм логикасына ышанып эш итәргә уйлыйбыз.

Зөһрә үзенең мәхәббәт тарихын сөйли. Ата-аналары аның язмышын үзләренә таныш булган һәм булдыклы күренгән Нәҗип белән бәйләргә телиләр. Нишлисең, егет үзенең рухы белән кызның күңелен яулап ала алмый. Зөһрә көтмәгәндә хәрби егет Бәхетгәрәй белән таныша һәм аңарда үз мәхәббәтенә тиң игтәш таба. Шуның хакына ул кыю рәвештә ата-аналарының теләгенә аркылы төшә һәм Нәҗип белән тормыш корудан баш тарта. Аның мәхәббәте, вөҗданы җиңә, тапталмый. Безнең заманда, безнең кешеләр мөнәсәбәтендә мондый хәлләр бармы һәм булырга мөмкинме? Барлыгын һәм мөмкинлеген инкарь итүче булмас кебек. Димәк, әсәрнең төп эчтәлеге заман рухына туры килә дигән сүз.

Әмма әсәрнең сюжеты күптән билгеле традицион схема белән төзелгән шикелле. Үзенә тиң мәхәббәтне эзләүче кыз, мәхәббәтсез егет, кызга тиң егет — менә шундый өчпочмак һәм алар арасындагы драматик мөнәсәбәтләрне үзләренчә кичереп, кыз язмышын үзләренчә хәл итүдән гаҗиз ата-аналар — болар безнең әдәбиятта да, башка әдәбиятларда да тулып яталар. Конкретрак булсын өчен, Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр»ен генә искә төшерегез. «Йөрәк сере» ниндидер күләмдә шул романны хәтерләтә димичә булмый. (Бәлки, бу минем эстетик зәвыкларымның алдануы гынадыр.) Шулай ук Зөһрәнең табигать тынычлыгында, аның тәнгә серле матурлыгы эчендә мәхәббәт тарихын хикәяләве дә билгеле әдәби алымнан гыйбарәт кебек.

Соң шулай булгач, «Йөрәк сере»нең заманыбызга хас әдәби яңалыгы бармы, әллә ул фәкать күптән билгелене кабатлау белән генә чикләнәме? Әйе, Ә. Еники аеруча бу әсәрендә мәхәббәт темасы үңаө белән әдәби традицияләрдән принципиаль рәвештә ерак китәргә теләми, дөресрәге — теманың характеры һәм аның сәнгатьчә максаты язучыны шулай булырга мәҗбүр итә. Әйе, теманың характеры һәм сәнгатьчә максаты. Чөнки әсәрнең нигезендә бик борынгыдан килә торган зур гуманистик идеянең мәңге яшәүчәнлеген, ягъни кешенең бөек рухи ирегә булган мәхәббәткә хыянәт эшләү һич мөмкин түгеллеген тагын бер мәртәбә совет кешесе һәм совет чынбарлыгы позициясеннән раслау ята. Социалистик җәмгыятьнең туры хокуклы кешесе булуын үзенең гражданлык горурлыгы итеп аңлау дәрәҗәсенә күтәрелгән Зөһрә тормышның вак-төяк максатлары өчен мәхәббәтенә җинаять эшләүгә бармый гына түгел, хәтта аның ирекле язмышы өстенә килә торган явызлыкны, фаҗигане үз ихтыяры, үз кулы белән читкә алып ташлауда батырлык күрсәтә. Менә шушында инде совет кешесенә хас эчке ихтыяр көче һәм үзенең кешелек хокукыңны тулысы белән ихтирам итү дә, яклый алу да. Шул рәвешчә, традицион теманың драматик коллизияләре бөтенләй икенче юнәлеш алалар, бөтенләй икенче яктылык астына куелалар. Шуңа күрә «Йөрәк сере»ндә заман рухын, заман стилен әллә кайдан түгел, ә язучының традицион теманы һәм стильне ничек итеп заманча хәл кылуыннан эзләргә кирәк.

Ә. Еники — кешеләр язмышындагы һәм үзара мөнәсәбәтләрендәге авыр хәлләргә, драматик кичерешләргә туры итеп карый алучы һәм шул турылыкны сәнгать чынлыгына әверелдерә белүче художник. Бу

[1] «Совет әдәбияты» журналы. 1963 ел. 3 сан. 121 бит.

яктан ул, әлбәттә, әйнык һәм кырыс реалист. Язучы үзе турында сөйләгәндә, мин үз әсәрләремнең яралгыларын тормыштан алам, тормышның чынлыгына һәрвакыт ышанычта булырга тырышам, дигән мәгънәдәге сүзләрне еш кына искә төшерергә ярата. Әмма моңардан Ә. Еникинең икенче иҗат методларына, аеруча романтизмга һичбер мөнәсәбәте юк дип буламы соң әле? Уйлыйбыз ки, болай катгый нәтиҗә ясар өчен һичбер нигез дә, ихтыяҗ да юк. Без югарыда Ә. Еники иҗатында классик әдәбият традицияләренә бәйләнешнең бик тотрыклы икәнлеген искәртеп киткән идек. Бу тотрыклылыкның зур өлеше реализмга карасa, бер өлеше романтизмга бәйләнгәнлеге дә күренә.

Безнең хәзерге әдәбиятыбыздагы иҗат методы турында гомумән, ә реализм һәм романтизм турында хосусан тик бер яссылыкта гына хөкем йөртү катлаулы эмоциональ-эстетик күренешләрне бик артык гадиләштерүгә генә кайтарып калдырыр иде. Ә менә шул гадиләштерү тәнкыйтьтә үзен һаман сиздереп тора әле. Минемчә, мондый кимчелек, әдәбияттагы иҗат методының тарихи-иҗтимагый табигатенә басым ясап та, аның эмоциональ-психологик көчкә ия булуына тиешенчә игътибар итмәүдән килеп чыга кебек. Вульгар социологизм нәкъ шул ике моментны бер-берсеннән аерып, соңгысын кыерсыту, кимсетү юлында күп тырышлык күрсәткән иде. Сәнгатьнең кешегә йогынты ясау көче барыннан да элек иҗтимагый һәм психологик башлангычларның аерылмас бердәмлеге җирлегендә генә мөмкин икәнлеген игътибар үзәгенә куймый хөкем итү иҗат методларының үзара мөнәсәбәтен дөрес аңлатмауга да бер сәбәп булды. / Реализмны тулысы белән яклау да һәм романтизмны кире кагу да күп кенә очракта әдәбиятның иҗтимагый функциясе белән аның эмоциональ-психологик сыйфатын, аңлапмы-аңламыйчамы, каршы куюга китерә иде. !

Бигрәк тә совет әдәбиятында иҗат методларының һәм стильләрнең үзара мөнәсәбәтләрен караганда, боларны әдәбиятның сәнгатьчә көчен һәм аның эмоциональ-психологик тирәнлеген үстерү ноктасыннан бәяләп билгеләү җитенкерәми әле. Шик юк ки, иҗат методларының һәм стильләрнең үзара бәйләнеше әдәбиятларда яңа экспрессив-эстетик үрентеләргә этәргеч бирә, сәнгать чынлыгының тагын да бай художестволы формаларда чагылуына юл ача. Шуңа күрә бер үк идея позициясендә торган совет язучыларының бер төркеме башлыча реалистлар, ә икенчеләре романтиклар булу гына түгел, хәтта бер үк совет язучысы бер үк вакытта һәм реалист, һәм романтик пландагы әсәрләрне дә тудырырга мөмкин. Мондый үрнәкләр шулай ук классиклар иҗатында да аз булмаган. Әлбәттә, бу хәл совет язучысы иҗатында башлыча сәнгать материалының, әдәби теманың үзенчәлеге һәм тормышны художестволы аңлауның эстетик пафосы ничек булу белән бәйләнгән. Икенче яктан, тегe я бу язучы иҗатында реалистик һәм романтик тенденцияләр естенлек алуында әдәби традицияләргә никадәр ышанычта булу шулай ук үзенең ролен уйный. Мәсәлән, әдәбиятта шундый традицион тема һәм проблемалар бар: аларны яки реалистик, яки романтик ачкыч белән генә ачу отышлы булачак. Әйтик, сатирик тема күп очракларда реалистик гротескны таләп итә, ә мәхәббәт һәм батырлык темалары исә романтик аһәңлелеккә (возвышенностька), эмоциональ югары стильгә тарталар.

Ә. Еники иҗаты турында сөйләгәндә дә, күпмедер күләмдә югарыда әйтелгәннәрне искә алмыйча булмый. Язучының гомумән иҗат һәм аеруча стиль палитрасын тулы һәм дөрес аңлау өчен моның конкрет әһәмияте бар дип уйлыйбыз.

Кабаттан Ә. Еники иҗатындагы мәхәббәт темасына һәм бигрәк тә «Йөрәк сере» повестена әйләнеп карасак, нәкъ шул урында романтизм традицияләре белән турыдантуры очрашабыз да инде. Бу уңай белән ниндидер күләмдә Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр»ен искә алуыбыз да, повесть композициясенең билгеле әдәби алымнарга аваздашлыгы да — болар үзләре үк романтик әсәр турында уйланырга мәҗбүр итәләр. Ниһаять, Зөһрәнең мәхәббәт тарихына бәйле драматизмы торган саен эмоциональ күтәренкелек ала, һәм хәтта аның сентиментальь-мелодраматик тоны көчәя бара. «Мин» образының да роле фәкать эмоциональ бер хикәяче һәм ахыр килеп Зөһрә кичергәннәрне борчылып тыңлаучы гашыйк (аның да платоник мәгънәсендә) булуы бу әсәр композициясенең һәм стиленең традицион-романтик агылышын тагын да тулыландыра.

Кайчандыр, кайдадыр, кемгәдер кабынып калган мәхәббәт сагышы Ә. Еники иҗатында әледән-әле лейтмотив булып яңгырап тора. Бу — мәхәббәтнең үткәне өчен генә үкенү түгел. Ул сагышта яхшы

кешеләрне, туган-үскән җырларне һәм яшәү матурлыгын ярату шикелле зур уй-кичерешләр дөньясына бәйле тамырлар да тибәләр («Икенче көнне», «Кәккүк ни диде» һ. б.). Әмма шулай да кабаттан уяныргa, балкып янарга тиешле беренче мәхәббәт романтикасы үзенең мөлаемлыгы, самимилеге һәм газаплы ләззәте белән үтәдән-үтә сызылып бара кебек. Мин моны безнең әдәбиятны ничә еллар буенча сугарган лирик канваларның берсе, шуның туктаусыз һәм көчле бер дәвамы дияр идем. Билгеле бервакытларда моңа каршы рәхимсез һөҗүмнәр дә, милли чикләнгәнлектә гаепләүләр дә булган иде. Хәзер инде моны бәхәс кылып торуның кирәге, мәгънәсе юклыгын һәркем белә. Күрәсең, мәхәббәтнең үзе шикелле үк, безнең әдәбияттагы мәхәббәт романтикасы да, үзенең күп кенә традицион сыйфатларын саклап һәм аларны кабат-кабат тергезеп, һаман яшәргә хаклы булуын дәгъва итәдер. Чөнки ул традицияләр тормышка, кешегә якын чынлык та һәм сәнгатьчә шартлылык та. Боларны берберсеннән аеруы бик читен. Һәм менә Ә. Еники хикәяләрендә мәхәббәтнең чынлыгы белән аның традицион-әдәби шартлылыгы үзәра ярашып, аларның романтик төсмерен, яңгырашын көчәйткәнлеге сизелә.

Моны көчәйтүче тагын бер элемент — җыр-музыка культы. Бу да шулай ук безнең әдәбиятның бер романтик сыйфатына әверелгән. Бу урында аның элекке һәм хәзерге әдәбиятыбызда нинди күләмдә һәм ничек гәүдәләнешенә тукталмастан, аны шул ук мәхәббәт романтикасының аерылмас юлдашы, хәтта игезе булып йөрүен ассызымлап әйтәсе килә. Ә. Еники иҗатында да җыр-музыка культы үзенең традицион сыйфатлары белән чагылышында дәвам итә...

Күзгә караңгы төннәрнең берсендә фронттан тылга үтеп барган вагонда авыр яралы лейтенант, татар егете ята. Ә каршы яктан, фронтка бара торган составтан бер кыз татарча матур итеп җырлый. Һәм яралы егет ничектер үзенә таныш тавыш белән җырланган көйгә, моңга таң калып, газапларын онытып, туган якларын искә төшереп, рухлану, терелү хис иткәндәй була. Ләкин ул шунда үлеп кала. Ә күрше вагонда җырлаган кыз аның сөйгәне Таһирә булган икән. (Нинди әсәр турында сүз барганын укучы аңлагандыр инде: «Кем җырлады?» дигән хикәя ул.) Газап эчендә, үлем белән көрәшеп ятучы сугышчы егет, шул хәлдәге сөеклесе белән очрашу бәхетеннән мәхрүм кыз, аның мәхәббәткә һәм яшәүгә сусау белән тулы сагыш моңы, шуны ишетеп сихерләнгән егетнең фаҗигале язмышы—болар һәммәсе романтик контрастлар букетыннан гыйбарәт. Аның уртасында мәхәббәт һәм җыр чәчәкләре күңелләргә дәрт һәм моң сирпеп балкып торалар. Әйе, мондый сурәт һәм мотивлар безне бик еpактан килә торган әдәби традицияләрне искә төшерергә мәҗбүр итә. Сугыш шартларында булырга мөмкин мондый гадәттән тыш, көтелмәгән коллизияләр һәм әдәби шартлылык — тагын да икесе бергә сәнгать чынлыгының романтик чагылышы булып алга баса. «Йөрәк сере»ндә Зөһрә дә моңлы итеп җырлый, хәтта «Рәшә»дәге Рәшидә моңының матурлыгына сугыш елларының михнәтләрен күргән колхозчылар гына түгел, тормыш авырлыкларыннан бик оста кача белүче Зөфәр кебек рухы туң кешеләр дә игътибар итми кала алмыйлар.

Шул рәвешчә, Ә. Еники иҗатында мәхәббәт һәм җыр-музыканы сурәтләү — герой кичерешләрен күрсәткән яки шуларга тапкыр лейтмотивлардан гына тормый, ә аңарда билгеле бер эзлеклелек, система алган этик һәм эстетик концепция дә бар. Менә шушы ноктадан без мәхәббәт һәм җыр-музыканы сурәтләүдә сәнгатьчә культ дәрәҗәсенә куелган романтик мәгънә бар дип уйлыйбыз, ә соңгысы инде идеаллаштырудан башка була алмый. Бу уңай белән матурлык төшенчәсен дә искә алырга туры килә. Моңа карата да Ә. Еники иҗатында билгеле бер эстетик концепцияне күрергә мөмкин. Аның бер хикәясе хәтта «Матурлык» дип тә атала. Монда тәскә-биткә бик ямьсез ана образы сурәтләнә. Әмма баланың анага булган һәм әчке, рухи матурлыкка әверелгән мәхәббәте бу тышкы ямьсезлектән өстен. Ананы ярату, ихтирам итүнең изге, ләззәтле гүзәллеген, романтикасын биргәндә дә, язучы музыка, көй чарасын кулланмыйча кала алмый. Бәдретдин, анасына багышлап, скрипкада «Салкын чишмә» көен уйный: «Берәүне дә күрмичә, бары әнисенә, әнисенең дә әнә шул башта безне чирканырга мәҗбүр иткән шадра, чалыш, акайган күзле йөзенә генә карап, ул скрипкасын уйнады. Аның бу аз гына моңсу уйчанлык, яшерен генә кызгану белән өретелгән җитди-җылы карашында, әнисең өзелеп ярату гына түгел, аны беткәнче аңлау, кадерләү, юату сизелеп тора кебек иде. Белмим, болай карый алыр өчен күңелләрдә нинди генә тирән мәхәббәт дәрь-

ясы ятарга тиештер инде?! Әллә бу шулай бик ямьсез ана белән бик матур бала яки, киресенчә, бик матур ана белән бик ямьсез бала арасында гына буламы икән? Соңгысы, ихтимал, еш очрый торгандыр, әмма беренчесен ишеткән дә, күргән дә юк иде».

Шулай итеп, мәхәббәт, җыр-музыка һәм матурлык төшенчәләре бер-берсеннән аерылгысыз бәйләнештә Ә. Еники иҗатында зур гуманистик мәгънә алалар. Икенче яктан, алар яхшы кешенең югары рухи сыйфатлары булып, ямьсезлеккә, явызлыкка, начарлыкка каршы куелалар. Менә шул яктан караганда да, Ә. Еники әсәрләрендә реалистик һәм романтик контрастларны байтак очратырга мөмкин. Мондый әсәрләре арасында өлешчә үткән тормыш темасына караганнары сюжет коллизияләрен төзүдә һәм аерым типларны сурәтләүдә романтик кискенлек белән аерылып торалар. Бу тенденция башлыча гадәттән тыш хәлләргә һәм контрастларга игътибар итүдә күренә. Ә. Еники иҗатында аның кайбер мисаллары электә дә бар иде инде. «Көзнең бер кичендә» (1939) дигән хикәясен искә төшереп китәргә мөмкин [1]. Бер колхоз өендә «мин» ике чорның ике вәкилен очрата: берсе аның — совет шартларында бәхетле булып үсүче чибәр Зөһрә, ә икенчесе — аның әбисе Миңҗамал. Хәзер үзенең кыяфәте белән куркыныч бер җан иясе булып калган карчык кыз чагында коточкыч фаҗига күргән. Ул үзенең ахирәте, дусы Гөлбану белән аның сөйгән егете Солтанны, һич уйламаганда һәлак итеп, мичкә ягу шикелле җинаять эшләргә мәҗбүр булалар, ләкин тотылалар. Гөлбану акылдан шаша, ә Миңҗамал сөргенгә җибәрелеп, мәңгегә бәхетсез булып кала. Хикәядә сурәтләнгән бу чамадан тыш, күңел тетрәткеч хәлләргә безнең чынбарлык һәм совет хатын-кызларының ирекле язмышы каршы куелган. Һичшиксез, бу каршы куюның нигезендә романтик контрастлар белән сурәтләү принцибы ята.

Ә. Еникинең сугыштан соңгы әсәрләреннән, югарыда искә алынган «Матурлык»тан башка, тагын «Корьәнхафиз» һәм «Мәчет җылый» хикәяләрендә дә шулай ук гадәттән тыш хәлләр һәм контрастлар психологик киеренкелек чыганагы булып торалар. Хәтта Кәрьәнхафиз образында артык ямьсез, мәкерле һәм явыз бер традицион тип күз алдына бастырыла. Аның тиз арада «иманын» алмаштырып, кызылгвардеец кыяфәтенә кереп, коралланып, җиде төн уртасында элек үзе укыткан авылга килеп, хәзрәтнең чибәр кызын көчләп алып китәргә маташуы һәм, моны эшли алмыйча, юлбасардай юкка чыгуы — болар һәммәсе гадәти хәлләр, вакыйгалар бозрасыннан байтак читкә чыгалар. Шуны да әйтергә кирәк: бигрәк тә иске тормыш тематикасына мөрәҗәгать иткәндә, язучы әнә шундый кискен алымнар, контрастлар белән сурәтләргә ярата. Әлбәттә, моның белән ул үткән җәмгыятьтәге чынбарлыкның ямьсезлеген, кошмарын куе һәм кискен буяулар белән күз алдына китерергә тели. Монда да шулай ук яхшылык белән явызлыкны, матурлык белән ямьсезлекне кара-каршы куеп сурәтләүче романтик принцип алгарак чыга, һәм язучының гуманистик концепциясе ярылып ята.

### 3

Чынбарлыктан азыкланган кырыс реализм һәм үзенең традицион сыйфатларын нык сакларга омтылган романтизм яктылыгында караганда, Ә. Еники иҗатының тагын бер үзенчәлекле ягы — явызлыкка һөҗүм һәм аны фаш итү пафосы ачылып китә. Нәкъ шунда сатира һәм ирония шикелле әдәби укларның да үткен очлары, чәнечкеләре һәм энәле очкыннары ялтырый башлый.

Геройның гуманистик йөзен ачу кешенең җәмгыять алдында булган әхлакый, мораль бурычы турындагы мәсьәләдән һәм шушы бурычка каршы торганны тәнкыйть итүдән башка була алмый. Гуманизм кешедәге кешечәнлекне әхлакый тикшерү һәм гуманизмга каршы булганны нәфрәт белән кире кагу максатын куя. Бу шулай ук безнең әдәбияттагы сатираның да төп максаты.

Билгеле булганча, догматик тәнкыйть искелек белән яңалык арасындагы көрәшнең мәгънәсен күп вакыт бик примитив итеп, артык гадиләштереп аңлады. Һәрбер әдәби әсәрендә язучы яңаны да, искене дә ниндидер идеаль төгәллек белән күрсәтә торган бизмәнгә салып бирергә, уңай һәм кире типлар арасындагы «нейтраль зона» мөмкин кадәр киңрәк булырга тиеш, дигән таләп куелып, бу инде әдәбиятта тормышчанлык һәм сәнгатьчә дереслек өчен көрәшнең иң ышанычлы критерийсе итеп каралды. Шуңа күрә кире типларга басым ясап сөйләгән әсәрләргә «тормыш чынлы-

[1] «Совет әдәбияты» журналы. 1939 ел. 8—9 саннар.

гына туры килми» диган мөһер дә бик тиз сугылды.

Әгәр дә бу сөйләгәннәребез тик күптән үткән һәм онытылып калган булсалар — бер хәл иде, әмма алар теге я бу төстә һаман да үзләрен сиздерәләр әле. Моның ачык дәлилләреннән берсе — Ә. Еникинең соңгы елларда чыккан әсәрләре тирәсендә барган бәхәсләр. Бигрәк тә аның «Саз чәчәге» һәм «Рәшә» кебек әсәрләренә карата капма-каршы фикерләр әйтелде. Боларда инде искергән критерийләрне ташларга теләмәгән догматик тәнкыйть белән әдәбиятның чынбарлык һәм заман таләпләре яктылыгында бәяләнергә тиешлеген яклаган иҗади тәнкыйть арасындагы бәрелеш шиксез иде. Беренче төр тәнкыйть, язучының ул әсәрләрендә безнең чынбарлыктагы начар күренешләрне һәм кире типларны сурәтләү өстенлек итә, ә аларга каршы куелган яхшы, уңай типлар җитәрлек эшләнмәгән һәм язучының начарны хөкем итү позициясе ачык түгел, дип чыкты. Икенче төр тәнкыйть исә әдәби әсәргә бу рәвешчә алдан ясап куелган, уйдырма нормалардан чыгып түгел, ә тормышчанлык күзлегеннән һәм язучының уңай, раслау идеалы бу конкрет әдәби формада ничек тулы чагылуыннан чыгып карарга кирәклекне таләп итте: «Эш уңай һәм кире геройлар пропорциясендә түгел, беренче чиратта язучының позициясендә. Язучы безнең тормышны нинди позициядә торып тасвирлый, кая чакыра, нәрсәгә нәфрәтләнә, кай ягын сокланып күзәтә?» [1] Шушы таләпне критерий иткәндә Ә. Еникинең югарыда искә алынган әсәрләре һич тә социалистик реализмнан читтә тормаганлыгын аңлау кыен булмаячак.

Менә сезнең алдыгызда, билгеле бер вакытларда партия-совет җитәкчелегендә рәтле генә эшләгән булып та, яшь хатыны һәм аның туганнары тәэсирендә обывательлек комсызлыгына һәм мещанлык саэлыгына бата барган Шакир Мостафин образы («Саз чәчәге»). Безнең тормышта мондый типлар бармы? — Бар, әлбәттә. Ни өчен совет язучысы, хәрам юллардан һәм карьерасыннан файдаланып, үзе өчен генә тыныч һәм тук тормыш кору исәбе белән яшәгән кешеләрнең йөзен ачып бирмәскә тиеш? Андый намуссыз кешеләрне фаш итү безнең җәмгыятькә файдалы эш түгелмени?

[1] Р. Мостафин. Кин колачлы, тирән фикерле. «Казан утлары» журналы. 1964 ел. 6 сан. 134 бит.

Мостафин кебекләр безнең тормышта яңа һәм сирәк тип булмаган кебек, Ә. Еники иҗаты өчен дә ул көтелмәгән табыш түгел, әлбәттә. Язучының 1929 елда басылган «Дус кеше» исемле бер хикәясен генә искә төшерәм. Анда да совет-партия аппаратындагы югары дәрәҗәсен үзенең мещанлык интереслары өчен файдаланырга маташкан һәм шуның аркасында карьерасыннан ычкынып, хөкем ителү куркынычы алдында калган Салих образы сурәтләнгән иде. Шакир Мостафинның да нәсел шәҗәрәсе шул типка барып тоташкан шикелле. һәм ул шулай да. Димәк, Мостафин да әле генә дөньяга килгән һәм язучы уйлап чыгарган «әр-яңа» герой түгел.

Мостафинны һәм аны камап алган обывательләрне язучы һич кенә дә вөҗдансыз совет кешеләре рәтенә бастырырга теләмәгән, ә, киресенчә, андый типларның безнең җәмгыятькә ябышкан сорыкортлар икәнлеген һәркем нәфрәтләнерлек итеп күрсәткән. Мостафинның акрынлап карьерасын югалта баруында совет кешеләренең аңа ышанычы бетә башлавын күрү авыр түгел. Аны сайлауларда юкка гына тәгәрәтмиләр. Димәк, язучының безгә чит мещанлык күренешләрен һәм шуларны сакларга тырышучыларны фаш итү теләге — уңай идея позициясе ачык.

«Рәшә» повестена карата да кайберәүләрнең эчен пошырган нәрсә — заводның сәүдә-хуҗалык эшләрен үз максатларына оста файдаланучы Зөфәр Сабитов образын «гомумиләштерү», «типиклаштыру», әсәрдә аны беренче планга кую һәм аңа каршы геройларның кычкырып тормавы булды. Хәтта мондый «әсәрләрдә үзләрен-үзләре аңлы рәвештә халыктан аерып куйган кешеләрнең рухи кичерешләре, аларның эчке драмалары җырлана» [1], аларның авторлары «үзләрен бүгенге җәмгыятькә каршы куйган кешеләрнең билгеле дәрәҗәдә трагедияләрен уртаклашалар» [2],— диган гаепләүләргә кадәр җитүчеләр дә табылды. Мондый гаепләүләрнең артында, әлбәттә, катлаулы чынбарлыктан һәм явыз кешеләрдән курку посып тора. Шунысы хак: Зөфәр шикелле сорыкортлар шулай ук безнең җәмгыятьтә бетмәгән әле, һәм алар тиз арада гына үзләренең мәкерле максатларыннан, мещанлык теләкләрен канәгатьләндерүдән ваз кичәрләр дә бик тәти бәндә-

[1] «Совет әдәбияты» журналы. 1964 ел. 6 сан. 151 бит.
[2] «Совет әдәбияты» журналы. 1965 ел. 3 сан. 136 бит.

ләргә әверелерләр дип хыялланырга урын юк шикелле. Ә. Еники тормышның бу чынлыгына күз йомарга һәм сәнгать дәреслеген дә аллы-гөлле иллюзияләргә әретеп бирергә теләми. Уйлыйбыз ки, «Рәшә»дә дә авторның позициясе явызлыкны сугышчан рәвештә фаш итү, аңа нәфрәт уяту икәнлеген исбатлап тору артык кебек.

Мостафин һәм Сабитов шикелле типларны биргәндә, Ә. Еники схематизмнан, җансыз шарж һәм карикатуралардан читләшергә омтыла. Әйе, Мостафин да, Сабитов та һәрбер җанлы кешегә хас сыйфатлардан мәхрүм ителмәгәннәр. Әмма баратора аларның бу сыйфатлары тышкы якта гына булганлыгы, ә эчке якларында бөтенләй башка сыйфатлар ятканлыгы яки көчәя барганлыгы ачыла. Әйтик, Мостафин баштә, партия работнигы буларак, үзенең эшенә күңел биреп, тырышып йөргәндәй. Ләкин ул партия эшендәге үз ролен һич тә вөҗданының изге, какшамас бурычы, кушуы дип карамаган икән. Мещаннар бөҗрәсына эләккәч, аның бөтенләй икенче теләкләре, түбән сыйфатлары баш калкыта. Әлбәттә, Мостафинны беренче адымнарыннан ук карьеристлык максатлары, үзенең шәхси бәхете өчен партиягә сырышкан кеше дип әйтеп булмый әле. Ләкин аңарда шул ук вакытта инде коммунистлык сыйфаты дә ачык һәм нык булмаган. Шуңа күрә андый кешенең тиз арада төрле яклап түбәнгә тәгәрәвенә каршы торырлык рухи нигез дә, таяныч та хәзерләнмәгән. Шуның нәтиҗәсендә ул үзенең бар булып күренгән беренче «уңай» сыйфатларын да югалта. Димәк, Мостафинның сазлыкка бату эволюциясе — гадәттән тыш хәл түгел, ә совет җәмгыятендә һәм партиядә үзенең вөҗдан бурычы нәрсә икәнлеген аңламаган яки аңларга теләмәгән кешенең табигый фаҗигасы, политик һәм рухи үлеме. Мондый кешеләрне безнең халыкның һәм аның белән бергә әдәбиятның да рәхимсез фашлавы һәм хөкем итүе бик хаклы. Шушы ноктадан килгәндә, Ә. Еникинең Мостафиннарга төбәлгән сатира һәм иронисе урынлы, вакытлы һәм кирәкле булуын һич кенә дә шик астына алу мөмкин түгел.

Сабитов, билгеле, Мостафин белән чагыштырганда, башкарак баскычта, икенчерәк дәрәҗәдә тора. Ул да башта ук сугыш елларының авырлыгыннан кача белгән һәм үз тормышын бик уңайлы итеп җайлаган обыватель булып килеп басмый әле. Шуның белән бергә аңарда аеруча Рәшидәгә мөнәсәбәттә интим якынлык, «мәхәббәт» хисләренең кузгалуы да билгеле бер күләмдә бу типның психологиясендәге «уңай» сыйфатны тәсмерләткән шикелле. Әмма алга табан, Зөфәрнең үз эшендәге вөҗдансызлыгы өскә күперә барган саен, аның мәхәббәт һәм семья мәсьәләләре тирәсендәге спекулянтлыгы да, оятсызлыгы да тәмам тулы төс ала, фаш була. Дөрес, бер карагында, ул образ наив, беркатлы кебек, әмма аның чын йөзе куркыныч. Һичшиксез, Ә. Еники бу урында совет хуҗалык оешмаларында үзенең тышкы «эшчәнлеге», «булдыклылыгы» белән үз шәхси бәхетен тәэмин итеп, аны ил күзеннән яшерә белгән һәм рухи хәерчелек чоңгылына тәмам баткан обывательнең мәкерле образын тудырган.

Мостафин шикелле үк, Сабитов та — безнең чордагы бер төркем кешеләрнең типик вәкиле, ә кайбер тәнкыйтьчеләр уйлаганча, «тормыштагы аерым фактлар», «очраклы моментлар белән күбрәк кызыксына башлау»[1] җимеше генә, художник хыялында туган тип кына түгел. Ул да мещанлык калдыкларының яшәүчәнлеген, алар үзләреннән-үзләре генә бетмәячәген, ә һаман да халык җилкәсен җылы урында тыныч кына кимереп яшәргә омтылуларын бик конкрет һәм җанлы гәүдәләндерә. Менә шуның өчен дә намуслы совет кешесе андыйларны нәфрәтли һәм хөкем итә. Язучы сурәтләвендә аның Зөфәрне гаепләү акты бик төгәл һәм аңлаешлы. Әмма хөкем итү бер укучы карамагына гына калдырылмый. Монда әле тагын да үзенең вөҗданын Сабитовларга һич тә сатарга теләмәгән Рәшидә шикелле горур совет кешесе образы да бар. Кайберәүләрнең бу образ белән исәп-хисапны җиңел генә өзүләрен һич тә җитди дип булмый. Искә алынган мәкаләсендә, мәсәлән, Ф. Мусин бер селтәнү белән Рәшидәне «уңай» герой пьедесталыннан бәреп төшерә: «Әсәр ахырында Рәшидә,— ди ул,— үзен алдап, мыскыл итеп яшәгән Сабитовка каршы чыга һәм аннан китә. Шуңа да карамастан, Рәшидә уңай тип роленә бармый. Бу функцияне үтәргә аңарда көч юк. Соңыннан аның Сабитовка каршы баш күтәрүе ничектер ясалма яңгырый, характерның моңа кадәр үсеше белән логик һәм психологик нигезләнми. Нәтиҗәдә, әһәмиятле фикер, идея чагылдырырдай зур фаҗига

[1] Ф. Мусин. Тормыш һәм характерлар дәресләге өчен. «Совет әдәбияты» журналы, 1964 ел, № 5 сан, 129 бит.

урынына, алданган хатынның чираттагы мелодрамасы алга баса».

Күрәсез, тәнкыйтьче Рәшидә образына «идеаль герой» башкарырга тиешле бурычларны йөкли. Инде Рәшидә боларны күтәрә алмагач, ул уңай герой хокукыннан да мәхрүм ителә. Тәнкыйть куйган нормаларны үтәмәгән герой, шул рәвешчә, тормышта гына түгел, хәтта әдәби әсәрдәге ролен дә югалтырга тиеш.

Әйе, тышкы яктан караганда, Рәшидәнең роле тар интим мөнәсәбәтләр белән бәйләнештә күренгән шикелле. Әмма аның эчке психологик һәм мораль мәгънәсе яхшы ук тирән һәм гыйбрәтле: башта Сабитовка үзенең намуслы замандашы дип караган Рәшидә аның һәр нәрсәне спекулянт буларак үлчәвен, вөҗданы саф түгеллеген сизенә һәм аның белән мөгамәләсен горур рәвештә өзә. Нәкъ шушы урында безнең моральнең мещанлык һәм намуссызлык белән килешмәс каршылыкка керүе ачык булып чагыла да. Нәкъ шушы урында Рәшидәнең роле үзенең иң әһәмиятле уңай сыйфатын ачып җибәрә дә инде. Аны мескен мелодраматик бер тип дип кенә читкә кагу өчен урын калмый кебек.

Совет әдәбиятында сатира, ирония һәм юмор булмаска тиеш дип әйтергә беркем дә ачыктан-ачык җөрьәт иткәне юк әле. Ләкин чынбарлыкны аллы-гөлле буяулар белән генә ялтыратып күрсәтүне яклау бу төр әдәби жанрларны кимсетү, читләтү һәм, ахыр килеп, просто кысрыклап чыгару исәбенә эшләнде. Әлбәттә, чынбарлыкка һәм әдәбиятның сугышчан бурычына ышанычта булган язучылар моның белән һич тә килешергә теләмәделәр һәм теләмиләр. Ә. Еники хикәяләренә багышлы бер рецензиясендә Ибраһим Гази бик хаклы рәвештә түбәндәге юлларны язган иде: «Сатира һәм юмор хикәяләрендә һәртөрле гомумиләштерүдән шикләнәбез: янәсе, гомумиләштерсәң, бик күп кеше өстенә шик төшәчәк. Менә шушы шикләнү аркасындамы, әллә бүтән сәбәпләре дә бармы, безнең бүгенге әдәбиятыбыз һәм сатирадан, һәм юмордан зур гомумиләштерүләргә ия булырлык әсәрләр биргәне юк»[1].

Сатира, ирония һәм юмор Ә. Еники иҗатында да күренекле генә урынны алып, хәзер инде алар язучы реализмының бер әзлекле тенденциясе дип бәяләнергә хаклы. Хәтта искә алынган «Саз чәчәге» һәм «Рәшә» повестьларыннан да сатирик җил бәреп тора. Аеруча беренчесендә аны турыдан-туры сизәргә мөмкин. Ә икенчесендә аны берникадәр мәхәббәт һәм интим мөнәсәбәтләр пәрдәсе каплап торган шикелле. Бара-бара анда да сатирик пафос өскә калкып чыга. Зөфәр Сабитовның йорт алу һәм өйләнү тирәсендәге кыланышлары аның чын кыяфәтен фаш иткән сатирик һәм ироник стиль элементлары белән сурәтләнәләр.

Ә. Еники иҗатында гомумән сатира-ирония алымнарын туры һәм тулы мәгънәсендә һәр очракта да аерып карау — яхшы ук катлаулы мәсьәлә. Бу — язучының сәнгатьчә стилендәге үзенчәлекле бер сыйфат итеп каралырга тиеш. Хәтта болай сатирадан бик ерак булып күренгән «Әйтелмәгән васыять» кебек хикәя стилендә дә иронияле пафос үзен әледән-әле сиздергәндәй. Бу, билгеле, драматик һәм психологик контрастлар тирәнлегендә ятканлыктан, аның характерлы сызыклары өстә калкып тормыйлар. Шулай да Суфиян кебек типларның ироник портретын тасмирләү кыен түгел.

Ә. Еникинең «Чәнечкеле хикәяләр» (1962) исеме белән һәм аннан соң чыккан кечкенә күләмле әсәрләре — парчалары, миниатюралары һәм памфлетлары — арасында да мәгънәле сатира һәм юмор үрнәкләре байтак. «Еники конкурентгәге беренче карашта кечкенә, вак булып тоела торган матур гына, мәгънәле генә хикәяләр чыгара алган. Моның өчен аеруча осталык һәм хикәяченең үткен күзе кирәк»,— дигән иде И. Гази искә алынган рецензиясендә. Боларда, мәсәлән, малае Фердинандны кечө яшьтән ук нахал итеп үстерә торган Фәхри Гыймадиев («Күңелсез мәҗлес»), яки шул ук Фердинандның игезе булган Наил («Кунакта»), иренең авторитетына аркаланып, үзен әллә кем итеп санаган Кәүсәрия («Кусия ханым»), район оешмаларының һәр җиргә яраучы «кадры», әмма бер профессиясе, һөнәре булмаган Сабирҗанов («Беке»), милиция бетә дип, «Кызыл йомычка» артелен күпләп сыбызгы эшләргә кушкан һәм шуның аркасында үзе дә «морҗадан очып» чыккан Франц Фәррахович («Сыбызгы») һ. б. шуның шикелле типларны байтак очратырга мөмкин. Алар арасында гаҗәп үткен һәм кыска итеп, берничә сызык, штрих белән генә җанлы сатирик портрет дәрәҗәсендә гомумиләштерелгән-

[1] «Совет әдәбияты» журналы. 1963 ел. 2 сан. 142 бит.

нәре, типиклаштырылганнары да бар. Мәсәлән, «Сыбызгы»ның беренче елларыннан ук безнең алга сатирик персонаж килеп баса: «Кызыл йомычка» артеленең председателе Франц Фәррахович үзенең бер генә тәрәзәле фанер кабинетына тирләп-пешеп кайтып керде. Шунда ук ул күрше фанер бүлмәләрдән артельнең баш кешеләрен янына чакыртып алды».

Шулай да Ә. Еникинең сатирик-юмористик объектларын һәрвакыт отышлы сайланган һәм тиешле эффект белән, гомумиләштерү сыйфатына ия булырлык итеп сурәтләнгән дип булмый. Бу хакта И. Гази рецензиясендәге искәртүләр, һичшиксез, дөрес иде. Чыннан да, тормыш фактларын сатирик формага әверелдерү ноктаЛарын табып җиткерә алмау яки аларны натурализм дәрәҗәсендә калдыру Ә. Еникинең кәнечкеле әсәрләре арасында еш кына очрый («Ахирәт», «Мөслим карт», «Кемгә карады ул?», «Майбәдәр карчыкның туган көне» һ. б.). Әгәр тормыш ноктасыннан карасаң, мәсәлән, «Кыз һәм сәгать» хикәясендәге Сәлим Галимович үзе сатирик образ булырга, мәсхәрә ителергә тиеш иде. Әмма ул бик мелодраматик позада ялыктыргыч хикәя сөйләүче «мескен бәкәй» ролен генә уйный.

Тормышчан фактларның һәм детальләрнең сәнгатьчә чамасын, күләмен һәм дәрәҗәсен үлчәп җиткерә алмау кебек натурализм, ваклану чиреннән азат булмау Ә. Еникинең повестьларында да күренгәли. Мәсәлән, «Рәшә»дә Зөфәр Сабитовның әхлакый тотнаксызлыгын ачыграк күрсәтәм дип булса кирәк, язучы бу персонажның Рәшидә белән очрашуларын сурәтләгәндә, берничә мәртәбә җенси якынлык мәсьәләсенә килеп төртелә. Бу факт кабатлана башлагач, ул үзенең реалистик сәнгатькә хас тыйнаклыгын югалта һәм натурализмга хас урынсыз, әһәмиятсез, теңкәгә, күңелгә тия торган детальләр белән мавыгу булып кына кала.

Ләкин күрсәтелгән кайбер кимчелекләр Ә. Еники иҗатының төп реалистик юнәлешенә, тормышчанлыгына һәм сәнгатьчә тәгәллегенә сизелерлек тоткарлык ясау дәрәҗәсендә түгелләр. Боларны башлыча язучының өзлексез эзләнүләре һәм тормышны җентекләп күзәтүләре вакытында булырга мөмкин мавыгулары, тормыш фактларын, дөреслеген әдәби фактка, сәнгать дөреслегенә әверелдерү ноктасын табып җиткерә алмавы белән бәйләп аңлатырга мөмкин булыр иде. Ә. Еники, ике аягы белән дә тормыш чынлыгына нык баскан хәлдә, аның матур бүгенгесенә һәм рухи тынгысыз, һәрвакыт эзләнеп, ашкынып, борчылып, дулкынланып яшәгән вөҗданлы гади кешеләргә мәхәббәт белән иҗат итә.

Ә. Еники, әлбәттә, гел бертөрле тема һәм геройлар дөньясында әйләнүче, күптән билгеле һәм әзер материаллар белән генә канәгатьләнүче түгел, ә туктаусыз эзләнүчән һәм тормыштагы ак белән караны, яхшы белән яманны нечкәләп күзәтүчән, аларның эчке, психологик контрастларын, каршылыкларын аңларга, ачарга омтылучан художник. Һәм менә шушы урында Ә. Еникинең кешеләр мөнәсәбәтендәге, язмышындагы драматик коллизияләрне, каршылыккыенлыкларны күрүче генә булмавы, ә алардан совет кешесенең яхшылыгы, югары морале, гуманистлыгы җиңеп чыгуына ышанучы икәнлеге дә үзен тулысы белән күрсәтә инде. Сугыш шартларындамы, тыныч тормыш һәм хезмәттәме — һәммәсендә ул зур уй-тойгылар совет кешеләренең мөнәсәбәтләрендә бик көчле һәм ачык. Ә. Еники иҗаты шул хакта сөйли.

Хикәя остасы буларак, Ә. Еники барыннан да элек психологик хикәяләр белән безнең бүгенге әдәбиятны баетты һәм баета. Бу жанрның укучы өчен никадәр кирәкле, ә язучы өчен күпме авыр әдәби форма икәнлеген исбатлап торуга хаҗәт юк кебек. Олы һәм тәҗрибәле хикәячеләребездән Ф. Хөсни тикмәгә генә хикәя жанрының урыны һәм әһәмияте турында әледән-әле тревога ясамыйдыр. Ул үзенең «Хикәя укыйсым килә!» дигән соңгы мәкаләләренең берсендә тагын бер мәртәбә хикәя жанрының язучыдан никадәр җаваплылык, кыюлык, төгәллек һәм осталык таләп иткәнлеген истә тотып сөйли. Һәм бу урында аның хаклы фикерләрен уртаклашмый мөмкин түгел. Шулай ук Ә. Еники хикәяләрен гыйбрәтле үрнәкләр итеп китерүен дә гомумән очраклы дип булмый.

Ф. Хөсни, хикәя жанрының төп хасиятен билгеләргә теләп, болай ди: «Роман яки повестьтан үзгә буларак, хикәя үз эченә бер яки берничә кеше катнашында «башкарыла» торган тик бер генә вакыйганы, аның да, агым суның тугайда бер бөтерелеп, чоңгыл ясап, «уйнап» торган ташкынлы төше кебек, дәртләр һәм омтылышлар үзара нык бәрелешә торган конкрет бер тугаен гына ала. Вакыйга шулай башлана, үсә, иң үткен бәрелеш ноктасына күтәрелә, аннары әкренләп түгәрәкләнә, бетә һәм тормыш

агымы тагын үз юлы белән китә. Бу яктан хикәянең драматик әсәр белән нык уртаклыгы бар»[1]. «Еш кына без тиешенчә игътибар итми торган тагын бер як: хикәя үтә гадәти вакыйгага корыла алмый. Хикәя нигезенә салынган вакыйга гадилектән чак-чак кына күтәрелебрәк, чыгыбрак торырга тиеш»[2].

Китерелгән өзектә язучының хикәя турында үз иҗат тәҗрибәсеннән чыгып һәм уйлануларыннан сөзеп алынган кызыклы гына нәтиҗәсе, концепциясе чагылган. Бик сурәтле итеп әйтелгән бу фикерләрдә, әлбәттә, хикәя жанрының табигатен дөрес билгеләүче моментлар ачык. Әмма шулай да алар Ф. Хөснинең күбесенчә үз иҗат практикасыннан килә торган субъектив карашлардан да азат түгел. Аның хикәягә карата «сюжет-вакыйга» төшенчәләрен янәшә куеп фикер йөртүе, сюжетны үткен итеп корырга өндәве һәм вакыйганың гадәти булмаганын яклавы — болар башлыча хикәянең новелла төрен күз алдында тотып сөйләүдән килә. Менә шуннан чыгып, ул Ә. Еникинең «Шаяру» хикәясен дә үз билгеләмәсенең характерлы мисалларыннан берсе итеп искә ала шикелле.

Ләкин Ә. Еники хикәяләрен тулаем алганда, Ф. Хөсни билгеләмәсенең кысалары тар булып кала. Сюжетны мавыктыргыч бар итеп, кинәт борылышлы, текә интригаларга кору алымнары булса да, Ә. Еники иҗатының иң үзенчәлекле сыйфаты психологик сюжет осталыгында гәүдәләнә. Бу инде геройларның үзара мөнәсәбәтләренә һәм кыланышларына бәйләнгән яки турыдан-туры шулардан үсеп чыккан уй-кичерешләр барышына, агылышына беренче игътибарны юнәлтү дигән сүз. Шуңа күрә Ә. Еники әсәрләрендә вакыйгаларга корылган фабула да, сюжет та әйдәүче түгел. Хәтта аның «Рәхмәт, иптәшләр!», «Йөрәк сере» һәм «Рәшә» кебек повестьларында да сюжетны оештыручы вакыйгалар күзгә бәрелеп тормыйлар. Алар арткы планда калалар, ә алга геройларның эчке, психологик мөнәсәбәтләре, Горький-ча әйткәндә, бер-берсенә симпатияләре һәм антипатияләре, бәрелеш-конфликтлары һәм каршылыклары калку булып чыгалар. Моны раслау өчен берничә мисал китерик. «Бер генә сәгатькә» хикәясендә совет солдаты Гөмәрнең фронтка үтеп баручы эшелоннан төшеп, үзенең туган авылына бер генә сәгатькә кереп, якыннары белән очрашып чыгуы түгел, ә шулай уңай белән төрле геройларда туган настроениеләр, геройларның үзара мөнәсәбәтләре тирәнлегендә яткан кичерешләр сюжет интригасын, аның психологик киеренкелеген тудыралар. Гөмәрнең кайтуы, очрашуы һәм китүе — болар фәкать кешеләр арасындагы эчке мөнәсәбәтләрнең, шатлыклы һәм борчылулы уй-кичерешләренең тышкы сәбәбе генә (повод). «Рәхмәт, иптәшләр!»дә Нургали язмышы белән бәйле һич тә эзлекле вакыйгалар тезмәсе юк, ә геройның эчке каршылыклар белән үсү тарихы гына бар. Инде «Йөрәк сере»ндә Зөһрәнең мәхәббәт тарихын шулай ук вакыйгалар тезмәсе белән генә чикләп булмый, аның сюжет үзәгендә дә Зөһрәнең мәхәббәте белән бәйле язмыш драмасы тора. Ләкин без моның белән Ә. Еники әсәрләрендә сюжетны һәм фабуланы оештыручы вакыйгалар юк яки алар бик йомшак диган нәтиҗә ясарга җыенмыйбыз. Алар бар, әлбәттә, һәм алардан башка хикәя була алмый. Әмма шуның белән бергә тормышка да, сәнгатькә дә уртак, характерлы бер хакыйкатьне искә төшерсәк, мәсьәләнең әһәмиятле ягы тагын да ачылып китәр төсле.

Әдәбият геройлары әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларның, хәлләрнең кол курчаклары ролендә калсалар, алар үзләренең кешелек характерларын ачып күрсәтү ихтыярыннан, активлыгыннан мәхрүм булалар. Инде геройлар вакыйга-хәлләрне һәм конфликтларны үзләре тудырып хәрәкәт итсәләр, аларга үзләренең рольләрен, характерларын эчке яктан ачарга киң мөмкинлек бар. Тормышта да ул шулай бит. Ә тормыш белән нык бәйле әдәбият барыннан да элек чынбарлыкның һәм кешеләр мөнәсәбәтенең әнә шул диалектикасына игътибарсыз кала алмый. Бу игътибар исә үз нәүбәтендә талантлы язучыларны кешеләр мөнәсәбәтен һәм язмышын аларның эчке психологик дөньясы аша күрсәтүгә китермәве мөмкинме соң? Нәкъ менә шушы урында Ф. Хөснинең искә алынган мәкаләсендәге бер фикерне кабатламыйча булмый: «Моннан тагын шул нәтиҗә килеп чыга: башка бернинди бизәк тә түгел, хикәяне, барыннан да элек, кешеләр язмышы гына тотып тора ала, кызыклы итә ала». Ерак китмичә, татар классик прозасыннан Ш. Камал хикәяләрен, Ф. Әмирхан һәм Г. Ибраһимов әсәрләрен генә искә төшерик. Алар әнә шул югарыда әйтелгән хакыйкатькә ышанычлы булып иҗат итте-

[1] «Казан утлары» журналы, 1968 ел, 8 сан, 119 бит.
[2] Шунда ук, 120 бит.

ләр. Әдәбиятта гомумән психологизм гына түгел, ә мораль һәм этик критерийләре билгеле, ачык, тенденциоз психологизмны якладылар. Моның асылында исә гуманизм, кешене ярату, аның өчен борчылу һәм сөенү ята. Алар традициясе, һичшиксез, Ә. Еники хикәяләрендә дә дәвам иттерелә һәм үстерелә дип әйтәсе килә.

Классиклар традициясенең иң әһәмиятле сыйфатларыннан берсе — кешеләр мөнәсәбәтенең һәм язмышының эчке, психологик тирәнлегенә кереп, шул тирәнлектә яткан драматизмга игътибар итү һәм аны ачып күрсәтү. Бу — бер үк дәрәҗәдә реалистларга да, романтикларга да хас омтылыш, максат. Драматизм дигәч тә, аны киң мәгънәсендә аңларга кирәк. Аның мәгънәсе — кешеләр тормышын, аларның үзара мөнәсәбәтләрен, уй-тойгы һәм кичерешләрен катлаулы — каршылыклы, шатлыклы, кайгылы һ. б. бик күп төрле сыйфатларга ия булган чынбарлык итеп карау дигән сүз. Бу драматизмны күрмәгән әдәбиятның укучылар өчен гыйбрәтле ягы һәм аларга тәрбияви тәэсире бик чикле икәнлеген исбат итеп торуның һич кирәге юк. Аның үрнәкләрен без күп күрдек инде. Алар, иртәнге томан шикелле, берникадәр әдәбият офыгында күзләрне алдап асылынып торалар да, тормыш кояшы ныграк яктырта һәм кыздыра башлагач ук, юкка чыгалар. Чынбарлыкның кояшы булган кебек, аның мәрхәмәтсез җил-давыллары да, яшен-күкрәүләре дә туктаусыз булып тора. Болар һәммәсе безгә киң чынбарлыкның һаман алга хәрәкәте, үзгәрүе һәм яңаруы турында сөйли. Менә язучы иҗатында да шундый чынбарлык диалектикасы теге яки бу күләмдә чагылса гына, аның тормышчанлыгы турында кыю итеп сөйләргә мөмкин. Минем ышануымча, Ә. Еники үз иҗатының төп юнәлеше белән әдәбиятның шундый булырга тиешлеген яклый. Аның әсәрләре заман, заман кешесе, кешеләр язмышы һәм мөнәсәбәте турында укучыда җитди уйлану һәм бәхәсләр уяталар. Бу уйлану һәм бәхәсләр хәтта каршылыклы да булырга мөмкиннәр. Әмма алар һәр очракта да укучының яхшы мәгънәсендә гыйбрәтле нәтиҗәгә килүенә ярдәм итәләр дип ышанасы килә.



# БИК БӘХЕТЛЕ ШАГЫЙРЬ

*Мин бу җирнең*
*иң җир шагыйремен.*

(Ә. Давыдов, 1961 ел.)

«Уйласам, уйларга батам!» — ди халык җыры. Шулай шул, мин дә әле менә уйланып, уйларымны сөйләсәм дә тәгәл генә аңлата алмам кебек хәлгә калып торам... Татар поэзиясе Татарстан җиреннән узган тау булып күз алдыма килә. Ул тауны хасил итүче биеклекләр бар...

Тукай, Дәрдмәнд, Такташ биеклекләре! Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Сибгат Хәким биеклеге! Хәсән Туфан биеклеге... Бер халыкның поэзия тавында мәһабәт биеклек булып калыккан шагыйрьнең үзенә генә хас поэзиясе — үз йөзе була. Мондый шагыйрь озын поэмаларында да, кыска шигырьләрендә дә, хәтта куен дәфтәренә ашыгып-ашыгып кына сызгалап үткән язмаларында да үзенчәлекле йөзе белән танылып тора. Ул нинди рәк масштабта фикер йөртүеннән, әйтергә теләгән фикерен ничегрәк тотып алуыннан һәм укучыны да шул фикер белән янарга мәҗбүр итүеннән, ничегрәк мәҗбүр итүеннән таныла.

Татар поэзиясендә үзенчәлекле биеклек булып аермачык танылып торган шагыйрьләрнең берсе — Әнвәр Давыдов. Аның 1950 елда «Беренче бөртек» исемле беренче китабы чыга. Аннан соң китап арты китап... «Ташу», «Тормыш лирикасы», «Ферма кызы», «Чорлар чатында», «Кеше арасына ашыгам»...

Артка карасаң, 1950 ел әле ерак та түгел, Әнвәр Давыдовның чын мәгънәсендә ашыгып үскән, гаҗәп тиз җитлеккән шагыйрь икәнен күрәсең.

Әнвәр Давыдов тормышның ниндидер бер генә тармагы турында җырлап танылган шагыйрь түгел. Ул төрле өлкәләргә, яңа туган көн белән бергә хәрәкәткә килгән төрле хәлләр-вакыйгалар эченә үтеп керә белде.

Яз көне яңа төшкән дымлы сукмакка карап шагыйрь болай ди:

> Нигә миңа бу шиблет,
> Оеклар нигә кидем,
> Ялан аягымны тидереп,
> Иөгереп узар идем.

Яки:

> Авыл язы! Миңа бик таныш
> Синең бөтен-бөтен ягың:

Саламга тамчыларны көмеш
Төймә итеп тезгән чагың;
Беренче гөрләвегеңнең
Сабыйча көйләве;
Түбәдән карлар йөгенең
Төшеп гөрселдәве...
*(«Ташу». 1955.)*

Югарыдагы юлларны гына укыгач та мин Әнвәр Давыдовның табигать баласы икәнен, табигатьнең бөтен нечкәлеген язарлык көче барлыгын күрәм... Дөресен әйтим, аның табигать турында азрак язуы өчен күңелем әчынып куя. Тик дөньяда әле табигать матурлыгыннан мөһимрәк әйберләр бар шул. Шуңа күрә, тыныч хезмәт тавышын пуля сызгырулары, туп гөрелтесе алыштырган чорда, Әнвәр Давыдовның тавышы болайрак яңгырап ишетелә башлый:

Тетрә, дошман! Сиңа үлем илтәм!
Ике адым, тик ике адым!
*(«Беренче яра». 1943.)*

Шагыйрь вакыт белән узышып бара. Заман биргән тәҗрибәсен, тойгыларын сәнгатендәге изге ниятенә куша. Сугыштан соң, әле генә ремонтланып беткән, язгы чәчүгә әзер булып, тезелеп торган чәчкечләргә карап:

Залп өчен хәзерләнгән
Тупларга охшаган алар,
Зур һөҗүмне башлар өчен,
Минутын көтеп торалар,

— ди шагыйрь.

Әнвәр Давыдов, бүгенге ике лагерь, ике идея көрәше югары накалда торган, тормыш тагын да катлаулана төшкән вакытта шашып-шашып җырлауны түгел, уйлап һәм тагын бер кат уйлап җырлауны мәгъкуль күреп, киң мәйдандагы хезмәт ыгы-зыгысы эченә керә:

Җирдә шаулый: яшәү чыганагы
Күмелә тормыш биргән шау-шуга.
Шагыйр!
Колагыңны
Ныграк сал шуңа.
*(«Шәһәр сулышы». 1957.)*

Тәне, җаны, каны белән чын коммунист шагыйрь булу Әнвәр Давыдовны коммунистик идея тантанасы өчен туктаусыз көрәшкә: көн тәртибендә торган һәм көн агышында гамәлгә ашкан һәр эшкә зур игътибар итүгә, шуны җырлауга — публицистикага этәрә. Моңа шагыйрь ихтыярый бара, үз идеясенә шиксез ышандыру өчен, шигырь юлларына әйбернең яки вакыйганың, образларның асылын салып, фәлсәфи шагыйрь булып бара:

...Кайдадыр көн.
Кайдадыр төн.
Кайдадыр җылы,
Кайдадыр суык,
Гөлләр...
Көлләр...

Бу юллар безне яшәү һәм үлем фәлсәфәсенә юнәлтә. Кинәт син караңгылыкта шомланып китсәң, тәнеңне суык куырып ала; аннан күз чүлләренә күрәсең, кайнар

көл пешерә. Җитмәсә ул күптән түгел генә күкрәп үскән гөлләр көле бугай! Аларны ник яндырганнар? Кем яндырган?

Чүлләр...
Үлем...
Туу...

Ярый әле көл чүлләре һәм үлем артында туу бар, яшәү бар... Инде шагыйрь олы фәлсәфәгә контраст публицистик ялкын өсти:

Әнә, өскә үрелә гигантлар:
Озын куллы тимер краннар,
Кирпеч-кирпеч салып, кемнәргәдер
Рәхәт, җылы тормыш коралар.
. . . . . . . . . . . .

4

...Кайдадыр яз,
Гөлләр җилдә уйный,
Ә аларны
Сагалыйлар салкын кыраулар.
Ләкин яз җиңелми.
Язга алмашка җәй килмичә булмый.
Болыннарда, бакчаларда
Кешеләргә шатлык көенә чыңлый
Зәңгәр, ал кыңгыраулар...

Тагын фәлсәфә өстенлек алды. Укыйсың, кан тамырларыңа оптимистик рух йөгерә, яхшы:

Кешеләргә шатлык көенә чыңлый
Зәңгәр, ал кыңгыраулар.
*(«Чорлар чатында». 1959.)*

Шушында туктап, уйланып торсак, әле без укып узган «Чорлар чатында» дигән поэмадан китерелгән өзекләр Әнвәр Давыдовның бөтен поэзиясенә хас икәне сизелә. Аның поэзиясенең нигезендә тирән фәлсәфә, публицистик ялкын, күтәренке рух бергә үрелеп бара икән. Шул нигездә калыккан эчтәлек Маяковскийга охшаш кебек, ләкин аңардан үзгә, Әхмәт Фәйзигә якын, ләкин аңа да охшамаган бер яңа форма тудыра:

...Төн буе төрле төсләрдәге неон якты:
«Полет»
«Дружба»
«Ракета» —
акты да акты.

Бу юлларда без публицистик поэзиянең тантаналы-декларатив яңгырашын ишетәбез. Моңа шагыйрь фәлсәфи поэзиянең драматизмын өсти башлый:

Себер трактын?
Еракмы?
Александрийский централлар
Турында мөмкин язарга,
Сөргеннәр турында...
. . . . . . . . . . . .
...Чыңлый авыр богаулар
Һаваны ярып чыңлый.

Көрәшчеләр баралар,
Җир шары сыкрап тынлый.
Гаделлек, ирек өчен —
Көрәшчеләр газабы.
Бармы бу юлның очы?
Бармы азагы?!

*(«Себер тракты». 1966.)*

Шулай, әле фәлсәфә, әле публицистика көчәеп, әле алар бергә үрелеп, бүгенге халыкара атмосфераның киеренкелеген дә, тормыш динамикасын да тоярга булыша торган, шигырь юлларына яңа бер көч өсти торган калып — Әнвәр Давыдов калыбының үзенчәлекле формасы туа.

Мондый кыска-кысан мәкаләдә Әнвәр Давыдов кебек зур шагыйрьнең поэзиясе турында сүз йөртү, билгеле, кыенрак. Киләчәктә калын фәнни хезмәтләр, иркенләп, тәфсилләп, Давыдов поэзиясе эчтәлек ягыннан да, форма ягыннан да, зәукый яктан да кызыклы һәм камил икәнне әллә ничә кат расларлар. Аның поэзиясе татар шигъриятендә яңа бер мәктәп икәнне икърар итәрләр. Ул мәктәптә тәрбияләнгән шагыйрьләрнең исем-фамилияләрен күрсәтерләр. Хәзер исә биредә тагын бер гена нәрсәгә тукталасы килә:

Узган хәлләргә «матур фантазия бизәкләре»н дә, күзгә яшь китерә торган «ачы»-ны да мулрак өстәргә була. Узганны язу, бәлки, җиңелрәктер?.. Киләчәк инде безнең күңелебездә үк матур, чөнки без — кешеләр — күптән, бөтен көчебез белән, матурлыкка омтылабыз. Бәлки, киләчәкне язу җиңелрәктер?.. Ә бүгенге тәзелешләрне, җыелышларны — бүгенге хәрәкәтне бүген үк язып, аны бер очы белән хыялыбызда йөргән матур киләчәккә тоташтыра бару ничек? Бусын тәгәл беләм. Бусы — авыр эш, чөнки бүгенге укучы өчен бүгенге тормыш әллә ни яңалык түгел, аннан соң... якыннан караганда ямь-яшел агачта да сары яфраклар күренә. Әнвәр Давыдов менә шул тормышның матурлыгын җырлады, шундагы көн саен шытып торган яңалыкларны күрде, аны укучыга да күрсәтә белде. Илебездәге матди үсешнең һәм алдынгы идея үсешенең бүгенге тизлегенә ул күпмедер тизлек өсти алды. Яшь каләмдәшләрен дә туктаусыз шушы эшкә өндәде. Очраклы сөйләшүләрдә, рәсми чыгышларында, шигырьләрендә өндәде.

Әнвәр Давыдов гадилеге белән сокландырып, эрудициясе белән кызыктырып, хаклыгы белән инандырып яшьләр күңелен үзенә аеруча тартты. Алар белән бәхәсләште, сөйләште, киңәште.

Бүгенге күп кенә яшь шагыйрьләр Әнвәр Давыдов та салышкан нык күпергә кыю басып шигъри мәйданга керәләр. Алар үзләрен күтәреп торучы күпернең остасын онытмаслар, «Укытучыбыз!» дип һәрвакыт искә алырлар.

Бик бәхетле шагыйрь ул Әнвәр Давыдов.

Рестәм МИНГАЛИМОВ.

# ФОТУЛА ЯННАКОПУЛУ



*Коммунист-язучы Фотула Яннакопулу— тынычлык һәм ирек өчен көрәш алып баручы грек интеллигенциясенең алдынгы вәкилләреннән берсе. Патриот грек гаиләсендә туган Фотула, үзенең ата-анасы һәм абыйлары белән берлектә, Туган иленең дошманнарына каршы көрәш юлына бик яшьли баса. Ул «АЭТОПУЛА» (Яшь бөркетләр) исемле пионер оешмасы сафларында тәрбияләнә. Ә Греция җирләрен немец-итальян фашистларыннан соң Америка-Англия империалистлары таптый башлагач, шагыйрә яшьләрнең «ЭПОН» дигән яшерен оешмасында — каршылык күрсәтүчеләр сафында көрәш алып бара. Кыюлыгы һәм фидакарьлеге өчен аңа хәрби бүләкләр бирелә.*

*Демократик Греция өчен барган күпьеллык көрәштә меңнәрчә грек патриотларының гаиләләре кырылды һәм таланды. Фотуланың да ике абыйсы Америка-Англия империалистлары белән көрәштә корбан була, ә әнисен һәм башка туганнарын грек реакционерлары зинданга ташлый. «Мин бомбалар шартлавы астында үстем һәм минем бала чагымның музыкасы — туплар авазы булды,— дип яза үзе турында Фотула.— Мин аларның яңадан кабатлануын теләмим. Балалар үз Ватаннарында үз ата-аналары белән тыныч тормышта яшәргә тиешләр».*

*Туган халкына чиксез мәхәббәт һәм дошманга нәфрәт көче шагыйрәне кыю көрәшче итә. Бу көрәштә аның коралы — кулындагы каләм. Күренекле грек язучылары Костас Варналис, Тефкрос Антиас һ. б. күпләр Фотуланың көрәштәге батырлыгын һәм әдәби хезмәтләрен югары бәяләделәр. Әле утыз ике генә яшьтәге шагыйрәнең 17 китабы басылып чыкты һәм алар 16 телгә тәрҗемә ителгәннәр.*

*Күптән түгел Казанга язган хатларының берсендә Фотула татар шагыйре Муса Җәлилнең шигырьләрен укып бик тәэсирләнүе, соклануы турында әйтә. «Мондый батырлыкны минем әлегә кадәр күргәнем дә, ишеткәнем дә юк иде», диелә ул хатта. Шагыйрә Муса Җәлилнең шигырьләрен үз теленә тәрҗемә итәчәге турында белдерә.*

*Татарстан китап нәшрияты 1969 елда Фотуланың «Эллада кызы» исеме белән сайланма шигырьләр китабын татар телендә бастырып чыгара. Шигырьләрне Мөхәммәт Садри, Нури Арсланов, Зәки Нури, Әдхәт Синегулов тәрҗемә иткәннәр. Бу санда без укучыларыбызны шул китапка кергән берничә шигырьнең тәрҗемәсе белән таныштырабыз.*

•

## Мин—Эллада кызы

**Мин — Мурганос ташы,**
**Мин — канланган Пинда таулыгы.**
**Мин — мәңгелек батыр**
**Фермопиллы.**
**Мин — Граммос кыясы,**
**Мин аның әрнүле ярасы.**

**Минем йөрәктә**
**Яңа таң балкышы,**
**Мин Витис сусавы**
**һәм тормышның**
**Мәңге сүнмәс уты.**
**Мин давылларда туып-үстем,**

Металл кебек
ныклы мин.

Мин
Туган илемнән читтә,
Тик бер дә
ят итмим
Ят туфракны,
зәйтүн агачыдай,
Саныйм
үз итеп мин.
Мин — бомба,
Миндәге ачу,
әйтерсең, баздагы дары,
Дошманнар белсен,
тиздән шартлар
Аларның
бары-бары.

Мин —
ирекле кош очырткан
Халкым байрагы.
Мин — биек күк,
Канатың талса,
Син яхшы бел аны.
Мин — көрәш китабы,
Эллада теле җырчан —
Бу китапны кайнар һәм саф
Дулкыным белән кочам.
Мин
җиңүче кылыч сыман,
Дошман качалмас миннән.
И Илем, үч алганда да
Булырмын
синең белән.

ӘДХӘТ СИНЕГУЛОВ
тәрҗемәсе

## Минем куллар

Минем куллар корыч кебек нык кул,
Кояш нуры төсле җылы кул.
Күрешкәндә күз сал минем учка —
Бай хатирә белән тулы ул.
Һәр тормышның үз тарихы була,
Тарихы бар минем кулның да.
Сиздә куллар очрашулар ямен
Һәм газабын белде юлның да.
Кер уды һәм ямау салды алар,
Башкаемны кысты кадерләп,
Бәйрәмнәрдә өйне бизәделәр
Дуслар өчен мул сый әзерләп.
Минем куллар кырда иген икте,
Тау-таш ишеп йортлар салдылар.
Мин утырткан чәчәкләр һәм гөлләр
Йолдыз булып җирдә яндылар.
Кирәк чакта корал алды кулым,
Калтырасын дип дошман куллары.
Киметмәде кулның кыю көчен
Кайнар утлы сугыш еллары.
Салды куллар бәхет сукмакларын,
Ачты алар ирек юлларын.
Алар һаман эштә һәм походта...
Шундый менә минем кулларым!
...Безгә күбрәк эш бир! — диләр куллар,
Ябышмыйлар алар юк-барга.
Станокны металл чыңы белән
Җырлаттылар алар цехларда.
Менә хәзер каләм алды куллар,
Чыкты каләм ап-ак кырларга.
Ашыктыра аны минем куллар
Җырланмаган җырны җырларга.
Кулларыма зур ышаныч белән
Тапшырам мин йөрәк серемне.
Эштә алар бик күп тирләделәр,
Күп сөрттеләр яуда сөремне.
Бар нәрсәмне бирәм кулларыма —
Минем күңел юмарт яз сыман.
Минем куллар минем хакта язсын,
Минем куллар тарих язсыннар...
Ә ул тарих ил тарихы булсын,
Чын тарихы булсын халкымның,—
Яшәсен ул сулмый мәңге-мәңге,
Сүндермичә йөрәк ялкынын.
Язсын куллар зәңгәр күк турында
Һәм дуслыкның көчен зурласын.
Яңа җырны куллар тынычлык һәм
Сөю җыры итеп җырласын.
Яңа җырда шаулап торсын шатлык,
Ә сагышлар анда аз булсын,
Дулкынлансын анда азат диңгез,
Анда чәчәк, анда яз булсын.
Яңа җырлар ишсен төрмәләрне,
Дошманнарга булсын үчлеләр.
Яңа җырлар якты таң кабызсын...
Минем куллар шундый көчлеләр!
Я, әйтегез, шул кулларны кояш
Җылытмыйча кала аламы!!
Ялкыннарны сөеп кочсын куллар,
Иркәләсен куллар баланы.
Яңа җырлар елга булып аксын
Дөреслекне сөйләп кешегә.
Күр кулымны!.. Корыч кебек кулның
Көче дә күп булсын, эше дә.

ЗӘКИ НУРИ
тәрҗемәсе

## Мәңгелек сәнгать

Үз иленнән шактый ерак-еракта,
Музейга яшеренеп, арып-талып,
Шәрәлектән оялган Афродита,
Басып тора кайгылы уйга калып.
Нинди кабахәт кискән аның кулын,
Чиркәү карагы куркамы алладан!
Пычак белән кем ташланган изгегә,
Гүзәллек алдында тетрәп калмаган!
Кемнәр булсын, гүзәллек сөймәүчеләр,
Сихри сәнгатьнең кара дошманнары! —
Вәхшилекнең дә чиген белмәүчеләр,
Үтерергә ялланучылар бары.
Син, Афина, безнең изге аллабыз,
Син, аерылып матур туган илеңнән,
Тотып хакыйкать кылычын кулыңда
Нигә интегәсең ятлар җирендә!
Французгамы, инглизгәме — кем ала,
Безне шуңа этеп-сатып бирделәр,
Чит-ят җирләргә чәчелеп-сибелеп,
Гүзәл Эллада нурлары сүнделәр.

Сүнделәр... Ләкин караклар тотылыр,
Гадел хөкем алдына басар алар,
Эш белмәүче булдыксызлар урлаша,
Тарих аларны ләгънәтләп тамгалар.
Эллада бүген зур кайгы кичерә,
Кайнар күз яше ага Афинадан,
Йөрәк әйтә: «Кайгырмагыз, туганнар,
Гүзәл сәнгать чәчәк атар яңадан!»
Өнди безне борынгы батырларның
Изге каберләре кискен көрәшкә,
Кем дә баса алмаслык көчле тавыш
Аңлашыла халыкка, һәр йөрәккә.
Өнди гомер — бөек акыл иясе,
Фермопилның борынгы батырлары,
Илнең данлы Праксителе, Фидие,
Аристотель һәм Эсхил күк уллары.
Алар биеклегеннән һәр замандаш
Бергә дәшә хыянәтсез дусларын
Күтәрергә илдә хөрлек байрагын,
Акропольнең һәм Парфенонның данын!

## Әнкәемә хат

### язасым килә

Кулымдагы гөлчәчәкне әнкәемә
Ай, җибәреп булса иде хатка салып,
Хуш ис сипсен,
　　　ана зур дәрт бирсен иде,
Тар төрмәдә яткан чакта газапланып.

Тәрәзәдән җылы җилләр исеп керсен,
Әнкәемә яз сулышы өрсен иде,
Төшләремдә һаман аны күрүемне,
Гел юксынып йөрүемне
　　　　　белсен иде.

Йөземнәрнең яфраклары җитсә иде,
Әнкәемә җибәргәндә хатка салып,
Ул да көзге шатлыкны хис итсә иде,
Тар төрмәдә яткан чакта газапланып.

Туган җирне һәм, әнкәем, сине янып
Яратканны, сагынганны җаным белән,
Назлы дәфнә һәм зәйтүннәр яфрагына
Язып салыр идем йөрәк каным белән.

Ышан, әнкәй, хакыйкать бар бу дөньяда,
Син яшисең безнең йөрәк каннарында,
Тар-мар килер канлы караңгы төрмәләр,
Мин кайтырмын беркөн
　　　　　илнең таңнарында.

МӨХӘММӘТ САДРИ
тәрҗемәләре

# ДУСТЫБЫЗ РИЗА ХАЛИД



*«Сугыш минем бөтен хыялларымны бутап ташлады...» дип яза Риза Халид үзенең тәрҗемәи хәлендә. Бөек Ватан сугышы елларында Ленинградта, үзе яклап сугышкан батыр калада әле бүген дә өлкән офицер Риза Халид Совет армиясе сафында хезмәт итә.*

*Шагыйрь Риза Халид 1919 елның 5 мартында Кырым өлкәсенең Богатырь авылында туа. Мәктәптә, педучилищеда укый, аннан пединститут тәмамлый. Укытучы булып эшләргә тели. Ләкин сугыш башлану белән аңа Горький шәһәрендәге зенит артиллериясе училищесына китәргә туры килә. Хәрби училищены тәмамлагач, чолганышта калган Ленин шәһәренең нәкъ уртасында — Марс мәйданында урнашкан зенит батареялары белән фашист козгыннарына каршы дәһшәтле көрәш алып бара. Шуннан бирле ул Ленинградта кала. «27 ел бу шәһәрдә хезмәт иткәнгә мин үземне чын мәгънәсе белән Ленинградлы итеп саныйм», дип, шагыйрь юкка гына горурланмый. Сугышчы шагыйрь башыннан чолганышның бөтен авырлыгы: йокысыз төннәр, ялкынлы көннәр, ачлык, узак өзеч төньяк салкыннары, үлем дәһшәтләре һәм, ниһаять, бөек җиңү шатлыклары кичкән. Шуңа күрә дә шагыйрьнең әсәрләрендә төзәлмәгән яралар, һәлак булган замандашларының язмышын уйлап сызланулар, дошманга бөек нәфрәт хисләре чагыла.*

*Аның әсәрләре бик күп газета-журналларда, рус, грузин, болгар, украин, башкорт, черкас һәм башка телләрдә басылып килә. Соңгы елларда безнең журналда да укучыларыбыз аның шигырьләре белән таныштылар. Татарстан китап нәшрияты аның шигырьләр китабын басып чыгарды.*

*Шагыйрь Риза Халидка бу елның март аенда илле яшь тулды. Аның әле иҗат эшендә дә, хәрби хезмәтендә дә җиң сызганып эшләр чагы, ул әле һаман яшьләрчә дәртле, көр һәм шат күңелле, ул әле дә үз постында һаман сакта, һаман сафта.*

## Яратам сине, Нева

**Кочагыңнан кояш чыгып**
**Шат нурларын чәчкәндә,**
**Дулкыннарың гөлләр булып**
**Чәчәкләрен ачканда,**

**Күрдем сине таң атканда.**
**Аерылалмам һич синнән.**
**Җырларыма шәп маҗараң**
**Серле моңнарын биргән.**

**Саф суларың ширбәт кебек,**
**Тамчыларың — күз яше.**
**Сөям сине туган күреп,**
**Әй гомерем юлдашы.**

**Синең бәллүр суларыңдай**
**Көннәр үтә — агалар.**
**Нигә син гел уйларымда,**
**Ник сиңа бәйле алар!!**

**Чөнки, дустым, бу төшләрдә**
**Кан түктем Ватан өчен.**
**Дошманымнан көрәшләрдә**
**Мин алган идем үчем.**

**Зәңгәр миләүшәләр, гөлләр,**
**Хуш исләрен чәчсен дип,**
**Яшәү дусты — күгәрченнәр**
**Канат кагып очсын дип,**

Нева, синең дулкыннарың
Азат шаулап аксын дип,
Безнең яшьлек горурланып
Манзараңа баксын дип.

Ил ялкынын үзеңә алып
Чыктың дошман каршына,
Син ул куәт бирдең безгә,
Шәһәрнең яшь-картына...

Җиңүләрне кояш күрде,
Яз кочты һәр ягыңнан,
Каһарманнар салют бирде,
Нева, синең ярыңнан.

Очан судай ак син шаулап,
Табигатьнең чибәре!
Исә сине сөеп -назлап
Ладоганың җилләре.

НУРИ АРСЛАНОВ тәрҗемәсе

## Өмет

Өметсезгә гомер ник кирәк:
Кояшсыз таң җиргә килерме!
Су буенда үскән тал-тирәк
Сусаганның хәлен белерме!

Өмет бит ул — айдыр күгемдә,
Өмет бит ул — минем кояшым.
Өмет булса әгәр күңелдә
Үз-үзеңне көчле тоясың.

Әгәр, өмет, ят дип санап син,
Иртә таңда мине күрмәсәң,
Әгәр миңа кырын карап син
«Эш ничек!» дип сорау бирмәсәң,

Әгәр, өмет, мине азаплап,
«Көтмә инде, килмим» дисәң син,
Якты күкне кара сүз каплап,
Көтмәгәндә әгәр сүнсәң син —

Нигә кирәк минем сүзләрем!
Җырым булып нигә ут янсын!
Сукырайсын минем күзләрем,
Я сулышым минем туктапсын.

Ләкин беләм: мәңге ул үлмәс,
Өмет тора минем янымда,
Миннән башка өмет юл йөрмәс,
Өмет агыла минем канымда.

Походларда, канлы һөҗүмдә
Минем белән, өмет, атладың,
Яз да, җәй дә, кыш та, көзен дә
Яуларда син мине сакладың.

«Тиздән юлга! Артка калма!» дип,
Син эндәштең миңа окопта,
«Мин җыласам — мине аңла», дип
Елмайдырдың авыр вакытта.

Барча юлны бергә узабыз,
Бергә булдык бөтен якта да.
Сагыну җырын бергә сузабыз
Туган яктан читтә чакта да.

Дус һәм юлдаш миңа син күптән,
Син бит, өмет, бөтен торышым!
Мәхрүм калсам әгәр өметтән,
Кирәк түгел миңа тормышым.

●

Кояш нуры болытларны ярып үтәр,
Иркәләнеп нурга күмел, күңел! диген.
Учыңны син кояш көлгән якка күтәр,
Әйт син нурга: мең кат күбрәк сибел!
диген.

Син карасаң — балкый җирдә барча урын,
Яктыртасың җирдә бөтен тирә-юньне.
Бәхәсләшмик: җитмәс ләкин синең нурың
Кабызырга минем кайнар йөрәгемне.

ЗӘКИ НУРИ тәрҗемәләре.

Кояш Тимбикова

# АЛТЫН СӘГАТЬ

ОЧЕРК



Ул, сөзәк таудан аска төшеп, алачыгы янындагы багана башына үрелде. Ачкыч шунда булырга тиеш иде бит. Багана башын капшаганда, кулларының калтырануын сизде. «Кулы калтыранган тимерче тимерчемени ул?»

Башка вакытта эшкә тотынса, ул бөтен борчуларын оныта, эч пошулар шунда ук юкка чыга торган иде. Шуңа күрә Сәрвәр, үзенә бер терәк тапкандай, алачыкка керде, өргечен көйләде, чүкечләрен, ачкычларын, кискечләрен барлап чыкты: эшкә тотынырга да бөтенесен онытырга кирәк. Әмма Сәрвәрнең башына төшкән бүгенге хәсрәте алай тиз генә юып ташларлык түгел икән шул. Тимер-томырлары да көндәгечә җанга рәхәт биреп чыңламады, өргече дә утны көчәйтмәде, чүкеченең дә куәте әллә кая китеп югалган кебек. Үзәкне һаман шул бер уй өзгәләде: Гөлнурның үз әнисе кайткан, бүген Гөлнур Сәрвәрләрдән китә.

Бу хәбәр аңа йокы бирмәде. Сәрвәр үткән төн буе күзләрен Гөлнур йоклап яткан караваттан ала алмады.

Ап-ак тышлы түшәк өстендә яткан шушы ябык кына гәүдәле, шоп-шома какча йөзле, очы сүтелеп юрган өстенә тузгыган саргылт толымкайларны һәр иртәдә күрер өчен Сәрвәр бөтен тормышын бирергә риза булыр иде.

Төне буе керфек какмаса да, ул үзе көндәгечә сәгать биштә үк торды, иртәнге чәй табынын әзерләде: мич төбенә салынган һәйбәт арыш ипиеннән зур-зур телемнәр кисеп куйды, күкәйләр пешерде. Өстәл янына утыргач исә, чынаяктагы шикәрсез-нисез куе чәйне дә бер-ике генә йотты. Табын җәелгән килеш калды, ул алачыкка ашыкты.

Әмма тиз генә чыгып китә алмады, бер генә йомышы булмаса да, кабат түр якка керде. Изрәп йоклап яткан Гөлнурга күз төбәде. Гөлнурның түшәгенә капланып елый-елый ялварасы: «Калдырып китмә! Бөтен теләкләреңне үтәрмен, күтәреп кенә йөртермен, китә генә күрмә!» — диясе килде.

Сәрвәр, үзен зур җинаять эшләргә җыенгандай хис итеп, сискәнеп куйды. Аннары, әллә әнә шул кырын эшне эшләп ташлавыннан шикләнеп, әллә сулкылдап җибәрүеннән куркып, өйдән чыгып китте...

Унбиш еллап бергә яшәделәр алар.

Гөлнурның алар өендә яшәп калуы көтмәгәндә, уйламаганда гына килеп чыкты.

Сәрвәр ул елны, ремонтын көздән үк түгәрәкләп куйды да, кышын фермада эшләп йөрде. Маллар күп, азыклары чамалы. Үлем-китем булмасын өчен, аңа көн-төн фермада торырга туры килә иде. Беркөнне Сәрвәр шулай таң беленер-беленмәстә фер-



*Социалистик Хезмәт Герое Сәрвәр Нәфыйкова, Зифа Галиева һәм Гөлнур.*

мага барып керде. Салам түшәлгән җирдә бер аксыл төргәк ята. Маллар куркышып читкә посканнар. «Төргәк» ишетелер-ишетелмәс кенә мышкылдый. Барып караса — бәби. Тәне ут кебек яна, бит алмалары кызарып кутырлаган. Гаҗәпләнүеннән, куркуыннан телсез калган Сәрвәр, баланы күтәреп алды да, идарәгә чапты.

— Менә,— диде ул, төргәкне председательгә сузып,— кабул итеп алыгыз. Кемдер бәбиен минем маллар янына ташлап киткән.

Председательнең эше бик тыгыз чак иде. Ул карап-карап торды да:

— Туктале, Сәрвәр,— диде.— Бу минутта гына кая куйыйк инде аны? Үзегездә торып торсын. Алырбыз, озатырбыз.

Соңыннан инде терелеп җиткән, туп кебек тумрап торган баланы Сәрвәрнең бирәүгә дә бирәсе килмәде. Шулай итеп, Гөлнур Сәрвәрләр баласы булып китте.

Алар өчәү яшәделәр: Сәрвәр, Гөлнур, Зифа. Сәрвәр белән Зифа Гөлнурга кадәр үк бергә торалар иде инде. Гөлнур аларның икесен дә якын итте. Зифа — май заводы сакчысы — эшеннән ашыга-ашыга кайта да өй эчендәге хуҗалык мәшәкатьләренә чума. Аш-су әзерләү, кием-салым тегү, өй кирәк-яракларын барлап тору — бары да аның өстендә.

Сәрвәр Зифага бөтенләй охшамаган. Хәер, кайдан килсен ул охшашлык, алар бит бер нәсел кешеләре түгел. Шулай да тормышның әчесен-төчесен бергә татый-татый, алар туганнардан да болайрак якынайдылар. Гөлнурның бу йортка килүе ике кызның дуслыгын тәмам беркетеп куйды. Зифа апасын Гөлнур өйгә җан өрүче итеп таныса, Сәрвәр белән киләчәк тормышы, хезмәт, уку кебек олы нәрсәләр турында сөйләшә иде, Сәрвәрне үзенең беренче киңәшчесе итеп саный иде.

Гөлнурның үзенә биргән бихисап күп сораулары каршында сүзсез калмас өчен, Сәрвәр ничек тырышуын хәзер генә тоеп алды. Гөлнур зурайган саен, ул бирә торган сораулар катлаулана барган саен, Сәрвәр дә үсә, күбрәк эзләнә башлады. Кичен, эштән кайткач, Гөлнур белән сөйләшер өчен, Сәрвәр алдан әзерләнә иде.

Эштән ул Зифа кебек ашыгып кайта алмый. Төрле вакытлар була. Артык соңлаган көннәрендә Зифа:

— Шул кадәр кыланмасаң, ярамыйдыр шул, йортта да эш бетмәгән, көчең артык булса, монда булышыр идең,— дип үпкәләп каршы ала.

— Трактор хәтле трактор төн буе тик торсынмыни? — Сәрвәр һәрчак аның үзен шундый бер сорау алдына китереп бастыра:— Минем өйдә бәрәңге әрчеп утыруым яхшыракмы, әллә тракторның басуда булуы кирәгрәкме?

Зифа апаның эссесе сүрелгәч, Сәрвәр аңлатып бирә.

— Инде кайтып китәргә җыенып тора идем, бер тракторны сөйрәтеп килеп җиттеләр. Тырмаларының рәте киткән. Әллә ничә төшен куеп, көйләп җибәрдем. Балам

мин андый малай актыкларын. Юри минем эш беткән җиргә киләләр. Янәсе, мин тезәтеп өлгертә алмыйм да, алар төнге сменада җир тырмалыйсы урынга, клубта «Әпипә» сиптерәләр. Җирнең теле юк, сорый алмый... Ну хәзер әйт инде — кем гаепле? — Сәрвәр, соравына җавап эзләп, Гөлнурга карый. Гөлнур бармагы белән Зифа апасына төртеп күрсәтә:

— Ул гаепле булып чыга инде,— ди.

Өчесе бергәләп көләләр.

Иртән дә Сәрвәр эшенә, сәгать-фәлән белән исәпләшеп тормыйча, таң ярылганда ук чыгып китә. Гөлнур аңардан йоклап кала. Кайчак ул, йокысыннан уянуга, ситсы күлмәген элеп, алачыкка килә. Алачык алардан ерак түгел. Берничә йорт үтәсең дә сөзәк тау астына төшәсең. Сәрвәр Гөлнурны тау өстеннән үк күреп ала, шатлана, әмма тыштан бик исе китмәгәндәй кылана, чүкеч белән тимер кыйнавын белә: чың, чың, чың... Үзе Гөлнурның сүзен, тимер чыңына карамастан, бик тиз ишетә. Гөлнур:

— Апам дим, апам! Нигә шул чаклы иртә килдең? — дип сорый.

— Килдем шул, наным,— дип җавап бирә Сәрвәр.— Кеше-кара йөри башлаганчы, бетерәсе эшләрем бар. Аннары я шоферы, я трактористы килә башлый. Бүленеп калам.

Гөлнур аңа озак итеп сокланып карап тора. Гәүдәсе дә кечкенә генә югыйсә. Тимер хәтле тимерне үзе теләгән рәвешкә кертә дә куя. Ярты потлы чүкечне уйнатып кына йөртә. Хәер, Гөлнур бу чүкечкәйне уйнатулар Сәрвәр апасына бик кыйммәткә төшүен дә яхшы белә. Ул эштән кайткач, еш кына:

— Кулбашларга көч килә,— дип зарлана.— Шул чүкечне кайчан гына алмаштырырбыз икән, бигрәк авыр.

Шулай да ул кулларының сулкылдавын сиздермәскә тырыша. Ашап-эчеп алгач, Гөлнурга:

— Укы әле, наным, мин ятып кына тыңлыйм, газетага ниләр язалар икән! — ди дә, башын мендәргә төртә...

Көннәрдән бер көнне Сәрвәр, иртән үк килеп, сабанның сынган тәрәнен ялгап ята иде, алачыкка сулуы кабып Гөлнур йөгереп керде.

— Апам, сөенче, сөенче! — диде ул, үрсәләнә-үрсәләнә.

Сәрвәр тураеп басты, уң кулындагы ачкычны күн алъяпкычы кесәсенә тыкты да Гөлнурга карады. Гөлнурның күзләре әсәрләнгән, борын канатлары киерелгән, бит алмалары кызарган иде.

— Ни булган? — дип сорады Сәрвәр, тыныч кына.

— Апам!..— Гөлнур тукталып, Сәрвәрнең сөенчегә ни вәгъдә итәсен көтмәкче иде дә, тыела алмады.— Беләсеңме син кем хәзер?

— Беләм,— диде Сәрвәр шаярткандай һәм кабат ачкычын алып гайканы боргалый башлады.— Мин — Сәрвәр Нәфыйкова, Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының Балтач районы, «Правда» колхозының өлкән тимерчесе.

— Түгел! Түгел! — диде Гөлнур, баскан урынында сикергәләп.— Син хәзер — Герой! Беләсеңме — Герой, Социалистик Хезмәт Герое!

Кичкә таба, радиодан ишетелгән бу хәбәрне раслап, газеталар да килеп җиттеләр. Турысын гына әйткәндә, бу хәбәргә башта Сәрвәр бик үк ышанып та җитмәгән иде. Гап-гади бер татар авылының тау буендагы кеп-кечкенә алачыгындагы тимерчене Социалистик Хезмәт Герое итсеннәр әле! Гаҗәп. Әмма аңар озак гаҗәпләнергә туры килмәде. Колхоз сабан туйларына әзерләнеп ятканда, председатель Галимҗан Газизов Сәрвәргә яңа хәбәр тапшырды: кунаклар килә, Сәрвәр, сиңа бүләкләреңне тапшырырга киләләр, әзерләнеп тор, диде.

Кунакларны Сәрвәр үзе генә түгел, бөтен Балтач районы бер булып каршылады. Сосна авылының кечкенә клубы тантанага җыелучыларны көчкә сыйдырды. Моңарчы бүләк-фәләннәрне күрмәгән, мактау сүзләрен әллә ни күп ишетмәгән Сәрвәр югалды да калды. Үзен президиумга чакырып, сәхнәдәге өстәл янына да утырткач, бөтенләй каушады. Кызган тимернең мыскалын да бик тиз чамалый торган үткен күзләр аска текәлделәр, ярты потлы чүкечне чөеп йөрткән көчле куллар нигә тотынырга белмичә, өстәл япмасының читен бөтерергә керешә.

Олы бүләкне тапшырырга килгән кеше — ТАССР Верховный Советы Президиумы председателе Салих Гыйлемхан улы Батыев:

— Сәрвәр туган,— дип сүзен башлады,— фидакарь хезмәтең өчен зур рәхмәт сиңа. Тырышлыгың белән син бөтен Татарстанга дан китердең. Яшермим, хатын-кызның, бигрәк тә татар хатын-кызының, тимерчелектә эшләп дан казануына мин башта сәерсенеп тә караган идем. Чөнки тимерче һөнәре безнең бабайлар өчен дә баш җитмәслек серле хезмәттән саналган. Революциягә кадәрге чорда татар авылларында крестьяннар рус тимерчесе яллаганнар. Тимерчеләр караңгы авылларга яктылык алып килүчеләр дә булган. Крестьяннар белән эшчеләр арасын тоташтырып торганнар. Хәтерегездә булса, Таҗи Гыйззәтнең «Чаткылар»ында да алпавытларга каршы торырдай көчләрне рус тимерчесе үстерә. Рус тимерчесе. Димәк, изелгән татар халкы арасында металл серенә төшенүче кешеләрнең булмавы патша галиҗәнаплары өчен бик кулай булган.

Без инде Октябрьның 50 еллыгын каршылыйбыз. Каршымда — татар кызы, коммунист Сәрвәр Нәфыйкова, Социалистик Хезмәт Герое. Рәхмәт сиңа, сеңел, рәхмәт. Сиңа карап «Правда» колхозының башка членнары да тырышырлар. Син аларга маяк булдың!

Верховный Совет Президиумы председателе залга, Сәрвәрнең авылдашларына караган иде, залдагылар аның сүзләрен хуплап дәррәү кул чаба башладылар.

Сәрвәрнең күкрәгенә Урак һәм Чүкеч сурәте төшерелгән алтын медаль һәм Ленин орденын тагып куйдылар. Нидер әйтергә, күңелдәге шатлыкны клубтагыларга да аңлатырга кирәк иде. Тик Сәрвәр күп сөйли алмады. Ул ишетелер-ишетелмәс тавыш белән:

— Рәхмәт инде,— диде.— Бик олыладыгыз, рәхмәт!

Сәрвәрнең кешеләргә әйтер сүзләре бик күп иде бит, югыйсә. Шул тантанада күңелендәгеләрен бушатып калырга алдан ук әзерләнеп тә торган иде.

Яшьләргә гыйбрәт өчен, сугыш елларын да искә төшереп үтмәкче, кешеләрнең бер-беренә ярдәме нинди изге бер көч булуын аңлатмакчы иде. Үзенең бу геройлыгында бөтен районидашларының өлеше булуын раслап күрсәтмәкче иде...

Сәрвәр, әнисе Фатыйма апа үлгәндә, нибары бишенче класста гына укый иде. Аннары укуны бөтенләй ташларга туры килде. Башта ул плугарь булып эшләде. Җәй үтеп, көз җитте, салкын кыш ишек кагарга тотынды. Шундый көннәрнең берендә Сәрвәр Балтач МТСына китте.

— Әй, туганкай,— диделәр анда, Сәрвәрнең йомышын тыңлап бетергәч,— син бигрәк яшь бит әле.

— Минем кебекләр станокта фронт өчен корал ясыйлар хәзер.

Шушы сүзләрне әйтү белән, Сәрвәрнең күзләренә яшь килеп тыгылды. Ул инде ишектән чыгып китәргә дә җыенган иде, ләкин ягымлы бер аваз аны кире борылырга мәҗбүр итте.

Ике-өч көннән Сәрвәр МТСта оештырылган тракторчылар курсында укый башлады. Озакламый үзенә дә трактор бирделәр.

Трактор ат түгел, бер чыгымлый башласа, тиз генә игә китерәм димә. Бу хакыйкатьне Сәрвәр белә инде. Шуңа күрә ул үзенә тапшырылган машинаны көйләп, яхшылап карап йөртергә, детальләрне саклап тотарга тырышты. Чөнки сугышта танк ничек булса, тылда трактор да шулкадәр кирәк һәм ансыз йөзләрчә гектар җирне эшкәртергә һич мөмкин түгел иде. Танк дигәннән, бер көнне Сәрвәрнең күңеленә тагын бер зур шатлык өстәлде: аның исеменә Мәскәүдән Верховный Башкомандующий И. В. Сталиннан рәхмәт язуы килеп төште. Сәрвәр танк колоннасы төзү өчен хөкүмәтебезгә үзенең саклап тоткан барлык акчасын тапшырган иде.

Кырык бишенче елның маен да Сәрвәр яхшы хәтерли. Ул үзенең тракторында сабан сөрә иде. Су ташучыдан җиңү турындагы хәбәрне ишеткәч, аңа басулар тагын да киңәебрәк киткәндәй тоелды.

Сугыш беткәч тә ул МТСтан китәргә ашыкмады. Сварщик һөнәрен үзләштереп алды, тимерчеләргә ярдәм итте. Яңа маркалы тракторларны өйрәнә барды. Әлеге Сосна авылына да ул «Беларусь» тракторы белән килеп урнашты. Аннары «Правда» колхозында бөтенләйгә урнашып калды. Инде менә тимерчелектә тупланүенә дә унике елдан артып китте. Шул ук колхозда ул Гөлнурны очратты, семья корды... Бу колхоз аның туган йортына, колхоздашлары кан-кардәшләренә әйләнделәр.

Юк, тантаналы кичәдә ул боларның берсе турында да, хәтта хезмәте турында да сөйли алмады. Баксаң, хезмәт бигрәк гаҗәеп нәрсә икән ул, шул яр буендагы алачыктан да нур булып балкый ала икән!

Әле ул алачыкны заманча җиһазлар белән тулыландырып та җибәрсәң!? Өргечне, бораулауны механизациягә күчерү генә дә эшне никадәр җиңеләйтте. Берничә яңа станок куйсаң, пневматик чүкеч булдырсаң!?.

Сәрвәрнең уйларын бүлеп, тагын кул чаптылар. Ул, оялуын көчкә басып, залга күз ташлады. Алкышлаучылар арасында иң ихластан сөенеп утыручы Гөлнурны күрде. Ә клубтан кайтып ишек алларына кергәч, Гөлнур Сәрвәрнең муенына килеп асылынды.

— Апам! Әнием! Героем! — дип өзгәләнде ул.— Барысы да син, Сәрвәр апам,— дип аңа сыенды.

Инде унбиш яше тулып узган Гөлнурның кайчакларда уйга калуының серләрен-сәбәпләрен Сәрвәр бик белеп тора: әти-әниле дус-ишләреннән ким-хур булып йөрергә туры килмәсә дә, вакыты-вакыты белән аны үзен тудырган ананы күрү теләге биләп ала. Мондый теләк кызкай башына җителмәгән кайгы төшсә яки зур бер шатлык кичерсә туа.

Сәрвәр үзе Гөлнурның чын әнисе түгеллеген: кызчыкны ничек, кайдан алып кайтуын яшерми дә. Кызның, күзләрен каядыр билгесез ноктага төбәп, уйга талган вакытларда Сәрвәр, үзен гаепле кешегә санагандай, сөйли башлый:

— Белмим бит, Гөлнур, мин ул хатынның кайда икәнен белмим. Танымыйм да, күргәнем дә юк...— Кабаттан Гөлнурны каян тапканын, ничек үзләрендә калдыруын сөйләп бирә.

Гөлнур аны серле әкият тыңлаган кебек тыңлый-тыңлый да, сагышлары таралып җиткәч, елмаеп куя. Күз алдына караңгыда кача-поса авылдан чыгып киткән хатын килә. Гөлнур ул хатынның үзе нинди икәнен билгели алмый. Әйләнеп Сәрвәр апасына карый. «Шундый уктыр әле,— дип уйлый ул.— Әни кешенең йөзе нәкъ менә Сәрвәр апаныкы төсле булырга тиеш».

Зифа, андый чакларда, Сәрвәрне өйрәтеп ала.

— Син үксез бала белән күп сөйләшмә, аның күңеле барыбер үз анасына тартылачак. Үсеп җиткәч, китәр дә барыр,— ди.

Зифа кешеләрне белеп эш йөртә шул ул. Аның әйткән сүзләре һаман дөреска чыга бара. Сәрвәр кичә Гөлнурның чын әнисе белән очрашты. Ул хатын Сәрвәрнең каршысына һич көтмәгәндә килеп чыкты да куркыныч тавыш белән:

— Кыз — минеке! Синең белән сөйләшеп тә тормыйм мин,— диде.— Атасы әйтте, кызны табып бирсәң, кабат өйләнәм үзеңә, диде. Иртәгә авыл Советына барам да председатель белән сөйләшәм!

Сәрвәр өнсез калды. Бу хатын алдында ул үзен бик көчсез тойды. Күзләре түбән иелгән керфекләре аша үзенең тузанлы башмакларыннан хатынның затлы туфлиларына күчте. Тән төсле үк нечкә капрон оеклар, гәүдәсенең бөтен матурлыгын белдереп тора торган тар гына кыска юбка. Үтә күренмәле ап-ак кофта астыннан челтәрле эчке күлмәкләре, ялтыравыклы тукымадан теккән лифчигы беленә. Йомры беләген кысып торган алтын беләзектәге бармак бите кадәр генә алтын сәгатькә карап, Сәрвәр күзәтүдән тукталды.

Уеннан кечкенә вакытта әбисеннән ишетеп калган бер әйтем узды: «Беләзегең чын алтын — йөрәккәең ник салкын?» Күзләр исә һаман кечкенә алтын сәгатьтә торды. «Гөлнуркаем кызыгыр инде,— дип уйлады ул.— Матур шул, өс-башы да, сәгате дә...»

Бу уй аны өйдә дә кич буе өзгәләде, иртән дә тынгылык бирмәде.

Үч иткәндәй, алачыкка кешеләр дә килми ичмаса. Ул бүген төшке ашка да өйләренә кайтмады. «Әнисе килгәндер, юлга җыеналардыр, әсләренә карап торуы кыен булыр»,— дип уйлады. Әмма кулкайлары да эшләп куандырмадылар. Моңарчы күңеленә моңлы бер җыр булып кереп урнашкан чүкеч тавышы да, тимер чыңы да җанга тынычлык бирә алмады.

Гөлнурны югалтудан күңел бөтенләй бушап калган иде. Яшәүнең, эшләп йөрүләрнең мәгънәсе бетеп бара кебек. Ул бит һәр талпынуын Гөлнурга багышлый, һәр җиңүен Гөлнурга булган олы мәхәббәтнең нәтиҗәсе итеп таный иде. Әгәр аның

янында Гөлнур яшәмәсә, ул бәлки геройлыкка да ирешә алмас, тимерчелеген дә, бу алачыгын да әллә кайчан ташлап киткән булыр иде.

Алар бергә-бергә нинди кыенлыкларны җиңделәр, авыр елларны кичерделәр. Хәзер, хезмәт шатлыклы бер җиңүгә әйләнгән көннәрдә, күңеленең яртысы убылып төшсен, имеш.

Сәрвәр аякларын көчкә сөйрәп өйгә кайтып житте. Тыштан ук күңелсезлек бөркелеп тора сыман. Өй эченә һич керәсе килми. Әле бүген генә, иртән генә ап-ак япмалы түшәк өстендә йоклап калган Гөлнуркайдан башка бу өйне күз алдына да китереп булмый бит.

Сәрвәр һаман өй эченә керергә батырчылык итмәде. Лапас астына күз салган булып, кош-кортларны барлагандай итеп, һаман соңгы өметенә ирек бирә килде. Бусаганы атлап өйгә кергәч, беренче минутта ук ул өмет кисәге очып юкка чыгачак бит. Көне буе күңелне сагышландырган сорауга кискен җавап яңгыраячак:

— Киткән!

Ишектән кергәч тә әле Сәрвәр күзләрен күтәреп зал якка карарга кыймый торды. Ишек төбендә Гөлнурның чүәкләрен күргәч кенә, бераз батырая төшеп алга атлады. Анда, түр якта, көзгеле шифоньер каршысында күбәләктәй киенгән Гөлнур басып тора иде. Баскан да, аклы ситсы күлмәге өстеннән генә Сәрвәрнең яңа пиджагын киеп көзгедән үзен-үзе караштыра. Сәрвәр ни диярга белмичә:

— Гөлнур! — диде.— Гөлнур! — Тамагындагы каты төер аңа сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмәде.

Гөлнур исә, үз алдына сөйләнгәндәй, хәлен аңлатты:

— Менә бу алтын ичмаса,— диде, пиджак түшенә кадалган Алтын Йолдызга күрсәтеп.— Ә ул, җүләр, алтын сәгате белән мактана, сиңа да алып бирәм, диган була... Алтын Йолдызлы әниемне ташлап китәмме соң?! Мин сезнең яннан бер кая да китмим! Балтачка йөреп укырмын, унны бетерермен, әйеме?!

Сәрвәр, кинәт җиңеләеп китеп, утыргычка утырды, рәхмәт әйткәндәгедәй ягымлы тавыш белән:

— Укыйм дисәң, мин шул алачыгымнан атна-ай буе чыкмый эшләргә риза,— диде. Аннары: «Китә генә күрмә, ташлама гына!» — дип өстәмәкче иде дә, көтмәгәндә, бөтенләй башка сүз ялгады:

— ...Хәзер инде пневматик чүкеч тә булачак...

**Фатих Урманчеев**

# ТАРИХИ ҖЫРЛАР

Халык авыз иҗатының төркемнәрен барлау, жанрларын ачыклау, аларны төрләргә бүлү бүгенге фольклор фәненең төп проблемаларыннан санала. Бу мәсьәләләрне хәл итү юлында шактый эш эшләнгән инде. Әкият, бәет, җыр, мәкаль-әйтемнәр буенча махсус җыентыклар чыгарылган, мәкаләләр, тикшеренүләр язылган.

Әмма ачыкланмаган мәсьәләләр дә җитәрлек әле. Татар халкының риваять һәм легендалары фольклорчылар игътибарыннан бөтенләй диярлек читтә тора. Кайчандыр йола фольклорына, туй җырларына берникадәр шикләнеп карау, алар татар фольклорында гомумән бар микән? — дигәнрәк уйлау очрый иде. Йола фольклорына карата махсус мәкаләләр язылмаса да, хәзер татар халкының йола, аеруча туй җырлары кайбер җыентыкларда басылып чыктылар инде. Татар эпосы дигән сүзләр дә фольклор фәнендә бик сирәк очрый. Халык иҗатының эпик яисә лиро-эпик төрләрен бәетләр белән чикләү тенденциясе дә үзен сиздергәләп куя. Бездә халык эпосының дастан кебек борынгы төрләреннән язып алынган үрнәкләр бик аз. Халык телендә алар гаять сирәк очрый. Бәетләр исә югары культуралы мәшһүр Болгар дәүләтенең варислары булган Урта Идел буе татарлары эпосының төп жанры. Татар халык иҗатына гына хас милли-оригиналь төр буларак, алар күп мәртәбәләр басылып чыгалар, еллар буена галимнәрнең игътибарын тартып киләләр. Тора-бара татар халык эпосының башка төрләре бәетләр күләгәсендә калдылар дип әйтергә дә мөмкин. Һәм бу аңлашыла да. 1940 елларга кадәр татар халкының поэтик иҗатын Татарстан территориясе белән генә чикләп карау тенденциясе бар иде. Безнең көннәрдә исә фольклористика фәне бу ялгыш караштан арыну чорын кичерә. Шуның белән бергә халык әдәбиятын өйрәнүче галимнәр алдында торган катлаулы проблемалар яңадан калкып чыга. Халыкның төрле этник төркемнәре иҗатына хас үзенчәлекләр, батырлар турындагы әкиятләр проблемасы, татар халык эпосы, аның төрләре, конкрет әсәрләре һәм башка шундыйлар махсус тикшерүчеләрен көтеп калалар. Бирегә исә шундый проблемаларның берсенә — татар халык иҗатында тарихи җыр мәсьәләсенә тукталып карыйк.

Бу мәсьәләне беренче булып без күтәрмибез. Татар халкының әдәби мирасыннан тарихи җырлар эзләү күптән башланган. Безнең фольклорның аерым әсәрләренә карата «тарихи җыр» терминын беренче булып Н. Ф. Катанов куллана. Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең 1899 елда уздырылган бер җыелышында ул «Казан татарларының тарихи җырлары» дигән темага доклад ясый. Ләкин асылда бу хезмәт тулысынча бәетләргә багышланган [1]. Ягъни,

[1] Н. Ф. Катанов. Исторические песни казанских татар. Изв. Общ. арх. ист. и этнографии. Т. XV. Вып. 3. Казань. 1899 ел. 273—306 битләр.

татар бәетләрен автор рус укучыларына тарихи жыр дип тәкъдим итә һәм кушымта рәвешендә К. Насыйри белән И. Барышов тарафыннан җыелган әсәрләрне китерә. Шул ук бәетләр «тарихи жыр» исеме белән 1911 елда «Шура» журналында да басылып чыга.

Беренче карашка, Н. Ф. Катановның бәетләрне «тарихи жыр» дип атавында әллә ни зур ялгышлык та юк. Чөнки б ә е т сүзе тарихи җырларга шактый якын торган әсәрләргә карата кулланыла. Аны русчага башкача тәрҗемә итү мөмкин дә түгел.

Теоретик яктан тарихи җыр мәсьәләсен беренче булып Г. Рәхим күтәрә. Халык иҗаты турындагы бер мәкаләсендә [1] ул, рус, казакъ, кыргыз халыкларының батырлар турындагы шигъри әсәрләренә кыскача тукталганнан соң, «бездә тотып күрсәтерлек тарихи җырлар... юк», чөнки «безнең һәммә җырларымыз лирический (хисси) җырлар гына» дигән нәтиҗәгә килә.

Татар халык иҗаты буенча XX йөз башына кадәр басылып чыккан китапларда тарихи җыр дип әйтерлек әсәрләр чыннан да бик аз. Димәк, Г. Рәхим фикере XX йөз башы фольклористикасы өчен дөрес шикелле. Татар фольклорында тарихи җырлар булмауның сәбәбен ул түбәндәгечә аңлата: «Безнең тарихи бәетләребез башка халыкларның тарихи җырлары урынына торалар». Автор биредә гомумән татар халык иҗаты турында түгел, ә бәлки Урта Идел, таррак алганда — Казан татарлары фольклоры турында гына сөйләвен дә әйтсә, аның фикере объектив дөреслектән ерак тормаган булыр иде. Г. Рәхимнең ялгышы шунда ки, ул татар халкының бер этник төркеме фольклорын өйрәнү нәтиҗәсендә туган фикерен бөтен халык иҗаты өчен дөрес булырга тиеш дип уйлый. Әнә шул юл белән XX йөз башында фәнгә «татар халык иҗатында тарихи җыр функциясен бәет башкара» дигән фикер килеп керә. Шуннан әлеге мәсьәлә фәннән төшеп кала һәм ярты гасыр буена күтәрелми дә.

Соңгы елларда тарихи җыр мәсьәләсе янадан калкып чыкты. Профессор Н. И. Воробьев, мәсәлән, Идел буе татарларында халык батырлары, Пугачев, 1812 елгы Ватан сугышы турында тарихи җырлар бар, дип яза [2]. Әмма конкрет әсәрләрне күрсәтми. Бу очракта сүз «Пугачев турында», «Рус-француз сугышы бәетләре» кебек әсәрләр хакында бара, күрәсең. Күптән түгел басылып чыккан бер мәкаләсендә М. Нигъмәтҗанов та «без болгарларда халыкның үткәнен гәүдәләндерүче тарихи-эпик җырлар да булган дип нәтиҗә ясый алабыз» [3], дигән фикергә килә. Шул ук вакытта автор ул чордагы конкрет әсәрләрнең сакланмавын да күрсәтеп үтә. Безнең көннәрдә басылып чыккан хезмәтләрдән тагы А. Абдуллин мәкаләләре игътибарга лаек. Ул татар халык иҗатында тарихи җырлар бар дигән фикерен конкрет мисаллар белән расларга тырыша [4]. Әмма, тулаем алганда, аның фикерләре каршылыклы. «Пугачев турында» дигән әсәрне, мәсәлән, ул бер урында тарихи җыр дип атый, икенче урында бәетләр рәтенә кертә. Халык көйләре китабында басылган «Себер юллары» җырының идея эчтәлеге дә А. Абдуллин тарафыннан ялгыш аңлатылган. Җыентыктагы искәрмәдә дә [5], А. Абдуллин мәкаләсендә дә — җыр патша Россиясенең татарларны Себергә көчләп күчерү фактын, колониаль политиканы чагылдыра, дип язылган. Чынлыкта исә бу л и р и к җыр татар-мишәрләр арасында киң таралган «Шәлчеләр» җырының бер варианты гына. Аның эчтәлеге бәхет, мал эзләп читтә йөрүчеләр турында сөйли. Җыр XVI—XVII йөзләргә түгел, нигездә XVIII—XIX йөзләргә карый [6].

Тарихи җырларны бастырып чыгаруда да төрле каршылыклар яшәп килә. 1964 елда чыккан «Татар халык көйләре» китабында «Тарихи җырлар» дигән махсус бүлек бар [7]. Ләкин шигъри эстетик үзенчәлекләре буенча анда урнаштырылган

---

[1] Г. Рәхим. Халык әдәбиятымызга бер караш. «Аң» журналы. 1914 ел. 14—16 һәм 19, 20, 22 саннар.

[2] Народы Европейской части СССР. «Наука» нәшрияты. Мәскәү. 1964 ел. 675 бит.

[3] М. Нигъмәтҗанов. Ерак чыганаклар. «Совет әдәбияты» журналы. 1963 ел. 2 сан. 123 бит.

[4] Музыкальная культура Советской Татарии. Мәскәү. 1959 ел.

[5] А. Ключарев. Татар халык көйләре. I том. Казан. 1941 ел. 199 бит. Алга таба А. К л ю ч а р е в диелер һәм китапның битләре күрсәтелер.

[6] И. Надиров. Татар халык җырлары. Казан. 1965 ел. 405 бит. Алга таба И. Н а д и р о в диелер һәм китапның битләре күрсәтелер.

[7] М. Мозаффаров, Ю. Виноградов, З. Хәйруллина. Татар халык көйләре. Мәскәү. 1964 ел. 60—66 битләр.

әсәрләрнең бишесе дә халык җырларыннан гомумән ерак торалар. «Йосыф җыры», искәрмәдә күрсәтелүенчә, Г. Коләхметовның «Яшь гомер» пьесасыннан алынган. Шәкертләрнең садалары да бәет яисә кульъязма әдәбият традицияләре нигезендә иҗат ителгән.

Караңгы икән юлыбыз,
Күрмәс икән күзебез.
Агладь бу хәлебезгә
Безнең вөҗданнарыбыз.

Күп мәшәкатьләр чиктегез,
Күп кайгылар күрдегез.
Аккан вакытлар булгандыр
Күзләрдән яшьләрегез.

*(«Өченче сада»).*

Шигъри ягы шактый «йомшак» бу саданы традицион җырлар белән бер рәткә куеп булмый, әлбәттә. Җыентыктагы «тарихи җырларның» калганнары да шундый ук яисә шуңа охшаш.

Кыскасы, татар халык иҗатында тарихи җыр мәсьәләсе гасыр башында ничек куелган булса, хәзер дә шулай тора. Чөнки тарихи җыр дип кисеп әйтерлек әсәрләр әлегә бик аз басылган. Мәсьәлә теоретик яктан да рәтләп өйрәнелмәгән.

* * *

Татар фольклор фәнендә тарихи җырларның теоретик билгеләмәсе юк. Димәк, мәсьәләне беркадәр ачыклау өчен, тарихи җыр дип уйланылган конкрет әсәрләргә тукталып, аларның бәет түгел, җыр, алай гына да түгел, тарихи җыр булуын исбат итәргә кирәк. Әйтик, халык арасында киң таралган «Шәрук беглый» һәм «Хәмидулла качкын» җырлары (И. Надиров, 70—73). Бу әсәрләрне бәетләр рәтенә, йола, уен-бию яки кыска (дүрт юллы) җырлар төркеменә кертеп булмаганлыгын исбат итеп торасы юк. Тик аларның лирик (яисә лирик озын) җырларга мөнәсәбәтен ачыкларга кирәк. Лирик җырларның төп үзенчәлеге шунда ки, аларның сюжетын кичерешләр алмашынуы, хисләр бәрелеше, алар арасындагы көрәш тәшкил итә:

Биек тау башындин кем соң килә,
Кузырлыкай чаналы, күк атлы?
Гашыйклык хәлләрен сорашсагыз,
Җиде тәмуг утыннан куәтле.
Җил тибрәтә нәзкәй каенны,
Кемгә сөйлим икән кайгымны?

«Кузырлыкай чана» (И. Надиров, 137) җырыннан алынган бу өзектә әчтәлеген сөйләп бирерлек вакыйга да, хәтта берәр әһәмиятле эпизод та юк. Хисләр дөньясын, кичерешләр динамикасын, фикер үсешен җанлырак, ачыграк итеп гәүдәләндерү өчен гадәттә лирик җырда билгеле бер шигъри образ үзәккә алына (бу очракта — кузырлы чана) һәм ул эпитет, чагыштыру, символлар белән баетыла:

Өзгән гөлләр кебек аерылыштык,
Кавышыр көннәр берәр булырмы?
Тал тибрәлә җилләр искәндә,
Өзелә бәгырем исемә төшкәндә.

Гомумән, лирик җырлар кеше күңелендәге иң нечкә хисләрне, аның кайгы-хәсрәтен, шатлык-куанычын һәм алар арасындагы төрле каршылыкларны, мөнәсәбәтләрне гәүдәләндерәләр.

Ә инде «Шәрук беглый» һәм «Хәмидулла качкын» җырларының төп үзенчәлеге шунда ки, аларның нигезендә «вакыйга сюжеты ята» (И. Надиров, 12). Әйтик, «Шәрук беглый» җыры геройның яшьлеге, бала чагын сурәтләүдән башлана:

Яшь вакытта үстем авылымда,
Әти-әни кәбәм кулында...

Үсеп җиткәч, Шәрук тормышында төрле бәхетсезлекләр башлана. Ул патша армиясенә алынырга тиеш була. Буйсынмас рухлы, ирек сөючән Шәрук солдатлыктан кача. Аны тотып төрмәгә ябалар, ләкин ул аннан да кача һәм, качкын булып, урманда яши.

Син сорасаң, эти, мин әйтием:
Минем урыным урман куенында.

Шәрук үзенең иптәшләре белән бергә авыл байларына каршы даими көрәш алып бара. Ахырда ул, патша солдатлары тарафыннан кулга алынып, сөргенгә җибәрелә. Әмма ул каушап калмый, изге ниятләреннән баш тартмый:

Кинәнмәгез юкка, тоттык диеп,
Тотканыгыз саен качармын.

Шул рәвешчә, җыр Шәрук тормышында булган әһәмиятле вакыйгаларны шактый тулы сурәтли.

«Хәмидулла качкын» җыры да нигездә төрле вакыйгалар турында сөйли. Хәмидулла күп еллар буена качкын булып яши, бер җирдән икенче җиргә күчеп, Мәскәү, Орел, Дон тирәләрендә йөрергә мәҗбүр була; солдатлар кулына эләгә һәм ерак Себергә җибәрелә. Аларның нигезендә вакыйга сюжеты ятуы күрсәтелгән җырларның лирик поэзиягә караганда эпик поэзиягә якынрак торуын раслый.

Шулай да әсәрнең бу сыйфатына гына таянып, аны лирик җырлардан бөтенләй аерып карап булмый. Чөнки «Шәрук беглый», «Хәмидулла качкын» кебек җырларда геройның рухи дөньясын — кичереш-хисләрен, кайгы-хәсрәтен ачуга шактый зур урын бирелә. Димәк, әлеге әсәрләрне тарихи җыр дип билгеләү өчен, вакыйга сюжетының тарихилыгын, чынбарлыкка мөнәсәбәтен ачыкларга кирәк.

Лирик җырларның төп өлешен кичереш үсешенә, психологик сюжетка нигезләнгән әсәрләр тәшкил итсә дә, алар арасында хикәяләү элементы сизелерлек булган җырлар да бар. «Фәрүзә кыз»[1] җырында, мәсәлән, сүз яшь кызны, сөйгәненнән аерып, картка көчләп бирү турында бара. Ләкин бу, һичшиксез, лирик җыр, чөнки ул башыннан ахырына кадәр хисләр диалектикасын чагылдыра. Вакыйга исә нәкъ шул кичерешләрнең сәбәбе генә булып тора. Мондый эпизодларның тормышта булуы мөмкин, әлбәттә, һәм алар күп мәртәбәләр булгандыр да. Әмма җырда сүз тормышта булган конкрет күренеш турында түгел, ә бәлки шул заман өчен характерлы типик вакыйга турында бара. Ә «Шәрук беглый», «Хәмидулла качкын» кебек җырларның әчтәлек нигезен билгеле бер шәхеснең тормышында булган конкрет, шул ук вакытта заман өчен типик вакыйгалар тәшкил итә. Мондый җырларның геройлары турында халык телендә әле бүген дә риваятьләр, легендалар яши. Һәм бу төрле халыкларның тарихи җырларына хас төп сыйфатларның берсе. Шәрук тормышын чагылдырган легендаларга килсәк, аларда җыр героеның яшьтән үк буйсынмас рухлы кеше булуы, армиядән һәм төрмәдән качуы, урманда яшәве тасвирлана: «качкын Шәрук дуслары белән бергә алпавыт, байларның котын алып йөри, алардан талаган акчаны, мөлкәтне авыл халкына, ярлыларга өләшә. Шуңа күрә халык Шәрукка теләктәшлек күрсәтә, аны яклый һәм яшереп саклый» (И. Надиров, 406). Шәрук турындагы легендаларның әчтәлеге белән җырның сюжеты бер-берсенә гаять якын. Халык телендә шактый киң таралган риваять һәм легендаларга таянып, «Шәрук беглый», «Хәмидулла качкын» кебек җырлар чынбарлыкта булган вакыйгалар нигезендә туган, аларда билгеле роль уйнаган конкрет шәхесләр тормышы белән бәйләнгән әсәрләр дип әйтергә мөмкин. Нәкъ әнә шул үзенчәлекләре белән алар лирик җырлардан аерылып торалар да инде. Халык тормышында булган тарихи вакыйгаларны һәм конкрет шәхесләр язмышын тасвирлауга нигезләнгән мондый җырлар гомуми фольклористикада тарихи җырлар дип йөртеләләр.

Конкрет вакыйгага багышланып чыгарылган җырларның һәммәсен тарихи җыр дип булмый, әлбәттә. Саратов өлкәсе, Верхазовка авылында язып алынган «Печник Сабир» җырына тукталыйк. Җыр бер байның мәгълүматлы гына кызын икенче байның надан, мәҗнүн улына кияүгә биргәч чыгарыла. Кыз исә печник Сабирны ярата. Пристав аркылы эш итеп, кызның әтисе Сабирны авылдан кудыра (И. Надиров, 72,

[1] Татар поэзиясе антологиясе. Казан, 1956 ел. 33 бит. Алга таба исеме кыскартылып күрсәтелер.

426—427). Димәк, җыр конкрет вакыйгага нигезендә туган. Әмма бу вакыйганы тарихи дип булмый. Чөнки тарихи вакыйга дигәндә, гадәттә, халык тормышында әһәмиятле роль уйнаган иҗтимагый-политик характердагы вакыйга истә тотыла[1]. Әнә шул күзлектән караганда, тарихи җырлар рәтенә «Пугачев турында» (Антология, 28), «Салават Юлай», «Тали», «Ташкай»[2], «Япон сугышлары яман икән», «Герман сугышы» (И. Надиров, 89, 91) кебек әсәрләрне кертергә мөмкин.

Конкрет әсәрләрне алып караганда, тарихи җырларның бәетләр белән мөнәсәбәте дә шактый җиңел хәл ителә. Югарыда саналган һәм башка шундый әсәрләрнең иң зур күпчелеге җыр китапларында басылган. Аларның бәет түгел, җыр булуында шикләнүчеләр юк кебек. Тик әлеге әсәрләрнең кайберләре генә җыр дип тә, бәет дип тә йөртеләләр («Тали», «Ташкай). Димәк, бәетләр белән тарихи җырларның охшашлыкларын һәм аермаларын ачыклаганда, сүз аерым әсәрләр турында гына түгел, ә бәлки тулаем жанрлар хакында барырга тиеш. Шулай булгач, иң элек тарихи җырларның кайбер специфик үзенчәлекләренә, тематикасына һәм образлар системасына тукталып үтәргә кирәк.

* * *

Татар халык иҗатында тарихи җырларның мөстәкыйль жанр буларак яшәвен исбат итү өчен, аларның яшәү чорлары турында, гипотеза рәвешендә генә булса да, кайбер фикерләрне әйтеп үтик.

Тарихи җырларның барлыкка килүе һәм формалашуы, димәк, шигъри үзенчәлекләре эпик традицияләр белән бәйләнгән. Шул яктан караганда, себер татарларыннан язып алынган кайбер әсәрләр игътибарга лаек. В. В. Радлов материаллары арасында төрле батырларга, мәргәннәргә багышланган кечкенә күләмле шигъри әсәрләр бар: «Кырамша», «Атолы батыр», «Ак бога»[3]. Алар борынгы эпик поэмаларның өзекләре, «калдыклары» булса кирәк. Чөнки исемнәрс белән генә түгел, форма үзенчәлекләре, образлары белән дә аларга якын торган зур күләмле әсәрләр башка төрки халыклар иҗатында билгеле. Казакъ фольклорында зур күләмле мөстәкыйль эпик поэмалар формасында сакланган «Кобланды», «Камбар батыр» эпослары да В. В. Радлов заманнарында Себер татарларында аерым өзекләр формасында яшәгәннәр[4]. Безнең көннәрдә язып алынган материаллардан исә «Тәвеш мәргән» яисә «Карьят батыр»[5] җырларын күрсәтергә мөмкин. Бу әсәрләрнең тарихи нигезләре, сюжетлары турында сөйләве читен. Әмма аларның шигъри стиле шактый үзенчәлекле. «Карьят батыр»да гомумтөрки, бигрәк тә казакъ һәм кыргыз эпосларының шигъри стиленә якынлык сизелә:

Дингезнең камышында кабан ятыр,
Шул кабанны атып алды Карьят батыр.
Ике батман санай угын ингә асып,
Ат уйнатып Карьят батыр аудан кайтыр.

«Тәвеш мәргән», «Карьят батыр» кебек җырларның образлары борынгы героик эпос образларының варислары ролен үти алалар. Мондый әсәрләрне тарихи җыр дип өзеп әйтүе кыен булса да, аларны героик эпос белән тарихи җыр арасында торган шигъри бер форма, шигъри күпер дип карау, жанрның формалашу чорын ачыкларга ярдәм итә торган әсәрләр дип бәяләү дөрес булыр. Һәрхәлдә, тарихи җырларга нинди дә булса мөнәсәбәте булган, эчтәлеге һәм формасы белән халык тормышының моннан да борынгырак дәверләрен чагылдырган әсәрләр безгә билгеле түгел.

Тарихи-хронологик яктан икенче урында, безнеңчә, Пугачев җитәкчелегендәге крестьян хәрәкәте белән бәйләнгән әсәрләр тора. «Салават Юлай»да (Х. Ярми, 60) мәсәлән, тарихи җырлар өчен характерлы күп сыйфатларны төсмерләп була. Җырның

---

[1] Б. Н. Путилов. Русский историко-песенный фольклор XIII—XVI вв. Изд. АН СССР. Мәскәү. 1960 ел. 7 бит.
[2] Х. Ярми. Бәетләр. Казан. 1960 ел. 60, 76—84 битләр. Алга таба исеме кыскартылып бирелер.
[3] В. В. Радлов. Образцы народной литературы тюркских племен. Ч. IV. Наречия барабинцев, тарских, тобольских и тюменских татар. СПБ, 1872 ел, 189—191 битләр.
[4] Шунда ук. 193—195 һәм 266—268 битләр.
[5] А. Ключарев. Татар халык җырлары. Казан. 1955 ел. 131, 203 битләр.

эчтәлеге халык тормышында гаять зур роль уйнаган, азатлык өчен даими көрәшнең иң киеренке моментларыннан берсен чагылдырган иҗтимагый-политик вакыйгалар белән бәйләнгән. Әсәрнең төп герое Салават исә хезмәт ияләре азатлыгы өчен көрәштә күрсәткән батырлыклары белән халык күңелендә мәңгелек урын алган ир образы. Җыр Салаватның кулга алынуы һәм кичерешләре турында сөйли. Әсәрнең сюжетында логик эзлеклелек булмаса да, «Салават Юлай» җырын формалашып җиткән бер әсәр дип карарга мөмкин. Җырдагы кыйдурыгый, ту, екерми кебек архаик сүзләр аның борынгылыгы турында сөйли. Әсәрнең стилендә дә героик эпос традицияләре сизелә:

Кызыл гына торат кыйдурыгый,
Күтәреп кенә чапкан ту кебек.

Салават образы да эпик планда — халык батыры образы буларак гәүдәләнә. Әмма бу җырда лирик төсмерләр, геройның кайгы-хәсрәтен чагылдырган моментлар да шактый көчле яңгырый:

Әдүрнә лә тартып ук атмаенча,
Талды гына бәнем беләккәем.
Яшь йөрәккәем чыдый алмый,
Хур иттем лә сәне, әнкәем.

Халыкның бу чордагы иҗтимагый вакыйгаларга һәм тарихи шәхесләргә карашын чагылдырган әсәрләрдән «Пугачев турында» (Антология, 28) җыры игътибарга лаек. Аны да, гәрчә ул тулы булмаса да, тарихи җырлар рәтенә кертергә мөмкин. Крестьян хәрәкәтенең башында торган Пугачев образы белән бәйле булган бу әсәрнең дә стиле эпик поэзиягә якын тора:

Пугачев патшаны күрсә иде́н,
Алларыннан буй бөгеп узса идең,
Аргамак менеп, дан тотып,
Җаек яуларында йөрсә идең.

Пугачев хәрәкәтенә бәйле туган тарихи җырларның саны моның белән генә чикләнми. «Казан утлары» журналының 1967 елгы 9 нчы санында «Курган татарларының авыз иҗаты» дигән исем астында халык җырлары һәм бәетләр басылып чыкты. Материал тапшыручылар: «Бу як татарлары өчен характерлы күренеш — халыкта көйле озын җырларның бик күп булуы,— дип язалар.— Бәет, озын җыр, тарихи җыр боларда буыннан-буынга күчеп, зур ихтирам белән сакланып килә икән». Курган якларындагы тарихи җырларның тематикасы турында авторлар түбәндәгечә язалар: «Тарихи озын җырлар арасында качкыннар турында, патша властеның җәберенә әләгүчеләр һәм 1812 елгы сугышта катнашкан егетләр турындагылары өчрый».

Шундый җырларның бер мисалы рәвешендә журналда «Габидулла бәете» урнаштырылган. Әсәрдә бәет йогынтысы яхшы ук көчле. Бу аның исеменнән һәм беренче юлларыннан ук күренеп тора. Әмма язып алучылар аны җыр дип атыйлар: «барлык җырлар арасында да Курган ягы татарлары бу җырны аеруча яраталар һәм картлар арасында моны белмәгән кеше юк диярлек». Әсәрнең эчтәлегенә һәм традицион образларга гаять бай поэтикасына игътибар итсәк, язып алучылар хаклы дип әйтергә туры килә. Җырда, «Карьят батыр»дагы кебек үк, казакъ халкы эпосына хас шигъри стиль йогынтысы сизелә:

Агыйделнең аръягында җәйләгәнем,
Билләремә ефәк билбау бәйләгәнем.

Яки:

Мәскәүләрдән килгән диләр җирән кашка,
Башкаенда көмеш йөгән, бавы башка.

Җыр туган иленнән, сөйгәненнән аерылып киткән егет турында сөйли. Әсәрнең эчтәлеге Пугачев хәрәкәтенә кагылмый кебек. Әмма аны язып алучылар җыр нәкъ

әнә шул тарихи вакыйгалар нәтиҗәсендә туган дип исәплиләр һәм әсәрнең кайбер строфалары соңгы вакытта Пугачев восстаниесенә кагылышлы архив документлары арасыннан табылуы турында язалар. «Безнең уебызча, Габидулла Казан ягы егете булып, Пугачев восстаниесендә катнашкан һәм ахырдан патша хөкүмәте тарафыннан сөргенгә җибәрелгән булырга тиеш».

Татар һәм башкорт халык иҗатында таралган «Габдулла ахун кантон» (А. Ключарев, 1941, 54—55) җыры да үзенең эчтәлеге белән шул ук чорга яисә бераз гына соңрак дәвергә карый булса кирәк. Җырның тарихи нигезе, героеның прототибы шактый яхшы ачыкланган инде (А. Ключарев, 1941, 199) [1]. Әсәрдә ике сюжет сызыгы рәттән бара. Аның берсе лирик герой образы белән бәйләнгән, икенчесе Габдулла ахун образын сурәтли. Шуңа күрә җырда ике стиль — татар халкының борынгы лирик озын җырларының шигъри үзенчәлекләренә якын торган лиро-эпик стиль һәм такмаклар тезмәсен хәтерләткән сатирик стиль аралашып бара:

Иртә дә лә томан да кич тә томан,
Ник ачылмый икән дә, ай, бу томан?
Габдулла ахун бик зирәк,
Ул зирәклек ник кирәк?
Юа җыйган хатын-кызны
Кудырырга ник кирәк?

Билгеле булганча, кантон башлыгы Габдулла ахун крестьяннарны талый, бөлгенлеккә төшерә. Аның бу эшләре авыл халкының нәфрәтен уята. Шуңа күрә җырда ахун образының сатирик планда гәүдәләнүе бик табигый:

Ахун идең заманында,
Инде калдың тынычка,
Кулыңдагы таягыңны
Алыштырдың кылычка.

Үзенең сатирик характеры белән әсәр башка тарихи җырлардан аерылып тора. Ләкин аны тарихи җырлар арасындагы бердәнбер сатирик әсәр дип булмый. Шул ук рухтагы җырлардан тагы да төрле өлкәләрдә язып алынган «Касимский Ибрай»ны күрсәтергә була (Х. Ярми, 191, 364—365). Аңа карата заманында Г. Тукай болай дип язган иде: «Бу — Касим шәһәрендәге чамадан тыш мөсриф бер байга чыгарылган көй. Касимский Ибрай гулять итә-итә дә актык тунын да сата. Ахыр гомерендә бик хосранлы рәвештә вафат була. Касимский Ибрай көе шул сәбәптән чыга» [2].

Безгә мәгълүм материалларга таянып, татар халык иҗатында тарихи җырларның жанр буларак үзенә генә хас традицияләр тудыруы нигездә XIX йөзгә карый дип әйтергә мөмкин. Нәкъ әнә шул чорда Горький, Пенза, Ульяновск, Саратов өлкәләрендә һәм Мордва республикасында яшәүче татар-мишәрләр арасында һәм татар халкының башка кайбер этник төркемнәрендә качкыннар турындагы җырлар барлыкка килә.

Патша самодержавиесенең һәм җирле алпавытларның изүеннән, җәберләвеннән, рекрут һәм солдатлыктан качып урманнарда яшәү, алпавытларга, авыл байларына каршы даими көрәш алып бару татар халкы арасында шактый таралган күренеш була [3]. Шул хәрәкәтнең житәкчеләре, авыр көрәштә аеруча кыюлык күрсәткән батырлар исеме легенда һәм җыр булып халык күңелендә бүген дә яши. Югарыда без Шәрук һәм Хәмидулла турындагы җырларга тукталган идек инде. Биредә башка кайбер мисалларны алыйк.

«Хәзерге Горький өлкәсе Кызыл Октябрь районы Актүк авылында Фәйзулла Сәйфетдинов (кушаматы Тали) дигән ярлы кеше була. 1850 елларда Актүк авылының зур бае — Мизан мулла дигән кеше Талине үзе урынына солдатка җибәрү өчен наемщик итеп яллый. Ләкин Тали солдаттан кача һәм 25 ел буена беглый — качкын булып йөри. Мизан мулла һәм аның ягында булган авыл кулаклары Талине үзләренең иң курки-

---

[1] Салават Галин. Еллар һәм җырлар. Уфа. 1967 ел. 106—107 битләр (башкорт телендә).
[2] Г. Тукай. Әсәрләр. Дүрт томда. Икенче том. Казан. 1955 ел. 258 бит.
[3] ТАССР тарихы. I том. Казан. 1959 ел. 194, 202, 232, 234, 324 һәм башка битләр.

нычлы дошманнары итеп карыйлар. Чөнки ул аларга карата аяусыз була. Патша түрәләре белән берлектә Талине эзләү башлана. Тали бернично мәртәбә тотылып, җавапка тартыла, ике мәртәбә Себергә җибәрелә» (Х. Ярми, 345). Соңыннан халык арасында Тали һәм аның тормышы турында гаять матур җыр иҗат ителә (Х. Ярми, 76—80). Вакыйга сюжетына нигезләнгән бу җырның үзәк образы Тали, Шәрук һәм Хәмидулла кебек үк, кыю йөрәкле бунтарь буларак гәүдәләнә. Солдатка чакырылган чакта ук аның ниятләре ачык була:

Приемда коръән үптергәндә,
Ният кылып үптем качарга.

Тали патша чиновникларына һәм авыл кулакларына каршы көрәшә. Геройның язмышы авыр һәм катлаулы. Патша шымчылары, фискаллар аның артыннан туктаусыз күзәтү алып баралар, бернично мәртәбә тотып Себергә җибәрәләр. Ул көрәшнең нәтиҗәсезлеген дә аңлый:

Себер җирләрендә күп йөрдем,
Асла чыга алмадым күектән.

Шулай да буйсынмас рухлы Тали көрәшен туктатмый, бер сайлаган юлыннан, ул нинди генә авыр һәм куркынычлы булса да, тайпылмый. Әнә шундый сыйфатлары өчен авыл халкы Талине хөрмәт итә. Тали да авылдашларына зур ихтирам белән карый, халык тормышын җиңеләйтә алмавы өчен авыл картларыннан гафу үтенә.

Төрле вакыйгалар, эпизодлар аркылы гәүдәләнгән Тали образы да эпик поэзиядәге батырлар образына якын тора. Әмма җырда геройның кичерешләре, кайгы-хәсрәте дә шактый тулы гәүдәләнә:

Очыгыз ла, казлар, әй очыгыз,
Очалмаганыгыз кайтыгыз!
Безнең туган җиргә җитә алсагыз,
Туганнарга сәлам әйтегез.

«Тали» — тарихи җырларның төп үзенчәлекләрен берләштергән иң матур әсәрләрнең берсе.

Шул ук качкыннар циклына кергән һәм «Тали» җырына шактый якын торган әсәрләрдән тагы «Ташкай»ны күрсәтергә мөмкин (Х. Ярми, 81—84). Халык арасында таралган легендаларга караганда, Ташкай, Тали кебек үк, патша законнарына буйсынудан баш тарта, авыл байларына һәм чиновникларга каршы көрәшә, кулга алынып, Себергә җибәрелә. Аннан кайткач, Ташкайны авыл кулагы Бикчәнтәй яңадан полициягә тотып бирә. Җырның эчтәлеге әнә шундый вакыйгаларны чагылдыра.

Курган татарларыннан язып алынган «Юркәй Юныс көе»н дә шул ук циклга кертергә мөмкин. («Казан утлары» журналы, 1967 ел, 9 сан, 143 бит). Һәм моны иң элек язып алучылар сүзе раслый: «Юркәй Юныс — патша түрәләренә протест йөзеннән бер төркем татарлар белән урманга качып, гомерен качкынлыкта үткәргән кеше дип сөйлиләр». «Юркәй Юныс көе» — качкынлыкның татар халкы арасында киң таралган күренеш булуын һәм качкыннарга халыкның мөнәсәбәтен чагылдырган матур әсәрләрнең берсе:

Бара гына торгач мин утырдым,
Ала елан басып үтердем.
Килә генә китә йөри торгач,
Газиз башкаемны бетердем.

Качкыннар циклына, югарыда искә алынган җырлардан кала, «Әбделмән купец»[1], «Аким беглый», «Әхсән Голова»[2] һәм башка кайбер җырларны кертергә мөмкин.

Качкыннар җыры — халкыбызның тарихи җырлары арасында классик бер цикл тәшкил итә һәм нигездә татар-мишәрләр иҗатында очрый. Ләкин эчтәлеге һәм формасы

[1] Материалы по татарской диалектологии. Т. 2. Казань. 1962 ел. 295—297 битләр.
[2] Бу җырлар Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының фольклор фондында саклана.

белән качкыннар жырына шактый якын торган әсәрләрне татар халкының башка этник төркемнәре иҗатыннан да табып була. Шундыйлардан себер татарларының бер этник төркеме булган бараба татарларында «Бәшир солдат», «Йомышчылар җыры» кебек әсәрләр билгеле. Әмма бараба татарлары арасында әле бүген дә иң популяр һәм искиткеч матур җырлардан «Әйтүкә»не күрсәтергә кирәк [1]. Бу җырны Новосибирск өлкәсенең Бараба, Чаны, Кышлау, Венгеров, Северный районнарындагы һәрбер авылда беләләр, яратып җырлыйлар. Әйтүкә (Әйтмөхәммәт) турында халык телендә бик күп риваятьләр һәм легендалар йөри. Картларның сөйләвенә караганда, Әйтүкә XIX йөз азагында, XX йөз башында Чаны районының Тармакүл авылында бер байда батрак булып йөри. Мәһабәт гәүдәле, үткен телле, кыю йөрәкле Әйтүкә бер байның матурлыгы һәм акылы белән тирә-якта дан тоткан Фатыйма исемле кызын ярата, аны иркәләп Батыш дип атый, аңа багышлап җырлар чыгара:

Иртә дә буран, кичтә дә буран,
Тармаклы [2] буен алган да сырау [3];
Син җаныемны уйлый-уйлый,
Сау гына башым булды да сырхау.

Фатыйма да Әйтүкәне ярата. Әмма Фатыйманы бер бай алмакчы була һәм аның атасы белән килешеп, ярәшеп тә куя. Батрак Әйтүкәнең калымга түләрлек байлыгы булмый. Туй якынлаша. Ике яшьнең тирән мәхәббәте реакцион гореф-гадәтләр алдында, җимерелү куркынычы астында кала. Фатыйма белән сөйләшеп, Әйтүкә аны авылдан алып китә:

Суда ла йөзгән ак балыкның
Баласын әйтерләр колтан дип;
Акча ла бирми ярлар сөйгән,
Әйтүкәне әйтерләр солтан дип.

Туган җирдән аерылган Әйтүкә белән Фатыйма, берничә ел буена тилмереп, читтә йөриләр, казакъ далаларында, сазлык-камышлыкларда, урманнарда яшиләр. Туган як сагындыра:

Каты ла тартып уклар аттым
Кырда ла йөргән киекләргә;
Уйлап ла йөрсәм исем китә
Быел ла йәйне кәекләргә.

Әйтүкә белән Фатыйма, авыллары янына кайтып, Тармаклы күл буенда камышлыкта яшиләр. Фатыйманың бай агалары һәм пристав аларны тотып, авылга китерәләр. Әйтүкәгә җәза бирергә, чыбык белән суктырырга тиеш булалар. Бу тамашаны карарга дип мәчет алдында җыелган авыл халкы арасыннан бер карт Әйтүкәгә:

— Улым, бу хурлыктан котылу өчен синең бердәнбер чараң бар. Син бит атаклы җырчы. Җырла җырларыңны! — дип киңәш бирә. Әйтүкә үзенең авыр язмышы, саф мәхәббәте өчен күргән михнәтләре, сөйгәне Фатыйманың гүзәллеге турында җырлый. Аның җырлары шулкадәр матур, тәэсирле була ки, авыл халкы Әйтүкәне җәзадан коткаруны таләп итә, һәм Әйтүкәне суктырмыйлар. Түбәндәге өзек драматик вакыйгаларның нәк шул моментын чагылдыра:

Ул да яхшы, бу да яхшы,
Ашасың килсә, бал да яхшы.
Авыр көнне, баш киткәндә
Баш коткарган тел дә яхшы.

Легендаларга караганда, Әйтүкәнең җәза алдыннан җырлаган җырлары бүген дә халык арасында таралган һәм «Әйтүкә» нәкъ әнә шул җырлардан тора да инде...

---

[1] Биредә сүз җырның 1967 елда Новосибирск өлкәсендә язып алынган вариантлары турында бара.
[2] Тармаклы — күл исеме. Тармакүл авылының исеме дә шунын белән бәйләнгән.
[3] Сырау — көрт. Русча «сугроб» сүзеннән.

Шулай да бай агалары Фатыймага ярлы батракка кияүгә чыгарга рөхсәт итмиләр. Әйтүкә белән Фатыйма бер-берсен ничек кенә яратсалар да, аерылып яшәргә мәҗбүр булалар. Әмма аларның фаҗигале мәхәббәте, гаять матур җыр буларак, Бараба далаларында бүгек дә яши. Әйтүкә белән Фатыйма образы борынгы эпос традицияләренә нигезләнгән легендаларга кушылып китә. Шуларның берсе сөйләвенчә, Әйтүкә Фатыйманы җырләп, берничә ел үткәннән соң үлә. Аңа кабер казыганда, очраклы рәвештә Фатыйма каберенә туры киләләр. Шуннан соң картлар:

— Хакыйкый гашыйк булган болар, җир өстендә язмыш аерса да, җир астында аларга бергә булырга язган икән,— дип, аларны рәттән куялар.

Җыр персонажларның образы халык күңеленә шулкадәр тирән үтеп керә ки, Әйтүкә белән Фатыйма бараба татарлары фольклорының иң популяр геройларына әвереләләр. «Әйтүкә» көенең ике төрле варианты халык арасына киң тарала; халык телендә йөргән бөтенләй башка җырлар һәм бәетләр дә еш кына шул ук көйләргә җырланалар; туй мәҗлесләрендә махсус киемнәргә киенгән җырчылар Әйтүкә белән Фатыйманың музыкаль-драматик диалогларын башкаралар...

XIX йөздә тарихи җырларның классик үрнәкләре барлыкка килсә, гасыр азагында һәм XX йөз башында жанрның иҗади үсеше дәвам итә. Солдатлар һәм рекрутлар тормышын тасвирлаган җырларның безгә мәгълүм булганнары нәкъ әнә шуны раслый.

Рекрут һәм солдатларның авыр язмышын сурәтләгән җырларның саны аз түгел. Әмма аларның күбесе конкрет вакыйгаларга нигезләнмәгән, геройның кайгы-хәсрәтен, моң-зарын чагылдырган лирик җырлар. Андый җырлардагы образларның да конкрет прототиплары булу-булмавы билгесез: «Әнекәем, монда килсәнә», «Некрутлар җыры», «Солдат булдым» (И. Надиров, 76—79).

Шулай да солдат һәм рекрут җырларының билгеле тарихи вакыйгалар белән бәйләнгәннәрен һәм хикәяләү элементы сизелерлек булганнарын тарихи җырлар рәтенә кертергә мөмкин: «Япон сугышлары яман икән», «Әхмәт солдат җыры», «Герман сугышы» (И. Надиров, 88, 89, 91). Бу җырларның образлары бәлки конкрет прототиплар нигезендә тумагандыр да. Әмма аларның эчтәлеге чын мәгънәсендә зур тарихи вакыйгаларга нигезләнгән. Бу җырларның сюжетларында да вакыйга тасвирлау элементлары билгеле урын алган:

Әчләрем пошса, мин чыгамын
Гөлләр чәчәк аткан бакчага.
Ике күзем нуры — ялгыз балам —
Солдат булып китте патшага.

Ерак та ла ерак Порт-Артурга
Тимер юллар киткән сузылып.
Япон сугышлары яман икән,
Йөрәк маем кайтсын котылып.

Күренекле фольклорчы В. И. Чичеров фикеренчә, өйрәнелә торган жанр составына тарихи вакыйгалар һәм конкрет шәхесләр турындагы җырлар гына түгел, ә бәлки солдатларның төрле сугышларда күрсәткән батырлыкларын, хәрби көнкүрешне һәм, ниһаять, XVII—XIX гасырлардагы революцион көрәш вакыйгаларын чагылдырган җырлар да керә. Мондый әсәрләрнең кайберсе лирик һәм эпик җырларның очрашкан ноктасында тора, аларның икесенә дә хас сыйфатларны берләштерә[1]. Шул ноктадан караганда, татар халкының тарихи җырлары рәтенә тагы «Көзге ачы җилләрдә», «Бетсен патша, янсын тәхет» (И. Надиров, 92, 344) кебек әсәрләрне кертергә мөмкин. Аларның беренчесе элекке тарихи җырлар белән яңа, революцион чор җырлары арасында торган шигъри күпер ролен үти. «Бетсен патша, янсын тәхет, безгә сугыш кирәкми!» Бу политик чакыру империалистик сугышка каршы көчле көрәш авазы булып яңгырый. Шул ук идея җырның революциядән соң туган «Бетсен патша, янсын тәхет» дигән вариантында да бар. Әмма беренче вариантта ул халыкның төп максатын гәүдәләндерсә, революциядән соңгысында бөтендөнья эшчеләрен сугыш уты кабызучы-

[1] В. И. Чичеров. Исторические песни. Ленинград. 1956 ел. 13 бит.

ларга каршы көрәшкә, халык массаларының азат тормыш турындагы хыялларын тормышка ашырырга чакыру авазы булып яңгырый:

Кулдан корал ташламабыз,
Сыйнфый дошман бетмичә.

Шул ук чорда туган һәм революцион пафос белән сугарылган «Ком бураны» җыры хөр тормыш өчен көрәшкә күтәрелгән халык көчен ком бураны көченә тиңләштерә:

Ком бураны каты була,
Каты булса җил көче.
Без бураннар туздырабыз
Көрәшкәндә ил өчен.

Дөньякүләм әһәмияткә ия булган тарихи вакыйгаларны чагылдырган һәм революцион чор рухы белән сугарылган тарихи җырлар жанрның иң көчле аккорды булып торалар.

* * *

Тарихи җырларның яшәү этапларына, тематикасына һәм образларына күз йөртеп чыкканнан соң, гомуми планда жанрның специфик үзенчәлекләрен ачыкларга һәм аларның бәетләр белән охшашлыклары һәм аермасы турында югарыда куелган сорауга җавап биреп карарга мөмкин. Биредә без жанрларның чынбарлыкка эстетик мөнәсәбәтенә тагы бер мәртәбә тукталырга тиеш булабыз. Әйтелгәнчә, тарихи жанрларның эчтәлеге тарихи вакыйгалар, күбесенең образлары конкрет шәхесләр белән бәйләнгән. Шул ук сыйфат бәетләргә дә хас. Димәк, чынбарлыкка мөнәсәбәт бәетләр белән тарихи җырларны аерып карау өчен ышанычлы критерий ролен үти алмый. Нәкъ әнә шуңа күрә Н. Ф. Катанов бәетләрне тарихи җырлар дип атый, бездә тарихи җыр функциясен бәет башкара дигән тезис килеп чыга һәм әле хәзер дә кайбер җыентыкларда, хәтта мәкаләләрдә дә алар аралашып китәләр.

Шулай да мәсьәләгә якынрак килгәч, чынбарлыкка мөнәсәбәттә бәетләр белән тарихи җырлар арасында билгеле аермалар да, жанрларның үзләренә генә хас үзенчәлекләре дә барлыгы ачыклана. Г. Рәхим белән Г. Газизнең «Татар әдәбияты тарихы» исемле хезмәтендә тарихи бәетләргә махсус бүлек бирелгән[1]. Бәетләр арасыннан тарихи әсәрләрне махсус бер төркем итеп карау объектив дөреслеккә җавап бирә, чөнки алар тарихи вакыйгаларны гына түгел, тормыш-көнкүреш хәлләрен дә чагылдыралар. «Сәхибә матур», «Асрау кыз» кебек бәетләрнең дә нигезендә конкрет вакыйгалар ята булса кирәк. Әмма үзләренең характерлары белән алар тарихи вакыйгалар рәтенә керә алмыйлар. Димәк, бәетләрнең сурәтләү объекты тарихи җырларныкыннан күп мәртәбә киңрәк. Әгәр тарихи җырларның сурәтләү объекты халык тормышында әһәмиятле роль уйнаган социаль-политик характердагы вакыйгалар булса, бәетләр халык тормышының башка якларын да, гаилә мөнәсәбәтләрен, аерым кеше тормышында очраклы рәвештә, көтмәгәндә килеп чыккан фаҗигаләрне, көнкүреш хәлләрен дә чагылдыралар. Шуңа күрә бәетләр арасында конкрет вакыйгалар белән бәйләнмәгән, ә бәлки бер социаль катлауның, группаның тормышын гомуми планда сурәтләгән әсәрләр дә бар: «Ялчылар бәете», «Шахтерлар бәете», «Киленнәр бәете». Тарихи җырлар арасында исә тарихи вакыйгаларга бернинди дә мөнәсәбәте булмаган әсәрләр, безнеңчә, гомумән, юк. Шулай булгач, жанрларның тематикасында да аермалар бар. Бәетләрнең тематикасы халык тормышының бик күп якларын чагылдыра. Тарихи җырларның эчтәлеге исә, әйтелгәнчә, нигездә социаль-политик вакыйгаларны, халык вәкилләренең самодержавиегә, реакцион гореф-гадәтләргә каршы көрәшен гәүдәләндерә.

Жанрларның эмоциональ яңгырашына хас үзенчәлекләр дә аларның чынбарлыкка эстетик мөнәсәбәте белән бәйләнгән. Бәетләрнең эчтәлеге, кагыйдә буларак, трагик вакыйгаларга нигезләнә. Чит ил баскынчыларына каршы сугышларның трагик

---

[1] Г. Рәхим, Г. Газиз. Татар әдәбияты тарихы. Казан. 1925 ел. 138 бит.

моментлары, һәрвакыт диярлек уңышсыз тәмамлана торган крестьян хәрәкәтләре, солдатларның, рекрутларның, хатын-кызларның сыйнфый җәмгыять шартларындагы авыр язмышы, көндәлек тормыштагы фаҗигале күренешләр — бәетләрнең төп эчтәлеген әнә шулар тәшкил итә. «Бәет» дигәч тә күз алдына берәр фаҗига, бәхетсезлек килеп баса. Һәм бу бәхетсезлек еш кына кешенең фаҗигале, үкенечле үлеме формасында гәүдәләнә. Нәкъ әнә шуңа күрә бәетләрдә үлем образы һәм, шигъри алым буларак, үлгән кеше исеменнән сөйләү, геройның якыннары, туганнары белән бәхилләшүен күрсәткән эпизодлар гаять зур урын алган.

Тарихи җырларда да бәхетле, шатлыклы тормыш турында сөйләнми. Аларның да күпчелегендә төрле бәхетсезлекләр, кайгылы вакыйгалар сурәтләнә. Әмма бу инде бәетләргә хас трагизм түгел. Тарихи җырларда үлем образы да, төрле хәлләрне тасвирлауда натурализмга кадәр барып җиткән урыннар да юк. Көрәш рухы, бунтарьлык хисләре, батырлык эшләүгә омтылышлар тарихи җырларда бәетләргә караганда күп мәртәбә көчлерәк яңгырый. Аларның эчтәлегендә героик башлангыч беренче планда тора һәм еш кына әсәрдәге трагик мотивларны җиңеп чыга. Шуңа күрә аларның образлары да героик характердагы образлар булып яңгырыйлар. Халык телендә дә алар качкын, мәргән, батыр эпитетлары белән таралалар: Карьят батыр, Тәвеш мәргән, Ташкай батыр һ. б. Тарихи җырларның геройлары — үзләренең кыюлыклары, буйсынмас рухлары белән халык күңелендә мәңгелек урын алган көрәшчеләр. Хәтта «качкын» сүзенең дә татар телендә, бигрәк тә халык иҗаты әсәрләрендә, үзенә генә хас стилистик төсмере, буявы барлыкка килә. Гадәттә ул хокуксыз тормыштан котылу өчен көрәшкә күтәрелгән батыр, кыю йөрәкле кешегә карата кулланыла. Гомумән, социаль тигезсезлеккә каршы көрәш мотивлары тарихи җырларда гаять көчле яңгырыйлар. Батырлык, кыюлык — тарихи җыр геройларының иң зур күпчелегенә хас сыйфат. Нәкъ әнә шуңа күрә дә халыкның бу төр әсәрләрендә нигездә ир-егетләр образы гәүдәләнә. Сыйнфый җәмгыять шартларында, ислам диненең реакцион гореф-гадәтләре хөкем сөргән чорда, татар хатын-кызларының язмышы аеруча авыр, еш кына фаҗигале була. Аларның тормышы белән бәетләрнең эчтәлеге арасында билгеле аваздашлык барлыкка килә. Хатын-кыз образы бәет жанрының төп образларыннан берсе булып әверелә. Тарихи җырларда исә ул сирәк очрый һәм тик аерым әсәрләрдә генә чагыла.

Фольклор жанры буларак, бәетләр халык иҗаты традицияләренә генә түгел, ә бәлки кулъязма һәм язма әдәбият традицияләренә дә нигезләнәләр һәм күп очракларда язма төрдә барлыкка килеп, халыкка дәфтәр-китаплар аркылы таралалар. Күп кенә бәетләрнең стиле китап теленә гаять якын тора:

Сәнә сиксән бишендә, хут аенда
Бәлалар чикте ил, язйым шуны да.
Галимнәрне галим дип белмәделәр,
Ятимнәргә тәрәххем кылмадылар.
*(«Кади бәете»).*

Тарихи җырлар исә тулысынча халык иҗаты, бигрәк тә борынгы дастаннар һәм лирик җырлар традицияләренә нигезләнәләр. Мәсәлән, «Ташкай»да героик эпос традицияләре шактый көчле:

Ташкай кебек батыр юк иде,
Җәялардән чыккан ук иде.

Ташкай борынгы эпос батырлары кебек күп санлы дошманнарга каршы ялгызы көрәшә:

Парша белән Бозлау арасында
Көлтә кебек солдат тезелгән.

Әмма әгәр батырлар эпосында герой күп санлы дошманны ялгыз җиңеп чыга торган булса, тарихи җыр бу яктан реаль чынбарлыкка якынрак тора һәм Ташкай батырның кулга алынуын сурәтли:

Бирелмәс тә идем Әбүзәргә,
Унау бәйләнделәр үземә.

Тарихи җырларда геройларның азатлык өчен көрәштә күрсәткән батырлыклары гына сурәтләнеп калмый. Халыкка турылыклы булу, туган илгә мәхәббәт геройларның күркәм сыйфатлары булып торалар. Качкыннар циклына кергән җырларның геройлары, мәсәлән, туган җирләрен сагынып, төрле авырлыклар аша, Себер киңлекләрен, суларны, елгаларны кичеп, кара урманнарны үтеп, ерак җирләрдән илләренә ашкыналар. Туган якларга кайту юлларының авырлыгы героик эпос традицияләренә хас алымнар белән сурәтләнә:

Ун мең чакрымнан качып килəм,
Казык йолдыз минем юлдашым.
(«Ташкай»).

Төннәр уртасында диңгез кичәм,
Рушан йолдыз минем юл гынам.
(«Хәмидулла качкын»).

Тарихи җырларда киң таралган мондый алымнар аларның эпик яңгырашын көчәйтә:

Тавышларым минем таулар яра,
Ишетелми микән авылга.
(«Юркәй Юныс көе»).

Героик эпос традицияләре белән бәйләнгән арттырулар (гиперболизация), борынгы дастаннар өчен характерлы булган җиде, җитмеш җиде, сиксән кебек эпик саннар, уртак урыннар тарихи җырларда еш очрый һәм аларда эпик әсәрләр йогынтысы шактый көчле булуы турында сөйли. Саналган алымнарның һәркайсына мисаллар табуны укучы ихтыярына калдырып, уртак урыннардан бер үрнәк китерик:

Озын гына көнне, кыска төнне,
Кортлар бал ташыйлар муртага.
Кара урманнарда йоклаганда,
Сиксән солдат алды уртага.

Бу строфа аерым вариацияләр белән «Тали», «Шәрук беглый», «Хәмидулла качкын» шикелле җырларда очрый.

Бәетләрдә еш кына традицион башлану («Бисмиллаһи вә билләһи...» яисә «Тарих мең дә сигез йөз дә...») һәм туганнар, дуслар белән бәхилләшү формасында әйтелгән бетемнәрне очратабыз («Мине белгән... бәхил булсын барчасы»). Тарихи җырларда мондый алымнар юк. Аның каравы, аларда татар халкының лирик поэзиясендә киң таралган шигъри алымнар гаять еш очрыйлар. Мәсәлән, качкыннар тормышын сурәтләгәндә кулланыла торган Себер җирләре, Себер сәхраләре, кара урман, ачы буран кебек образлар геройларның авыр язмышын чагылдыралар. Аларның ялгызлыгы табигать дөньясыннан алынган шигъри янәшәлекләр белән сурәтләнә.

Кыйгак та гына кыйгак каз кычкыра —
Адашкан киек казның баласы.
. . . . . . . . . . . . . .
Үле дә генә үрдәк әй үендә,
Үсез үрдәк йөри күлендә.
(«Тали»).

Гаять үзенчәлекле поэтикасы нигезендә тарихи җырлар — татар халык иҗатының мөстәкыйль бер жанры дип әйтергә мөмкин.

Бәетләр белән тарихи җырларның бер-берсеннән шактый аерылып торган жанрлар булуын аларның төрле этник төркемнәр фольклорында сакланып килүе дә раслый. Ш. Мәрҗанинең Болгар дәверендә «Шәһре Болгар газыйлары» һәм «Нәүрүз бәетләре» булуы турында язуына, бернičә мәртәбә басылып чыккан «Казан тарихы», «Ханәкә Солтан бәете» кебек борынгы әсәрләргә караганда, бәетләр Идел буе татарлары иҗатында бик күптәннән бирле яшәп киләләр. Бу традицияләрнең чыганагы Болгар

культурасы белән бәйле булса кирәк. Бәетләрнең язма әдәбиятка якын торуы һәм татар эпосының бик борынгы жанрларыннан булуы да шуны раслый кебек. Күрәсең, бәетләр Болгар җирлегендә барлыкка килеп һәм формалашу дәверен кичереп, Казан дәүләте чорында камилләшкән бер жанр булып әверелә. Тора-бара алар татар халкының башка этник төркемнәренә: мишәрләргә, Урал, Себер якларында яшәүче татарларга таралып, гомумтатар фольклорына хас жанр булып китәләр. Тарихи җырлар исә нигездә Себер, Көньяк Урал, бигрәк тә мишәр-татарлар иҗаты өчен характерлы жанр.

Шулай да, халык иҗатының аерым жанрлары арасында үтмәс чик юк. Героик эпос традицияләрен дәвам итүе, эчтәлекләренең чынбарлыкка мөнәсәбәте, конкрет вакыйгага нигезләнгән сюжетлары белән тарихи җырлар бәетләргә, бигрәк тә тарихи бәетләргә шактый якын торалар. Әмма жанрга хас көчле лиризм аларны лирик җырларга якынайта. Җырны, гомумән, лирикасыз күз алдына китереп булмый. Халык эпосының дастан кебек борынгы формаларын һәм тарихи бәетләрне поэзиянең эпик төрләре дип, халык җырларын лирик поэзия дисәк, тарихи җырлар — әнә шуларның икесенә дә хас үзенчәлекләрне берләштергән лиро-эпик әсәрләр. Тарихи җыр мәсьәләсенең бездә аннан-моннан гына өйрәнелүенең сәбәбе дә жанрның катлаулылыгы, спецификасының төрле жанрларга хас үзенчәлекләрне оригиналь формада берләштерүе нәтиҗәсендә барлыкка килүе белән бәйләнгән.

* * *

Соңгы елларда Горький, Куйбышев, Ульяновск өлкәләрендә, Мордва республикасында, Новосибирк, Курган, Омск якларында һәм башка җирләрдә татар халкының тарихи-эпик фольклорына караган бик әһәмиятле әсәрләр язып алынды. Менә бу факт халкыбызның төрле этник төркемнәренә хас әсәрләрне ныклап җыю һәм тикшерү дәвамында тарихи җырларга караган материалларның күләме киңәер һәм гипотеза рәвешендә әйтелгән кайбер фикерләр дә расланыр дип уйларга мөмкинлек бирә. Хәзергә исә, безнеңчә, бер нәрсә бәхәссез: татар халык иҗатында тарихи җырлар, хәтта аларның классик үрнәкләре дә бар. Һәм алар халык иҗатының аерылгысыз бер өлеше булып торалар.

# КҮПНЕ БИРСӘҢ, КҮПНЕ АЛАСЫҢ

*Татарстан нефтьчеләре узган чирек гасыр дәверендә бик күп мәртәбәләр бөтен ил алдында дан яуладылар, зур уңышларга ирештеләр. Иң кыю инженер фикерләүләр, таң калдырырдай рекордлар — Татарстан дигән шул төбәктә туды. Республикабызны бик хаклы рәвештә илнең зур нефть чыгару лабораториясе дип йөрттәләр. Ватанның «кара алтын» җитештерү тарихына бик күп шөһрәтле яңа юллар язды безнең нефтьчеләр.*

*Ләкин әле Татарстан нефте барысы тик яңа рекордлар, тәвәккәл техник казанышлар һәм җир катламыннан өскә кудырылган миллионнарча тонна ягулык белән генә чикләнми. Ул шулай ук Идел — Урал табигате киңлекләренең өр-яңадан үзгәрүе генә дә түгел. Татарстан нефте төшенчәсе иң элек безнең күз алдына чиксез батырлык, олы фидакарьлек белән аерылып торган кешеләрне китереп бастыра. Чирек гасыр дәверендә резервуарларга тутырылган нефть күләме генә артмады, бу вакыт эчендә бездә бик әйбәт һөнәр ияләре, үз эшләренең җәүһәре булган нефть осталары үсеп чыктылар. Илнең иң атаклы нефтьчеләре сафында татар халкы вәкилләренең дә лаеклы урын алулары аеруча әһәмиятле факт. Р. Мингәрәев, К. Вәлиев, Г. Вахитов, А. Гимазов, А. Вәлиханов һәм башка бик күпләрнең исемнәре хәзер илдә бик күпләргә таныш. Болар — бертуктаусыз иҗади эзләнү юлына баскан, үз-үзләренә таләпчәнлек белән аерылып торучы һәм чын-чыннан эш сөюче кешеләр. Аларның төп сыйфатлары — Ватанга фидакарь хезмәт итү. Алар тормышы — һәр намус иясе өчен олы үрнәк.*

*Әлмәт шәһәренең Ленин урамында нефть чыгару мастеры З и н н ә т а г а Ш ә р и ф у л л и н яши. Татарстан җирендә беренче вышкалар күренә башлауга, үз язмышын шушы яңа эшкә багышлаган кеше ул Зиннәт ага. Ул хәзер республиканың атаклы нефтьчесе, Социалистик Хезмәт Герое дигән мактаулы исемгә лаек булган кеше. Зиннәт ага Шәрифуллин җитәкчелек иткән бүлекчә — «Елховнефть» идарәсендә иң алдынгылардан исәпләнә.*

*Зиннәт ага үз эшенең остасы, олы һөнәр иясе генә түгел. Ул тормышта бик киң карашлы, рухи омтылышлары гаять колачлы кеше. Журнал редакциясенең үтенүе буенча күптән түгел аның белән «Комсомольская Правда» газетасының махсус хәбәрчесе Жан Миндубаев очрашты. Бу очрашуда Зиннәт абый җәмгыять һәм аерым шәхес үсеше хакында уйлануллары белән уртаклашты. Сүзне Хезмәт Герое Зиннәт ага Шәрифуллинның үзенә бирик.*

**Күптән түгел булып узган бер җыелышны искә төшерәм. Унтугыз яшьлек егетнең үз-үзен тотышы, прогул ясаулары, начар эшләве тикшерелде анда. Бик күп хак сүзләр сөйләнде. Соңында егет — чын күңелдәндерме, юктырмы — тәртибен үзгәртергә сүз бирде. Җыелыштан таралышкан арада кемдер шунда, ишек катында:**

**— Чынын әйт әле, Сережа, ни сәбәпле син һәр атнаның дүрт көнендә эшкә соңлап киләсең! — дип сорап куйды.**

**— Гудок юклыктан...— диде Сережа.— Гудок гүелдәп торса, шәт, соңламас идем...**

Егетнең җавабы менә таңга калдырды. Билгеле, егет бу сүзләрне ихлас күңелдән әйтте. Бәлки, дөрестән дә, һәр иртәдә кала күгеп яңгыратып гудок гүләсә, Сережа да эшкә вакытында җитешер иде. Ләкин аңлыймы соң ул безнең бабалар өчен гудокның нәрсә булганлыгын! Гүелдәп күк ярган гудок тавышының надсмотрщиклар кычкырыны белән тиң яңгыравын беләме ул!

А. М. Горькийның «Ана» романын хәтерегезгә төшерегез. Җиргә сеңеп, тыгызланып утырган эшчеләр бистәсе... Үкереп, кара таңны ярып улаучы гудок тавышы. Шул куркыныч тавышка уянып, бер кабым икмәк өчен көчләрен, кан һәм җаннарын сатарга дип, корымлы фабрикалар ягына ашыгучы ярым ач, таушалган чырайлы кешеләрне күз алдыгызга китерегез. Ни чаклы дәһшәт тупланган шул әче гудок авазына!

Бабаларыбыз өчен гудок тавышы ирексезләү, көчләү символы булып калган. Октябрь революциясеннән соң кайбер предприятиеләрдә гудок авазын бөтенләй бетерү — фәкать тынлык яратудан гына түгел. Социаль хәрәкәт бу, элеккеге көчләү һәм куркыту дисциплинасыннан азат ителеп, бүгенге, ирекле дисциплинага күчү хәрәкәте иде бу. Яңа дисциплинаның нигезендә яңа символ — үз өстеңә йөкләнгән эш өчен җаваплылык, үз ватанында хуҗа булып калган эшче сыйныфының шәхси дәрәҗә хисе ята.

Мәскәү шәһәре коммунистлары конференциясендә ясаган чыгышында иптәш Л. И. Брежнев: «Фәкать үз хезмәтеңә карата аңлы мөнәсәбәттә булу, партия эшенә, коммунизм идеалларына тирәнтен бирелгәнлек кенә совет хезмәткәренең идея ягыннан җитлеккән булуын билгели»,— дип, бик нигезле әйткән иде.

Озаккарак сузылган кереш сүз миңа әңгәмәмне ачыграк итеп аңлатып бирү өчен кирәк булды. Ә минем әйтәсе фикерем беренче карашка гап-гади мәсьәлә булып тоелган хезмәт дисциплинасы хакында. һәм бу сөйләшү иң элек яшь буын өчен булыр...

Бәлкем, бу кайберәүләргә ошамас та. «Янә шул... Берәр кызыклырак хәл хакында сөйләр сүзең юкмыни!» — диячәр андыйлар. Әмма, минем үз уемча, хезмәт дисциплинасы турында сөйләшү бик кирәк. Бик кирәк. Әле күпме кеше бездә үз эшенә сүрән карый. Юк-бар сәбәп белән дә эшкә чыкмый кала. Ник алай дисәң: «Абыем кайткан иде, чыгасым килмәде»... дип, гап-гади аклануучылар да шактый. «Аның ни гаебе бар!» — диләр кебек андый кешеләр, бер дә аңламагандай.

Ачыктан-ачык әйткәндә, менә шушындый караш бигрәк тә гаҗәпләндерә. Андый карашта яшәгән кеше, димәк, хезмәт дисциплинасы хакында гына түгел,— җәмгыять тормышы, яшәү мәгънәсе хакында да беркайчан да уйланмаган була. Үзенең шәхси тормышы, тәкъдире хакында да бервакытта да чын-чынлап кайгыртмый булып чыга. Андый кеше әле вакытында эшкә килү дигән гап-гади төшенчә белән чиксез зур мәгънә — ничек яшәү мәгънәсе арасындагы уртаклыкны төшенми. Ә ул уртаклык — һәр адымда, һәр эштә максатка юнәлгәнлек, тупланганлык һәм тормышта, гади көнкүрештә чын кеше булып кала белү. һәм ул төшенчәләр һәрчак янәшә, бергә булдылар, бергә булып калачаклар да. Бары тик моны аңламаган, белмәгән кешеләр генә: «Әле бит эш көне дә бар», дип искә алу өчен гудок-будильникларга, мәҗбүр итүләргә мохтаҗлык тоялар.

Фикеремне куәтләп әйтәм: без яшәгән җәмгыятьнең дикъкате хәзер производствоны үстерү һәм планлаштыру эшләрен камилләштерүгә юнәлтелгән. Әлбәттә, бу — безнең бик зурдан үсеп киткән, киң-киң тармакларга җәелгән халык хуҗалыгыбызның көн тәртибендә торган беренче бурычы һәм, әйтер идем, катгый таләбе. Әмма кайберәүләр хәзер башкарыла торган яңа экономик реформаны бар бәладән бердәнбер котылу чарасы дип карыйлар. Коллективларда производствоның бүгенге торышы, экономик чаралар һәрьяклап тикшерелә. Тик, тыңлап, торсаң, әле без күп очракта хезмәт дисциплинасына әһәмият бирел җиткермибез шикелле. Яңа экономик реформа безне намуслы хезмәт итүдән, бар белгәнен түләем үз эшенә бирүдән азат итми бит! Эш ритмы, эш тәртипләренә вөҗдансыз караучыларны да кичерми ул. Киресенчә, без үскән, алга киткән саен, ил хуҗалыгы катлауланган саен, үз хезмәтләрен теләр-теләмәс, эленке-салынкы гына башкаручылар, прогулчылар безгә күбрәк зыян китерәчәк. Ялкаулык, хезмәт сөймәүчәнлек — безнең алда зур киртә, алга баруыбызга комачаулаучы иң төп сәбәп ул.

Татарстанның нефть ятмаларын үзләштерүнең беренче, авыр елларын хәтерлим. Эш ысуллары бүгенге белән чагыштырмасыз кыен: юллар начар, механизмнар юк, электр энергиясе җитешми иде. Нефть үткәрү траншеяларының барысы да, күп көч сарыф итеп, көрәкләр белән казыла. Яңгырлар... Суыклар... Икешәр тәүлек өйләргә кайтмыйбыз — эш күп, ә вакыт санаулы иде. Шуңа да карамастан, яшь-яшь нефтьчеләр чиксез тырышып, онытылып, янып-ярсып эшлиләр. Авыр димиләр. Чөнки һәркем белә: башкача мөмкин дә түгел, башкача уйларга да ярамый. Хәзерге яңа шәһәрләрнең якты урамнары, бакчалар, киң-иркен мәйданнар һәм культура сарайлары, яңа, җылы квартиралар — болар бары да минем яшьтәшләрем, беренче нефтьчеләрнең намуслы хезмәте нәтиҗәсе.

Менә кемнәрдән өйрәнергә, үрнәк алырга кирәк!

Киеренке, иҗади табышларга бай хезмәт кенә безне алга, ил муллыгына илтәчәк, дисәм, арттырып әйтү булмастыр дип уйлыйм. Бердәмлек көчебез дә, дәүләтебезнең ныклыгы да шунда безнең. Җәмгыять нәкъ шул нигездә һәр совет гражданының хезмәт хокукын билгеләү законнарынраслады.

Без, «кара алтын» хәзинәсен ил кулына тапшыручылар, һәрчак җылы өйләребездән дистәләгән чакрым ераклыкларда, ачык һавада эшләүчеләр, әйтергә кирәк, үзебезнең өлешкә төшкән шактый авыр хезмәтне намус белән башкарып килүчеләр — бердәмлек, бөек таләпчәнлек көчен, аның кирәклеген бик яхшы тоябыз.

Әгәр дә безнең билгеле уңышларыбызның сәбәпләрен эзли китсәң, шактый кыска гомер эчендә ватанга йөзләгән миллион тонна «кара алтын» бирелгән, әлбәттә, бердәмлек, эшче намуслыгы үрнәкләрендә, коллектив җаваплылыкны да, хезмәт дисциплинасының уңай торышын да табар идең. Болар — безнең җиңүләребезнең нигезе. Шул көчкә таянып Татарстан нефтьчеләре илдә 300 миллион тонна нефть җитештерү өчен ярышка кушылдылар.

Бүген күтәрелгән мәсьәләнең икенче мөһим ягы да бар. Кайчакта без, үз эшеңне намус белән үтәү хакында сүз алып барганда, берьяклырак сөйлибез. Сүз намуслы, максатлы хезмәтнең кешенең эчке дөньясына, шәхси хасиятенә йогынтысы турында һәм, ниһаять, аның омтылыш-уңышларына ирешү өчен дә бик әһәмиятле булуы хакында бара. Ә бит борынгы Рим укымышлылары: «Бәхет хезмәткә тиң»,— дия торган булганнар. Бу әйтем бүген дә искермәгән. Үз-үзенә таләпчәнлек, эш сөючәнлеккә кешелек дөньясы һәрвакыт иң югары бәя бирә килде. Һәм, киресенчә, эчке оешканлыкка ия булып җитлекмәгән таркау кеше һәрчак аяныч хәл кичерде.

Әле генә мәктәп тәмамлап эшли башлаган кайбер яшьләр хезмәткә сүлпән тотыналар икән — бу хәлдән аның иптәшләренә дә, производствога да начар. Һәм аның үзе өчен дә бик шәптән түгел. Аны тиргиләр, җәзага тартулары бар, премиясез калдыралар. Гадәттә андый кеше «яшь әле мин. Эшләп туярмын әле» дип юана. Ә кайберәүләр: «Җәмгыятькә азрак бирсәм, үземә өлешләрәк калыр»,— дип тә уйлый. Нинди беркатлылык! Юк шул, тормыш законы эшне башкачарак хәл итә: күпне биргән генә күпне алырга хаклы! Һөнәр үзенчәлекләрен тирәнтен өйрәнмәгәндә, иренгәндә, мәртәбәгә ирешеп булмый.

Язучыларны, көненә кимендә өч-дүрт сәгать өстәл артына утырып эшләргә тиеш, шул очракта гына ул язучы була ала, диләр. Ә бит әле ул уйланырга, тормышны бертуктаусыз өйрәнергә, укырга да тиеш. Ә аның хезмәт дисциплинасын даими тикшерүче дә, гудок биреп, куалап торучы да юк. Аңа аның үз аңы, даими эшләү ихтыяҗы тынгы бирми. Һәркемдә, һәр хезмәткә менә шушындый ихтыяҗ булдыру өчен безнең һәркайсыбыз көрәшергә, шуларны үзендә булдырырга тырышырга тиеш. Әгәр дә коры үгетләү, бары тик хезмәт законнарын куллану юлы белән генә барсак, без моңа ирешә алмаячакбыз. Яшьләргә хезмәтнең матурлыгын, масштаб-киңлекләрен күрсәтә белергә, һәркемнең үз көчен сынарга мөмкинлекләр тудырырга кирәк.

Урындагы комсомол комитетларының күпчелеге яшьләрнең даими укуын, һөнәр төрләре буенча ярышу, көч сынашуларын, аерым хезмәт бәйрәмнәрен яхшы үрнәк булсын дигән принциптан чыгып оештыруы бик кирәкле һәм бик әһәмиятле эш. Кайбер очракларда комсомол яшьләр, комсомол эшендәге иптәшләр бары бер як — күңел ачу кичәләрен оештыру, шул өлкәдә эзләнүләр белән генә үзләрен чиклиләр. Һәм күп җыелышларда төп мәсьәлә — хезмәт сөю, яхшы эшләү, дисциплина мәсьәләләре

каралмый. Әйтерсең, яшьләрнең барысы да бер тигез эшли, араларында ялкаураклары да, тормыш-хезмәткә җиңел караучылары да юк. Яшьләр арасында хәтта бик ялгыш бер караш та яшәп килә кебек әле: кем дә кем начар эшли икән — эше күңеленә ятмый, ошамыйдыр, диләр. Әйтерсең, эшли башлауга һөнәр үзеннән-үзе ачылырга, тир түкми, төрле яклап, төрлечә тотынып карамый гына яуланырга тиеш. Бигрәк тә күңел бирми торып... Ә ихтыяр көче кая! Зур тормыш юлы һәрчак киртәлә була бит.

Олыларга, хезмәт осталары өлешенә, безнең өлешкә дә эш җитәрлек бу өлкәдә. Үз хезмәтен яратып, белеп башкаручы һәркем киләчәк буынга туктаусыз ярдәм итәргә, үз юлларына чыгарга булышырга тиешле, минемчә. Безнең Әлмәттә мактаулы нефть чыгару остасы Корбан ага Вәлиев яши. Аның үзенең бервакытта да эшкә соңлап килүен дә, эшен килде-китте генә башкаруын да, кемгә дә булса ярдәм кирәк булганда, ярдәмләшми калуын да күрүче-хәтерләүче юктыр. Хәзер инде ул пенсиядә. Ләкин әле дә, кая гына барма, кайсы гына бригадага юлыкма, син аның яхшы эшен, үрнәген күреп, сокланып китәсең. Участок саен аның шәкертләре эшлиләр. Ничәмә буынга ул остаз да, ярдәмче дә, үрнәк тә булып килә алды, ничәмә-ничә кешене чын кеше итте! Минемчә, һәркем шулай, үзе яхшы эшләү белән генә канәгатьләнмәскә, бар белгәнен эстафета итеп башкаларга тапшырырга, көндәлек хезмәтнең кадерен белү серләре белән уртаклашырга, дигән хисләр белән яшәргә тиеш.

Хезмәт — кешенең җир йөзендәге иң мактаулы һәм шул ук вакытта иң җаваплы бурычы булуын онытырга ярамый.

Безнең адымнар көннән-көн ашкынулырак. Җәмгыятьнең һәркемгә булган таләбе көннән-көн югарырак, катгыйрак. Кешелек дөньясы үз-үзен тагын да тирәнтенрәк аңларга омтылып яши. Бүген минем сөйләгәннәрем, бәлки, зур ачыш та, яңалык та түгелдер. Әмма кабатлап әйтүдән дөреслек бозылмый диләр бит. Җир йөзенең иң мөһим хакыйкате исә үзгәрешсез: кешене чын кеше итүче бары хезмәт. һәм хезмәт белән генә җәмгыять бәхетле яши ала.

Гомәр Бәширов

# «ГӨЛҖАМАЛ» КАЙСЫ ЯК КЫЗЫ?

Каяндыр, әллә күктән, әллә җирдән, диңгез дулкыннары кебек салмак кына күтәрелә-төшә, «Гөлҗамал» җыры ишетелә. Мин бу җырны бервакытта да тыныч кына тыңлый алмыйм. Нәрсәдә аның көче? Ничек ул күңелләрне шулкадәр әсир итә? Ул халыкның рухи дөньясына, халык күңеленең иң эчкәргесеннән кайнап чыккан катлаулы хисләр дөньясына алып керә. Минемчә, аның тәэсир көче шунда. Беренче тыңлауга гади генә кебек ишетелсә дә, «Гөлҗамал» башка күп кенә көйләрдән үзенең затлылыгы, моңга байлыгы белән аерыла. Халык үзе иҗат иткән күңел җәүһәрләре арасында, ихтимал, бу иң талантлы көйләрнең берседер, җырларның энҗесе, иң нәфиседер. «Иске кара урман», «Әллүки», «Зиләйлүк», «Сибелә чәчәк» кебек җырлар белән бергә, «Гөлҗамал», минемчә, татар халкының гасырлар буена һаман үсә һәм камилләшә килгән күп яклы музыкаль талантының матур бер үрнәге, аның гүзәл җимешләреннән берсе. Эстетик ләззәт бирүе ягыннан мин бу көйне иң танылган операларның мәшһүр арияларына тиңләр идем.

Бу көй хезмәт кешеләренә багышлап чыгарылган булырга тиеш. Аның сүзләре дә шуны искәртәләр:

> **Шәмдәлләрдә генә утлар яна, Гөлҗамал,**
> **Җиткән кызлар киндер җеп эрлиләр...**

Әгәр җырда, чыннан да, җеп эрләп утыручы кызлар күздә тотылса, билгеле, шәм яки чыра яктысында аларның өйләре дә караңгы, эшләре дә ялыктыргыч булгандыр. Хәер, нидәндер канәгать булып җитмәү, беркадәр моңсулык көйнең үзендә дә сизелә. Шулай да мин әле моны, «Казан утлары» журналында басылып чыккан истәлектә [1] әйтелгәнчә, зарлану димәс идем. Болай дип раслау бу көйнең эчтәлеген чиктән тыш тарайтып, үтә гадиләштереп, бер яклы гына аңлауга илтә торгандыр. Бу хакта уйлашырга кирәк. Бездә әнә шул «Гөлҗамал» кебек бай эчтәлекле, моңлы, озын көйләр турында сүз кузгалса, аларның тыңлаучыга нинди эстетик ләззәт бирүе, аңа нинди рәхәт минутлар бүләк итүе белән исәпләшеп тормастан, һәммәсенә дә диярлек «кайгы-хәсрәт җыры» дигән мөһер басарга әзер торалар. Дөрес, борынгы җырлар арасында моңсулары аз түгел. Күрәсең, ул җырлар чыккан вакытта заманасы шулай булгандыр. Ләкин мин аларны күз яше түгүче, зарланып иңрәүче елак җырлар дип әйтә алмас идем. Төшенкелек, өметсезлек аһәңнәре гомумән халык җырларына хас сыйфат түгел. Рус халык җырларына карата М. Горький да шул ук фикерне әйтә. Күрәсең, бу халыкның түземлелеген, нинди генә авыр заманнарда да төшенкелеккә бирелмичә, үзен җәберләүче залимнәр алдында горур башын имичә, көрәшелек дәрәҗәсен югары тотуын чагылдыра торгандыр.

Инде моң, моңаю, моңсу дигән сүзләрнең үзләрен аңлауга килгәндә, моң бит ул зарлану да, кайгы-хәсрәт чигү дә, өзгәләнү, иңрәү дә түгел. Мәгълүм ки, табигатьнең

---

[1] «Казан утлары» журналы, 1968 ел. 6 сан.

гүзәллеген аңлаучы һәм аны сөюче нечкә күңелле кешене сандугач сайравы белән күке кычкыруы да, челтерәп аккан чишмә тавышы да, алсуланып таң беленеп килүе дә, хәтта кызгылт-сары япанчасын бөркәнгән көзге урман да моңландыра. Әйе, кеше моңая, бер мәлгә аның тел белән әйтеп булмастай иң нечкә күңел кыллары тибрәнеп ала, йөрәге сулкылдап куя, хәтта кайберәүләрнең керфек төпләре дә дымланып өлгерә. Ләкин бу зарлану да, елаклык та, кайгы-хәсрәт тә, кайберәүләр уйлаганча, төшенкелеккә бирелү дә түгел. Юк! Бу нормаль кешеләрнең гади бер кичереше, кояшлы яңгыр кебегрәк бер күренеш. Бу — туган якларыңа, халкыңа, үзеңне әйләндереп алган табигатькә, якын кешеңә булган зур мәхәббәтнең әеруча бер нечкәреп дулкынланып алу моменты. Мондый минутларда кешенең күңеле вак-төяк тормыш ыгы-зыгысыннан бушанып, үзенә бер төрле пакьләнеп һәм сафланып кала түгелме соң? Әгәр дөньяда берничә дә күңеле нечкәрми, беркайчан да дулкынланмый һәм моңаймый торган таш бәгырьле кешеләр генә калса, тормыш ифрат та җансыз һәм күңелсез булыр иде. «Гөлҗамал» җыры да күңелләрдә әнә шундый рәхәт дулкыннар уята. Бу көйне тыңлаганда кеше рухының бөеклеге, аның яктыга, бәхеткә омтылуы сокландыра. Син үзеңне вак-төяк борчуларыңнан арынган итеп, ниндидер саф хисләр дөньясында итеп сизәсең.

Минемчә, «Гөлҗамал» көе мәхәббәт дәрте канатында шулай яхшы җырлар дәрәҗәсенә күтәрелгән булса кирәк. Тормышның теләсә кайсы ягын да үзенә буйсындырырга, караңгы төнне дә якты нур белән балкытырга сәләтле булган яшьлек мәхәббәте бу көйгә ялкынлы илһам сулышы өргән, аны зарлануылардан югары күтәреп, өмет чаткылары белән яктырткан. Дөрес, җырның кушымтасы, кызларга хас тыйнаклык белән, ул хакта башкачарак әйтә әйтүен:

**Энҗе дә мәрҗән кызларның кулбавы,**
**Авыр җан сөйгәннәрнең булмавы...**

Ләкин булачак ул җан сөйгәннәр, тәгаен булачак! Тик күңелне генә төшермәскә, рухыңны гына әнә шулай бай, иркен тотарга кирәк. Гөлҗамал исемле кызга киңәш итә-итә, иң нечкә тойгыларны уята-уята, басынкы һәм тыйнак бер дәрт белән менә нәрсә хакында көйли бу җыр!

Хәер, мин бу карашымны һич тә бәхәс итеп күтәрмим, фәкать шулай гына, башкача булуы һич мөмкин түгел дип кистереп тә салмыйм. Мин музыка белгече түгел, бу көйне үземнең ничек аңлавымны гына язам. Музыканың һәйбәт бер үзенчәлеге, мәгънә тирәнлегенең әһәмияте шунда ки, аны һәркем үзенчә аңлый, аннан һәркем үзенчә ләззәт ала.

Халык җырларының зарланудан, төшенкелеккә бирелүдән югары торуларына башка мисаллар да китерергә мөмкин. Сез иң сөелеп җырлана торган җырлардан, мәсәлән, «Иске кара урман»ның сүзләренә, ул сүзләрнең ничек җырлануына колак салыгыз. Бигрәк тә беренче юлларына:

**Кара да гынай урман, караңгы төн...**

Ишетәсезме? Төн караңгысы басып яткан кара урман эченнән нинди үзәк өзгеч авыр моң, нинди дәһшәтле ялгызлык аһәңе бәреп чыга. Син үзеңне чыннан да шомлы кара урман эчендә кебек хис итә башлыйсың һәм әсәрләнеп сагаеп каласың. Шунда ук төшенәсең: кара урманны гына түгел, бәлки бөтен халык тормышын авыр караңгылык баскан икән бит. Халыкның исемсез композиторы һәм талантлы шагыйре шушы хәлне, кара урманның караңгы төне белән чагыштырып, музыка теле белән тетрәткеч бер образ итеп күз алдыбызга китереп бастыра. Шулай да бу җырның сүзләрендә дә, көендә дә өметсезлек зары ишетмисең. Чөнки «заманалар авыр, еллар ябык» булса да, халык күңелен төшерми, ул оптимист. Халык бу кыенлыкны җиңеп чыгарга өметләнә. Кара урманны үтәргә яхшы атлар кирәк булган кебек, авыр тормышны да дуслар белән бергәләп җиңәргә кирәк, ягъни бер сүздә булырга кирәк, ди.

Билгеле, «Гөлҗамал»ның, әлеге истәлектә язылганча, музыка һәвәскәре Хәмит Таһиров тарафыннан үз вакытында язып алынуы, шуның нәтиҗәсендә аның зур музыка дөньясына килеп кушылуы, һичшиксез, һәртөрле ихтирамга һәм рәхмәткә лаеклы изге эш. Халык иҗатының шедеврларыннан булган мондый көйләрнең тарих караң-

гылыгыннан яңадан безнең бүгенге дөньябызга килеп чыгуын иң кадерле һәм кыйммәтле борынгы кульъязмалар табылуга тиңләп булыр иде. Әмма моны, минемчә, «Гөлҗамал»ның дөньяга беренче чыгуы дип түгел, бәлки икенче тапкыр тууы дип аңларга кирәктер. Чөнки ул борын заманнарда ук иҗат ителгән көй булса кирәк. Өлкәнрәк яшьтәге кешеләр аны моннан күп еллар элек үк ишетүләре турында сөйлиләр.

Шушы уңайдан, киңәшү тәртибендә, бер фикер әйтер идем. Мәгълүм ки, халыкның культурасы югарырак баскычка күтәрелгән саен, аның профессиональ музыкага ихтыяҗы арта бара. Шул ук вакытта тормышыбызда халык җырлары да зур урын тотуында дәвам итәләр. Көндәлек радиотапшыруларны, җыр һәм бию ансамбле концертларын, үзешчән сәнгать һәвәскәрләре чыгышын, аерым күңел ачу кичәләрен әйткән дә юк, хәтта шәһәрнең иң зур залларында, тантаналы кичләрдә, танылган артистлар катнашы белән уздырылган концертларда да халык җырлары иң хөрмәтле урынны алалар. Моның шулай булуы бик табигый... Әмма без менә шушы якын сердәшебезгә, шушы иксез-чиксез бай эстетик ләззәт хәзинәсенә тиешенчә игътибар итәбезме? Йөз еллар буенча күңелләребезне хушландырып килгән иң мәшһүр җырларның гына булса да тарихларын беләбезме, шуның белән кызыксынабызмы? Кызганычка каршы, юк, белмибез, белергә бик үк тырышмыйбыз да дип җавап бирергә туры килә.

Дөрес, тарихның бу бите бөтенләй үк ак килеш калган дип, әйтеп булмый булуын, ул аз булса да языла башлаган. Кайбер көйләрнең риваятен, заманы һәм яшәеш шартлары мөмкинлек биргән кадәр, Габдулла Тукай сөйләп калдырган. Моннан тыш тагын, 1912 елларда «Әүлия» имзасы белән чыгарылган кечкенә китапчыкларда «Зөләйха бикә көе», «Чегән көе» һ. б. ларның кыска гына булса да легендалары теркәлгән. Ләкин, әгәр дә ялгышмасам, шуннан соңгы илле-алтмыш ел эчендә аларга игътибарга лаеклы әллә ни өстәлмәде шикелле.

Көй һәм җырларның чыганаклары өйрәнелмәүгә иң беренче булып Г. Тукай борчыла башлаган. Халык иҗатына багышланган мәгълүм лекциясендә ул болай ди:

«Җырларыбыз вә көйләребезнең тарихын вә мәнбәгъләрен [1] тикшерергә бер заман махсус хезмәт куярмын да, шаять халыкка шул тугрыда әсаслырак [2] мәгълүмат бирермен диган өметем бар әле».

Сүз дә юк, бу изге теләк булган. Ләкин, кызганычка каршы, шагыйрь бу теләген гамәлгә ашырырга өлгерә алмыйча калган.

Дөрес, Казанда СССР Фәннәр академиясенең тел, әдәбият һәм тарих институты ачылганнан бирле халык җырларын язып алуга зур көч салынды. Г. Тукай сүзләре белән әйткәндә «халкыбыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә рәушан көзгесе» булган халык җырларының иң күп өлеше, һичшиксез, җыеп алынды инде һәм аларны фәнни яктан өйрәнү дә уңышлы дәвам итә дип әйтә алабыз. Илленче еллардан башлап шул ук институтта җырларның көйләрен язып алуга да керешелде. Ләкин шушы көннәргә кадәр җырларның һәм көйләрнең кайда, кайчан, нинди уңай белән, кем тарафыннан чыгарылуларына, һич югында, беренче мәртәбә кайчан, кайда җырлана яки уйнала башлауларына нигәдер бераү дә игътибар итми диярлек. Хәтта махсус чыккан экспедиция кешеләре дә көйне һәм җырны язып алганда, ни сәбәпледер, аларның чыганаклары белән кызыксынуны кирәк тапмыйлар. Бу мәсьәләгә кайбер музыка һәвәскәрләренең зәвык капризларын канәгатьләндерү өчен генә кирәк булган кечкенә бер эш дип карау һич дөрес булмас иде... Бу — халыкның рухи тормышы, күңел хәзинәсе ни дәрәҗәдә бай булуын, бигрәк тә, аның музыкаль таланты нинди югарылыкта торуын өйрәнү өчен кирәк. Шушылар өстенә тагын борынгы җырлар тарихы ханнар, патшалар заманында халыкның нинди драма һәм фаҗигалар кичерүе хакында сөйләп бирмәс идемени?

Алай гына да түгел, бу әлеге шул «Гөлҗамал», «Тәфтиләү», «Кара урман», «Рәйхан» кебек җырлар энҗесен иҗат иткән, әмма исемнәре тарих сәхифәләренә теркәлми калган талантлы халык композиторларына үзенә күрә бер истәлек тә булыр иде.

---

[1] Чыганакларын.

[2] Төплерәк, нигезлерәк.

Кызганычка каршы, кайберәүләр халык җырларын әле һаман да юк-бар нәрсә дип, халык көйләрен яшь-җилбәзәк гармун тартып шаярып утырганда очраклы гына килеп чыккан арзанлы такмак, «урам кее» дибрәк карыйлар. Халыкның музыкаль иҗатына кайбер музыка әһелләренең дә игътибары җитеп бетми. Шуның нәтиҗәсендә, кайвакыт гафу ителмәслек дорфалыклар да эшләнә. Мәсәлән, борынгыдан ук чарлана килгән тирән мәгънәле, шигъри кыйммәте ягыннан сокландыргыч югарылыкта торган һәйбәт халык җырларын аннан-моннан гына «яңача» ясап, аңа колакны рәнҗетердәй тупас сүзләр өстәп, килбәтсез такмакка әйләндергәлиләр. Янсә кайбер җырларның поэтик эшләнешен аңламыйча, аңа һич ятышмый торган чит-ят бер көйгә җырлап ташлыйлар. Халык җырын башкаруга талант та, осталык та таләп ителми торган гамьсез бер кәсеп итеп караучылар да юк түгел. Бу да, күрәсең, халыкның музыкаль иҗатына тиешенчә бәя бирмәүдән, аның җәмгыять тормышында тоткан урынын һәм әһәмиятен халыкка аңлатып җиткермәүдән килә торгандыр. Хәлбуки, халык иҗатының бу төре күңел байлыгыбызның иң кадерле һәм кыйммәтле бер хәзинәсе. Җәмгыять тормышында ул бик әһәмиятле урын тота.

Халык җырының бөтен тарих буенча җәмгыять тормышы белән үрелеп килүе, халык көйләренең күбесенең нигезендә нинди дә булса бер җитди сәбәп ятуы, байтагысының җан тетрәткеч драма яки фаҗига уңае белән чыгарылган булуы электән үк билгеле. Заманында моңа Г. Тукай да игътибар иткән. Ул, мәсәлән, болай яза:

«Безнең җырланмакта булган көйләребезнең һичберсе дә бер-бер сәбәпсез, бер-бер нәрсәнең тәэсиреннән башка чыкмаган...»

Шушы фикерен раслау өчен Г. Тукай «Ашказар», «Сак-Сок» һәм башка көйләрне мисал итеп китерә. «Тәфтиләү» көе хакында: «Тәфкилев көенең моңлылыгына карагандә, егет белән кыз арасында мотлак бер фаҗига булгандыр», ди.

Билгеле, кайбер көйләр нинди дә булса шәхси драмага нигезләнеп чыгарылган булсалар да, аларны тудыручы сәбәпләр тирәндәрәк ята. Гаҗәеп музыкаль көчкә ия булган тирән эчтәлекле «Әллүки» һәм «Кара урман» кебек җырлар бөтен халык язмышын кайгырту, шуңа борчылу, дулкынлану, тирән кичерешләр җимеше буларак кына туарга мөмкин.

Менә шуннан алга ифрат та җаваплы, мавыктыргыч бер мәсьәлә килеп баса: халыкның гасырлар буенча җырланып килә торган шундый атаклы җыр һәм көйләре кайсы замандарак, кайсы якларда, нинди вакыйгалар йогынтысында чыкты икән? Археологлар борынгы бабайларның нинди киемнәр киюләренә, өйләрендә мичләре нинди булуына, ул мичләргә нинди утын ягуларына кадәр өйрәнәләр. Менә беләсе иде бит: моннан йөз, ике йөз, өч йөз яки дүрт-биш йөз ел элгәре шул өйләрдә нинди «җырулар» җырлаганнар, ничек биегәннәр, ул вакытта нинди уен кораллары булган? Ислам диненә кергәнчә, ягъни мәҗүсилек чорында халыкның музыкасы нинди булган? Бөек Болгар дәүләтендә нинди җырлар җырлаганнар? Менә шушылар белән, музыка һәм сәнгать тарихы белән хәзерге талантлы яшь галимнәр тагын да тырышыбрак шөгыльләнмәсләрме икән?

Билгеле, бик борынгы җыр һәм көйләрнең ничек чыгуын ачыклау хәзер кыен булыр инде. Кайберләре, бәлки, мәңгегә шулай тарих караңгысына күмелеп калыр. Чөнки ул хакта борынгылардан язма документлар, истәлек кебекләр бик аз калган. Уен кораллары да сирәк табыла булса кирәк. Шуның өстенә, көй һәм җырларның халык тарафыннан иҗат ителү процессы үзе үк чиктән тыш катлаулы да, четрекле дә мәсьәлә. Ихтимал, хәзер без тыңлый торган көйләрнең кайберләре һич көтелмәгәндә, кинәт кенә килеп тугандыр. Мәсәлән, күтәрә алмастай зур шатлык яки хәсрәт баскан берәр җырчы я уенчы, ялкын кебек кабынып, минут эчендә яңа көйгә җырлап җибәрүе, я булмаса, элекке көйгә яңа җыр әйтеп ташлавы мөмкин. Ләкин әгәр дә без һәммә җырлар да шулайрак иҗат ителгән, бер утыруда көен дә, җырын да чыгарганнар да шул ук көнне җырлый да башлаганнар дип гөман кылсак, бу бик беркатлылык булыр иде. Көе Минзәлә ягында, җыры исә Казан артында чыккан булырга да мөмкин бит. Янсә шәһәрдән отып кайткан көйгә авылда яңа җыр чыгарулары да бик ихтимал. Шул ук борынгы көйләрнең безнең заманга килеп җиткәнче танымаслык булып үзгәрүләре дә билгеле. Халык музыкасын өйрәнүче музыка белгече Мәхмүт иптәш Нигъмәтҗановның раславынча, шул ук «Тәфтиләү» җырының көе борынгы заманда бөтенләй башка булган.

Кыскасы, көйләр һәм җырлар тарихын өйрәнү — ул төрле гыйбрәтле һәм мавыктыргыч маҗаралар эченә килеп керү, күп төрле табышмакларны ачу, хәзерге заман өчен көрәш юллары буйлап тагын бер мәртәбә узу дигән сүз. Әмма ничек кенә булмасын, әгәр дә без үзебезне күп гасырлык тарихы булган мәдәни халыклардан берсе дип саныйбыз икән, ул чагында халыкның материаль һәм рухи культурасына кагылышлы бер генә мәсьәлә дә тикшерелмичә, өйрәнелмичә калмаска тиешлә.

Борынгы көйләр шулай. Әмма әле бит, безнең заманда, революция алдыннан янсә революциядән соң чыккан көйләр дә байтак кына. Без бит аларның да тарихын өйрәнмибез. «Галиябану» яки «Шомыртым» кайчан һәм кайда җырлана башлаган? Болар арасында хәзерге көндә яратып җырлана торганнары да аз түгел. Мәсәлән, «Көзге ачы җилләрдә», «Фазыл чишмәсе», «Рәйхан», «Рамай» кебекләрне мин шундыйлар исәбенә кертер идем.

«Көзге ачы җилләрдә» дигән җырны без, яшь сугышчылар, 1920 елның җәендә Врангельгә каршы сугышка чыгып китәр алдыннан, Казан урамнарында бөтен рота һәм батальоныбыз белән җырлап йөрдек. Без аны Октябрь революциясе алдыннан солдатлар чыгарган яңа җыр булырга тиеш дип уйлый идек. Чөнки анда менә нинди юллар бар:

> **Бетсен патша, янсын тәхет,**
> **Безгә сугыш кирәкми шул...**

Патша армиясе таркала башлаган бик чуалчык бер вакытта чыккан җыр булганлыктан, анда «Йөгереп китәрдәй булам, кайтып җитәрдәй булам... туган-үскән илләргә» дигән юлларның булуы да бер дә гаҗәп түгел. «Татар халык җырлары» дигән китапта язылганча, хәзер халык бу җырны, яңа бер яңгыраш биреп, бик хаклы рәвештә революцион җырларның берсе итеп җырлый.

Сирәгрәк ишетелсә дә мондыйлардан мин тагын «Атлы гаскәр» дигән җырны искә алып үтәр идем. Эчтәлегеннән чыгып хөкем йөрткәндә, монысын Буденный гаскәрендә Врангель армиясенә каршы сугышкан атлы кызылармеецлар чыгарган булса кирәк. Я булмаса, шулар йогынтысында башкалар тарафыннан иҗат ителгәндер. Аның сүзләре, революцион дәрт белән рухланган батыр сугышчыларга хас рәвештә, сугышчан өндәү булып яңгырый:

> **Эскадрон, атларга,**
> **Тезелик сафларга!**
> **Әзер булыйк илебезне**
> **Дошманнардан сакларга.**

Әгәр шушы җырларның ничегрәк тууын ачыкларлык истәлекләр табылса, аннан да бигрәк, заманында шушы җырны үзе җырлап йөргән берәр атлы сугышчы үзе килеп чыкса, болар бит революцион җырлар тарихына чиксез кадерле бер бүләк булыр иде. Янсә «Рамай» дип йөртелгән җырга тукталыйк. Ул Бөек Ватан сугышыннан соң гына ишетелә башлаган иде шикелле. Әмма, кайбер иптәшләрнең сөйләвенә караганда, мәшһүр музыкант Фәйзулла ага Туишев бу җырны элек үк ишеткән булган, Рамайның тегермәнче егет булуын да белгән. Ничек кенә булмасын, бу иң күп таралган җырларның берсе. Халыктан аның ике дистәдән артык варианты язып алынган. Күрәсең, моның шулкадәр сөелеп җырлануы бу җырның үзенә күрә бер серле романтика белән сугарылуына бәйледер. Чыннан да, «Рамай»ны тыңлаганда каядыр, чит җирләргә чыгып киткән бунтарь холыклы, батыр йөрәкле, әмма китек күңелле бер егет күз алдына килеп баса. Ни булган ул егеткә? Бу җырның нигезендә нинди тормыш вакыйгасы ята? Менә мондый юллар җырга ни сәбәпле килеп кергән?

> **Безгә кемнәр теләк теләде икән, Рамай,**
> **Гомерләре аерым үтсен дип...**

Җырның эчтәлеге бу сорауларга җавап биреп җиткерми, гадәттәгечә беркадәр уйландыра торган итеп калдыра. Әгәр «Рамай» җырының эзеннән йөреп, аның иң башта җырланган вариантыннан алып соңгыларына кадәр чагыштырып карасаң, халык җырларының ничек тууларын һәм заман таләбе буенча ничек үзгәрә баруларын ачык-

ларга мөмкин булыр иде. Әйтик, Фәйзулла ага Туишев телгә алган егет, тегермән хуҗасының җәберенә түзә алмыйча, читкә чыгып китәргә мәҗбүр булган иде, ди. Билгеле, җыр да шул вакыйгага багышланып чыгарылган булырга мөмкин. Соңыннан җырлаучылар исә аңа үзләрен дулкынландырган бүтән уй-хисләрне куша башлыйлар. Шул рәвешчә, әсти һәм төзәтә торгач, җыр бөтенләй үзгәрә. Аның элеккедән яхшыруы да ихтимал. Әмма баштагы халыкчанлыгын югалтып, мещанлык фәлсәфәсе белән сугарылган төче һәм затсыз бер вульгар җырга әйләнүе дә бик мөмкин.

Шул рәвешчә, халык җырларны өзлексез чыгарып тора, җырлап тора. Аларның кайберләре тора-бара искерә дә, онытыла башлый, аның урынына яңа җырлар туа. Җырлар дөньясында кайвакыт таң калырдай гаҗәеп һәм гыйбрәтле хәлләр дә булгалый. Әхмәт Фәйзинең «Умырзая» дигән шигыре бар иде. Әмма шагыйрь үзе исән чагында ул исемдәге җырның беркайда да ишетелгәне булмады шикелле. Әхмәт Фәйзинең вафатыннан соң күп тә үтмәде, каяндыр, ничектер, «Умырзая» дигән яңа җыр килеп туды. Бу көй шундый моңсу, анда шундый юксыну аһәңнәре ишетелә ки, әйтерсең, халык бу көйне вакытсыз дөнья куйган сөекле шагыйрьнең истәлегенә багышлап махсус рәвештә иҗат иткән. Менә бит, бу да игътибарга лаек бер хәл. Чыннан да шулай булганмы, әллә башкачаракмы? Бу көй кайда чыккан? Аны беренче мәртәбә кем җырлаган?

Бу яңарак җырларның халык арасына таралуларына әле күп тә түгел. Аларны иҗат итүчеләрнең күбесе әле хәзер дә исән булырга мөмкин. Әгәр, шушыларның яисә башка яңа җырларның, бәхеткә каршы, башлап җибәрүчеләре, я булмаса, беренче тапкыр җырлаучылары килеп чыкса, бу бит гаҗәеп бер вакыйга булыр иде. Мин ышанам, әгәр дә иң кадерле, иң танылган җырларның тууларына сәбәп булган тарихи яки шәхси вакыйгаларны ачыклап булса, бу халыкның музыкаль иҗатын өйрәнүгә зур өлеш булып керер, шул ук вакытта бәлки яшь композиторларга да азык булыр, аларга яңа әсәрләр язарга, гомумән, иҗатларын халыкчанлык рухы белән сугарырга ярдәм итәр иде. Әдип һәм шагыйрьләргә исә шул бай материалга нигезләнеп хикәяләр, поэмалар, хәтта драма әсәрләре язарга да мөмкин булыр иде.

Мин монда берничә җырны гына мисалга китердем. Композиторларыбызның яңа җырлары белән янәшә халык җырларының да яңалары туып тора. Алар халыкның тау кадәр талантыннан саф чишмә булып агып чыгалар да музыка дигән киң һәм куәтле дәрьяга килеп коялар. Без тауны күрәбез. Әмма җырлый-җырлый аккан шул чишмәләрнең кайсы кайдан, тауның кайсы култыгыннан, нindирәк тирәкләр төбеннән чыгуын абайлый алмыйча калабыз. Чөнки табигать үзенең бу тылсымлы серен, яман күзләрдән яшергәндәй, бераз томан белән өретебрәк куючан була.

Әмма шуңа да карамастан, бу серле тауга бераз якынаебрак булмасмы икән? Нигә безгә көйләр һәм җырлар хакындагы легендаларны, риваятьләрне, ишеткән-белгәннәрне халыктан җыеп карамаска икән? Әгәр кызыксынучы кешеләр җыр һәм көйләр тарихы турында ишеткән-белгәннәрен язып җибәрсәләр, бик кирәкле һәм төрле-төрле бик күп мәгълүмат тупланыр иде. Дөрес, бу әле чын тарихның үзе үк булмас. Шулай да аларны чагыштырырга, фәнни яктан өйрәнергә мөмкин булыр һәм мондый материал мәгълүм дәрәҗәдә төпле бер фикергә килергә ярдәм итәр иде. Болардан иң кыйммәтле һәм кирәкле дип табылганнары матбугатта басылыр, радиодан сөйләнер иде. Әгәр инде бу башлангыч уңышлы чыкса, тора-бара, бәлки җыр һәм көйләр турындагы риваятьләрдән махсус бер китап та чыгарырлык булыр, шулай итеп, халыкның рухи байлыгын өйрәнү юлында бик әһәмиятле зур бер эш башкарылган булыр иде.

# УҢГАН КЫЗ



Йолдыз Вәлитова янына мине Корчагин сукмагы алып килде. Күп еллар буе Николай Островскийның иҗатын тикшерү, бигрәк тә «Корыч ничек чыныкты» романының укучыларга йогынтысын өйрәнү сәбәп булды моңа, күрәсең. Шушы тыйнак кына кызда мин Корчагиннарның бүгенге буынын бизи торган күркәм сыйфатларны таптым һәм аның характерының бу гүзәллеге турында язарга кирәк дигән карарга килдем.

Менә мин Мәскәүнең Ленин таулары янындагы яңа салынган районында, алар квартирасында.

Башлап шуны әйтергә кирәк, гади семья түгел бу. Йолдызның әтисе Габдрахман ага, 1919 нчы елда ук партия сафларына кереп, тормышның олы юлыннан атлаган кеше. Совет власте елларында югары белем, алай гына да түгел, педагогия фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алуга ирешкән Габдрахман ага гомерен яшь буынны тәрбияләүгә багышлаган. Соңгы елларда СССР Педагогия Фәннәре Академиясе институтларының берсендә фәнни-тикшерену эше алып барган. Хезмәте барның хөрмәте бар, дип халык юкка әйтми. Габдрахман аганың да озак еллар буена нәтиҗәле эше хөкүмәтебезнең югары бүләкләренә лаек булган. Аңа Кыргызстанның атказанган укытучысы дигән мактаулы исем бирелгән. Йолдызның әнисе Кояш ханым исә шулай ук педагог, Надежда Константиновна Крупская җитәкчелегендә эшләгән кеше. Ә апасы Айсылуга килгәндә, менә инде чын мәгънәсендә алма агачыннан ерак төшмәгән. Ул филология фәннәре кандидаты, өлкән гыйльми сотрудник.

Оясында ни күрсә, очканында шул була, диләр бит. Тормышта лаеклы урын алу өчен көрәштә әти-әнисенең, апасының йогынтысы, халыкка хезмәт итүдә алар сайлаган авыр, ләкин мактаулы юл матур үрнәк булган Йолдызга. Ә бу үрнәк бик тә, бик тә кирәк булган аңар.

Йолдыз, каты авыру аркасында, алты яшенә кадәр йөри дә, сөйләшә дә алмас була. Бу җитди физик кимчелекне бераз гына булса да җиңеләйтү өчен кызга көн саен, сәгать саен ялыктыргыч күнегүләр ясарга туры килә. Хәзер дә, ничәмә ничә еллардан соң да, аңа элеккечә үк хәрәкәтләнү авыр, язу, аудитория алдында чыгыш ясау исә тагын да кыенрак.

Менә шушындый шартларда Йолдыз язмышка баш иямәскә карар бирә.

Бу вакытта аларның семьясы Фрунзеда яши. Кыз мәктәптә укуын өченче класстан башлый. Класстан класска Мактау грамоталары белән күчеп, җиде ел эчендә урта мәктәпне алтын медальгә тәмамлый. Шул чакта анда шигъри сүзгә мәхәббәт уяна. Йолдызның беренче шигырьләре Кыргызстан радиосында яңгырыйлар, «Советская Киргизия», «Комсомолец Киргизии» газеталарында басылып чыгалар. Лирик җылылык белән сугарылган, һәр строфасында самимилек бөркелеп торган бу шигырьләрне укучылар яратып каршы ала. Соңыннанрак Йолдыз татар шагыйрьләренең әсәрләрен тәрҗемә итүдә дә көчен сынап карый.

...Мин Йолдыз бүлмәсендә утырам. Җыйнаграк кына бу бүлмә галимнең эш кабинетын хәтерләтә. Шкафлар рус, татар, башкорт, әзербәйҗан, үзбәк һәм башка телләрдәге әдәби китаплар белән тулган. Өстәлдә һәм тартмаларда кульязмалар, хатлар, картотекалар... Бүлмәнең хуҗасы — карлыгачдай кара күзләреннән акыл көче бәреп торган чандыр, уйчан Йолдыз — язу машинкасында чираттагы мәкаләсен басып утыра. Ә мин аның төрле басмаларда чыккан мәкаләләрен, шигырьләрен күздән кичерәм.

Белем миңа гаҗәп факел бирде,
Нинди генә куе томан да
Каплый алмас ерак киңлекләрне
Шушы факел — акыл булганда,—

дип язган Йолдыз, урта мәктәпне тәмамлагач.

Шигырьләр, шигырьләр... Яз, яшьлек, Ангара ярларында ГЭС төзүче комсомоллар, туган ил киңлекләрендә өлгергән тук башаклар, яшәү һәм бәхет турында... Күбесе Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетының Көнчыгыш телләре бүлегендә укыган вакытта, актив җәмәгать эше алып барганда, «Комсомолец» исемле стена газетасына, күп тиражлы «Московский университет»ка язышканда туган.

Йолдыз характерының тагын бер күркәм сыйфаты — сәнгатьне ярату. Семьялары Кыргызстанда яшәгәндә үк ул Мәскәү радиосы тапшыруларын йотылып тыңлый, бигрәк тә аны Надежда Обухованың ягымлы тавышы таң калдыра.

— Мәскәүгә күчкәч,— ди Йолдыз,— Надежда Андреевнаның исәпсез-хисапсыз дуслары арасында мин дә бар идем. Ул миңа тормышымда юл күрсәтүче якты нур — өмет нуры булды. Аның: «Кешене сәламәтлек, матурлык һәм сәләт кенә бәхетле итә алмый әле. Чын бәхет халыкка хезмәт итүдә, халык өчен яшәүдә, хезмәтең белән кешеләр тормышын бизәүдә...» — дигән сүзләре һаман да колак төбемдә яңгырый.

Менә студентлык еллары да артта кала. Йолдыз университетны отличнога тәмамлый. Яшь филолог үз алдына татар халкының сөекле шагыйре Габдулла Тукай иҗатының тел үзенчәлекләрен тикшерүне максат итеп куя. Тема итеп төрек-угыз элементларның шагыйрь иҗатындагы ролен өйрәнүне сайлый, СССР Фәннәр Академиясенең Азия халыклары институтына аспирантурага керә.

Ул диссертация темасына төрле басмаларда уннан артык мәкалә чыгара һәм менә 1967 елның 17 февралендә «Габдулла Тукайның шигъри әсәрләрендә чит тел элементлары» дигән кандидатлык диссертациясе Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетының Көнчыгыш телләре институтының Гыйльми Советына куела.

Диссертациягә кайлардан гына уңай бәя килмәгән! Казаннан, Ташкенттан, Уфадан, Нальчиктан, Ашхабадтан, Бакудан... Рәсми оппонентларның да фикерләре уңай. Һәм менә Гыйльми Совет бертавыштан карар кабул итә: Йолдыз Габдрахман кызы Вәлитовага филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә бирергә. Карарны залда утыручылар көчле кул чабулары белән каршы алалар.

Әйтүе генә ансат, алты яшенә кадәр йөри дә, сөйләшә дә алмаган кыз авыр язмышны җиңеп, галим дәрәҗәсенә үссен! Заманыбызның Корчагины түгелме бу!

Ш. ВЯДРО,
филология фәннәре кандидаты.
Киев.

Йолдыз Вәлитова,
филология фәннәре кандидаты

# ТУКАЙ ШИГЫРЬЛӘРЕНЕҢ ТЕЛЕ ХАКЫНДА БЕРНИЧӘ СҮЗ

Габдулла Тукай бик хаклы рәвештә татар әдәбиятының классик әдибе булып танылды. Һәм ул, һәр зур художник кебек үк, өзлексез иҗади эзләнүләр белән тулы катлаулы үсеш юлы үтте.

Тукайның башлангыч чорда иҗат ителгән кайбер әсәрләренең, шул исәптән 1905—1907 еллар арасында язылган шигырьләренең дә, теле хәзерге әдәби тел

нормаларыннан нык кына аерыла. Объектив һәм субъектив характердагы төрле сәбәпләр аркасында, әдипнең беренче чор әсәрләрендә татар әдәби теленең үз табигатенә ят булган лексик һәм грамматик элементлар, һәртөрле морфологик күрсәткечләр һәм синтаксик конструкцияләр еш кулланылган, шагыйрьнең ул чор иҗаты бүгенге көндә сирәк очрый яки бөтенләй диярлек очрамый торган архаик формалар һәм кушымчалар белән чуарланган иде.

Әмма, художник һәм гражданин буларак җитлегә-өлгерә төшкән, шигъри таланты тулырак ачылган саен, Тукай шигырьләренең теле дә халыкның җанлы сөйләменә якыная, татар халык теленә генә хас төс һәм бизәкләр белән байый барды. Ахыр килеп, Габдулла Тукай әдәби телнең бөтен тармакларын — аның лексикасын, морфологиясен һәм синтаксисын — кыю рәвештә яңарткан кешеләрнең иң күренеклесе булды. Аның иҗаты әдәби телгә новаторларча якын килүнең матур үрнәге булып санала ала. Кыскасы, Тукай үзен татар теленең бай мөмкинлекләрен оста файдалана белүче гаҗәеп бер тылсымчы итеп танытты; дәһи шагыйрь кулында тел искиткеч көчле, искиткеч үткен коралга әйләнде.

Татар әдәбияты һәм әдәби теле тарихында Тукай мирасының кыйммәте әйтеп бетергесез зур. Һәм, үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, аның иҗат мирасын тел-стиль ягыннан җентекләп өйрәнү дә җитди әһәмияткә лаек. Укучылар игътибарына тәкъдим ителә торган бу мәкаләдә төрек-угыз теленә хас алмашлыкларның, ярдәмче сүзләрнең һәм төрле кушымчаларның Тукай шигырьләрендә ничек кулланылуы күзәтелә, аларның нинди синтаксик функцияләр башкаруына һәм нинди стилистик мәгънәләрдә йөрүләренә кыскача гына булса да анализ ясала.

Алдан ук шул кадәресен әйтеп үтәргә кирәк, Тукай тарафыннан кулланылган төрек-угыз элементларының байтагы хәзерге төрки телләрнең дә күбесе өчен хас, алар шулай ук урхун-енисей язмаларында, «Котадгу билиг»тә һәм төрки телдәге башка язма истәлекләрдә дә очрыйлар.

Мәгънәләре ягыннан чыгып, Тукай кулланган төрек-угыз алмашлыкларын түбәндәге төркемнәргә бүләргә мөмкин: зат алмашлыклары (бән, сән), зат-күрсәтү алмашлыклары (у — ул, анлар — алар), күрсәтү алмашлыклары (бунлар — болар, шунлар — шулар), сорау алмашлыклары (нә — нәрсә, һанки — нинди), кайтым алмашлыклары (кәндем — үзем, кәндеңә — үзеңә), аеру алмашлыклары (һәп — бөтенесе), билгесезлек алмашлыклары (кемсә — кемдер), шулай ук төрекчә зат һәм күрсәтү алмашлыкларыннан килеп чыккан рәвешләр һәм аларда ясалган исемнәр (бәнчә — минемчә, безчә — безнеңчә, аңларча — аларча, бонча — шулкадәр, бөйлә — бу рәвешчә, шөйлә — шул рәвешчә). Шунысы кызык, таралулары һәм куллану ешлыклары ягыннан караганда, беренче урында зат алмашлыклары тора. Бу — иҗатының башлангыч дәверендә Тукай язган шигырьләрнең жанр үзенчәлекләреннән килә булса кирәк. Аларның күбесе югары пафослы одалар һәм лирик шигырьләр, я булмаса үткен сатирик әсәрләр формасында эшләнгән.

Кушымчасыз билгесез килештә, шулай ук төрле килеш һәм хәбәрлек кушымчалары, сүз ясый торган кушымчалар белән килгәндә, төрек-угыз алмашлыклары җөмләдә төрле (ия, хәбәр, аергыч, туры яки кыек тәмамлык, хәл төркемнәре) функцияләрне башкаралар. Башка исемнәр белән чагыштырганда, төрек-угыз теленә хас модаль сүзләрнең (эвәт — әйе, вар — бар, билә — хәтта), «дәгел» дигән юклык сүзнең, «ми» формасындагы сорау кисәкчәсенең, «дәхи» теркәгеченең һәм «дәк» (кадәр) рәвешендәге бәйлекнең Тукай шигырьләрендә кулланылыш даирәсе нык чикләнгән. Шуңа күрә аларның синтаксик рольләре дә юк дәрәҗәсендә аз.

Аерым очракларда югарыда телгә алынган төрек-угыз элементларының кайберләре («вар» сүзе, сорау кисәкчәсе, юклык сүзе), үзләренең төп синтаксик вазифаларын үтәүдән тыш, контекстта рифмалашкан кисәкләргә әйләнәләр һәм шигъри сурәтләү чаралары системасына кушылып китәләр.

Габдулла Тукай шигъриятендә аеруча киң саналган төрек-угыз элементларының берсе — «илә» бәйлеге. Әдипнең беренче әсәрләрендә әлеге бәйлекнең тулы формасы сирәгрәк очрый. Тик шунысы бар, әгәр «илә» бәйлегенең кыска варианты беренче дәвер әсәрләрендә генә кулланылса, аның тулы варианты ике мәртәбә шагыйрьнең соңгы шигырьләренә дә кертелгән. «Илә»нең тулы формасы төрле килешләр, шулай ук исемнәр белән яраша һәм җөмләдә төрле мәгънәләрне (уртаклык, инструменталь,

«вә» теркәгеченең синонимы, мөнәсәбәтле сүз тезмәләренең бер кисәге] белдереп килә. Аерым очракларда бу бәйлек юмор чарасы итеп кулланыла яки, рәдиф буларак, катлаулы рәдифле рифмалар составына керә. «Илә» бәйлегенең тулы вариантын куллану Тукай шигырьләренең салмак һәм тигез агышына билгеле бер тәэсир ясаган, аларның стилендәге архаизмны, пафослы югары тонны көчәйтеп җибәргән.

Әлеге бәйлекнең кыска формасын Тукай күбрәк инструменталь төшенчәне белдерү өчен ала һәм нигездә беренче чор әсәрләрендә генә куллана. Сирәк очракларда гына әлеге бәйле уртаклык төшенчәсен белдерә, «вә» теркәгеченең синонимы булып йөри яки, «кадәр», «кәррат» кебек гарәп сүзләре белән кушылып, тезмә рәвешләр [кадәрлә, кәрратлә] ясауда катнаша.

«Илә»нең кыска формасы кайбер татар һәм төрек-угыз фигыльләренең «мак-мәк» кушымчасы ялганып ясалган инфинитив төре белән дә яраша. Соңгы очракта ул я инструменталь төшенчәне белдерә, я русларның нәрчен сәбәп җөмләләренә хас эчтәлекне белдереп килә. Шуның өстенә, морфологик төзелешләре һәм килеп чыгышлары ягыннан бер-берсеннән шактый ерак торган төрле сүзләр, әлеге бәйлекнең кыска формасы белән ярашып, тиңдәш рәдифле рифмалар чылбыры хасил итәләр. Бусы инде монорим шигырьләргә хас бер үзенчәлек: җанымлә бән — җананымлә бән — кальбе гирьянымлә бән — күздән аккан канымлә бән — нуры мәжгяныңлә бән— җөмлә илһамыңлә бән — наре һиҗраныңлә бән — яэс вә хирманыңлә бән — аһе әхзаныңлә бән — намыңны китманымлә бән.

Югарыда бер тапкыр әйтелгәнчә, Тукайның беренче шигырьләрендә күбрәк «илә» бәйлегенең кыска формасы очрый. Бу, күрәсең, шигъри телнең үзенә генә хас үзенчәлеге, рифмаларның теге яки бу характерда булулары һәм шигырьдәге билгеле бер үлчәүне, ритмны саклау мәҗбурияте белән бәйләнгәндер.

Шул рәвешчә, төрек-угыз алмашлыклары һәм ярдәмче сүзләре, тулы мәгънәле исемнәр кебек ук, Тукай шигырьләренә органик төстә кереп китәләр һәм еш кына шагыйрь кулланган сурәтләү чаралары арасында әһәмиятле урын билиләр. Әлеге лексик һәм грамматик категорияләр әдипнең беренче шигырьләренә тантаналы югары пафос, көнчыгыш шигъриятенә хас үзгә бер рух өстиләр, югары стиль өчен характерлы затлылык, чуарлык һәм катлаулылык бирәләр.

Беренче шигырьләренең теле төрек-угыз теленә хас морфологик күрсәткечләр [килеш, тартым һәм хәбәрлек кушымчалары] белән артык күп чуарланган булу да Тукай иҗатында чит тел элементларының никадәр мул кулланылуын раслый алыр иде. Төрек-угыз кушымчаларын шагыйрь чыгышлары ягыннан төрле сүзләргә, аеруча гарәп сүзләренә ялгый. Әлеге юл белән ясалган исемнәр, үзләренең төп стилистик һәм синтаксик вазифаларын башкару белән бергә, еш кына рәдифле һәм башка төрле рифмалар [гади, эчке, каламбурлы] хезмәтен дә үтиләр һәм, шул рәвешчә, аерылмаслык төстә шигырьләрнең әдәби тукымасына үрелеп китәләр. Аерым очракларда мондый исемнәр синоним буларак та файдаланылалар.

Төрек-угыз теленә хас морфологик күрсәткечләрнең Тукай әсәрләрендә тоткан урынын һәм ролен тикшергәндә шул нәрсә ачыклана: арада иң күп кулланылганы фигыльнең инфинитив төрен ясый торган кушымчалар икән. Шагыйрь аларны татарның төп үз фигыльләренә ялгарга ярата. Татар фигыльләренең инфинитив төре күбрәк билгесез килештә, аерым очракларда исә модаль сүзләр һәм бәйлекләр белән ярашкан, шулай ук төрле кыек килешләрнең кушымчалары ялганган хәлдә очрый.

Билгесез килеш формасындагы инфинитив, үзенең төп мәгънәсен белдерү белән бергә, хәрәкәтне аңлаткан исем ролендә дә йөри һәм гадәттә ия яки тәмамлык хезмәтен үти. Аерым очракларда фигыльләрнең инфинитив төре, гади яки рәдифле рифмалар буларак, шигырьләрнең сурәтләү тукымасына әверелгән була.

Билгесез килештәге инфинитив фигыльне шагыйрь «кәрәк» дигән модаль һәм «белән», «өчен» кебек бәйлекләр белән янәшә дә куллана. Модаль сүзләр белән янәшә килгәндә [ифтихар итмәк кәрәк, акмак кирәк], инфинитив затланышсыз конструкцияләр хасил итә. Мондый конструкция XII—XIII йөз язма истәлекләрендә актив кулланылган, әмма бүгенге көн өчен искергән санала. Тукай шигырьләрендә алар һичшиксез булырга янсә башкарылырга тиешле эшне белдерәләр.

Фигыльләрнең төрек-угыз теленә хас инфинитив формалары нәлек килеше кушымчалары белән ярашкан хәлдә очрыйлар һәм, фигыльдән ясалган исем мәгънә-

сендә йөреп, контекстта төрек изафәсе конструкцияләре составындагы аергыч булып торалар.

Юнәлеш килешендәге төрек-угыз, шулай ук татар кушымчалары ялгану юлы белән ясалган инфинитив формалар да очраштыргалый. Мәгънәләре ягыннан алар күбрәк рустагы иярчен максат җөмләләргә якын торалар. Бер очракта исә андый форма фигыльдән ясалган исем төшенчәсендә йөри һәм кыек тәмамлык хезмәтен үти, контекстта исә эчке рифмалар парының бер компонентын тәшкил итә. Тагын бер фигыльнең төшем килешендәге инфинитивын Тукай шулай ук фигыльдән ясалган исем урынына куллана, синтаксик яктан аны тәмамлык ясый.

Иҗатының соңгы елларында ике мәртәбә әдип дәвамлы хәзерге заман хикәя фигыленең өченче зат, берлек сан, барлык формасын куллана. Төрек теле грамматикасының табигатенә бик ятыш бу форма бүгенге татар телендә искергән санала һәм хәзерге әдәби телдә сакланмаган диярлек. Урын-вакыт килеше кушымчалары ялганып ясалган, өзлексез дәвам итә һәм хәзер дә бара торган эшне белдергән, төрек-угыз телендә инфинитив хезмәтен үти торган «утыр», «тор» кебек фигыльләрне дә Тукай дәвамлы хәзерге заман формасында куллана:

Уйга баткан, утырмакта шагыйрь язып...[1]

Бирәдә икенче фигыль ике төп фигыль ярдәмендә белдерелгән эшнең дәвамлылыгын аңлата һәм контекстта ярдәмче роль генә башкара.

...Аңламак, белмәк, тәрәккый, мәгърифәт, хикмәт белән
Әйләнеп һәм нурланып тормакта һәрдәм башлары...[2]

Әдәби эшчәнлегенең беренче елларында Тукай аерым очракларда төрек-угыз теленә хас инфинитив кушымчалары һәм татар телендәге чыгыш килеше кушымчалары ярдәмендә ясалган фигыльләр куллана:

Тырышмактан, тырмашмактан һич бушамыйк...[3]

Әлеге мисалдан күренгәнчә, эшнең искиткеч киеренке төстә баруын белдерү өчен, Тукай мәгънәләре бер-берсенә якын булган ике фигыльне янәшә куллана. Үзара синоним фигыльләрнең бу рәвешчә янәшә килүен рус телендә дә, аерым алганда фольклор әсәрләрендә, очратырга була (горевать — печалиться, бить — колотить). Бу урында шул кадәресен искәртеп үтәргә кирәк, синонимнарның байлыгы һәм төрлелеге ягыннан Тукай шигърияте гомумән нык аерылып тора. Синонимнар шагыйрьнең телен баетапар, аның шигъри теленә күп төрле мәгънә төсмерләре өстиләр һәм җанлы картиналар тудырырга ярдәм итәләр.

...Язу язмактан ма гадә юк базарым...[4]
...Бәнчә, үлмәктән әшәт мәнси вә мәтрукиятем...[5]
...Әмәл юк гайре очмактан, кәчеп дөнья вә гокбадан[6].
...Җаһилем чөн, ормазым, бу сирри белмәктән, дәми...[7]

Тукайның беренче шигырьләрендә «тартыш» фигыленең «җәенке инфинитив» дигән төре кулланыла. Фигыль тамырларына «мак-лык» рәвешендәге катлаулы кушымчалар ялгау юлы белән ясала торган бу форма хәзерге тел өчен искергән санала. «Җәенке инфинитив» формасындагы әлеге фигыль контекстта ясалма исем функциясендә йөри:

...Изге эштер тартышмаклык хокук өчен...[8]

Поэмаларының берсендә «кич» фигыленең «кисек инфинитив» дигән төре урын-вакыт килешендә очрый. Фигыльдән ясалган мондый исем җөмләдә хәбәр ролендә йөри:

...Кичмәдә шул хәлдә сане садисә...[9]

---

[1] Г. Тукай. Әсәрләр. II том. Казан. 1955 ел. 175 бит.
[2] Шунда ук, 186 бит.
[3] Г. Тукай. Әсәрләр. I том. 8 бит.
[4] Шунда ук, 28 бит.
[5] Шунда ук, 50 бит.
[6] Шунда ук, 69 бит.
[7] Шунда ук, 125 бит.
[8] Шунда ук, 79 бит.
[9] Шунда ук, 27 бит.

Бүгенге телдә «кисек инфинитив»лы конструкцияләр шулай ук искергән форма исәпләнә.

Югарыда сөйләнгәннәрдән чыгып, шундый нәтиҗә ясарга кирәк: төрек-угыз теленә хас инфинитив катнашында ясалган барлык форма һәм конструкцияләр Тукай әсәрләренең стиленә, соңгы әсәрләрендә кулланылган очракта исә бигрәк тә, ниндидер борынгылык, китапчалык рухы өстиләр. Тукайдан соңгы поэзиядә татар фигыльләренә төрек-угыз кушымчалары ялгану очраклары бөтенләй диярлек күренми.

Шагыйрьнең чит лексик һәм грамматик берәмлекләр белән аеруча нык чуарланган беренче шигырьләрендә татар фигыльләренә төрек-угыз кушымчалары ялгау да [хикәя фигыльнең кайбер гади һәм катлаулы формаларының, йөкләтү, теләк, боеру юнәлешләренең, шулай ук төрек теленә генә хас шартлы модаль формаларның] шулай ук төрек-угыз фигыльләренең саф формаларын [үткән һәм хәзерге заман сыйфат фигыльне, хәл фигыльне] ялгау да очрый.

Кайчакларда, төп синтаксик вазифаларны ачу белән бергә, әлеге фигыль формалары контекстта Тукайга үз шигырьләренең сәнгатьчә матурлык хасиятен сизелерлек көчәйтергә ярдәм итәләр, алар фразеологик әйләнмә һәм идиоматик тәгъбирләрнең аерым компонентлары, синонимнар, антонимнар булып йөриләр, грамматик омонимнарга нигезләнеп ясалган каламбурлар, сүз уйнатулар, үзара рифмалашып килә торган сүзләр ясауда катнашалар.

Тукайның беренче шигырьләрендә татар фигыльләренә төрек-угыз теленә хас затлы фигыль кушымчалары ялгау очраклары күбрәк күренә. Шуның белән бергә, төрек-угыз теленә хас сыйфат фигыль кушымчаларын куллануга да Тукай ешрак мөрәҗәгать итә. Ә хәл фигыль кушымчалары исә сирәгрәк очрый.

Югарыда сөйләнгәннәрдән чыгып, тагын да гомумирәк характердагы нәтиҗәләр ясарга була.

Беренче шигырьләренең чит тел элементлары, сүзләре һәм грамматик формалары белән артык чуарланган булуы үзенең тамыры белән бер-берсенә тыгыз бәйләнгән ике моментка барып тоташа.

Иҗатының беренче чорында әдәби жанрлар, әдәби формалар, шигъри алым һәм үлчәү өлкәсендә киеренке эзләнүләр алып бару белән бергә, Тукай әдәби тел һәм аның стильләрен камилләштерү, үстерү юлларын ачыклауда да күп эшли. Бу үз чиратында әдәби телне халыклаштыру эшен нык тизләтә.

Аннан соң, тантаналы хисле, ода тибындагы югары пафослы шигырьләр иҗат итәргә кирәк булганда, шулай ук комик эффект тудырырга кирәккәндә яки пародияләр язганда, Тукай аңлы рәвештә гарәп-фарсы, төрек-угыз лексикасына мөрәҗәгать итә. Тукайның беренче чор шигырьләренең төп әдәби үзенчәлеге шунда, беренче юлдан алып азаккы юлга кадәр алар, гүяки, бер төрле рифмаларның озын чылбыры белән уратылып алынган булалар. Шул рәвешчә көнчыгыш поэзиясендә киң таралган монорим шигырьләр барлыкка килә.

Бу нәрсәләр исә, табигый, аның беренче әсәрләренең теленә дә тәэсирсез калмый. Төп татар сүзләреннән һәм грамматик элементларыннан тыш, Тукай әсәрләрендә бик күп гарәп-фарсы, төрек-угыз элементлары, искергән сүзләр һәм кушымчалар очратабыз. Сирәк кенә рус теленә хас элементлар да күренгәли.

Башлангыч чоры белән чагыштырганда, соңыннан Тукай шигърияте зур үзгәрешләр кичерә. Һәм бу үзгәрешләр, барыннан да бигрәк, шигъри телнең тамырдан яңаруында гәүдәләнәләр.

Тукай шигъриятендәге чит тел элементларын тикшерү шуны күрсәтә: әдип шигырьләренең стиле, лексикасы, телендә барган үзгәрешләр, бер тамчы судагы кебек, гомум татар әдәби телендә барган процессларның динамикасын, төп тенденциясен дә чагылдыра.

Әлеге күзәтү тагын шул фикерне куәтли: әдәби телнең гади халык сөйләменә нигезләнеп формалашуы һәм үсүе тарих барышы белән акланган мәҗбүрият икән, бары шул юл гына әдәби тел үсеше өчен чикләнмәгән мөмкинлекләр ача.

◇ ◆ ◇

С. Латыйпова

# ТАТАР СТУДЕНТЛАРЫ һӘМ РЕВОЛЮЦИОН ХӘРӘКӘТ



Россиядәге азатлык хәрәкәтендә Казан студентлары күренекле урынны алып тора. Студентлар арасындагы буталышлар, сходкалар, революцион түгәрәкләр һәм җәмгыятьләр, яшерен әдәбият тарату, Россиянең башка районнарындагы революцион фикерле яшьләр белән бәйләнешкә керү — болар барысы да аларның революцион активлыгын күрсәтә торган фактлар. Студентлар арасындагы бу хәрәкәт, В. И. Ленин әйткәнчә, иң төп массовый эшлеклесен разночинецлар тәшкил иткән бөтен Россия күләмендәге демократик хәрәкәт белән тыгыз бәйле була. Нәкъ менә Казан студентларының күпчелеге разночинецлар булган. 1857—1860 елларда ук Казан университетында укучыларның җитмеш проценты диярлек разночинецлар булган.

В. И. Ленинның «...студентлар башка җәмгыятьтән аерым түгел һәм шуңа күрә алар үзләрендә җәмгыятьнең барлык политик группировкаларын чагылдыралар» [1],— дигән сүзләре тулысы белән Казан студентларына да карый.

Буржуаз тарихчылар хәзергә кадәр әле рус булмаган халыкларның, шулар исәбеннән татар халкының да, революцион хәрәкәттә катнашуын танымаска тырышалар. Мондый караш һич тә тарихи дөреслеккә туры килми.

XIX йөзнең алтмышынчы елларында Казан студентларының активлыгы гаять тә киңәя. Шул ук елларда татар мәгърифәтчелеге дә үзенең беренче этабыннан (Сәгыйть һәм Ибраһим Хәлфиннар, С. Кукляшев, А. Ваһапов, М. Мәхмудов, Х. Фәезханов эшчәнлекләре) Каюм Насыйри башлап җибәргән икенче этабына күчә. Ә студентлар арасындагы революцион хәрәкәтнең мәгърифәтчелеккә йогынтысы зур була.

Ибраһим Хәлфин, Салихҗан Кукляшев кебек татарның беренче мәгърифәтчеләре үк үз эшчәнлекләрен шул заманның алдынгы иҗтимагый-политик карашлары белән тыгыз бәйләгәннәр. Ә бу заманда географик һәм административ яктан Казан шәһәре хөкүмәткә каршы революцион фикерле кешеләр өчен сөрген урыны булып хезмәт иткән.

Мәсәлән, 1824 елда Адам Мицкевич һәм Осип Ковалевскийларның якын дусты, күренекле поляк революционеры Ян Верниковский Казанга сөрелә. Ян Верниковскийның укытучы булып эшләргә сәләтен билгеләү өчен Ибраһим Хәлфин, профессор Франц Эрдман белән бергә, аңардан имтихан алырга тиеш була. Ибраһим Хәлфин Ян Верниковскийга, хөкүмәткә каршы кеше булуына карамастан, бик яхшы отзыв бирә. Шул отзыв нигезендә Верниковскийны Беренче Казан гимназиясенә гарәп һәм фарсы телләре укытучысы итеп билгеләләр. Моннан Хәлфинның политик карашлары буенча Верниковскийга теләктәшлек белдергән булуы күренеп тора.

Ян Верниковский Казанда сөргендә вакытта үзенең дуслары белән элемтәне өзми, Адам Мицкевичтан яшерен әдәбият алып тора, Тодеуш Костюшконың восстаниегә чакырып язган өндәмәләрен яшереп

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. 7 том. 348 бит.

саклый. Соңрак ул Казаннан да сөреләә һәм ул вакытта Вяткада сөргендә булган А. И. Герцен үзенең «Былое и думы» әсәрендә Вятка гимназиясенә җибәрелгән күренекле ориенталист Верниковский турында искә ала.

Салихҗан Кукляшев та поляк революцион эшлеклеләре белән бәйләнештә торган булырга тиеш. Эш шунда: берничә прогрессив журналларда эшләгән, үзенең иҗтимагый-политик карашлары белән Н. Г. Чернышевскийга, Н. А. Добролюбовка, Т. Г. Шевченкога якын торган күренекле поляк революционеры Сигизмунд Сераковский, 1848 елдагы революцион вакыйгалардан соң, Оренбург шәһәренә урнашкан линейный батальонга сөрелә. Анда ул 1856 елга кадәр була. Шунысы кызыклы: ул француз, немец, инглиз телләреннән башка татар телен дә яхшы белгән [1]. Ә нәкъ шул вакытта С. Сераковский хезмәт иткән хәрби корпус карамагындагы Неплюев хәрби училищесында татар мәгърифәтчеләренең берсе Салихҗан Кукляшев та эшләгән. Көнчыгыш телләре укытучысы буларак, С. Кукляшев С. Сераковскийга татар телен өйрәнергә ярдәм иткән булса кирәк.

Патша хөкүмәтенең азчылык милләтләргә каршы колониаль, руслаштыру политикасы татар яшьләренә университет ишекләрен яба алмый. Алай гына да түгел, университетта укучы татар студентлары демократик хәрәкәтләргә, студентлар арасындагы күтәрелешләргә дә актив катнашалар.

Менә шундый фактлар билгеле: татар студенты Габдрахман Габдрахимов, үз тормышын куркыныч астына куеп, Себердән качкан тоткыннарны яшереп тота. Әгәр моның өчен Габдрахимов күп мәртәбәләр һәм төрле формада җәзага тартылган икән, димәк, бу качкыннар гади тоткыннар гына булмаган [2].

Мәгариф министрлыгы таләбе буенча Казан уку-укыту округы университетта һәм гимназиядә укучы яшьләрнең фикер йөртүләре турында хәбәр җибәреп торган. Шундый хәбәрләрнең берсендә, 1863 елда, чыгышы белән татар булган күп кенә укучыларның исеме саналган. Алар арасында Сембер гимназиясе укучылары М. Дамиров белән П. Тәфкилев, Оренбург гимназиясе укучысы Н. Акмәмәтов, Пенза дворяннар институты студенты И. Дәүләткильдиев, Беренче Казан гимназиясе укучылары Әбүсәгыйть Әхтәмов, Гатиатулла Бикмиев, Садыйк Мөхәммәдиев, Мөхсәет Вәлитов, Мәндиар Туктамышев, Мостафа Котлыбаев һ. б. бар.

Яшьләрнең фикер йөртүләре белән хөкүмәтнең кызыксынуы юкка гына түгел. Ул алар арасына азатлыкка омтылу идеяләре, хөкүмәткә каршы фикерләр үтеп кергәннән шикләнгән. Ләкин, шулай әзерләнеп торуга карамастан, татар укучыларының күбесе студентлар хәрәкәтенә, хөкүмәткә каршы чыгышларга актив катнашалар. Югарыда исеме телгә алынган Мостафа Котлыбаев, мәсәлән, Казан гимназиясен бетереп, университетка укырга кергәч, студентлар хәрәкәтенең күренекле җитәкчеләре Сомов һәм Гауэнштейн белән танышa, алар белән бергә студентларның хөкүмәткә каршы чыгышында катнаша [3]. III курста укыганда Котлыбаев, Сомов, Гауэнштейн, Лохтин, Решетников, Попов, Иванов һ. б. белән бергә, гаять кыю адым ясый — губерна дворяннар йортында спектакль барган вакытта, полицейскийлар ыгы-зыгы килеп торуга карамастан, хөкүмәткә каршы прокламация-өндәмәләр тарата [4].

Татар студентларының революцион хәрәкәтләргә катнашуын тасвирлый торган документларны архивлардан күп табарга мөмкин.

Менә шундый бер вакыйга.

1856 елның 2 декабрендә кичке сәгать 9 да, Казан полицмейстеры язганча, Измаил Салих улы Рәҗәпов, П. Г. Страдин, В. Ф. Понизовский белән берлектә, патша хәрби офицерының намусына һәм дәрәҗәсенә тап төшерә торган адым ясый. Бу, бәлки, егетләрнең гади бер шаяруы гынадыр? Һич тә түгел. Ул вакытта полицейскийлар белән бергә, хәрби офицерларга да студентлар артыннан күзәтү эше тапшырылган була.

Рәҗәпов, 1856 елда Беренче Казан гимназиясен алтын медаль белән бетереп, университетның медицина факультетына кабул ителә. Университетта ул юридик факультетның IV курс студенты, Сембер шәһәрендә үк пропаганда түгәрәге оешты-

---

[1] «1863 елгы восстание һәм 60 елларда рус-поляк революцион бәйләнешләре». Мәскәү. 1960. 77 бит.

[2] ТАССРның дәүләт архивы. 1 ф. 2 саклау берәмлеге. 443 арх. 68 б.

[3] Шунда ук, 92 ф. 1 саклау берәмлеге. 8968 арх. 1 бит.

[4] ТАССРның дәүләт архивы. 92 ф. 1 саклау берәмлеге. 8968 арх. 1 бит.

руда тәҗрибәсе булган Н. Саковкин белән аралаша. Ә Саковкин Мәскәү университетыннан куылып, Казан университетына укырга керергә йөрүче Шешуков белән бер бүлмәдә яши торган була. Шешуков Казан университетына кабул ителмәү генә түгел, Рәҗәпов чыгарган җәнҗалдан соң, мәгариф министры кушуы буенча, шәһәрдән үк куыла [1].

Бу вакыйгадан соң Измаил Рәҗәпов һәм аның иптәшләре университеттан чыгарыла. Шушы ук приказында министр соңыннан күренекле революцион эшлеклеләр булып әверелгән А. Яновский, В. Попов, В. Билярский, И. Умнов һ. б.ларны да төрле сәбәпләр белән университеттан куарга боера. Берьюлы 13 студент университеттан чыгарыла. Димәк, Измаил Рәҗәпов университет студентларының алдынгы отрядында була һәм, студентларның революцион хәрәкәтенә актив катнашып, татар халкының алдынгы вәкилләре белән азатлык өчен көрәшүче рус халкы арасындагы бәйләнешне ныгытуга зур өлеш кертә.

Әхмәтҗан Габделгалләмов та Беренче Казан гимназиясен тәмамлый һәм 1852 елда университетка керә. Ике ел уку дәвамында берничди кисәтү дә алмый әле ул. Әмма IV курста укыганда, 1855 елның 5 февралендә, ул рөхсәтсез-нисез университеттан китә һәм кәне буе кайтмый. Архив документларында аның ул кенне кайда булуы һәм нишләп йөрүе турында берни дә әйтелмәгән. Ләкин шунысы кызыклы: бу вакыйгадан соң Габделгалләмов университеттан чыгарыла. Сәбәбе: «Үз-үзен тотышында әдәпсезлек күрсәткән өчен»,— ул заман өчен бик гадәти сәбәп. Эш анда гына да түгел, шул ук приказ нигезендә элек студентлар кузгалышында актив катнашуы белән билгеле булган Семен Сретенский да университеттан куыла. Шуңа күрә Г. Габделгалләмовның да шул вакыттагы тәртипләргә каршы чыкканы өчен университеттан чыгарылуы шиксез.

Студентлар хәрәкәте киңрәк колач ала барган саен, бу хәрәкәтнең формалары да үзгәрә. 60 еллар башында татар студентлары революцион әдәбият таратуга да турыдан-туры катнаша башлыйлар. Мәсәлән, Казан университеты студенты Г. Алиев крестьяннар арасында «Земля и Воля» оешмасының революцион прокламацияләрен таратуда гаепләнә. III отделение документларыннан күренгәнчә, «Оханск шәһәрендә халыкны патшага каршы, җирне түләүсез алырга чакырып язылган коткы таратучы 10 данә өндәмә табыла». Бу өндәмәдә властьның сайлау тәртибендә урнаштырылырга тиешлеге, «50 миллион халыкка каршы 500 мең солдатның берни дә эшли алмаячагы» әйтелгән була. Бу эш буенча кулга алынган Илья Понамарев ул өндәмәләрне Казан университеты студенты Иван Яковлевич Орловтан алуын, Казанда бу өндәмәләрне бүтән губерналарга таратучы үзәк комитет барлыгын әйтә.

П. Алиев та бу комитетның актив члennарының берсе була. Яшерен тикшерү эшендә Оханскида табылган прокламацияләргә «студентлардан Орлов, Жеманов, Бирюков, Алиев һәм Лаврскийларның катнашы барлыгы» турында әйтелә.

Санап үтелгән студентлар тарихта революцион хәрәкәтнең актив эшлеклеләре булулары белән билгеле. Ләкин моңа кадәр тарихчылар Алиевны ни өчендер телгә алырга теләмиләр иде. Ә яшерен тикшерү эшендә Алиевның революцион прокламацияләр таратуы расланып кына калмый, Казан губернасы начальнигына аны «үзе сизмәслек итеп полициянең каты зәзрлекләве астына алырга» боерык та бирелә. Алай гына да түгел, аңа Казаннан чыгарга да рөхсәт ителми [2].

Озакламый, 1883 елның маенда, Казанның хәрби губернаторына Оханскида прокламацияләр таратуга катнашкан барлык студентларның яшертен рәвештә Казаннан китүләре хәбәр ителә. Астраханьдагы казак гаскәрләре сотнигы улы Алиев 18 апрельдә туган шәһәренә кайтып китә. Ул, зәзрлекләүләргә дә карамастан, Астраханьда да прокламацияләр таратуын дәвам итә.

Шул ук 1863 елда патша властьлары Алиевны «Черняк кушуы буенча, акча, револьверлар һәм коткы сала торган прокламацияләр алып Казанга килгән Ост-Сеньковский катнашында Полиновский квартирасында үткәрелгән җыелышта булуы һәм аның турында хәбәр итмәве» өчен гаеплиләр [3].

Илле кешедән торган Полиновский түгәрәге бик яшертен оешма була. Алиевның бу түгәрәк эшенә катнашуы һәм аның поляк, шулай ук гомумроссия революцион хәрәкәте белән тыгыз бәйләнештә булуы

---

[1] ТАССРның дәүләт архивы. 92 ф. 1 саклау берәмлеге. 7163 арх. 26 бит.

[2] ТАССРның дәүләт архивы. 1 ф. 2 саклау берәмлеге. 1883 арх. 118 бит.

[3] «Красный архив». 1923 ел. № 4. 296 бит.

шиксез. Моны тагы шул факт раслый: патша властьлары Алиевны Андреев дигән кешегә «Офицерларга» дип исемләнгән прокламацияләр тапшыруда һәм «Великорус» дигәнен тапшырырга теләүдә гаеплиләр. П. А. Алиев 1863 елда кулга алына һәм 1864 елның ноябренда 6 елга каторгага хөкем ителә[1].

Казан губернасында күп кенә поляк революционерларының сөргендә булуы рус, поляк, татар халыкларының алдынгы вәкилләре арасында бәйләнешне ныгытуга мөмкинлек бирә. ТАССРның дәүләт архивында табылган документ — 1863 елда Казан губернасында полиция күзәтүе астында торучыларның исемлеге моны ачык раслый. Бу исемлеккә кергәннәрдән Петров, Травин, Васильев кебек танылган революционерлар — «Молодая Россия» дигән кулъязманы таратучылары, университетның элеккеге студенты Семенов — Н. Г. Чернышевскийның теләктәше, Себергә сөрелгән Михайлов белән бәйләнешкә кергәне, Беневитский — Бездндада һәлак булганнарны искә алуда катнашканы, университет студенты Николай Шеффер — «хәзергә хәлендә калса, Россиядә беркайчан да тәртип булмаячак, халыкның шул дәрәҗәдә хәерчелектә яшәвенә төп сәбәп — рус императорларының самодержавие властеь»,— дип белдергәне өчен әзәрлекләнгән. Шул ук исемлеккә кертелгән 17 нче кеше — Казан университеты студенты Сәләхов. Ул Сергач өяз училищесы укытучысы Курбаковский белән хат алышканы өчен исемлеккә кертелгән. Ул хатларда нәрсә язылганы безгә билгеле түгел. Шулай да Курбаковскийны характерлый торган кайбер документлар сакланган.

А. Н. Курбаковский 1861 елда Казан университетына укырга керә. Аның иҗтимагый-политик карашлары А. П. Щапов лекцияләре, «Современник» журналы һәм Герцен «Колокол»ы йогынтысында формалаша. Студентлар хәрәкәтенә актив катнашуы өчен ул университеттан чыгарыла һәм халык укытучысы булып эшләргә керешә. Җәмгыятьнең социаль-политик төзелешендә ул беренче планга «барлык сословиеләрнең тигезлеген» куя. Мондый җәмгыятькә ирешү юлларын Курбаковский үзенең «Побатухи» дип исемләнгән прокламациясендә тасвирлый. Революцион пропаганда рухында язылган бу документта ул крестьяннарны азатлык, тигезлек өчен көрәшкә чакыра.

Болар — күренекле демократ, революционер А. Н. Курбаковский тормышының кайбер фактлары гына. Әмма Сәләхов белән Курбаковский язышкан хатларның революцион-демократик характерда булуына төшенү өчен шулар да җитә булса кирәк. Тагын шунысын да әйтеп үтик, патша властьлары Курбаковскийны кулга алгач та, Казанда Сәләхов та кулга алына.

Шулай итеп, Казан университетында укыган татар студентларының революцион эшчәнлеге, бер яктан, татар халкының алдынгы вәкилләренең мәгърифәт эшчәнлекләре белән бәйле булса, икенче яктан, ул татар мәгърифәтчелегенең узган гасырның 70 елларындагы яңа үсеш этабына аяк басуына ярдәм итә.

---

[1] «Красный архив». 1923 ел. № 4. 296 бит.

# САНДУГАЧ ҖЫРЫ ДӘВАМЛЫ БУЛСЫН

1

Фаил Шәфигуллинның быел Казанда басылып чыккан беренче хикәяләр җыентыгын укыгач, аның 1965 елда «Казан утлары» журналы аша үзе турында әйткән сүзләре искә төште: «Поэзия һәм проза магнит кырлары арасында тартышам. Кайсы җиңәр? Әлегә билгесез». Әйе, «Авылым сандугачы» исемле прозаик китапны поэзияне белгән, яхшы аңлаган һәм яраткан кеше язган, һәм шуңа күрәдер Шәфигуллинның прозасы шактый көчле шигъри хис белән сугарылган. Ә бит чын һәм тирән поэзия һәрвакыт дулкынландыра.

Шулай итеп, мин «Авылым сандугачы»-на гомуми бәяне бирдем дияргә була. Бәлки, моны соңрак эшләргә кирәк булгандыр, әмма мин укучыдан үземә индульгенция — аклану кәгазе — алырга ашыктым: әгәр ул миңа, «проза язмый торып, прозаик әсәрләр турында белгечләрчә фикер йөртергә ни хакың бар?» — дисә, мин аңа: «Бу бит шигъри проза, ә мин азмы-күпме шигырь язган кеше»,— дип җавап бирәм.

Димәк, «Авылым сандугачы» — шагыйрь (яшь шагыйрь) прозасы. Бу беренчедән. Икенчедән, бу китап инде шактый күпне күргән, күп эшләрне эшләп өлгергән яшь кеше китабы. Мин укучының игътибарын рецензияли торган җыентыкка гына түгел, аның авторына, авторының шәхесенә юнәлтергә телим. Менә нәрсә дигән иде ул үзе турында 1965 елда: «Эш урыннарым:

колхоз кырлары,
Чирәм җирләр,
Пермь урманнары,
Находка төзелешләре,
Ерак Көнчыгыш
һәм Төньяк диңгезләре,
Тын океан...

Профессиям:

тракторчы, слесарь,
балыкчы, урман кисүче
һәм башкалар.

...Хәзер заводта эшлим, кич укыйм...»

Булачак язучы өчен бик өметле анкета бу, минемчә. Һәрхәлдә, аны тутырган кеше язган китапны мин кызыксыну белән ачтым.

2

Алласы кем бу кешенең?
Дошманы кем?

Әйе, җирдә кискен көрәш барган бу чорда һәр китапка карата куела торган сорауларның иң мөһимнәре әнә шулар бит, хөрмәтле иптәш!

Ә кайберәүләр миннән көләрләр һәм болай диярләр:

— Нинди алласы, нинди пәйгамбәрләре булсын Фаил Шәфигуллинның? Алласыз бит ул! Ышанмасаң, җыентыкка кергән «Тәүге адымың белән, әби...», «Яшьлек хатирәсе» һәм «Өч бөти» исемле хикәяләрне укып кара!

Тик алар белеп торсыннар: алласыз Фаил Шәфигуллинның һәрнәрсәдән изге идеясе бар. Һәм чирәм җирләрне күтәргәндә, Пермь якларында урман кискәндә, Ерак Көнчыгыш диңгезләренең тозлы суы кулларын ашаган минутларда булачак яшь язучының йөрәгендә һәм аңында яшәгән ул идея. Бу идеяне мин Ватан хисе дип атар идем.

Төрле кешеләр — яшь язучының дуслары һәм геройлары — яши бу хикәяләрдә. Үз бәхетләре өчен ахырынача көрәшә белгән Гөлнисалар («Көзге юлда»), аяклары югалтып та горурлыкларын югалтмаган ирләр («Яшел эшләпәле кеше»), кешеләрнең генә түгел, атларның да нинди тугры дус икәнен яхшы белгән Ярулла абыйлар («Айлы төндә»), җырлары белән тойгыларны да, табигатьне дә гүзәл иткән Раушанияләр («Авылым сандугачы»)... Менә син шул Раушаниянең — гади бер студентка кызның җырын тыңлыйсың һәм «бөтен дөньяны онытасың. Тәмам тулып җиткән ай Гөбенә суына ташып ага; су читенә үк килеп тирәлгән җәйләү киртәлә-

ре, көмеш яфраклы тал куаклары, гаҗәеп авазлар дулкынында тирбәлә-тирбәлә, каядыр еракка, зәңгәр томан эченә шуыша. Зур булып ачылган күзләрне дымлы пәрдә каплый. Әллә ниләр эшлисе, әллә кайларга китәсе килә...» Чү, шунда тукталыйк. Әллә кайларга, ләкин читкә, чит, ят илләргә түгел. Һәм, китсәң дә, мәнә шушы көмеш яфраклы талларга, сипкелле борынлы көләч Раушанияләргә, томаны да соры түгел — зәңгәр булган дөньяга хыянәт итеп түгел!

Һәм дезертир Сәетнең актык минутта күз алдында җилфердәгән кызыл комач кисәге — совет танкерының флагы, безнең флаг — ул Ватан хисенең иң югары ноктасы, теге зәңгәр томаннарның, көмеш яфраклы талларның символик квинтэссенциясе!

Менә алласы кайда Фаил Шәфигуллинның.

### 3

Ә дошманы кем аның? Ул дошман — инвалидны ертлач иткән, кешене комсыз рационалист иткән, аны куркаклыкның колы иткән һәм бу колны туган җиренә хыянәт итүче дезертирга әверелдергән, гомумән, кешене горур, кыю, гүзәл кешелеклелек рамкаларыннан чыгарган характерларның җыелмасы.

Шунысы куанычлы, яшь язучы ул характерларны безнең алга катып калган статуя иттереп китереп бастырмыйча, аларның туу, килеп чыгу юлын күрсәтергә тырыша. «Ничек булды соң әле бу?» «Көзге юлда» исемле новелланың герое Гөлниса куйган шушы сорауны, чынласаң, китапның бик күп битләрендә автор үз алдына куя һәм аңа җавап эзли.

Дөресен әйтергә кирәк, кайбер хикәяләрдә эзләнүләр ашыгыбрак алып барыла. Мисал итеп әлеге «Көзге юлда» исемле хикәядә бирелгән Харис образын алыйк. Менә аның портретын тасвирлый торган җөмлә: «Гөлниса сискәнеп китте һәм берничә секунд Харисның тар, шома маңгаена, әллә кая, бик эчкә, күз чокырына үк кереп яшеренгән төссез күзләренә карап торды». Монда тискәре типка алдан ук заявка бирелгән, хикәя әле башланып кына китә, ә акцентлар инде куелып та чыккан. Хикәянең ахырында да әдәби штамп бар: «Кинәт кенә көнбатыштан салкын җил өрде. Таллык өстендәге кургашын болытларның бер чите аз гына ачылып китте дә, көз кояшының згыйфь нурлары юл буендагы чирәмлектән ашыга-ашыга авылга таба атлаучы кызның килешле буй-сынын, горур йөзен яктыртты. Ләкин ул нурлар, атын юлга аркылы куйган килеш, алма әрҗәләре өстендә башын тотып утыручы кешегә барып җитә алмадылар...» Димәк, кояш яхшы кешене генә яктырта, ә начар кешенең өлешенә кояш нурлары да тими. Мондый «кул астында» гына яткан параллельлекләрдән барыбызга да сак булырга кирәк, минемчә.

Китапның шактый зур өлешен алып торган «Дезертир» исемле хикәядә дә кимчелекләр юк түгел. Ике моментны күрсәтеп үтәсе килә. Беренчедән, хикәядә әдәбилек (литературщина) шактый нык сизелеп торган урыннар бар (мисал өчен Сәетнең японнар кулына төшүен тасвир иткән битләрне алырга була). Икенчедән, хикәяне сөйләп чыгучы Тимершин кулына төшкән дәфтәрнең теле, егерме ел Ватаныннан читтә яшәгән татар эмигрантының теле булганга күрә, хәзерге татар әдәби теленнән ничектер аерылып торырга тиеш иде. Әмма ул хикәянең бүтән өлешендә һәм хәтта китапка кергән кайбер башка новеллаларда кулланган телдән аерылмый диярлек. Бу кимчелекләргә карамастан, үзенең хикәясендә, «Ничек булды соң әле бу?» дигән кыен сорауга Фаил Шәфигуллин уңышлы гына җавап бирә.

Ничек булды соң әле бу? Ничек итеп Сәет дезертир булган? Бит Сәет тә, аның иптәше Тәнзил дә бер үк җирдә туганнар, бер үк авылда үскәннәр, аларның кеше булып формалашуына бер үк объектив факторлар йогынты ясаган. Әмма тормышның кискен бер моментында аларның үзенүзе тотулары төрлечә булып чыга: Тәнзил атакага күтәрелә һәм туган җире өчен һәлак була, ә Сәет сугыш кырыннан качып китә. Нигә алай?

Эш субъектив факторда. Сәетнең характерында. Менә Сәетләр, Тәнзилләр сугышка китәләр. «Киткән чагымда мин үзем дә тилерә-тилерә, башымны арба төбенә бәрә-бәрә еладым»,— дип яза дезертир үзе турында.— Ә бит шуннан берничә көн генә элек фермада тирес түккәндә кызларга: «Иртәгә үк районга барып, фронтка җибәрүләрен сорыйм»,— дип мактанып йөргән идем».

Әйе, сугышка киткәндә бик күп кеше елап китте. Балачакның кайбер көннәре хәтергә сеңеп кала торган була, ә дәһшәтле 1941 елның июнь һәм июль айлары йөрәккә һәм мигә биграк та тирән уелып

калган. Елаган ирләрне, егетләрне күп күрдем, әмма үзен-үзе җиргә бәрә-бәрә елаганны никтер хәтерләмим. Андыйлар да булгандыр, билгеле, әнә шундый Сәет кебекләр. Ерак юлга чыкканда үземә юлдаш итеп алмас идем мин үзен-үзе бәреп елаучыларны: мондый кешеләр йомшак ихтыярлы булалар.

Гадәттә андый кешеләр үзләрен кирәгеннән артык яратучан да була. Менә Сәет сугышка барганда үзе кызыгып йөргән Хәлимә исемле кызның Тәнзилне яратуын белә. Һәм куркаклык хисен көнчелек алыштыра: «Ә бит Тәнзил безнең арада почтальон булып кына йөргән иде. Кара, кара, Хәлимәгә карап елмайган була тагын! Ах, мут суфый!..»

Тәнзил сугышка үзе теләп китүен сөйли, һәм Сәет аның бу изге омтылышын шик астына куя: «Буен үлчәгән чак ничек итеп аяк очына басып торуын, тәртип бозган өчен өлкән врачның аның куып чыгаруын, аннан тагын военкомга, тагын өлкән врачка керүен сөйләгәндә, ни өчендер миңа Тәнзил ялганлыйдыр, үзенең кайгысын кешегә белдермәс өчен генә шулай ике йөзләләнеп матаашадыр кебек тоелды». Бу ышанмау Сәетнең характерына тагын бер штрих өсти: ул үзе алай эшләмәс иде.

Менә тагын бер өзек:

«Сайра әле, сайра,— дип уйладым мин Тәнзилнең әллә нинди эчке рухлану белән яктырып киткән йөзенә гаҗәпсенеп карап.— Тегендә баргач ничек сайрарсың икән». Тәнзилдә үзендә булмаган көчле рухлы кеше сыйфатларын күреп, аларны тулысы белән аңламаган һәм шул ук вакытта алардан көнләгән кеше уйлары бу. Һәм без аның усал кеше икәнен сизәбез.

Хикәяне укыганда Сәетнең рухи йөзе ачыкланганнан-ачыклана бара. Һәм хикәянең иң киеренке урынында — Тәнзилләр атакага күтәрелгән минутта Сәетнең тылга качып китүе безнең өчен кинәт, көтелмәгәндә булган хәл түгел. Аның сугыш кырындагы уйлары да, эшләре дә, дезертирлыгы да — барысы да инде күптән, хәтта сугышка кадәр үк, балалык һәм үсмер елларында формалашкан табигатенең, характерының дәвамы.

Җыентыкка кергән «Хыялбай» исемле хикәясендә Фаил Шәфигуллин буш хыялчы Маниловның бүгенге токымы — Ризван исемле малай турында яза. Башта Ризван очучы булырга хыяллана, ләкин «дүртенче класста укыганда, кем авызыннандыр кай яктадыр ниндидер бер самолетның җиргә егылып челпәрәмә килүен ишеткәч», ул хыялыннан баш тарта. Аннан соң ул шоферлык турында уйлап йөри башлый, тик, җирдә йөргән машиналарның да аварияга очраулары мөмкин икәнен белгәч, бу хыялыннан да ваз кичә... Ниһаять, бу хыялый сабантуйда кузла өстендә көрәшүчеләр арасында җиңүче булып чыгарга карар итә. Тик чынлыкта, сабан туе көне җиткәч, кузладан очып төшкән, хурлыкка калган Ризванны көрәш мәйданыннан ашыгыч ярдәм машинасы алып китә... Хикәядә юмор бар, аның стиле «Дезертир» стиленнән аерылып тора, һәм бу ике әсәр арасында һичнинди дә бәйләнеш юк. Тик шунысы кызыклы: Ризван образы Сәет образын аңларга ярдәм итә. Чыннан да, йомшак ихтыярлы, хыялларын перчатка урынына алыштыра торган Ризваннардан дезертир Сәетләр килеп чыгуы бик ихтимал нәрсә.

## 4

Фаил Шәфигуллинның пәйгамбәрләре дә бар. Аларның иң әһәмиятлеләре, минемчә, өчәү: лирик хис, юмор, татар теленең алтын хәзинәсен яхшы белү. Бу пәйгамбәрләрнең беренчесе турында рецензиянең башында әйтеп үткән идем инде. Хәзер фикеремне куәтли торган мисал китермәкче булам.

Яшерен-батырын түгел, җыентыкка кергән хикәяләрнең миңа иң ошаганы — «Ана күңеле». Ул китаптагы иң кыска хикәя һәм үзенең саран, ләкин йөрәккә үтеп керә торган, бер үк вакытта бик реаль һәм бик лирик җөмләләре белән шигъри әсәргә якын. Аның эчтәлеге гади: яңгырлы, яшенле бер төндә Сәлия исемле кыз һәм аның карт әнисе өйләрендә шул төнге яңгырны, күк күкрәвен тыңлап яталар. Ана менә инде биш ел туган өенә кайтмаган, читкә киткән «юньсез» малае, Рәхиме турында уйлый...

Тагын күк күкри, һәм без бу көчле стихия тавышын ишеткән кебек булабыз: «Бу аваз тоныклана барып, кайдадыр кибетче Шакирҗаннар турысында булса кирәк, бөтенләй юкка чыкты». Менә кайда гадилек һәм төгәллек!

Сәлия, дә, әнисе кебек, Рәхим турында уйлап ята. Егет өч ел моннан элек: «Кайтам, көтегез»,— дип телеграмма да җибәргән. Үзе кайтмаган, хат язган: «Исәнсау. Өйләндем. Быелга кайта алмыйм». Шуннан соң хаты булмаган... Менә хикәянең ахыры: «Ишек шыгырдаганы ишетелде. Сәлия сагаеп тыңларга кереште. Идән

такталарына су тамчылары агыза-агыза ишек төбендә кемдер йөри иде.

— Әни, синме ул?

— Мин,— диде хәлсез карчык тавышы,— әле син дә йокламыйсыңмыни?.. Кичә почта ящигын карарга онытканмын, имеш. Хат-мазар килеп чыланып ятмасын дип чыккан идем... Карале, кызым, абыең соңгы хатында плащ алам дип язган идеме әле? Алды микән соң, ходаем... И ява инде... Бер генә учы-кизе юк, тач көзге яңгыр...»

Бу юллар яхшы шигырьнең көчле тәмамланышын хәтерләтәләр. Менә ул ана мәхәббәте нинди була, ышанасезме, шәфкатьсез, ваемсыз уллар?

«Айлы төндә», «Авылым сандугачы» исемле хикәяләрдә дә лирика тантана итә.

Юмор язучының икенче таланты, диләр. Һәм бу талант та Фаил Шәфигуллинда бар. (Аның икенче таланты — икенче пәйгамбәре!) Көлке, юмористик ситуацияне ул яхшы сизә һәм сурәтли белә. Менә динле әбине оныгы әлифба укырга өйрәтә («Тәүге адымың белән, әби...»): «...Беркөнне ахшам намазына егылган җиреннән әби бөтенләй төсе китеп, дерт итеп сикереп торды:

— Кызым, зинһар, икенче күземә күрсәтмә теге китабыңны. Шул шайтан сабагы белән әллә ничә тапкыр намазымны боздырдым. Дога укыйм дисәм, тел очыма әллә нинди «барабаннар», «балаганнар» килә, гөнаһ шомлыгы...» Әһә, теге китап әби аңына да юллар сала башлаган икән, аның менә шушы «дерт итеп» сикереп торуын, аптырау катыш көлке сүзләре вакыйганы бик реаль итеп күз алдына китереп бастыра.

Хикәяләрдәге аерым детальләр дә, дөрес сизелгән юмористик рухта бирелсәләр, бик тормышчан булып чыгалар һәм истә калалар. «Казыкка элеп куйган тары көлтәсе шикелле, ике якка салынып төшкән кызгылт мыеклар» («Яшел эшләпәле кеше») һәм динле карчыкның «яулык читләре белән бик җентекләп авыз тирәләрен томалап маташуы» да («Яшьлек хатирәсе») нәкъ шундый уңышлы детальләр рәтенә керәләр.

Һәм, ниһаять, өченче пәйгамбәр турында.

Фаил Шәфигуллин авылда туып үскән, ул авыл тормышын, анда торган кешеләрнең гореф-гадәтләрен яхшы белә. Аның беренче китабы да авыл тематикасына багышланган. Авылда яшәгән булуының Шәфигуллин өчен тагын бер әһәмияте бар: авыл — татар теленең нигезе, чыганагы, чишмәсе. Шул чишмәнең суын эчеп үскән яшь прозаик үзенең китабында татар телен, аның нечкәлекләрен, аның нәфисләгән яхшы белүен күрсәтә. Мисал өчен аның «Яшьлек хатирәсе» исемле хикәясеннән бер өзек китерик:

«Чит-читләренә күе булып әнеч, бәбкә үләне катыш ямь-яшел чирәм үскән сукмак буенда, фәкать ир токымына гына хас үҗәтлек белән тырыша-тырыша кәҗә сакалы кимереп утыручы алача штанлы, кызыл чәчле, сипкелле малай ялт итеп миңа күтәрелеп карады. Аннары, кәҗә сакалы тамырларын артына яшерә-яшерә, мыштым гына аягына басты һәм акрынлап болдырга таба чигенә башлады. Аның: «Әби»,— дип шәрран ярып сөрән салуы, рамнары элек сарыга буялган булса да, хәзер буявы уңып, төссезләнеп калган фанер капкачлы тәрәзәдән ишек алдына ургылып чыкты».

Монда сүзләр берсе берсенә үрелеп укучының күз алдына җанлы, буяулы, тавышлы, бик үзенчәлекле картина китереп бастыралар. Сирәгрәк кулланыла торган «алача», «болдыр», «шәрран яру», «сөрән салу» кебек сүзләр бу картинаның шундый җанлы булуына ярдәм итәләр.

Шагыйрь Шәфигуллинның прозасында җөмләне матурлата торган аллитерацияләр очрый, менә аларның бер үрнәге: «кара кашлары карлыгач канаты кебек» (кыз турында, «Яшьлек хатирәсе» исемле хикәядән). Монда таргык «к» авазы бер үзе генә түгел,— ул беренче дүрт сүздә сузык «а» авазы белән бергә «ка» булып кабатлана.

Кирәк чагында автор хикәяләренә махсус терминнар да кертә. Мәсәлән, «Дезертир» исемле хикәядә «кранец», «форштевень», «штормтрап» кебек диңгез терминнары бар. Әмма, искәрмә итеп, бу сүзләрнең аңлатмаларын бирергә кирәк иде, укучыларның кимендә туксан проценты диңгезче булмагандыр, шуңа күрә «форштевень» кебек сүзләрнең мәгънәсен алар бөтенләй аңламыйлар дип әйтергә була, ә чит телләрдән кергән терминнар сүзлеге һәрвакыт кул астында булмый. Бу кечкенә төгәлсезлеккә, автордан башка, китапның редакторы да гаепле.

5

Китапта очраган кайбер кимчелекләр турында да әйтеп үтәсе килә. Аларның бер өлешенә югарыда тукталып узган идек инде. Алдан ук акцентлар куеп чыгуны

«Көзге юлда» исемле хикәядә генә түгел, «Яшел эшләпәле кеше»дә дә очратабыз. Менә уңай геройның портреты бирелә: «Киң җилкәле, чигә чәчләренә чал керә башлаган...» Автор безне алдан ук кисәтеп куя кебек: «Саташтырмагыз, бу яхшы кеше!» Бу арзан алым, һәм динамикада, үсештә бирелгән Ярулла, Сәет, Ризван, шул ук «Яшел эшләпәле кеше»дәге Таһир образлары белән Фаил Шәфигуллин үзе үк бу арзан алымны инкарь итә.

«Галимҗан бабай табышмагы» исемле хикәя миңа ошап җитмәде. Бу хикәя җыентыкка кергән һәм завод тематикасына багышланган бердәнбер әсәр, хәер, монда эшчеләр тормышы бөтенләй тасвирланмый диярлек.

Менә аның кыскача эчтәлеге. Элек үзе эшләгән заводка пенсионер Галимҗан бабай килеп йөри. Билгеле, ул киткәннән соң цехларга яңа станоклар куялар, автомат участогы барлыкка килә. Ләкин пенсионер картка нидер ошамый. Эш нәрсәдә? Бу сорауга бабай табышмак белән җавап бирә: янәсе, завод моннан ун ел элек нинди булган булса, бүген дә шулай. Бер елдан соң Галимҗан бабай тагын килә, бу юлы заводтан, цехтан бик риза була. Табышмакка да җавап табалар. Хикмәт завод янындагы бакчада икән, анда Галимҗан бабайлар утырткан алмагачлар үсә. Башка елларда ул алмагачларның алмаларын июль башында ук өзеп бетергәннәр, ә бу юлы август ахырында да алмалар ботакта. Билгеле, бу мораль, этик мәсьәлә дә мөһим. Әмма зур завод, яңа станоклар фонында бирелгән интригалы табышмакның җавабы канцелярия бүлешмәләрендә генә очрый торган коры аңлатмага кайтып калуы мине, укучыны, канәгатьләндермәде. Бу бер. Икенчедән, бер ел эчендә завод эшчеләренең шундый «тәрбияле» егетләргә әйләнүе ничектер ышандырмый. Алай да була торгандыр, ләкин бу очракта тәрбияләү процессын күрсәтергә кирәктер дип уйлыйм.

«Әллә йокладыңмы, якташ?..» исемле хикәядә куелган мәсьәләнең чишелеше дә, минемчә, артык оригиналь түгел. Химия белән кызыксынган кызлары читкә, укырга китә дип куркып йөргән ата белән ана хикәянең ахырында кызларының читкә китмәячәген һәм колхозда агрономия кабинетында лаборантка булып калачагын белә. Хикәя инде шактый тәҗрибәле хикәяче кулы белән язылган, әмма аның үзенчәлекле үзәге, «төше» юк.

Әйе, китапта кимчелекләр бар, әмма аның йөзен кимчелекләр түгел, уңышлар билгели: яшь язучының беренче проза җыентыгы уңышлы һәм кызыклы булып чыккан.

«Авылым сандугачы» кечкенә бүлмәдә, тар читлектә тавышсыз-тынсыз утырган бичара кошчык та, кайбер Хыялбайлар башында пәйда була торган абстракт, җансыз җырчы да түгел,— ул гүзәл тавышлы кош булып, тормыш кошы булып туган. Сайравы кешеләрне соклындырсын, үзе озын гомерле булсын!

Исемен бөтен җыентыкка биргән хикәядә яшь автор үзе балачакта тыңлаган сандугачны ниндидер бер малайның таш атып куркытуы һәм сандугач җырының яртыюлда өзелеп калуы турында яза. Хәзер без әйтә алабыз: гүзәл кошның җыры яңадан ишетелә. Дәвамлы булсын ул җыр: яңа, талантлы китаплар көтәбез Фаил Шәфигуллиннан!

**КАМИЛ МОСТАФИН**

# КЕШЕЛӘР һӘМ ЧӘЧӘКЛӘР

«Кешеләр һәм чәчәкләр» — Әлмәт әдәби берләшмәсе чыгарган өченче китап. Әсәрләре бу китапка кертелгән авторларның әдәби стажлары төрлесенеке төрлечә. Аларның күпчелеге үзләрен вакытлы матбугатта танытып өлгергән кешеләр булса, ә кайберләре исә әдәбиятта беренче адымнарын гына ясыйлар әле. Барлыгы унбиш автор. Димәк, унбиш төрле биография. Әхмәт Вильданов — укытучы, Флера Гыйззәтуллина — тегүче, Рафаил Субаев — рәссам, Марсел Зарипов — журналист, Зәһәр Гатауллин — нефть чыгаручы оператор, Нариман Касыймов — зоотехник, Җәүдәт Исмәгыйлов — артист. Профессияләре генә түгел, аларның уй-тойгылары да, язган әсәрләренең сыйфатлары да төрлечә.

Иҗатына карап һәрбер авторның биографиясен төсмерләргә була диләр. Минемчә, Ә. Вильданов Бөек Ватан сугышында катнашып, утлар-сулар кичкән кеше булырга тиеш. Аның «Юллар җыры» исемле шигыре әнә шул турыда сөйли төсле. Җиңү яулап алганчы, солдат күпме авыр юллар үткән, күпме иптәшләрен югалткан. Шуларның барсын үз җилкәсендә кичергән кеше генә болай йөрәкләргә үтеп керерлек җылы итеп язарга мөмкин.

Ә. Вильдановның һәрбер шигыре, ул нинди генә темага язылган булмасын, юморга бай. Менә «Вахта җыры» шигыреннән бер строфа:

Верховой дус, шәмнәреңне
Җитез күчер:
Бүрегеңә болыт кунган —
Бәреп төшер!

Яки менә «Яңгыр» шигырен алып карыйк. Яңгыр турында күп яздылар инде. Ләкин күп тапталган тема булуына карамастан, Ә. Вильданов аны үзенчә хәл иткән, яңача чишкән.

Шыбыр-шыбыр,
Мин шифадыр,
Коенсын гөл,
Туенсын җир:
Кинәнсен бер
Әлмәт, Шөгер.
Гөлдер-р-р!

Ә. Вильданов — үзенчәлекле һәм сәләтле шагыйрьләрнең берсе. Кызганычка каршы, җыентыкка аның барлыгы өч кенә шигыре кертелгән...

Җәүдәт Исмәгыйловның да шигырьләре образлы матур тел белән язылган. Ул лирик геройның кичерешләрен тормышчан, җанлы картиналар аркылы бирә белә. «Ләйсән яңгыр килә сибәләп», «Кеше үзе дөнья куйгач та» шигырьләре шундыйлардан.

Рафаил Субаевның шигырьләре мәсәл формасына якынрак язылганнар. Ләкин аларның мәсәлләрнеке кебек морале булмаса да, алар болай да бик яхшы аңлашылалар. «Бизәкләр», «Үз үлчәве», «Әңгәмә» шигырьләрен алырга була. Соңгысы менә шундый:

— Дустым керпе,— диде төлке,—
Нинди матур булыр иден
Инәле туныңны салсаң...
— Дустым төлке,— диде керпе,—
Салыр идем,
Тешләреңне алдырырга
Син врачка барсаң.

Флера Гыйззәтуллинаның шигырьләре кеше тормышының авыр, кайгылы минутларына багышланган. Берәүне ашыгыч ярдәм машинасы белән больницага алып баралар («Сүнмә, йөрәк»), Бөек Ватан сугышы еллары, баянчы чигән малаен һәм тагын кемнәрнедер фашистлар аталар («Үз авазы»). Шунсы характерлы, алар берсе дә сыкраулы тонда түгел, ә оптимистик рухта язылган. Ә менә «Мәк чәчәге» шигыре, шома тел белән язылган булуына карамастан, күңелдә әйбәт тәэсир калдырмый, чөнки ул безгә берни дә

яңалык алып килми: такыр юл кебек таптапып беткән иске фикерне кабатлау гына булып калган.

Имам Шәрәфетдиновның «Айсылу» исемле поэмасын укып чыкканнан соң көрсенеп, авыр сулап куясың. Поэманың геройлары Айсылу белән Галимҗанның язмышлары гына ясалма түгел, әсәрнең сюжеты да шомарып һәм тапталып беткән. Автор конфликтны ничек җиңел генә тудырган булса, аны шулай ук җиңел генә чишеп тә ташлый.

Галимҗан Айсылуны прорабтан көнләп, үпкәләп йөри. Бер кичне клубка барганда, Галимҗан бакча эчендә прорабның мәхәббәтен бүтән бер кызга аңлатып торганын күрә һәм үзенең юкка көнләп йөргәнлеген аңлап ала...

Мәхмүт Газизовның «Маңгай сырлары», Рахмай Хисмәтуллинның «Һаман яңа», Әзһәр Гатауллинның «Кеше туды» шигырьләрен дә укучылар яратып каршы алырлар дип уйлыйм.

Шигырьләр турындагы сүземне Нариман Касыймовның «Бәхетлерәк миннән юк кебек» шигырендәге юллар белән тәмамлыйсым килә.

Кояш көлсә авылыма карап,
Су өстендә йөзсә ак күбек,
Кырлар тулы сары башак күрсәм,
Бәхетлерәк миннән юк кебек,

— ди автор, җирдә яшәүнең мәгънәсен һәм шатлыгын тоеп.

Хикәяләр турында берничә сүз.

Җыентыкка тупланган хикәяләрнең төп герсйлары яшьләр, безнең замандашларыбыз.

Редакциягә корректор булып эшкә кергән яшь-яшь кыз Рәхимә (М. Зарипов. «Кешеләр һәм чәчәкләр»), медицина техникумын бетереп авылга эшкә килгән шәһәр кызы Гөлсәхрә (М. Хәбибуллин. «Гөлсәхрә»), чирәм җирләрдә эшләүче тракторчы егет Камил (Л. Шәфикова. «Исәнме, Камил!»), авылда тавык фермасында эшләүче кыз Халисә (Н. Шәрәпов. «Күрше авыл егете») — болар бар да эш сөюче хезмәт кешеләре.

Моңа кадәр, күпчелек әсәрләрдә, шәһәрдә туып үскән егетләрне һәм кызларны кире образ итеп тасвирлыйлар иде. Янәсе, алар авылга барырга аяк-кулларын терәп каршы, ә шәһәрдә калырга теш-тырнаклары белән ябышып яталар.

Яңа гына медицина техникумын тәмамлаган шәһәр кызы Гөлсәхрәне башта районга, аннан бер авылга эшкә җибәрәләр. Гөлсәхрә куркып тормый, китә. Бик тиз арада авылны һәм кешеләрен яратып өлгерә. Гөлсәхрә җаны-тәне белән бирелеп эшкә чума... М. Хәбибуллинның «Гөлсәхрә» исемле әлеге хикәясе матур язылган, күңелдә җылы тәэсир калдыра.

М. Зариповның «Кешеләр һәм чәчәкләр» хикәясе дә бу җыентыкка тупланган башка хикәяләрдән үзенең шаян тонда язылган булуы, җиңел теле белән аерылып тора. Ә менә М. Ибраһимовның «Тау белән тау гына очрашмый» һәм Н. Шәрәповның «Күрше авыл егете» исемле хикәяләре йомшак язылганнар. Аларның темалары тар, укучыга әйтәсе фикерләре яңа түгел.


Менә китапны укып чыгып, ябып та куйдык. Әхмәт Вильданов, Җәүдәт Исмәгыйлов, Мөсәгыйт Хәбибуллин һәм Марсел Зарипов кебек талантлы яшьләр килүе безне шатландырса, шушы китапта кайбер төссез, фикерсез, йомшак әсәрләрнең урын алуы күңелне борчып куйгалый. Кечкенә генә китапка унбиш авторның берәр-икешәр әсәрләрен биргәнче, иң яхшыларын сайлап биш авторның әсәрләрен күп итеп биргән булсалар, нинди әйбәт булыр иде.

«Үтәр заманнар, кем белә, шушы җыентыкка беренче әсәрләре кергән яшьләрдән бәлки менә дигән язучылар үсеп чыгар, татар әдәбияты талантлы яңа исемнәргә баер»,— ди Гариф Ахунов шушы китапка язган кереш сүзендә. Аның сүзенә куәтләп, әйткәнең килсен иде диясе килә.

**БУЛАТ СӨЛӘЙМАНОВ.**

## Марзия Фәйзуллина

### Мин кунаклар яратам



Минем әби песиләрнең
Холыкларын шәп белә:
— Әгәр дә песи юынса —
Өйгә, ди, кунак килә.

Шуңар песи юынсын, дип,
Савытына су салам.
Безгә кунаклар килсәләр,
Шатланам да куанам.

### Юк нәниләр әтәче



Безнең кызыл әтәчебез
Уяна да бик иртүк,
Канатларын кага-кага
Кычкыра: — Ки-ке-ри-күк.

Шулай әтәч үз телендә:
— Инде ал таң ата, ди,—
Сызылып таңнар аткан чакта
Кемнәр йоклап ята? ди...

Бик иртә уятасың, дип,
Килә аңар әйтәсем...
Чынлап, нигә безнең өчен
Юк нәниләр әтәче?

## Мин Артектан кайттым

Мин Кырымнан үзем белән
Алып кайттым диңгезне.
Диңгез бик зур, ничек аны
Алып кайттың дисезме?

Бер дә аптырап тормадым,
Суын алдым шешәгә.
Ә шаулавын — ракушкасын
Салып кайттым кесәгә.

Татырга суын тамызам
Телегезгә мин сезнең.
Ракушкасы — колакларга,
Анда шавы диңгезнең.

## Керпе кабак



Чыршыдан энәләр алып
Өстенә куйгач кадап,
Нәкъ керпе булды да куйды
Бакчада үскән кабак...
Кичен әби кабакларга
Су сибәргә тотынган:
Күрә — кабак керпе булган,
Чүт язмаган һушыннан.
Тик бераздан тынычланган
Ул моның серен белеп...
Әби һаман бу турыда
Искә төшерә көлеп.

• • •

# ЯЗЫЛУЧЫЛАР САНЫ АРТТЫ

**Балтач районы хезмәт ияләре «Казан утлары» журналында басылып чыккан романнарны, повесть һәм хикәяләрне, шигырь һәм поэмаларны һәм башка жанрдагы барлык материалларны яратып укыйлар.**

**Халыкның журналга булган мәхәббәте елдан-ел үсә. Колхозчылар, укытучылар, укучылар һәм хезмәткәрләр «Казан утлары» журналына елдан-ел күбрәк язылалар. Районда, мәсәлән, 1966 елда нибары 200 гә якын кеше журнал алдыра иде. Ә 1967 елда аны 244, 1968 елда 391 кеше алды.**

**Быел исә балтачлылар «Казан утлары» журналын 851 данә алдыра башладылар. Шулай итеп, районлагы татарча укучы һәр 29 кешегә бер журнал килә.**

**Журналга язылу Балтачта зур оешканлык белән барды. «Яңа тормыш» колхозы идарәсе (председателе Тәбрис Зарипов, башлангыч партия оешмасы секретаре Рәшит Җамалыев иптәшләр) алдынгы терлекчеләрдән һәм игенчеләрдән 50 кешене «Казан утлары» журналына еллык подписка белән бүләкләде.**

**Мондый башлангычны «ВЛКСМның 50 еллыгы» (председателе Р. Зарипов, башлангыч партия оешмасы секретаре Н. Салихов иптәшләр), «Маяк», Тимирязев исемендәге, Калинин исемендәге, «Алга», «Социалистик Татарстан» газетасы исемендәге, «Якты юл» колхозлары идарәләре дә яклап чыктылар һәм үз хуҗалыкларындагы хезмәт алдынгыларыннан 20—50 кешене журналга еллык подписка белән бүләкләделәр.**

**Журнал таратуны Салавыч элемтә бүлекчәсе аеруча яхшы оештырды. Аның начальнигы Сания Нәсыйхова колхоз активларының ярдәме белән һәр өч хуҗалыкка бер данә «Казан утлары»на подписка җыйды.**

**Журналның быел 12 табакка җиткерелүе дә укучыларны шатландыра. Чөнки аның битләрендә әдәби әсәрләргә күбрәк урын бирелә башлады.**

**Балтач районында хәзер «Казан утлары» журналын системалы укучылар саны сигез мең кешедән дә артыграк.**

**Н. МАДЪЯРОВ.**

## РЕДАКЦИЯДӘН

*Иптәш Мадъяров хатына өстәп шуны әйтергә кирәк: 1969 ел өчен «Казан утлары» журналына язылу гомумән бик әйбәт булды. Югары Ослан, Лаеш һәм Биектау районнарын исәпләмәгәндә (ул районнарда журналга язылучылар саны узган елгыдан кимрәк), республикабызның барлык районнарында да безнең журналны алучылар бу ел сизелерлек артты. Әгерҗе, Азнакай, Актаныш, Әлмәт, Апас, Әлки, Баулы, Бөгелмә, Буа, Алабуга, Кукмара, Түбән Кама, Лениногорск, Мамадыш, Мөслим, Чаллы, Октябрьск, Чирмешән, Сарман һәм Чистай районнарының һәркайсында, мәсәлән, журналны алучылар саны узган елгыга карaганда 200—400 кешегә күбрәк.*

*«Казан утлары» узган ел 65 000 данә басылып килгән булса, бу ел аның тиражы 84000 данәгә җитте. Халкыбызның культура дәрәҗәсе, матур әдәбият белән кызыксынуы елдан-ел арта бара дигән сүз бу!*

*1969 ел өчен журналга язъдыруда республикабызның КПСС район Комитетлары, район газеталары редакцияләре, элемтә бүлекләре хезмәткәрләре, колхоз идарәләре, колхоз партоешмалары һәм җәмәгать эше тәртибендә матбугат таратучы иптәшләр бик зур активлык белән эшләделәр.* ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ИДАРӘСЕ, ЖУРНАЛ РЕДКОЛЛЕГИЯСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯСЕ ИСЕМЕННӘН БЕЗ УЛ ИПТӘШЛӘРНЕҢ БАРЧАСЫНА ЧЫН КҮҢЕЛДӘН РӘХМӘТ БЕЛДЕРӘБЕЗ ҺӘМ ЭШЛӘРЕНДӘ ЗУР УҢЫШЛАР ТЕЛИБЕЗ.

*«Казан утлары»на язылучылар саны бу ел Башкортстан республикасында да шактый күбәйде. Узган ел анда журналга 19 000 кеше язылган булса, бу ел 25 000 гә якын кеше язылды. Башкортстанда да җәмәгать эше тәртибендә безнең журналны таратучы иптәшләребез күп. Андый дусларыбыз Оренбург, Пермь, Куйбышев, Ульяновск, Чиләбе, Свердловск өлкәләрендә, Үзбәкстанда, Казагыстанда, Төркмәнстанда һәм башка күп кенә республикаларда һәм өлкәләрдә дә байтак.* АЛАРГА ДА БЕЗ ЧЫН КҮҢЕЛДӘН ЗУР РӘХМӘТ БЕЛДЕРӘБЕЗ ҺӘМ КИЛӘЧӘКТӘ ДӘ БУ МӨҺИМ ЭШТӘ БЕЗГӘ ЯРДӘМ ИТӘРЛӘР ДИП ЫШАНАБЫЗ.

## Хөрмәтле Габдрахман ага Әпсәләмов!

**Сезнең «Казан утлары» журналында басылып чыккан «Миңа унтугыз яшь иде» повестегызны без бик зур кызыксыну белән яратып укыдык. Бөек Ватан сугышында катнашкан яшьләребезнең батырлыгы турында күңелләрне тетрәндерерлек итеп язылган шушы әсәрегез сугышның нинди рәхимсез икәнлеген тагын бер кабат безнең күз алдына китереп бастырды һәм тыныч туган илебезгә сугыш белән кергән дошманнарга йөрәкләрдә бетмәс-төкәнмәс нәфрәтләр уятты. Шушындый гүзәл әсәр тудырганыгыз өчен сезгә мең-мең рәхмәтләр әйтеп калабыз.**

**Габдрахман ага!**

**Сезгә безнең тагын бер үтенечебез бар. Югары уку йортларын бетергәч, авылларга китеп, туган ана телебезне үстерүдә армый-талмый эшләгән яшьләребез турында да берәр китап язып чыксагыз иде.**

**Эшегездә яңадан-яңа уңышлар, үзегезгә бик нык сәламәтлек теләп, ерак Ташкент шәһәрендә яшәүче, Сезне ихтирам итүче**

**Мидхәт Якупов.**

## Көтеп алабыз

**Без «Казан утлары» журналын гаять яратып укыйбыз. Бу журналда басылган әсәрләр турында радио аша ишеткәч, аның килүен түземсезлек белән көтеп алабыз. Аннары цехларда, участокларда тәнәфес вакытларында журналны безгә кычкырып укыйлар. Безгә бигрәк тә халкыбызның тарихы һәм геройларыбыз турындагы материаллар, хәзерге матур тормышыбызны сурәтләп язылган хикәяләр, очерклар, повестьлар һәм романнар ошый. Без ул әсәрләр хакында өйгә кайткач балаларыбызга да сөйлибез. Кыскасы, «Казан утлары» журналы безгә бик якын һәм ул безнең күңелләребезне яктыртып тора. Бер тыңлаганда ул бабаларыбызның борынгы моңын көйли, икенче тыңлаганда Сәйдәш маршлары булып яңгырый... Тик, нигәдер, бу журналны тарату мәсьәләсе үз агымына гына куелган. Аны таратуда без «Союзпечать» хезмәткәрләренең һәм урыннарда җәмәгать эше тәртибендә матбугат таратучыларның, башка газета-журналларны тараткандагы кебек үк, чын күңелдән тырышып эшләүләрен телибез!**

**Гәрәева, Әхмәтҗанов, Фәйзуллина, Виноградова, Лукина, Әглиева, Кәримова, Галимуллина.**

**Алабуга шәһәре**

## Киләчәктә дә шулай булсын

Без Үзбәкстан республикасының Карши шәһәрендә яшибез. Монда татарлар бик күп. «Казан утлары» журналын алгач, анда басылып чыккан роман һәм повестьларны укыгач, туган якларыбызны искә төшереп, бер-беребез белән сөйләшәбез һәм шулай ук үзебезнең фикерләребезне дә әйтәбез. Журналда басылып чыккан барлык әсәрләр бик матур язылганнар, киләчәктә дә шулай булсын иде.

Язучы Гариф Ахуновның 1968 елгы 8—9—10 нчы саннарда басылып чыккан «Хуҗалар» романы безгә бик ошады.

Берничә ел элек журналда язучы Шәйхи Маннурның «Муса» романы басылып чыккан иде. Аңа бик зур бәя бирделәр, чөнки ул моңа лаеклы әсәр. Шуннан бирле Ш. Маннурның журналда роман яки повестьлары күренгәне юк, без аның яңа әсәрләрен көтәбез.

ИБРАҺИМОВ БУЛАТ

## Шәүкәт, балакаем!

Шәүкәт, балакаем! Мондый эндәшү гаҗәпсендермәсен, мин үземә якын булган кешеләргә шулай эндәшәм. Ә сез миңа шигырьләрегез аша шулай якын булдыгыз.

Мин гади укучы, шуңа күрә, әлбәттә, тәнкыйтьчеләр шикелле акыллы сүзләр язмыйм, бәлки үземнең хисләремне генә белдерәм. Ни өчен Сезнең шигырьләрегез миңа ошый! Аларда берниндн дә шалтыравык сүзләр әйтеп шаккатырырга тырышу юк. Шигырьләр халык җырлары шикелле җиңел, гади, җылы, йомшак кына булып җанга үтеп керәләр. Мин үзем юморны бик яратканга, сезнең шигырьләрдәге шул сыйфатлар мине сихерли. Аерым шигырьләрне күрсәтеп, әйтеп тормыйм, анысы инде тәнкыйтьчеләр, әдәбиятчылар эше. Ләкин шуны әйтәсем килә, Шәүкәт Галиев дигән исемне күрсәм, мин хәзер илтифатсыз гына үтеп китә алмыйм.

Сәламәтлек, чын бәхет, зур илһамнар теләп:

ХӘДИЧӘ АЛМАЕВА

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ФАТИХ КӘРИМНЕҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

Республикабызның партия-совет һәм культура җәмәгатьчелеге, күп санлы әдәбият сөючеләр 15 январьда күренекле шагыйрь Фатих Кәримнең туууына 60 ел тулу көнен билгеләп үттеләр. Бу уңай белән уку йортларында, китапханәләрдә шагыйрь иҗатына багышланган китап күргәзмәләре оештырылды, әдәби кичәләр үткәрелде.

Казан шәһәренең мехчылар клубында язучылар, журналистлар, укытучылар, студентлар һәм күп санлы әдәбият сөючеләр шагыйрь истәлегенә багышланган әдәби кичәгә җыелдылар. Ф. Кәримнең тормышы һәм иҗаты турындагы докладны С. Хәким ясады. Язучы Ф. Хөсни, музыка белгече З. Хәйруллина, пенсионер З. Курмашев, шагыйрьнең кызы Ләйлә Кәримова, композитор Җ. Фәйзи Фатих Кәрим турында истәлекләр сөйләделәр.

Соңыннан республикабызның сәнгать көчләре зур концерт бирде.

Түбән Кама шәһәре хезмәт ияләре дә күренекле шагыйрь Фатих Кәримнең 60 еллык юбилей бәйрәмен киң итеп билгеләп үттеләр. Шагыйрьнең якты истәлеген искә алуга багышланган тантаналы кичә шәһәрнең үзәк культура учагы «Нефтехимик» клубында булды. Юбилей кичәсенең тантаналы өлешен КПССның Түбән Кама шәһәр комитеты пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире Таһир Гыйльметдинов ачты. Кыска гына кереш сүздән соң, ул сүзне докладчыга — нефтехимкомбинатның күптиражлы газетасы редакторы Вәгыйз Зәйнетдиновка бирде.

Соңыннан «Төзүче» һәм «Нефтехимик» клубларының татар үзешчән сәнгать түгәрәкләре Фатих Кәрим иҗатына багышлап зур концерт бирделәр.

## ЖУРНАЛ ТУРЫНДА ФИКЕР АЛЫШУ


Январь уртасында Татарстан язучылары союзы идарәсенең чираттагы киңәйтелгән утырышы «Казан утлары» журналының 1968 елда чыккан 10, 11, 12 саннары буенча фикер алышуга багышланды.

Журналда чыккан проза әсәрләре турында докладны яшь язучы Р. Батуллин ясады. Докладчы Ә. Еникинең «Вөҗдан» повестен уңай яктан бәяләде. Э. Касыймовның «Бир кулыңны, дустым» повестена карата укучылардан килгән хатларга җавап төсендә язылган «Җиде сорауга бер җавап» мәкаләсенә тукталып, ул әсәрдәге кимчелекләрне, образлар эшләнешендәге, характерлар бирелешендәге бәхәсле урыннарны күрсәтте. Р. Батуллин шулай ук Г. Әпсәләмовның «Миңа унтугыз яшь иде», Л. Ихсанованың «Ана көндәлеге» повестьлары, Ф. Хөснинең «Поп кызы Әхсәнә», С. Сабировның «Гәрәйнең бер җәе» хикәяләре һәм башка әсәрләр турындагы фикерләре белән уртаклашты.

Поэзия турында сөйләү өчен сүз яшь шагыйрь Г. Рәхимгә бирелде. Ул журналда басылган шигъри әсәрләрнең авторлары күбрәк яшьләрдән булуын уңай күренеш дип бәяләде, Н. Арсланов, Р. Мингалимов, Рәшит Әхмәтҗанов, К. Мостафин, Р. Закиров, И. Рушан (Х. Туфан), Р. Гатауллин, Н. Дәүли шигырьләрендәге уңышлы һәм кимчелекле якларга тукталды. Филология фәннәре докторы, тәнкыйтьче И. Нуруллин журналның соңгы саннарында басылып чыккан тәнкыйть әсәрләре турында сөйләде. Докладчы бүгенге көн әдәбиятына багышланган мәкаләләрнең, яңа чыккан китапларга карата рецензияләрнең даими бирелеп барылмавын журналның кимчелеге итеп күрсәтте, кайбер авторларның мәкаләләрендәге фикерләр белән бәхәскә керде. Докладлар буенча фикер алышуларда Г. Кашшаф, С. Хәким, А. Шамов һ. б. лар катнаштылар.

## РУМЫНИЯДӘН КУНАК

Билгеле булганча, 1962 елда Казан шәһәре делегациясе Румыния Социалистик Республикасындагы Венгр автономияле өлкәсендә булган иде. Шул вакыттан башлап Казан һәм Венгр автономияле өлкәсе



Рәсемдә: **Фабиан Лайош.**

баш каласы Тургe-Муреж шәһәре арасында дуслык элемтәсе урнашты. Безнең республикабызда да венгр дуслар кунак булдылар. Делегация составында «Хак сүз» исемле әдәби журнал редакторы, язучы Һайду да бар иде. Татарстанда һәм Румыниядә шушы очрашуларның нәтиҗәсе буларак, «Хак сүз» журналында татар әдәбияты турында мәкалә һәм татар язучыларының әсәрләре венгр теленә тәрҗемә ителеп басылып чыкты. Ә Татарстан китап нәшрияты, венгр язучыларының әсәрләрен туплап, татар телендә «Кояшлы Карпат» дигән китап бастырып чыгарды. Бу китапка әсәрләр туплауда безнең Тургe-Муреждагы дустыбыз, лицей профессоры Фабиан Лайош иптәш зур ярдәм күрсәтте.

Күптән түгел Фабиан Лайош безнең республикабызда кунакта булды. Ул Казанда В. И. Ленин белән бәйле урыннарны карады, татар әдәбиятының яхшы үрнәкләрен венгр теленә тәрҗемә итү өчен материаллар туплады, М. Җәлил белән бәйле документларны өйрәнде һәм Мәскәүдә геройшагыйрьнең семьясы белән очрашып сөйләште.

## ПРОЗАИКЛАР СЕКЦИЯСЕНДӘ

Язучылар союзы каршындагы прозаиклар секциясенең 8 январьда үткәрелгән чираттагы утырышында Г. Ахуновның «Хуҗалар» романы тикшерелде.

«Мин «Хуҗалар» романын яратып укыдым,— диде беренче булып сүз алган М. Әмир.— Аннан бүгенге көн сулышы бөркеп тора. Уңай геройларның эшләнеше матур, алар әчке дөньялары, катлаулы кичерешләре белән күз алдына килеп баса. Ышандырмый торган, фальш образлар да юк түгел. Мәсәлән, Мөстәкыймов образы. Аның әсәрнең баш герое Арсланга каршы корган интригалары миңа примитив булып күренде».

Аннары ул аерым эпизодларны сурәтләгәндә автор уйлап җиткермәгән урыннарга, аерым геройларның үзара мөнәсәбәтләрендәге укучы күңелендә ризасызлык тудыра торган кайбер детальләргә тукталды.

Госман Бакиров та романга уңай яктан бәя бирде, вакыйгаларның киң колачлы итеп сурәтләнүен, семья мөнәсәбәтләренең, көнкүреш детальләренең матур тасвирлануын әйтте.

И. Нуруллин исә, киресенчә, күбрәк романның кимчелекле яклары турында сөйләде. «Хәзинә» романы белән чагыштырганда, «Хуҗалар» романын ул чигенеш дип бәяләде, авторны ясалмалыкта, чынбарлыктагы вакыйгаларны йөрәк аша үткәреп, хис белән сурәтли алмауда гаепләде һәм, үз фикерләрен дәлилләү өчен, аерым эпизодларның язылышын, кайбер образларның бирелешен анализлады.

Яшь тәнкыйтьче Ф. Миннуллин, И. Нуруллин фикерләренә өстәп: «Романда әсәрне бер бөтен итеп күз алдына бастырырдай үзәк юк, укучы алдына зур проблемалар куелмый»,— диде. «Хуҗалар» романын таркау әсәр, дип тәнкыйтьләде, моның сәбәбен әсәрнең төп герое — Арслан образының оешып җитмәвендә күрде.

Аннары чыгып сөйләгән Г. Иделле һәм А. Гыйләҗев тәнкыйтьчеләрнең фикерләре белән дә, үзара да бәхәскә керделәр. «Әсәрдә проблема бар,— диде Г. Иделле,— ләкин уңай образга күтәрә алмаслык йөк тапшырылган: Арсланның бер үзе генә завод кадәр завод салу мәсьәләсен хәл итәргә дә, артыннан йөрергә дә сәләтле булуы мөмкин түгел».

«Безнең геройлар,— диде аңа каршы А. Гыйләҗев,— бер завод артыннан гына түгел, ун завод салдыру артыннан йөрергә һәм моңа ирешергә сәләтле булырга тиеш. Әсәрдә образлар хәтердә кала, аларның иҗтимагый йөзе дә, үзенчәлекләре дә бар. Кайбер иптәшләр «Хәзинә» белән «Хуҗалар» романнарын аерып карыйлар. Бу дөрес түгел, алар — берсе икенчесенең дәвамы, икесе бер бөтен әсәр».

Х. Сарьян да И. Нуруллин белән Ф. Миннуллин фикерләре белән килешмәде. «Әсәрдә проблема бар,— диде ул, Г. Иделле сүзләрен куәтләп,— әсәр тормышчан икән, анда тормыш, кешеләр язмышы сурәтләнгән икән, проблеманың булмавы мөмкин түгел. А. Гыйләҗев дөрес әйтә: «Хәзинә» белән «Хуҗалар»ны бер-берсеннән аерып карарга ярамый. Алар — бер әсәр».

Ф. Хөсни дә романга уңай бәя бирүчеләрнең кайберләре белән бәхәскә керде, әсәрдә мәхәббәт бәйләнешенең калку бирелмәвен, сюжеты таркау булуын, төп геройның тормыш каршылыкларын «шома» җиңеп чыгуын тәнкыйтьләде.

## ТӘНКЫЙТЬЧЕЛӘР СЕКЦИЯСЕНДӘ

Тәнкыйтьчеләр секциясенең 17 январьда үткәрелгән чираттагы утырышында әдәбият белгече З. Максудова белән филология фәннәре кандидаты, СССР Фәннәр Академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге Казан тел, әдәбият һәм тарих институтының гыйльми хезмәткәре Ш. Абилов XII йөз Болгар шагыйре Дауыт Саксини-Суари иҗаты турында белдерү ясадылар.

Дауыт Саксини-Суари Болгар һәм Суар шәһәрләрендә яшәгән, 1120—30 елларда белем алган, XII гасырның урталарында иҗат иткән. Аның «Дастани могҗиза» дигән әсәре үзенең сәнгатьчә эшләнеше, образлы теле, матур шигъри төзелеше белән игътибарга лаек.

Д. Саксини-Суари иҗаты борынгы болгар-татар әдәбияты тарихында әһәмиятле урын алып тора.

## ФӘННИ-ТЕОРЕТИК КОНФЕРЕНЦИЯ

СССР Фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтында «Татарстанда иҗтимагый-политик фикер һәм культура тарихы проблемалары» дигән темага фәнни-теоретик конференция булып үтте.

20—24 январьда булган бу конференциядә КПССның Татарстан өлкә комитетының фән һәм уку йортлары бүлеге мөдире, филология фәннәре кандидаты М. Хәсәнов «Татар халкының иҗтимагый-политик фикерләү һәм ТАССРда культура революциясе тарихын өйрәнүнең кайбер актуаль

мәсьәләләре», тарих фәннәре докторы А. Халиков «Бөек Болгар һәм Казан ханлыгы культуралары», филология фәннәре докторы Х. Госман «Борынгы төрек һәм татар культурасы, Идел буе әдәбияты тарихының кайбер проблемалары», тарих фәннәре кандидаты С. Алишев «XVIII йөзнең икенче яртысында татарларда алдынгы иҗтимагый фикерләү», философия фәннәре кандидаты К. Фасиев «Татар иҗтимагый фикер һәм культурасы тарихының кайбер чишелмәгән мәсьәләләре», тарих фәннәре докторы Р. Нафигов «Татар иҗтимагый фикер үсеше тарихын өйрәнүнең кайбер мәсьәләләре (XIX йөз һәм XX йөз башы)», философия фәннәре кандидаты Я. Абдуллин «Татар мәгърифәтчелегенең үзенчәлекләренә карата (XIX йөзнең икенче яртысы)», экономика фәннәре кандидаты Ф. Газизуллин «Г. Фәезхановның «Муллыкка ирешү һәм тормыш итү ысуллары турында әңгәмәләр китабы»нда авторның социаль-экономик карашларының чагылышы», филология фәннәре кандидаты А. Кәримуллин «XIX йөздә халыкның рухи тормышында татар телендәге китапларның әһәмияте», филология фәннәре кандидаты М. Мәһдиев «Татарларда дөньяви белем алу өчен көрәш тарихыннан», Казан дәүләт университетының тарих кафедрасы ассистенты А. Мәхмүтова «Татарларда хатын-кызларга дөньяви белем бирү өчен көрәш тарихыннан (XIX йөзнең ахыры XX йөзнең башы)», филология фәннәре кандидаты Б. Гыйззәт «Татар милли театрын тудыру һәм үстерү өчен көрәш тарихыннан (1905—1917 еллар)», сәнгать фәннәре кандидаты Х. Гобәйдуллин «Абдулла Кариев һәм татар театры», филология фәннәре кандидаты И. Надиров «Революциягә кадәрге татар халык лирикасында социаль мотивлар», аспирант З. Сәйдәшева «XIX йөз ахырында, XX йөз башында татарларда шәһәр музыкаль фольклоры», Казан дәүләт университетының фәнни китапханәсе хезмәткәре А. Фәтхиев «XIX гасырның икенче яртысында, XX йөз башында татар язучылары һәм галимнәренең кульязмалары һәм аларны фәнни-библиографик тасвирлауның кайбер мәсьәләләре», тарих фәннәре докторы М. Мөхәррәмов «Татарстанда культура революциясе тарихын өйрәнүнең торышы һәм аның кайбер мәсьәләләре», тарих фәннәре кандидаты Т. Насыйров «Октябрь һәм татар партия-совет матбугатының барлыкка килүе», философия фәннәре кандидаты К. Гыйззәтов «Сәнгатьнең милли формасы һәм социалистик эчтәлек проблемасына карата», тарих фәннәре кандидаты Ж. Гыйльманов «Бөек Ватан сугышы елларында фән һәм югары мәктәпләр», Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының кече фәнни хезмәткәре Т. Фәләхов «Сугышка кадәрге бишьеллыклар чорында Татарстанда эшчеләр сыйныфының культура-техник дәрәҗәсен күтәрүдә Советларның роле», тарих фәннәре кандидаты Е. Г. Матвеева «Совет крестьяннарының культура-техник дәрәҗәсен күтәрү юлында», тарих фәннәре кандидаты М. Софронов «Коммунизм төзү шартларында Татарстанда хезмәт ияләренең культурасын күтәрүдә төп юнәлешләр», тарих фәннәре кандидаты Р. Волков «Татарстанда социалистик төзелешне тәмамлау чорында производство-техник интеллигенция составының сан ягыннан һәм сыйфат ягыннан үзгәреше», Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының кече фәнни хезмәткәрләре Н. Георгиевская «Сугыштан соңгы бишьеллыклар чорында Татарстан профсоюзларының культура-агарту эше», В. Воздвиженский «Татар әдәбиятында романтизм (1905—1945 еллар)», КПССның Татарстан өлкә комитетының партия архивы мөдире М. Кочурова «Партия архивында культура революциясе буенча материаллар», ТАССРның Үзәк дәүләт архивы өлкән фәнни хезмәткәре Р. Хәкимова «Республиканың Үзәк дәүләт архивында культура төзелеше тарихы буенча документаль материаллар» дигән темаларга докладлар укыдылар.

Соңыннан докладлар буенча фикер алышулар булды.

## «ҮЛЕМСЕЗ ҖЫР» НОВГОРОД СӘХНӘСЕНДӘ

Январь аенда, Новгород шәһәренең фашист илбасарларыннан азат ителүенә чирек гасыр тулуга багышлап, өлкә драма театры татар язучысы Риза Ишморатның «Үлемсез җыр» драмасын сәхнәгә куйды.

Премьерага әсәрнең авторы үзе дә катнашты. Тамашачылар һәм спектакльгә катнашучылар татар халкының батыр улы, герой-шагыйрь Муса Җәлил образын тудырудагы хезмәте өчен Риза Ишморатка рәхмәтләрен әйттеләр, аңа чәчәк бәйләмнәре бүләк иттеләр.


«Үлемсез җыр» спектаклен сәхнәгә режиссер Н. Витарский куйды. М. Җәлил ролен артист Җамал Вадкария башкарды.

Р. Ишморат, Новгород шәһәрендәге заводларда, фабрикаларда, культура сарайларында, китапханәләрендә хезмәт ияләре белән очрашып, татар әдәбияты, татар язучылары һәм үзенең «Үлемсез җыр» әсәрен ничек эшләвен сөйләде.

## ЯҢА СПЕКТАКЛЬ

Г. Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театры күптән түгел драматург Ю. Әминовның «Гөлҗәннәтнең җәннәте» исемле пьесасын сәхнәгә куйды. Баш рольләрдә ТАССРның халык артистлары: Галимә Ибраһимова, Асия Харисова, Ибраһим Гафуров, Шәүкәт Биктимиров, ТАССРның атказанган артистлары: Асия Галиева, Рауза Хәйретдинова, Дэллюс Ильясов, Ринат Тажетдинов, артистлар: Флера Хәмитова, Фирдәвес Әхтәмова, Ирек Баһманов һ. б. лар уйный. Премьераны тамашачылар яратып карадылар.

Быелгы сезонда тамашачылар тагын М. Гали белән Х. Уразиковның «Каюм Насыйри», Ж. Жаббарлының «Айдын», Н. Әсәнбаевның Муса Җәлилнең үсмер елларын сурәтләгән «Мостафа егете» һ. б. әсәрләрне караячаклар.




# ТУГАЙЛАРЫҢ

САРА САДЫЙКОВА музыкасы
ИЛСӨЯР ГАНИЕВА сүзләре

Тугайларың, ахры, мине гашыйк
итте,
Күнелем калды шунда бәйләнеп.
Агыйделкәй,
кайтырмын ла сиңа
Киек-казлар кебек әйләнеп.

Кушымта:

Юксынма!
Ярларыннан инде китәмен,
Җырларыма салып синең
гүзәллегең
Якын дусларыма илтәмен.

Нигә сине шулай өзелеп яратуның
Үзем генә беләм серләрен.
Йөрәгемә сүнмәс хисләр салган
Иң кадерле туган җирләрем.

Кушымта:

Юксынма!
Ярларыннан инде китәмен,
Җырларыма салып синең
гүзәллегең
Якын дусларыма илтәмен.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210